# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**12**
ДЕКАБРЬ
1969

## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

**Х. САРЬЯН.** Уфа кунагы . . . . . . . . . . . 3
Ленин чишмәсе. Әкият . . . . . . . . . . . . 15
Халыклар җырлый. Шигырьләр . . . . . . . . 18

РОМАН, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

**А. ГЫЙЛӘҖЕВ.** Урманнар артында яшел болын. Роман . . . . . . . . . . . . . . . . 24
**Ш. ГАЛИЕВ.** Сигезюллыклар . . . . . . . . . 84
**Ә. ЕНИКИ.** Җиз кыңгырау. Хикәя-истәлек . . . 87
**М. ӘГЪЛӘМОВ.** Балам, бәгырем, диеп. Уфа юлы. Каз канаты ак була. Ленин рәсеме. Юлдашым. Кыңгыраулар эзлим. Шигырьләр . . . . . . 113

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 70 ЯШЬ

**С. ХӘКИМ.** Исәнбәт — шагыйрь . . . . . . . . 117
**Г. ШАМУКОВ.** Исәнбәт драматургиясе . . . . 118
**Ф. ГАНИЕВ.** Исәнбәт — тел галиме . . . . . . 122
**Ф. УРМАНЧЕЕВ.** Энҗеләр бөртекләп җыела . . . 126
**Б. УРМАНЧЕ.** Исәнбәтнең урыны . . . . . . . 130
**Г. ИСӘНБӘТ.** Күп кырлы, киң колачлы әдип . . 134

СӘЙФИ КУДАШКА 75 ЯШЬ

**Х. ТУФАН.** Гомер эзләрең буйлап . . . . . . 137
**С. КУДАШ.** Көнләшәм. Бөркет килсә. Эчтә ялкын. Исемем хакында. Әгәр дә... Ни кылырсың. Тиз ятмастыр... Тик шулай да... Гөлләрнең дә телләре бар икән. Изге илһам кебек. Каләм югалгач. Урман юлыннан. Шигырьләр . . . . . . 139

ХАРИС ЯКУПОВКА 50 ЯШЬ

**А. ФАЙНБЕРГ.** Җитлеккән художник . . . . . . 143

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Я. ЧАНЫШЕВ. Татар егетләре гражданнар сугышында . . . . . . . . . . . . . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. АХУНҖАНОВ. Тәрҗемә практикасында үзенчәлекле бер уңыш . . . . . . . . . . . . . 161
Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . . 164

ТӨРЛЕСЕННӘН

М. МӘҺДИЕВ. Буби мәдрәсәсе . . . . . . . . 167

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Р. ГАТАУЛЛИН. Шигырьләр . . . . . . . . . . 180
М. РӘФИКОВ. Былбыл Хәбир . . . . . . . . 181

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 182

1969 елда «Казан утлары» журналы битләрендә басылган әсәрләр исемлеге . . . . . . . . 184

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 8/X-1969 ел. Басарга кул куелды 24/XI-1969 ел. ПФ 09050.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 36.406 экз.
Заказ В-513. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.




## *ЛЕНИН— БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

*Казаннан киткәч*

**Хәсән Сарьян**

# УФА КУНАГЫ

Тын. Ульянов бала йөзенә карый
Ата хисе — җылы хис белән.
Ул бит шулай рус халкы нелә
Туар Башкортстан өстенә.

РӘШИТ НИГЪМӘТИ.

## I

Карталарда аның сурәте сәламәт кеше йөрәгенә охшап тора. Ул үзе дә минем күңелемә йөрәктәй якын. Ул — Башкортстан. Йөрәктәге саф кан юллары шикелле, Башкортстан туфрагын да бик күп елгалар сугарып үтә. Шуларның икесе — Базы белән Сөн. Алар, бер-берсен күздән югалтмыйча гына, икесе дә бер якка агып, башкорт иленең иң өлкән, иң гүзәл елгасы Агыйделгә килеп коялар. Шул ике елга арасына сыенып яткан бер район бар. Ул — безнең район, Башкортстандагына түгел, Россиянең үзендә дан тоткан Илеш районы. Мин елына бер шунда кайтып килмәсәм, зыңлап торган саф һавасын иснәмәсәм, таң-сәхәрләр Агыйдел буен күз иркәләп әйләнмәсәм, туган җир җылысын ялан аягым аша йөрәгемә алмасам — мин үземне башка җирдә, хәтта бабалар иле Казанымда да ике аягым белән нык басып йөри алмас кебек тоям. Шуңа мин ел саен Илешемә кайтам. Кайткан саен яңа төс, кайткан саен яңа ямь. Ә быел кайтуымда мин күңелләрне тагын да дулкынландырып җибәргән бер тантанага тап булдым.

Ул турыда башта өлкә газетасына яздылар. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көнен каршылау уңае белән Уфадан Мәскәүгә рейс-эстафета чыккан. Уфа җәмәгатьчелеге аны хәерле юл теләп озатып калган. Илеш җиренә килеп җиткәнче ул Кушнаренко, Бөре, Дүртөйлегә туктый. Туктаган бер җирдә эстафета коллективы колхозчылар, эшчеләр белән очраша, халыкны Владимир Ильичның биографиясе, революцион эшчәнлеге белән таныштыра, коммунизм төзү чорында Ленин мирасының тиң-



*Кунакларны Груздевка пристанендa каршы алу.*

дәшсез әһәмияте хакында сөйли, концерт куялар, теплоход салонында кино күрсәтәләр. Эстафетаны һәр җирдә ачык чырай, якты йөз белән каршы алып, озатып куялар.

Ниһаять, 28 июльдә «Агитатор» белән «ВТ-65» теплоходлары безнең Илеш җиренә — Груздевка пристанена килеп туктады. Быелгы яңгырлы җәйдә бик сирәк кенә ялтырап китә торган аяз көннәрнең берсе иде. Кичке сәгать биш. Груздевка ашлык хәзерләү пункты эшчеләре, авыл халкы Агыйдел буена җыелган. Утыз өч километрдагы район үзәгеннән музыка мәктәбенең тынлы оркестры килгән. Партия райкомы секретаре Фәтхиев иптәш килгән. Менә оркестр Яруллин, Сәйдәшев музыкаларын уйный. Ярга эстафета башлыгы Григорий Васильевич Чернов җитәкчелегендә агитколлектив кешеләре чыга. Алар арасында Ленин белән өч тапкыр очрашкан, гражданнар сугышы һәм социалистик хезмәт ветераны Россомахин Василий Федорович та, журналист, кинооператор, лектор, художниклар да, үзешчән сәнгать осталары да бар. Кадерле кунакларны бик олылап, митинг ясап каршы алганнан соң, алар Груздевка ашлык хәзерләү пункты биләмәсенә юнәләләр, пункт директоры Каюмов иптәш аларны үзләренең эше белән таныштыра.

Ә кич сәгать сигездә Агыйдел буендагы «Агыйдел» колхозында зур кичә булды. Клубта халык тулы иде. Башта кунакларны пионерлар тәбрик итте. Алардан соң райком секретаре Фәтхиев белән колхоз председателе Рафаил Әхметов котлау сүзе әйттеләр, районның, колхозның эшләрен сөйләделәр. Әхметов иптәш эстафета башлыгы Черновка, татарча чигелгән борынгы сөлге өстенә салып, кабарып пешкән Илеш икмәге тапшырды.

Илеш икмәге... Мин ул икмәкнең ничек үстерелгәнен, шуңа күрә кадерен дә бик нык беләм. Трибунадан Фәтхиев сөйләгәндә дә, яңа председатель, минем яшьтәшем Рафаил Әхметов сөйләгәндә дә мин шул турыда уйлап утырдым. Илеш икмәге... Ул икмәкне узган ел минем райондашлар һәр гектардан 28,4 центнер алганнар! Ә бит моннан ни бары ун ел элек кенә район буенча барлык уңыш гектарына җиде центнер да юк иде. Мин моны бик яхшы беләм. Ә хәзер Илеш районы — Башкортстанның маягы. Ул дәүләт амбарларына 2 миллион 286 мең центнер ашлык салып, биш еллык планны өч елда төгәлләп куйды. Менә шул ул Илеш икмәге!

Быел инде, юлбашчыбыз Ленинның тууына йөзенче ел киткән язны, минем райондашлар аеруча фидакарьлек белән эшләгәннәр. Һәр елдагы кебек үк, бу кайтуым-

да да мин район буйлап иген басуларын карап йөрдем. Ярсыз-кырыйсыз су өстендәгедәй, киң, озын дулкыннар ишелеп үткән, чайкалган бодай, арыш басулары минем күңелемә дә чиксез дулкынлану хисе алып килде. КПСС райкомының беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое, бик тә мөлаем йөзле кеше — Тәлгат Рахманов белән сөйләшеп утырганда да мине тоташтан райондашларым өчен горурлык хисе биләп алган иде.


Әле исә, клубта, эстафета белән килгән кунаклар сөйләгәнне, аеруча Ленин белән өч кабат очрашу бәхетен татыган В. Ф. Россомахин иптәшнең истәлекләрен тыңлаганда, мин президиумнан клуб тулы авылдашларым йөзенә карап утырдым. Монда минем зурлар да, минем белән бергә уйнап үскән урта буын яшьтәшләр дә, бездән соңгы яшь буын да бар. Миңа таныш йөзләр, карашлар. Хәтта мин танымаган яшьләре дә миңа таныш. Һәр кайсы — олысыннан алып кечесенә кадәр — Ленин бабай турындагы һәрбер сүзне йотлыгып тыңлый. Мин күреп торам: Ленинга булган мәхәббәт, нур булып, аларның йөзенә чыккан. Бу нур аларның ялкын күңелләреннән килә бит! Бу — Ленин эшенә, Ленин төзегән Коммунистлар партиясе эшенә ышаныч нуры, искечә әйтсәк: иман нуры. Авылдашларым күңелендә шундый нур чәчрәдәй ялкын яна икән, алар хезмәттә дә ут уйнатачаклар.

Юлбашчыбызның 100 еллыгына багышланган рейс-эстафетаны үз районым туфрагында каршылау тантанасында мин шуларны уйладым.

Иртәгесен без кадерле кунакларны озатып куйдык. Ул көнне дә, кичәге сыман, көн аяз, ә Агыйдел өсте көнбатыш җиленнән аз гына шадраланып тора иде. Без теплоходлар Кәсәләү (Сөннең бер тармагы) тамагын үтеп Акман борылмасына кереп югалганчы, яр буенда басып тордык. Эстафета Татарстанның Әҗәкүл пристанена китте. Ул анда да бер көн булачак. Аннары — Агыйдел тамагы Дербешка. Анда инде эстафетаны Кама елгачылары кабул итәчәк. Аннары — Идел. Шулай итеп Уфадан башланган эстафета Мәскәүгә җитеп, В. И. Ленинның Үзәк Музеена тапшырылачак.

Мин яр буенда басып торам. Ә эстафета кайчандыр Ленин узган Агыйдел буйлап Мәскәүгә китте. Уйларымны да бик еракларга алып китте ул.

Ленин үткән юллар, Ленин булган җирләр... Шулай. Моннан нәкъ алтмыш тугыз ел элек, ягъни 1900 елның ямьле җәендә, Ленин менә шушы Агыйдел буйлап Уфага барган. Миңеште тамаклары, Тоба борылмалары шаһит: ул менә шушы төштән дә узып киткән. Алай гына түгел — туктаган да. Бәлки әле ул менә шушы, без басып торган җиргә дә төшеп урагандыр...



*«Агитатор» һәм «ВТ-65» теплоходлары эстафетаны дәвам итәләр.*

Мин — үзем күрмәгән, ләкин укып, бабайлардан сорап белгән чорны — мең тугыз йөзенче елларны күз алдына китерәм. Ул чакны менә бу, елына 84 мең тонна ашлык кабул итеп, үткәреп җибәрерлек пункт та юк (ул кадәр ашлык ялгыз крестьянның төшенә дә кермәгән), һәр кайсы 15 әр тонна күтәрә ала торган автомобиль бушаткычлар да юк, куәтле киптерү-тазарту башнялары да юк,— ул чакны фәкать купец Груздевның агач амбарлары бар да, шул амбарларга эчәктәй сузылып килгән пычрак арба юлы бар. Ә төяү-бушатулар... Анысы өчен ходай биргән җилкә бар. Әле быел, мин кайткач кына, сиксән ике яшенә җитеп Кыргыз авылының Исрафил бабай үлде. Ул үз гомерендә Груздев икмәген күп төягән, хәтта арка тирелəре аяк табаныдай сөялләнеп каткан. Бер вакыт шулай (земский больница ачылгач, күрәсең) чирләп китеп, арка итенә укол кадау кирәк булган, ләкин кадый алмаганнар — тояктай каткан тирегә энә кермәгән!

Моннан бер җиде-сигез ел элек район газетасында бер кечкенә мәкалә басылган иде. Анда Ленинның, Уфага барышлый безнең пристаньга туктап, Груздевларда чәй эчеп чыгуы турында язылды. Бу эпизодның, әлбәттә, булуы да, булмавы да мөмкин,— минем өчен анысы мәһим түгел, минем өчен башка нәрсә мәһим, башка нәрсә хак: яшь Ульянов чынлап та безнең пристаньга туктап үткән, алай гына да түгел, ул безнең якын-тирә Яңа-Аю, Кыргыз, Андреевка авылларыннан килгән җирсез-сусыз крестьяннарның Груздевларга бил бөгеп капчык ташуларын, шунда ук ул вакытта уникеунөч яшьтә генә булган Исрафил бабайларның да көч җитмәстәй эш эшләп йөрүләрен, кыскасы — кояшлы көн, якты Агыйдел, хуш исле табигать кочагында көчкә тереклек итүче халкымның кояшсыз-айсыз тормышын күргән. Ул моны бер безнең пристаньда гына түгел, Дүртөйлесе, Бәресендә — бөтен Агыйдел буенда күргән. Ул моны шул ук елның кышында да күргән. Ул чакны ул, Уфада туктап, губернаның көнчыгышыннан көнбатышына үтеп киткән. Аңа кадәр дә Ленин башкортлар тормышын белгән булган. Ул аны әнисе ягыннан икенче буын туганнары — бигрәк тә Уфа губернасының Иске Бүздәк дигән татар авылында земский больницада ике ел врач булып эшләгән, татар телен яхшы ук өйрәнгән апасы Анна Ивановна Веретенникова сөйләве аша, китаплар аша белгән. (Сүз уңаенда шуны әйтәсе килә: 1957 нче елны без, Уфа шагыйре Гайнан Әмири белән икәү, А. И. Веретенникова эшләгән урыннардан йөреп кайткан идек. Дөрес, ул вакытта ук инде без бу шәфкатьле докторны күреп белгән кешеләрне таба алмадык, ләкин халык күңелендә аның исеме һаман да яши иде.)

Димәк, Ульянов Башкортстандагы төп халыкның ачы язмышын үзе Уфага килгәнче үк белгән. Белмәсә, «Россиядә капитализмның үсеше» (1899) дигән китабында Башкортстан турында: «Бу — колониаль сәясәтнең шундый бер кисәге ки, аны немецларның, әйтик, Африкадагы теләсә нинди батырлыклары белән генә чагыштырырга мөмкин», дип язмас иде. Инде Уфага үзе килгәч, ул чыннан да колонизаторларның башкорт җирләрен, урманнарын талавын, «кыргый» башкортлардан арчылган җирләрне бодай басуларына әйләндерүләрен үз күзләре белән күреп ышанган.

Әйе, 1900 нче елны Ленин ике тапкыр Уфада булып, ике тапкыр Башкортстанны иңләп үтә. Беренче тапкырында сөргеннән кайтышлый керә...

## 2

Охранкада аның фамилиясе
Ульянов дип язып куелган.
Ленин сүзе тик ел ярым үткәч
Исем булып телгә алыныр —
«Таң»да[1] калыккан якты йолдыз сыман
Мәңге сүнмәс өчен кабынып.

**Рәшит Нигъмәти.**

Сөргеннең соңгы елында Владимир Ильич легаль булмаган политик газета чыгару уе белән янып яши башлый. Чөнки фәкать шундый газета ярдәмендә генә халык

---

[1] «Таң» («Заря») — марксистик гыйльми-политик журнал. Шул журналда 1901 нче елны бер мәкаләгә беренче тапкыр Ленин дигән имза куела.

массаларын самодержавие һәм капитализмга каршы революцион көрәшкә әйдәрлек куәтле партия төзү мөмкин булачак. Владимир Ильич, сөргеннән кайту көне якынлашкан саен, төннәр буе йокламыйча, үз планының барлык детальләрен кат-кат уйлап чыга; үзе янындагы Надежда Константиновна белән дә, Шушенскоедан кырык чакрымдагы Минусинскида сөргендә яткан Глеб Максимилианович Кржижановский белән дә кат-кат киңәшә; шулай ук сөргендәге Юлий Цедербаум, Потресовлар белән хат язышa, газета чыгару өчен чит илгә китү турында алар белән сүз куеша.

Ул сөрген срогы бетү көнен ашкынып, түземсезләнеп, шул ук вакытта бик борчылып көтә. Чөнки күп вакытта патша властьлары, юк кына сәбәп табып, сөрген срогын озайта торган булганнар. Бәхетенә, Владимир Ильичның борчылулары тиккә булып чыга — сөрген срогы озайтылмый.

Ниһаять, зарыгып көткән көн килеп җитә. 1900 елның гыйнваре башында Себергә ике башлы сәмруг кош сурәте сугылган кәгазь килеп төшә. Шул Владимир Ильич Ульяновның сөрген срогы бетүен хәбәр итә. Бер үк вакытта полиция департаменты: «Исемнәре күрсәтелгән кешеләрнең сөрген срогы 1900 елның 29 гыйнварында тулганлыктан, аларга 3 ел дәвамында башкала шәһәрләрендә һәм С.-Петербург губернасында, шулай ук фабрикалы районнарда, университетлы шәһәрләрдә (бу урында бик күп шәһәр исеме санала) яшәүне тыярга кирәк дип саный».

Ничек кенә булмасын, сөргеннән котылу бу. Тик шулай да шатлык бөтен түгел: Надежда Константиновнаның тагын бер елы бар. Аңа исә Уфадан ары китәргә рөхсәт бирмиләр, ул сөргеннең калган бер елын Уфада үткәрергә тиеш. Ә Владимир Ильичка Псковта яшәргә рөхсәт итәләр. Псковны ул, анда бер кеме булмаса да, үзе сайлап ала, чөнки бу аулак шәһәр Петербург белән элемтә тоту өчен иң якыны, иң уңайлысы була.

29 гыйнварның салкын иртәсендә, көнгә көн туры китереп, Владимир Ильич, Надежда Константиновна, Елизавета Васильевна Крупскаялар белән өчәүләп, Шушенское авылыннан китә. Шул ук көнне кич белән Минусинскига барып җитәләр, анда бер кич куныл яңадан юлга чыгалар. Яңа гына салынып беткән тимер юл станциясенә почта тракты белән өч йөз чакрым җир барырга кирәк. Чатлама суык, битләрне кисепискән ачы җил. Ап-ак кар астында тынсыз яткан күңелсез, җансыз тайганың очы да, кырые да юк кебек. Тирә-якта үле тынлык. Тик ат дугаларындагы кыңгырау чыңы гына шушындый бушлыкта иң бөек кеше барлыгына аваз биреп, аның ашкынган күңелен тагын да алга әйдәгәндер. Шулай, каты суыкка карамастан, көнен дә, төнен дә юлда булалар, ниһаять, ике тәүлек дигәндә Ачинск станциясенә барып җитәләр. Владимир Ильич китапларын багаж итеп сала — алары исә 15 пот тарта! Аннары алар поездга утыралар. Ул чактагы поездлар белән сөйрәлеп кенә диярлек Россиягә кайтканда, алардан алда икенче бер кәгазь юлга чыга:

«Хәбәрдар булып тору өчен шуны белдерәм: Минусинск өязендә полициянең ачык күзәтүе астында яшәгән Н. К. Ульянова (кыз фамилиясе Крупская), полиция департаменты рөхсәте нигезендә шушы елның 30 гыйнварында тору өчен Уфа губернасына китте; Ульянованы әле генә телгә алынган полиция күзәтүенә буйсындыру хакында боерык бирү өчен, мин бу турыда Уфага губернатор әфәндегә хәбәр иттем. Тагы шуны да өстәп әйтәм: Ульянованың ире В. Ульянов, шушы елның 29 гыйнварында ачык полиция күзәтүе астында яшәү срогы беткәннән соң, тору өчен Псков шәһәренә китте...»

Уфа губернасы. Сүнеп баручы башкорт иле! Владимир Ильичларны алып кайтучы поезд синең тәнеңә сузылып яткан салкын рельслар буйлап үзәгеңә килеп кергәндә, син калын кар ябынып, бөгәрләнеп яткан булгансың. Синең ул вакыттагы чын хәлең дә мәңге кар астында калган, изеп тапталган ил-юл хөкемендә булган бит. Салам түбәле, карындык тәрәзәле, йорт-курасыз өйләрең ач үлемнең куркусыннан катып-бөршәеп, салкын җилләргә, акман-тукманга[1] түзә алмыйча дереләдәп утырган. Авылга бер я ике мәчет манараларың гына, үз генә булса да күккә, ходай тәгаләгә якынаер өчен, кар эченнән тәртеп чыккан курай кебек, шул фәкыйрь, кыйшык дөньядан кутә-

[1] Кышның соңгы бураннары.

релеп торган. Башкортларның кот очкыч авырлыкта яшәвен күргән рус язучысы Глеб Успенский йөрәкләрне телгәләрлек сүзләр язып калдырган: «Бетә бит башкорт, бетә!» — дигән ул. Владимир Ильич моны белгәнме? Белгән. Үз күзләре белән күргән. Шул ук вакытта ул язучы күрмәгәнне дә күргән: башкортны бетәргә дучар иткән яман шешнең — самодержавиенең үзен бетерү юллары да бар бит! Ләкин бу — Себердән алып кайтучы юл түгел. Бу — бөтенләй башка, моңа тикле кеше аягы басмаган юл. Бу — самодержавие белән капитализмга каршы көрәш юлы. Көрәш, көрәш, көрәш! Владимир Ильич Ульяновның яшәү максаты фәкать шул булган. Шул максатка ул, энә белән кое казыгандай, һәр кайда, һәр көн, һәр сәгать ирешә барган,— ике-өч көнә көнгә Уфага туктап китүен дә шул максат өчен файдаланган.

Туктау сәбәпләренең берсе, әлбәттә, хатыны Надежда Константиновна белән әбисе Елизавета Васильевнаны яңа җиргә урнаштырып китү була. Әмма Владимир Ильич революцион эшне бер генә минутка да күз уңыннан җибәрми. Уфада аның Казан чорыннан ук белгән танышы — китап кибете тотучы народоволка Четвергова яши икән. Владимр Ильич, отельгә төшеп номерга урнашу белән, шул Четвергованы эзләп китә. Аның белән сөйләшкәндә, дип яза соңыннан Надежда Константиновна, Владимир Ильичның тавышы ук ягымлыланып, йөзләре мөлаемләнеп китте. Шул ук көнне алар туктаган номерга сөргендәге социал-демократлар — А. Д. Цюрупа, А. И. Свидерский, В. М. Крохмальләр килеп керә. Алар Владимир Ильичның кайда туктаганлыгын Четвергова аркылы белгәннәр, чөнки аның китап кибете конспиратив очрашу урыны булып хезмәт итә икән.

Уфа — әчпошыргыч тын кала, агач кала. Иртәләрен дисләгән чиркәү чаң какмаса, дисләгән мәчет манарасыннан иртәнге азан әйтмәсәләр, Уфа обывателе уянмас та кебек. Уянгач та әле тормас кебек. Шәһәр тын. Урамындагы кучер тавышлары белән манараларга, шәрә агач башларына ияләшкән чәүкә тавышыннан башка тавыш юк кебек. Ләкин бу тыштан гына шулай. Эчтән — Уфа хәрәкәттә. Охранкалары, шымчылары белән кара груһ хөкем сөрә. Шуңа каршы яшерен революцион көч туплана.

Икенче көнне Владимир Ильич шул көчне тәшкил иткән кешеләр белән киңәшмә үткәрә. Сөргендәгеләр монда да икегә бүленгән: народниклар һәм социал-демократлар бар. Народниклар һаман булса Россияне крестьян общинасы аша гына социализмга бара ала дип уйлыйлар. Ләкин алар күпчелек түгел. Күпчелек — социал-демократлар. Владимир Ильич аларга партия органы булачак газета чыгаруның максатын ачып бирә, җентекле планы белән таныштыра. Аның бу планын Уфа социал-демократлары хуплап каршы алалар. Владимир Ильич күрә: марксизм эшенә чын күңелдән бирелгән кешеләр Уфада да бар. Шундыйларның иң беренчесе — Александр Дмитриевич Цюрупа. Ул күкрәк сугып шапрынмый — нәкъ Владимир Ильич ярата торган гади, эчкерсез кеше. Андыйларга һичшиксез һәр эштә исәп тотарга мөмкин.

Ләкин Уфада озак торырга ярамый — алда эш көтә, эш. Әлбәттә, Уфадан китмичә Надежда Константиновна янында гына да калырга мөмкин булыр иде. Ул чакта, ихтимал, әбисе Елизавета Васильевна да кызының чит-ят шәһәрдә ялгызы яшәвенә кайгырмас иде. Ләкин революцион эш китәргә куша. Надежда Константиновна соңыннан бу турыда болай дип яза: «Чын» эш әле башланып кына килгән бер вакытта аерылышу бик кызганыч иде, ләкин Питерга якынрак күчәргә җай барында, Владимир Ильичка Уфада калырга мөмкин дигән уй хәтта башка да кереп чыкмады», ди. Чөнки, һәр вакыттагыча, беренче планда шәхси тормыш, уңайлыклар түгел, ә бәлки һәр икесе дә бөтен гомерләрен багышлаган революцион эш тора.

Уфа вокзалында Владимир Ильичны иң якын кешесе — Надюшасы озатып кала. Яна тагын — әле калын боз астында беленер-беленмәс кенә тын алып яткан Агыйдел белән тиздән гөрләвекләр агачак ташлы-кыялы Уфа таулары озатып кала...

Икенче тапкырында аны Уфага җәйге Агыйдел үзе алып килә. Китканенә әле дүрт ай ярым гына вакыт үткән, ә шул вакыт эчендә күпме эш эшләнгән! Максат бер генә — таркау хәлдәге партия көчләрен коеп куйгандай туплау өчен партия органы булдыру. Владимир Ильич инде аның исемен дә күптән тапкан: «Искра» — «Очкын»! «Очкыннан ялкын кабыныр!..» Пушкинның декабристларга җибәргән хатына җавап итеп Одоевский язган шигырьдән алынган сүзләр газетаның эпиграфы булачак. Әйе, иң

беренче максат — газета чыгару. Ләкин моның өчен кешеләр кирәк. Россиядән хәбәрләр язып торучы, аны чик аша үткәреп җибәрүче яшерен элемтә кирәк, эшчеләр күп яши торган төбәкләргә җиткерүче яшерен агентлар кирәк.

Полициянең тыюына карамастан, Владимир Ильич Псковка китешли Мәскәүгә туктала. Ул анда үзенең политик фикердәшләре белән, шулай ук Самарада яшәгән чакта ук белгән кешесе — хәзер Екатеринослав комитеты вәкиле Исаак Христофорович Лалаянц белән очраша. Сөйләшү нәтиҗәле бетә: идея һәм оештыру үзәге булачак газета төзү планы Лалаянцка ошый, аның күз алдында киң офык ачылып киткәндәй була.

«Искра»га материаль ярдәм итәргә әзер торучылар да табыла. Шундыйларның берсе — мәрхүм сенаторның тол хатыны Александра Михайловна Калмыкова. Владимир Ильич шуны күрер өчен Петербургка китә. Пенсиясеннән тыш, китап сәүдәсеннән елына 100 мең сум керем алган Калмыкова «Искра»ны акча белән тәэмин итеп торарга бик теләп ризалаша. Владимир Ильич Петербургта күптән түгел генә чит илдән кайткан Вера Ивановна Засулич белән дә очрашып сөйләшә. Засулич Плехановның «Хезмәтне азат итү» группасында бик йогынтылы кеше санала, ә «Искра»ны ул группа катнашыннан башка чыгаруны Владимир Ильич уена да китерми. Бу сөйләшү шулай ук файдалы үтә.

Псков чоры аеруча киеренке. Владимир Ильич анда илнең төрле калаларында чәчелгән социал-демократик группалар һәм аерым кешеләр белән элемтә урнаштыра, газетаны турыдан туры редакцияләү өчен үзе янына, революционер булу өстенә, әдәби яктан да сәләтле иптәшләрне — Ю. Цедербаум белән Потресовны тарта, шулай итеп өч кешедән торган әдәби группа төзи. Алар газетаның программасын, характерын билгелиләр. Псковта чакта Владимир Ильич Рига шәһәренә дә барып кайта. Анда Себер сөргененнән туры солдатка җибәрелгән Михаил Сильвин хезмәт итә. Владимир Ильич аны — башта «Көрәш союзы»нда эшләгәндә, аннары сөргендә бергә булган чагыннан ук яхшы белә. Шул Сильвин аша ул хәзер латыш социал-демократлары белән элемтә урнаштырып кайта. Шулай ук Псковта Владимир Ильич чит ил паспорты алуга да ирешә. Кыскасы, Надежда Константиновна сүзләре белән әйткәндә, ул анда — Псковта утырган килеш, бик тырышып, чит илдә чыгачак гомум рус газетасы белән Россияне, рус эшен бәйләүче оешманың җепләрен үрә.

Ниһаять, Псков белән дә хушлашыр көн җитә. Ләкин әле, чит илгә чыгып киткәнче, тагын Петербургка барып, андагы иптәшләр белән чит илдән бәйләнеш юлларын билгеләргә, Подольскига кагылып әниләре янына кереп чыгарга, аннары тагын Уфадан әйләнеп Надежда Константиновна белән дә күрешеп-хушлашып кайтырга кирәк.

19 майда Владимир Ильич Псков вокзалыннан Подольскига, багаж итеп, 13 потлык китап һәм кульязмаларын җибәрә. Ә үзе Ю. Цедербаум белән Петербург поездына утыра. Икенче көнне үк полиция департаментына Псков охранкасыннан 192 нче номерлы яшерен кәгазь килеп төшә. Анда: «Элек үзем җибәргәннәргә өстәп Сезгалиҗәнапләргә түбәндәгеләрне ирештерәм: Юлий Цедербаум (Мартовның паспорттагы фамилиясе.) Псковка килгәч, Владимир Ульянов янында булды, алар икәүләп елга аръягына — Ульяновның филерларга мәгълүм булган «Лесной» кушаматлы белешләренә бардылар. Шул ук көнне Ульянов белән Цедербаум чиктән тыш яшерен төстә 18 нче поезд белән Санкт-Петербургка киттеләр...» — диелә.

Ә 21 майда иртә белән Владимир Ильичны да, Мартовны да Петербург урамында кулга алалар. Тентиләр. Көпә-көндез кулларыннан каерып тоткан килеш охранкага озаталар. Владимир Ильичның Псковтан җибәргән багажын да Мәскәүдә ачып тикшерәләр. Мәскәү охранкасы башлыгы Зубатов: «Пломба сугылмау сәбәпле, багаж тимер юл Уставы нигезендә ачылды, ул китап һәм тенденциоз кульязмалардан тора», дип Петербургка телеграмма суга.

Бәхетләренә каршы, икесеннән дә гаепләрлек нәрсә табылмый. Полковник Пирамидов полиция департаментына җибәргән кәгазендә: «...Хәзерге вакытта Ульянов белән Цедербаумны фәкать үз белдекләре белән башкалага килгән өчен генә гаепләргә мөмкин булганлыктан, мин сорау алу белән чикләнүне кирәк саныйм. Надзиратель күзәтүе астында Цедербаумны Полтавага, ә Ульяновны Подольскига озату җитә дип уйлыйм», дип яза.

Шулай итеп, охранкада ике атнадан артык тотканнан соң икесен дә чыгаралар. Әгәр Владимир Ильичның ниндидер счет кәгазенә химик ысул белән язылган чит ил адресларын, Плеханов исеменә язылган хатын, серенә төшенеп, укый алган булсалар — аны яңадан да төрмәгә ябачаклар, ул чакта очкын — кабынып өлгермәстән сүнәчәк иде. Нинди очраклы бәхет!

Полиция чиновнигы Владимир Ильичны Подольскига чаклы китереп, туп-туры өяз исправнигы Перфильев кулына тапшыра. Менә шунда Владимир Ильичтән чак кына чит ил паспортын алмый калалар. Әгәр ул исправникны полиция департаментына жалоба бирү белән куркытмаса, йөрәксез һәм ахмак Перфильев аның паспортын кире бирмәгән булыр иде.

Россиядә үткәргән соңгы атналар... Ләкин Владимир Ильич бер генә көнен дә бушка уздырмый. Чит илгә киткәнче мөмкин кадәр күбрәк иптәшләрне күреп калырга кирәк. Подольскида да ул кирәкле кешеләр белән — атап әйткәндә Лепешинский һәм Шестерниннар белән очраша, һәркайсы белән шифр турында сүз куеша.


Ниһаять, инде тулысынча ял итеп, Надежда Константиновна янына Уфага барып кайтырга кирәк. Владимир Ильич әле Псковта чагында ук полиция департаменты директоры Зволянскийга үтенеч кәгазе язган була: «...Хәзерге көндә Уфада,— дип яза ул,— ачык күзәтү астында минем хатыным Надежда Константиновна яши. Аны Псков шәһәренә күчерүләрен сорап язган үтенечемне канәгатьләндерү тиеш табылмады. Хатынымнан килгән соңгы хәбәрдән мәгълүм булганча, ул хатын-кыз чире белән авырып киткән... Врачларның әйтүенә караганда, аны дәвалау өчен кимендә алты атна вакыт кирәк... Алда әйтелгәннәргә таянып, миңа Уфада бер ай ярым торырга рөхсәт итүегезне үтенәм».

Ләкин бу үтенечне кире кагалар. Ахырда, улына рөхсәт алу өчен, Петербургка Мария Александровна үзе китә.

И ана! Бөек улыңның бөек анасы! Береннән бере гүзәл балалар табып, шат, тыныч гаилә белән агылып кына яшәп китүең күпкә бармаган шул... Иң әүвәл, 1886 нчы елның январенда сөекле ирең, алты балаңның әтисе, атаклы мәгърифәтче, изелгән халыклар дусты Илья Николаевич вафат булган. Ә бер елдан соң — бу кайгыдан айнып та җитә алмаган йөрәгеңә тагы да катырагы килеп ава — патша палачлары бәгырь парәң Александрны асып үтерәләр. И ана! Хөкем залында газиз углыңның актык сүзләрен тыңлаганда, судьяның: «Александр Ульяновны асарга», дигән хөкем карарын ишеткәндә күкрәгеңдә ярылмыйча түзәрлек ничә йөрәк булды икән?!. Александр эшенә бәйләп зур кызың Аннаны төрмәгә ыргытканнар. Шул ук елны уртанчы улың Володя да Казан император университетында революцион рухлы студентлар җыенын оештырган өчен төрмәгә эләгә... Болардан соң — уртанчы кызың Ольганың үлем кайгысы... Аннан соң тагы — Володяның Себер сөргене... Кече улың Дмитрий белән Марияңнең аллы-артлы төрмәдә утырулары... И революционерлар анасы! Мондый балалар үстерер өчен күкрәгеңнән нинди сөтләр акты икән!..

Менә син кабат, Владимир Ильичны Уфага җибәрүләрен сорап, үтенеч белән Петербургка баргансың. Синең аякларың ул департамент юлын күпме таптамаган! Шунда бит инде сиңа департамент директоры үзе: «Балакайларыгыз белән горурлана аласыз — берсен астык, икенчесен дә дар агачы зарыгып көтә» дип, тупас йөз белән кансыз сүзләр әйткән. «Әйе, мин балаларым белән горурланам!» дип, йөзенә бәргәнсең син аның. Бәлки бу юлы да син шул ук бәндә янына кергәнсеңдер. Ләкин кем янына керсәң дә, горурлык хисеңә авырлык китертмәгәнсең, «улым белән бергә үзем барам» дип, Владимир Ильичка рөхсәт алып кайткансың. И ана...

Владимир Ильичлар Уфага әнисе Мария Александровна һәм апасы Анна Ильинична белән өчәүләп китәләр. Нижний Новгородка (хәзерге Горький шәһәре) кадәр поезд белән баралар, аннары пароходка утыралар. Идел, Кама, Агыйдел буйлап берничә көнгә сузылган бу сәяхәт, тынчу җәйнең су өсте һавасы, яшел яр буйлары күзләрне генә түгел, йөрәкләрне иркәләп, барысына да рәхәт ял бирә. Бу сәяхәт турында Анна Ильинична болай дип яза:



*Мария Александровна, Анна Ильинична, Владимир Ильичлар утырып килгән «Ост» пароходының макеты.*

«Июнь ае иде. Елганың әле мул сулы вакыты. Башта Идел, аннары Кама, ниһаять, Агыйдел буйлап бару искиткеч күңелле иде. Без көн буе палубада булабыз. Володяның күңеле бик шат, ул елгадан, яр буендагы әрәмә-урманнардан бөркелгән хуш исне ләззәтләнеп сулый. Без Кама һәм Агыйделдән баручы бәләкәй генә пароходның бупбуш өске палубасында төн авышканчы сөйләшеп утырабыз. Әни арып каютага төшеп китә. Анда-санда гына күренгән бүтән пассажирлар аңардан да элек кереп югалалар. Палуба тик икебезгә генә кала, тынлыкка чумган талгын елга һәм изрәп йоклаган ярлар яныннан үткәндә яшерен әңгәмә кору бик тә уңайлы иде».

Владимир Ильичларның Нижнийдан нинди пароходка утырып китүләре мәгълүм түгел. Ул вакытта Нижнийдан Казанга хәтле Булычев пароходлары, ә Казаннан Уфага Якимов пароходлары йөргән. Шулай булгач, Владимир Ильичлар Казанга хәтле бер, Казаннан соң икенче пароход белән киткәннәр. Казанга төшмәгәннәр, бер пароходтан икенчесенә генә күчеп утырганнар. Ул вакытта Казан белән Уфа арасында Якимовларның «Ост», «Норд», «Латвия», «Златоуст» дигән пароходлары йөргән. Ленинның Уфага бәйле булган чорын өйрәнүче Уфа журналистлары Владимир Ильичлар Уфага «Ост» пароходы белән килгән дип исәплиләр. Әгәр чыннан да шул пароход булса, мин аны бик яхшы беләм: ул сугыштан соң да «Генерал Шайморатов» исеме белән Агыйделдә байтак вакытлар йөрде. Хәзер исә Караиделдә йөзмә ял йорты икән.

Менә шул пароход белән Владимир Ильичлар 1900 елның искечә 15 июнендә Уфаның Сафрон пристанена килеп төшәләр. Аларны анда килүләрен сагынып көткән Надежда Константиновна каршы алган. Пристань тавыннан ук башланып киткән Центральнея урамы шәһәрне билбаудай уратып аккан Агыйделнең үрге башына турыдан гына кистереп чыга. Ул — иң озын урам. Аның озынлыгы дүрт чакрым чамасы. Владимир Ильичлар шул урам буйлап өскә күтәреләләр. Шактый баргач, сулга борылалар да Тюремная белән Жандармская урамнары чатындагы бер өйгә туктыйлар. Бу — Сембердән күчеп килгән помещик Языковның сатып алган өе. Шуның мезонинын-

да энисе белән Надежда Константиновна яши. Тәрмә һәм Жандарм урамнары чаты! Сөрген срогын үткәрүче кеше өчен моннан да төгәл адрес булуы мөмкинме?!

Егерме биш басмалы, үзе тар, үзе текә баскыч борылып мезонинга алып менә. Кечерәк кенә ике бүлмә — берсе аш, икенчесе йокы бүлмәсе. Аш бүлмәсенең ике тәрәзәсе Тәрмә урамына карый. Ләкин аннан аскы кат түбәсенең буялган калае гына күренә, аңардан кызган калай исе бәреп тора. Бәркү, тынчу.

Мария Александровна белән Анна Ильинична Уфада күп булмыйлар, ике-өч көннән китәләр. Ә Владимир Ильич монда ике атнадан артык тора. Ялга дип килсә дә, ял итми. Кунак та булмый. Уфадагы социал-демократлар аны тыннары белән суырып алырдай көтеп торганнар. Яңадан киңәшмә, яңадан сөйләшүләр башланып китә. Мондый сөйләшүләр, киңәшмәләр конспирация максатында төрле урында үткәрелгән. Аеруча Пушкин урамындагы Кадомцевлар квартирасы файдаланылган. Кадомцевлар гаиләсендә ничектер буйсынмаучан холык, революцион рух хөкем сөрә. Әтиләре, чыгышы ягыннан керәшен татары, казна палатасында писарь гына булып эшләсә дә, хөрлеккә омтылган, хөрлек сөйгән. Үзе дә, Анна Федоровна да тыелган китаплар укыганнар, дин тотмаганнар. Балалары да шул рухта тәрбияләнеп, соңыннан революция эшенә актив катнашучы булып киткәннәр.

Уфада Владимир Ильичның бер генә көне дә эшсез узмый. Квартирадан тыш, сөйләшү, очрашулар өчен шәһәр бакчалары да файдаланылган. Бу килүендә Владимир Ильич Уфа социал-демократларыннан «Искра»ның ышанычлы группасын төзи. «Искра»-ны таратачак, эшчеләргә җиткерәчәк агентлар билгели, хәбәрчеләр таба; Уфадагы иптәшләр белән, Энәсеннән җебенә кадәр, чит илдән торып ничек элемтә тоту, ничек газетаны кайтарту, ничек һәм кая җибәрү, шифрлар турында сөйләшеп сүз куешалар. «Искра»ның Уфадагы агенты итеп Александр Дмитриевич Цюрупа билгеләнә. Киев адвокаты В. М. Крохмаль дә, сөргене бетеп Киевка кайткач, анда «Искра» группасы төзүне өстенә ала.

Уфада Владимир Ильич Нижнийдан ялга килгән социал-демократ Пискунов белән очраша. Дөрес, монда килешендә үк әле ул, Нижнийга туктагач, андагы социал-демократлар оешмасы вәкилләре белән киңәшмә үткәреп китә. Һәр мөмкинлектән файдаланып калу мөһим. Ул шулай ук үтеп барышлый Уфага кергән Урал эшчесе Малышев белән очрашып сөйләшә. Бу очрашуны Инна Кадомцева оештыра. Күз буяу өчен, туганы Эразм Кадомцевны да чакыра. Эразм — Оренбургтан ялга кайткан кадет, бөтен формаларын киеп, погоннарын такса да, күкрәгендә революцион рух кабынып килә. Инна белән Эразм ярдәмендә Владимир Ильич Малышев белән очраша. Алар башта Ушаков паркында сөйләшәләр, аннан соң Фролов урамындагы юкә аллеясы буйлап Агыйдел буена Случевский бакчасына төшәләр. Малышев белән сөйләшүгә Владимир Ильич аеруча нык әһәмият бирә. Чөнки Россиянең бик күп үзәк районнарында «Искра»чы группалар төзелсә дә, Урал белән бернинди бәйләнеш тә булмый. Урал социал-демократларының бердәнбер вәкиле менә шушы Малышев була. Ул Владимир Ильич планын тулысы белән хуплый, үзе кайту белән иптәшләре арасында «Искра»-чылар булдырырга сүз бирә. Шулай итеп, Уралга да ныклы җеп сузыла.

Иске стиль белән 2 июльдә Владимир Ильич Уфадан китә. Әйткәнебезчә, Уфада ул ике атнадан әз генә артык тора. Ял итеп, Надежда Константиновна белән хушлашып китәргә дип килүе тулысынча эш белән үтә. Ул, кайда гына булмасын, тынчып яткан искелекне җимереп, аның урынына ялтырап торган яңалык кертә. Уфада да шулай була. Моңа тикле эшчеләр арасында марксистик түгәрәкләр белән генә шөгыльләнгән Уфа социал-демократлары йөрәгенә революцион очкын салып китә. Ә очкын тиздән ялкын булып кабыначак! Владимир Ильич килеп киткәннән соң, Уфа социал-демократлары әйтүенчә, тынчу бүлмәнең тәрәзәләре каерып ачылгандай, бүлмәгә иртәнге саф җил бәреп кергәндәй булып кала. Аның эшен Уфада Надежда Крупскаялар, Цюрупалар, Якутовлар дәвам иттерә.

Алар Владимир Ильичның ышанычын аклыйлар. «Искра»ның беренче саннарында ук Уфа һәм Урал җирләреннән килгән мәкаләләр басыла, беренче саннары ук губернага килеп җитә. «Искра» 1900 елның декабренда чыга башлый, ә 1901 елның җәендә исә, тентү вакытында, Уфа, Бөре һәм башка өяз калаларында яшәүче социал-демократлардан «Искра» газетасы да табыла.

3


Галим
жирнең юлын борыр өчен
Эзләгән иде берәр теракне.
Ленин,
партияне терәк итеп,
Кешелекнең юлын үзгәртте.

РӘШИТ НИГЪМӘТИ.

Уфада бөек юлбашчыны һәр вакыт искә төшереп торган бик кадерле урыннар бар. Шундыйларның берсе — Ленин (элекке Центральная) урамы белән Коммунистическая урамы почмагындагы Ленин бакчасы. Бу чат элек, Ленин килгән елларда һәм соңыннан да, Гостиный рядка ялганып киткән һәр төрле кабактыр, сыраханәдер тулы, жигүле ат тулы базар мәйданы булган. 1924 елның Беренче маенда бу урында Владимир Ильичка һәйкәл нигезе салына. Һәм шул ук елның 7 ноябрендә Советлар Союзында беренчеләрдән буларак, Ленин һәйкәлен ачу тантанасы үткәрелә. Элекке көнне генә Уфада, шулай ук зур тантана белән, В. И. Ленин исемендәге балалар йорты ачылган булган. Республиканың төрле урыннарыннан, хәтта чит өлкәләрдән җыелган ятим балалар һәйкәл тирәсенә беренче булып агач утырталар. Уфа архитекторы Д. М. Ларионов төзегән бу монумент һәйкәл бүген дә әле бөтен Союзда иң яхшы һәйкәлләрнең берсе санала.

Ә 1941 елның 21 гыйнварында Н. К. Крупская белән В. И. Ульянов яшәгән йорт В. И. Ленинның йорт-музее булып ачыла. Һәйкәлнең дә, йорт-музейның да проектларын Надежда Константиновна исән чагында үзе хуплаган. Йорт-музейдагы бөтен нәрсә алар яшәгән вакыттагыча тора.

Бу йортка ел саен меңнәрләгән кеше килә. Бөек Ватан сугышы елларында фронтка китүче сугышчылар да, башта анда кереп, партиягә, халыкка турылыклы булырга, ил өчен җаннарын бирергә ант итеп чыкканнар. Шул ук дәһшәтле елларны биредә Долорес Ибаррури һәм Георгий Димитров та булган. Күренекле язучыбыз Мариэтта Шагинян да, Советлар Союзы Герое, очучы космонавт В. М. Комаров та була биредә. Ә Уфа пионерлары монда тантаналы линейкалар үткәрәләр, Ленин эшенә турылыклы булырга ант итәләр



*Уфада В. И. Ленин һәйкәле.*



*Уфада В. И. Ленин музей-йорты.*

Кайдан гына, кем генә килсә дә, алар үзләренең уй-тойгыларын, эшләрен даһи Ленин исеме белән бәйлиләр. Күпме дулкынландыргыч сүзләр язып калдырылган анда! Әнә анда минем райондашлар язган сүзләр дә бар:

«Районның һәрбер коммунисты, һәрбер хезмәт иясе В. И. Ленинның 100 еллыгын тагы да яхшырак, тагы да зуррак эшләр белән каршыларга диган бер генә теләк, бер генә омтылыш белән янып яши...»

Бер Илеш районы гына түгел, бүген бөтен Башкортстан данлы юбилейны дан белән каршы алырга күтәрелгән — яңадан-яңа йөкләмәләр алган. Мин ышанам, Башкортстан кешеләре бу йөкләмәләрен дә, тагын бер йөкләмә өстәп, намус белән үтәп чыгарлар.

Шулай. Бүгенгегә карыйсың да үткәнне уйлыйсың. Чөнки фәкать үткән белән чагыштырганда гына бүгенгенең эше, бөеклеге ачык күренә, үткәннән торып кына бүгенгене чын дәрәсе белән бәһалап була.

Әйе, Ленин бабай ике кабат Уфада булган, ике кабат башкорт җирләрен иңләп-буйлап үткән. Сүнеп, сүрелеп барган башкорт иле язмышын күргән. Ләкин ул моны гына түгел, шул сүнеп баручы язмыштан чыгу юлларын да күргән. Очкын гына булып башланып киткән шул юл унҗиденче елны ялкынга әйләнгән дә, шул ялкын яшендәй яшьнәп, башкортны бетәргә дучар иткән бөтен кара көчләрне дә көйдергән. Ике ел да үтми, 1919 елның 23 мартында Ленин, тарихта беренче буларак, башкортларга автономия бирә. Моннан илле ел элек чабаталы, салам түбәле Уфа губернасы илле ел эчендә иң алдынгы — мул икмәкле, мул нефтьле, мул культуралы, белемле республикага әйләнде. Бу — Ленин эшенең, ленинчыл милли политиканың сүздә түгел, эштә гамәлгә ашуы инде. Үзенең 50 еллыгын Башкортстан Уралдай киң күкрәгенә ике Ленин ордены, бер Октябрь Революциясе ордены тагып бәйрәм итте.

Без, Башкортстанда туып үскән кешеләр, туган республикабызның бу кадәр зур җиңүгә ирешүе белән горурланабыз, аңа яңадан-яңа шан-шәрәф телибез.

# ЛЕНИН ЧИШМӘСЕ

ӘКИЯТ

Карурманда, биек таулар һәм тарлавыклар арасында, Григорий исемле бер карт яшәгән. Аның олысы Иван, уртанчысы Кеша, кечесе Митя атлы өч улы булган. Өчесе дә аучылык белән көн күргәннәр — көн саен ауга йөргәннәр.

Бервакыт кече улы Митя, иртүк торып, ауга ялгыз гына чыгып китә. Ләкин юлы уңмый: көн буе йөреп, бер нәрсә дә ата алмый. Буш кул белән кире кайтырга чыга бу. Инде кайтып җитәм дигәндә генә бер зур мөгезле болан очрый Митяга. Бик куанып, чакмалы мылтыгын тиз генә иңеннән сала да төзәп торып атып җибәрә. Болан башын читкә борып торган чак була — пуля аның мөгезенә генә тия. Шуннан болан пыр туздырып чаба башлый, Митя, кан эзе буйлап, боланны куа китә. Ләкин озак бара алмый: көн тәмам караңгылана, кан эзләре күренми башлый. Митя өйләренә кайтып китә.

Кайтып җиткәч, өлкән абыйлары сорый аннан: нигә безгә әйтмәдең, ник үзең генә чыгып киттең, диләр. Митя берни дә әйтми, йокларга ята.

Икенче көнне тагын иртүк тора. Тора да, коры икмәк ашап, су гына эчеп, абыйлары уянганчы ашыгып чыгып китә.

Кичәге боланның эзен тапмакчы һәм шул эз буенча аны эзләмәкче була Митя. Көн буе эзли ул аны. Әмма, күпме тырышса да, таба алмый. Тәмам караңгыланганчы урманда йөри. Аннары, тагын эш чыкмады дип, ачуланып кайтып китмәкче була. Шул вакыт кинәт нәрсәдер кыштырдаганын ишетә. Ныклабрак тыңлый башлый һәм шунда боланга охшаган бернәрсә күреп ала. Куркытмас өчен, үрмәләп кенә боланга якынлаша башлый. Янына ук барып җиткәч карасә — болан башын селкеп тора. Ярты мөгезе юк боланның, шуңа селки икән башын. Байтак карап торгач, Митя аптырап кала: башын селеккән саен мөгезе үсә бара боланның. Мөгезе үсеп, тәмам элекке хәленә кайткач, болан зур-зур атлап үз юлы белән китә, ә Митя ул торган урынга килә. Шунда казандагы су шикелле богырдап кайнап торган су күрә бу. Болан үзенең мөгезен шул суга тыгып дәвалаган булган икән.

Митя, бик кызыксынып, үзе дә чишмәдән бер уч су алып эчеп карый. Башта су аңа тәмсез, әче булып тоела, әмма бераздан бик тәмле булып китә.

Ул көнне дә өенә бик соң гына кайта Митя. Аннары абыйлары белән бергәләп аш ашарга утыра. Болар Митядан сораштыра башлый: нигә бүген дә иртүк торып киттең, кайларда булдың,ниләр күрдең, сөйлә, диләр.

Митя аларга болан торган урында кеше ышанмаслык зур хәзинәгә юлыкканлыгын сөйләп бирә. Теге чишмәдә ничек итеп болан үзенең атып сындырылган мөгезен дәвалавын әйтә.

Моны авырып урында яткан әтисенә дә сөйли.

— Иртәгә, савыт белән барып, шул чишмәнең суын сиңа да алып кайтам әле, эти,— ди.

— Таба алырсыңмы икән соң син аны, улым? — ди атасы.

Ә абыйлары һич тә ышанмый Митяга, андый чишмә буламы соң дип, көләләр генә.

Икенче көнне иртүк Митя, пыяла савыт тотып, теге шифалы чишмәгә китә. Бик тиз барып җитә. Ул килгәндә чишмә янында бик күп җәнлекләр: боланнар, тау тәкәләре, кыр кәҗәләре, төлкеләр, куяннар җыелып су эчәләр һәм үзара сөйләшәләр икән.

— Тау-ташлар арасында йөргәндә мөгезем сынган иде, хәзер шуны дәвалыйм,— дип әйтә кыр кәҗәсе.

— Бер җирдә кырт борылган идем, муеным сына язды. Шуңа бу чишмәгә дәваланырга килдем,— ди болан.

Башка җәнлекләр я тамакларыннан ризык үтмәүдән, я ашказаннары авыртудан зарланалар.

Митя җәнлекләрне борчымаган, тыңлап кына торган. Җәнлекләр китеп беткәч кенә чишмә янына барган. Савытына су тутырган да аны бик шәп итеп бөкеләп куйган. Аннары кайтырга чыккан. Әмма, күп тә бармаган, әлеге су савыты шартлаган моның.

— Кара инде нинди бәхетсезлек килеп чыкты бит! — дип, Митя кайгысыннан елап ук җибәргән. Аннары, икенче килгәндә чишмәне ансатрак табар өчен, агач ботакларын, куак башларын сындыргалап, билге ясый-ясый, өйләренә кайткан.

Абыйлары, каршына ук чыгып, көтеп торганнар.

— Я, агай-эне, күрсәт, кая шифалы суың? — диләр алар.

Суның авырлыгына түзә алмыйча, савытым ватылды, ди Митя. Абыйлары тагын да ныграк көлә башлыйлар.

— Юк, агай-эне, синең шифалы чишмә табуыңа ышанмыйбыз,— диләр.

Митя бер сүз дә әйтми аларга, ята да йоклый. Иртән иртүк тора да, алюмин савыт алып, суга китә. Кичә ясап кайткан билгеләре буенча барып, теге шифалы чишмәне бик тиз таба. Чишмә суын савытына сала да йөгерә-атлый кайтып китә. Шуңа бик ашыга — савыт ярылмасын дип курка. Әмма савытка берни булмый.

Өйләренә кайткач, савыттагы суны кружкага салып, атасына бирә. Атасы сакланып кына эчеп карый. Башта су тәмсезрәк тоела. Әмма бөтенләй эчеп бетереп азрак торгач, ашказанына бик рәхәт булып китә.

Шуннан соң шифалы чишмә турындагы хәбәр бөтен тирә-якка тарала. Митя янына килеп, бик күп кеше сораштыра башлый. Митя аларның барысына шифалы чишмәне күрсәтеп йөри. Аннары бу хәл байлар колагына да барып җитә. Байлар чишмәне барып табалар да янына төрле корылмалар төзи башлыйлар. Чишмә янына гади халыкны бөтенләй китермиләр — сакчы куялар. Ел саен әлеге шифалы чишмәдә дәваланырга бик күп байлар килә башлый.

Шул рәвешле бер, ике, өч ел үтә. Шифалы чишмәнең суы һаман кими барып, бөтенләй юкка чыга. Бик тырышып эзләп карый аны байлар, әмма таба алмыйлар.

Кая китте икән ул шифалы су, дип хәйран кала Митя.

Бер караңгы төндә, сакчылар йоклаган вакытта, Митя чишмә янына бара да, үлән өстенә ятып, тыңлый башлый. Байтак яткач, үзара чылтырашып, берничә чишмәнең сөйләшкәнен ишетә.

— Килер заман,— ди берсе,— дөньяга бөек һәм акыллы кешеләр туар. Аннары алар илне үз кулларына алырлар. Менә шул чакта без яңадан җир өстенә чыгарбыз һәм безгә төрле яктан бик күп эшчеләр килә башлар...

Берәрсе күреп алмасын дип, озак ятмый Митя — кайтып китә. Кайта да ишеткәннәрен атасына һәм абыйларына сөйләп бирә.

Абыйлары тагын көлә моннан:

— Кайдан шулай күп беләсең син, Митя? — диләр.— Теге чакта җәнлекләр сөйләште дигән идең, ә хәзер инде чишмәләр телен дә аңлагансың!

— Аңламас идем мин аларны. Әмма бер вакыт тайгада нинди-дер гаҗәеп җимешләр күрдем. Ул җимешләрне кошлар ашап тора иде. Алардан күреп, нәрсә икән бу дип, мин дә ашап карадым. Менә шуннан ары агачлар телен дә, үләннәр телен дә аңлый башладым,— ди.

Абыйлары ышанмый, тагын көләләр.

Ә Митяның аларга һич тә исе китми.

...Менә бер заман патшаны бәреп төшерәләр. Патшаны гына түгел, аның тирәсендә йөргән кешеләрне дә куалар. Аннары акыллы кешеләр бөек Ленин җитәкчелегендә Совет властен урнаштыралар. Шуннан инде акыллы кешеләрне кайда нинди яхшы нәрсәләр барлыгын тикшерергә җибәрәләр. Яхшы әйберләрне тагын да яхшыртырга, ә начарларын юкка чыгарырга кушалар. Ул яхшы кешеләрнең берничәсе теге чишмә янына да киләләр һәм аның суы бик тә шифалы икәнлеген беләләр. Шул турыда Ленинга хәбәр итәләр.

Шифалы чишмәне чистартырга, аның тирәсенә кунак өйләре, ашханәләр төзергә кушып, Ленин үз кешеләрен җибәрә. Алар анда электр үткәрәләр, тайганы яктырталар. Радио да кертәләр.

Аннары шифалы чишмәгә халык килә башлый. Гадел хезмәт белән яшәүчеләргә бөтен уңайлыклар тудырыла. Алар анда ял итәләр, дәваланалар. Ә өйләренә кайткач Ленинны мактап сөйлиләр. Эш урыннарында тагын да яхшырак эшли башлыйлар.

Шифалы чишмә янына баһадирларга һәйкәл куелган. Ял итәргә хокукы булган барлык кешеләрне кочак җәеп чакырып тора ул.

Ул шифалы чишмәгә Ленин исемен бирәләр һәм аның даны бөтен дөньяга тарала.

Еллар үткән саен чишмәнең шифалы суы һаман чистара, арта, әйләнә-тирәсе һаман матурлана бара. Ленин исемендәге ул чишмә өстендә кояш та яктырак балкый. Дөньяда аннан да матуррак чишмә юк!

Русчадан В. НУРУЛЛИН тәрҗемәсе.

# ХАЛЫКЛАР ҖЫРЛЫЙ

*«Халык,— дип язган иде Максим Горький,— материаль байлыклар тудыра торган көч кенә түгел, ә рухи байлыкларның да бердәнбер һәм бетмәс-төкәнмәс чыганагы ул». Безнең бүгенге көннәрдә халыкларның поэтик иҗат өлкәсендә дә үзешчәнлеге көннән көн үсә бара, һәвәскәрләр күп санда җырлар һәм шигырьләр уйлап чыгаралар. Ул иҗат үзенең тормышчан һәм халыкчан булуы белән көчле.*

*Илебезнең төрле якларында һәм төрле өлкәләрендә яшәүче эшчеләр, колхозчылар һәм хезмәткәрләр Ленинга һәм Партиягә багышланган җырлар, легендалар һәм шигырьләрне күп язалар.*

*Укучыларыбызга без шул язма фольклор үрнәкләреннән кайберләренең татар теленә тәрҗемәләрен тәкъдим итәбез [1].*

*ЗӘКИ НУРИ*

## Һәр җирдә, һәр нәрсәдә

Бала тавышы яңгыравында —
Ленин,
Кырда йөргән комбайнда —
Ленин,
Тук башаклар шаулавында —
Ленин,
Гармунчылар моңнарында —
Ленин,
Мул уңышлы көз җырында —
Ленин,
Кыюларның күз нурында —
Ленин,
Биек таулар кыясында —
Ленин,
Коммунизм кояшында —
Ленин.

Киров өлкәсе

## Шушенскоеда

Түбәләрдә калын кар ята,
Юлда чыпчык канат кагына.
Зур бер төркем малай иртеп
Ленин төшә елга ярына.

---

[1] Мәскәүдә «Советская Россия» нәшрияты чыгарган «О чем поет Родина» дигән китаптан сайлап алындылар.

Син аларга бөтен серне ач.
Белгәнеңнән сөйлә барын да.
Сизгер дә соң бала йөрәге,
Рәхәт тә соң алар янында...

Петя дигән чая бер малай
Бигрәк әрсез бүген нигәдер.
— Володя абый, сезнең конькида
Шуып карыйм әле мин дә бер!

Ленин көлә шунда кычкырып,
Ул үзе дә бала шикелле:
— Булмас, булмас, шуа алмассың,
Тәпиләрең бик зур, сөйкемлем!

Петя кыю, Петя җанлы ул,
Үз теләген көйли-җайлый ул.
Ялтырап торган яңа конькины
Аягына инде бәйли ул.

Шаулап ала тагын балалар,
Алар янда, алар якында:
— Вәгъдәгез бар иде, сөйләгез
Сез могҗиза иле хакында...

Ленин карый шаян елмаеп,
— Ашыкмагыз, түземсезләрем!
Килер көне, җитәр вакыты,
Мин барысын да сезгә сөйләрмен!..

Горький өлкәсе

## Наташа исемле кыз һәм яхшы бабай

Сакчы аны бик тиз күреп алды,
Коридорда юлын бүлдерде.
Һәм, бәхеткә, шуннан узган чакта
Кызны Ленин күреп өлгерде.

— Адаштыңмы? Синең исемең ничек? —
Сорый Ильич туктап бер мәлгә.
Әйдә киттек, минем белән атла,
Ял итеп чык минем бүлмәмдә.

Сакчылардан гафу үтенде ул,—
Кызны, димәк, кирәк кертергә.
Кабинетта икәү утыралар,
Наташа һәм Ильич — бер түрдә.

Язу язды, кәгазь караштырды,
Һәм сорашып барысын белде ул.
— Наташенька, синең әнкән бармы?
— Күптән түгел ачтан үлде ул.

— Димәк, монда син адашып кердең!..
Я, әйбәтләп утыр, мә, аша!..
Оеп китә йомшак урындыкта
Һәм йокыга тала Наташа.

Зур дөньяның белми хәл-әхвәлен,
Үз йокысы йокы сабыйның.
Бүлмә тып-тын. Кинәт телефонга
Кулы үреләә яхшы абыйның.

— Миңа бик тиз Эдмундович кирәк!
Исәнмесез! Эшләр барамы?
Менә нәрсә: бүген коридорда
Очраттым бер сабый баланы.

Әнисе юк, танышларын белми,
Кичке якта кергән ул безгә...
Балаларны кайгыртырга кирәк —
Совнаркомнан боерык шул сезгә.

Каңгырмасын бала урамнарда,
Ана булсын Ватан аларга...
Әһә, әйе! Спекулянт эшен
Зур җинаять диеп санарга.

Горький өлкәсе

## Кадак турында бер язу

Сөйләштеләр бөтенесен ярып салып...
Булганы — бар, мөмкин түгел киләчәксез...
— Сез әйтәсез, Волхов мохтаҗ кадакка, дип,
Табачакбыз, сезгә кадак бирәчәкбез!

Кәгазь ала, кызу-кызу яза башлый,
Түбәнгәрәк төшә бара юл арты юл.
Йөгерек имза куела аска: «В. Ульянов».
Һәм «Ленин» дип куя җәя эченә ул.

...Ильичны без һәммә эштә шулай күрдек
Аның өчен олы иде бөтен нәрсә.
Россиянең зур язмышын хәл иткәндә
ГОЭЛРО да һәм кадак та мөһим нәрсә.

Мәскәү

## Карт шофер

*Булган хәл*

Ул хәтерли, начальнигы чакырып алды,
Җилкәсенә кулын куйды: «Сине беләм,
Шуны аңла, Войсков, сиңа ышанабыз...
Бүген юлга чыгасың син Ленин белән».

Һәм күрә ул: машинага Ленин утыра...
Кызу чапты — машина бик күндәм иде...
Менә алар калага да килеп керде...
Петроградны төн тынлыгы күмгән иде.

— Тиз життек без, бик тиз! — диде аңа Ленин.
Рәхмәт! дигәч бераз тынлык булып алды.
Ә аннары шоферга ул кулын сузды,
Шофер исә аптырап һәм тынып калды.

Хәтерли ул сүз әйткәндә буталганын,
Әй син тел, тел, ник син болай оста түгел:
— Кичерегез, кулым, Ильич, бензинлы бит,
Сау булыгыз... Хәзер кулым чиста түгел...

Күзгә карап торды Ильич һәм елмайды,
Җавап итеп әйтелделәр изге уйлар:
— Сез бит эшче! Димәк, сездә була алмый,
Юк, юк, әйтмә, була алмый пычрак куллар!

Ленинград

## Очрашу

Күзге көн. Яфрак саргайган.
Юллар тигез. Урләр юк.
Мәскәү тирәсе кырлары,
Сездән ямьле җирләр юк!

Яңгырлар сибәләп узса —
Җил исә дә җир кибә.
...Якшәмбе көннәрне Ленин
Ял иткәли Горкида.

Ауга йөри. Җилдән курыкмый.
Карамый пычракка ул.
Бер көн урманга барышлый
Бер картны очрата ул.

Кулында кәрзин, өстендә —
Иске тун, башта — бүрек.
— Исәнме, иптәш! — ди Ленин,
Сәламне башта биреп.

— Хәерле иртә! — ди бабай.
— Гөмбә бармы?
— Факт, бар.
Җыярга тик саулык җитми,
Йөрергә тик вакыт тар.

Ленин яңа мылтык өскән.
Карап торгач шуңарга,
Бабай тагын әйтеп куя:
— Ә сез, димәк, сунарга?

— Ауга шул. Инде күзгә дә
Күренде озын колак,
Өч тапкыр аттым — тимәде,
Һәм әйттем аңа: олак!

— Ә ник артыннан чапмадың?
— Ул бит яшен күк шылды...
Аучы да кычкырып көлде,
Гөмбәче дә кушылды.

Чабата кигән бабайдан
Күз алмый итеклесе.
Янәшә атлап китәләр —
Әйтерсең, ике күрше.

Гәпләшеп шактый узалар
Куе урман юлыннан.
Бабай әйтә: — Күптән хат юк
Солдаттагы улымнан.

Мохтаҗлыктан һәм сагыштан
Карчык та бик ябыкты.
Очын очка көчкә ялгап
Тотабыз хуҗалыкны.

— Ә ат бармы?
— Каян килсен...
Йорт та иске житмәсә...
Тәмам эштән чыга идек
Комбед ярдәм итмәсә.

Тормыш кайчан рәтләнердер?
Кыен бит бик тә, бик тә.
Дөресен сөйләгән өчен
Син инде гаеп итмә.

— Әйе, — ди аучы, — дөрес бу,
Халыкка җиңел түгел.
Нужа каплый болыт булып
Әлегә илнең күген.

Өр-яңа тормышны власть
Төзи алмый тиз генә —
Өскә күпме дошман килде,
Каршы тор да түз генә...

Үзгәрер тиздән тормышлар,
Безнең көч җимми калмас.
Кышлар күпме котырса да,
Җылы яз килми калмас.

Иркен сулап куя бабай:
— Ярый шулай булса,— дип.—
Мәскәүдә иптәш Ленин бар,
Илдә иң зур большевик.

Дошман тиздән җиңелер, дип,
Син менә хак сөйлисең.
Ленин да шулай ди микән?
— Шулай булмый ни дисен...

Урманнан чыктылар. Алда
Күренде күксел елга.
— Хушыгыз! — Аучы кул бирде,—
Мин китәм хәзер сулга.

Жиләс жилләр исте кырдан
Яңартып картның хисен.
Әйтте бабай: — Син кем, иптәш,
Ничек соң синең исем?

— Исемем минем Владимир,
Шулай диләр күптәннән.
— Ә атаң кем? Ә атамны
Илья диеп йөрткәннәр...

Якты күз нуры бабайның
Аучы юлына төште:
— Бу да большевиктыр, ахры,
Күр, нинди яхшы кеше.

Витебск

## Зурларның зуры

Зурны зурга тиңләү өчен
Сайлый сүзне йөрәк үзе.
Кояш һәм Җир дигәне бар,
Бар Океан һәм Даһи сүзе.

Ләкин кояш көндез генә
Яктырта да китә бездән.
Ә җир исә үз серләрен
Яшерен саклый безнең күздән.

Океанда томан күп була,
Күрмисең хәтта күкләрне.

Даһи диеп йөртә халык
Үз арасыннан күпләрне.

Тиңләштерер өчен шулай
Эзләдек без сүзнең зурысын —
Ул сүздә Ленин бөек тә,
Ачык та, гади дә булсын.

Таптылар сүзне йөрәкләр,
Әйтте аны илем үзе:
Ленин — Мәңгелек дигән сүз,
Ә Мәңгелек — Ленин үзе.

Мәскәү өлкәсе

## Көннәрнең берендә

Мин урман юлын илле ел
Рәттән таптадым.
Бер чакны Ленин белән дә
Бергә атладым.

Ауга барышлый очраштык
Аулак урында.
Бик төпченеп сорашты ул
Авыл турында...

Болынга чыккач урманнан —
Артта калды ул.

Тсс! ди Ильич — суда үрдәк
Күреп алды ул.

Ашыкмый ләкин — уйларсың
Нидер көтә дип...
Мин әйтәм: — Тизрәк атыгыз,
Очып китә бит!

Юк, Ленин басмый чакмага,
Мылтык атылмый:
— Үрдәкнең баласы бар ич,
Ничек атыйм?! — ди.

Саратов өлкәсе

## Ленин бүлмәсендә

...Стенасы буйлап китап тезгән,
Язуы бар: «Тартмыйк!» дип әйткән.
Шушында ул җир язмышын яклап
Маркс белән кат-кат сөйләшкән.

Кешеләр килгән. Хат һәм чыгыш язган,
Декретларга имза салган ул.
Кайбер таңда гудок җырын тыңлап
Шул бүлмәдә тынып калган ул.

Шул бүлмәгә менә без керәбез,
Били уйны, били хисне ул:
Бер заводтан ашыгып кайтып кереп
Безнең кулны кысар төсле ул.

Ярославль

## Халык әйтә

Гранит дибез — Урал ташы, безнең таш ул,
Матурлык та, ныклык та бар ташыбызда.
Тик аннан да мәһабәт һәм матур булып
Ленин сыны үзе тора каршыбызда.

Җил киссә дә, су тишсә дә бирешми таш,
Тиңдер җирдә һич какшамас чынлыкка ул.
Ленин рухы ләкин гранит таштан да нык,
Чөнки утлар-сулар кичеп чыныккан ул.

Гранит ташы — безнең таулар батыры ул,
Хезмәт итәр җирдә бик күп буыннарга.
Халык әйтә: Ленин гомере аннан да зур,
Җитәчәк ул җирдә бик күп миллионнарга!

Свердлов өлкәсе

**Аяз Гыйләҗев**

# УРАМНАР АРТЫНДА ЯШЕЛ БОЛЫН

РОМАН[1]

## 18



Ниса Чәймилова милиция бүлегеннән пакет килгәч, бохар пылавы исен сизгән тамакай кебек сикергәләде...

Ниһаять, кирәк кешесе килеп капты, тәбе капкачы «шап!» иттерде...

Аның уенча, кешеләр бер-берсенә капма-каршы төркемнәргә бүленәләр иде. Бер төркемдә — үз ишләре, төрдәшләре. Ә кем уңганрак, кем булдыклырак, кемнең эше тырышлык нәтиҗәсендә тиз һәм уңай бара — андый кеше Нисага дошман.

Ул үзе бөтен нәрсәне дә авырлык кичереп, кан-яшь коеп, газаплы түбәнлекләр, әрнүле михнәт аша гына үзләштерде. «Дүрт яшенә кадәр кашык та тота белмәден!» дип орыша иде дәү әнисе.

Кыенлыклар берьюлы өерелеп килделәр. Тапкырлау таблицасы аның өчен дөньядагы иң авыр, иң чуалчык әкәмәтләрнең берсе булды. Таблицаны үзләштерә алмаган өчен генә ул беренчедә өч ел утырды. Әнкәсе, аның башын өстәлгә бәрә-бәрә: «Ангыра сарык!.. Бер ангыра сарыкны икегә тапкырласаң ничә аңгыра сарык була?» дип тирги иде. «Дүрт» дия иде нәфрәтне аңларга житешмәгән бәләкәй Ниса...

Кыйнасалар кыйнадылар, мыскылласалар мыскылладылар, әмма Ниса Чәймилова тапкырлау таблицасын мәңге онытылмаслык итеп үзләштерде.

Ниса ел башында тотынган кулъяулыгын май бәйрәменә генә чигеп өлгертте, кырык җебе чиялэнде, йөз мәртәбә сүтте, буталды... Ә аның яшьтәш кызлары әллә кайчан эшләрен тәмамлап болыннарга, кырларга йөгерделәр, кичке уеннарга төштеләр...

Дөньяның кыл урталай бүленгәнен яшьли аңлады Ниса.

---

[1] Дәвамы. Башы 10, 11 саннарда.

Кешеләрне ул үз фәлсәфәсе белән генә бәяләде, аларның кылган эшләрен үз бизмәнендә генә үлчәде. Нәтиҗәдә, берәүләрне чамасыз яклады, икенчеләрнең тегәрмәчләренә астыртын гына таяк тыкты, ике төркемнең арасын бутады.

Батмады да, калыкмады да Ниса Чәймилова!

Аның иң яратмаганы вундеркиндлар, ун-унике яшьтән интеграллар-ны, генетиканы, пе-мезоннарны һәм Гегель диалектикасын капшый башлаган өлгер һәм тырыш үсмерләр иде. Ул үзе исә соңгы ун-унбиш ел эчендә партия тарихы китабының дүртенче главасыннан узмады дисәң дә була...

Әхәт Нуруллин Ниса ярат-мый торган төркемнең иң зарарлы, иң куркынычлы бер вәкиле иде. «Парвеню», «сәнәктән кирәк булган кеше», «эше уңайга барып ята гына бит мөртәтнең!..»

Әхәт университетта татар бүлегендә укып йөргәндә үк (Нисаның яшьләр газетасының хатлар бүлегендә ныгыган еллары!) ул аны, өйрәнгән гадәте буенча, башкалардан аерып куйды, күрә алмады һәм аңа үчекте.

Ниса кош теледәй информация ясар өчен дә көн-төн башын вата, телефонны интектереп бетерә, үзе борчыла, тиргә бата, йокысыз кала, тәмәке уба. Шулай кырык җәфа чигеп язылган материалын да секретариатта эле печеп, эле кыркып сыкрый-сыкрый гына газетага үткәрәләр, хурлык!.. Ә теге малай, кызыл кәпәчле яшь этәч, (аңа башка кушамат та юк!) редакциягә килә, керә, тегенә эш кушалар, ул шуны наять иттереп башкарып чыга. Кызык та яза, газетага иң кирәкле кешеләрне, вакыйгаларны чокчып чыгара, ялгышмый, буталмый. Бүген кушсалар бүген үти, ялт итә. Бара-кайта, зур-зур репортажларны туп-туры редакция машинисткасына диктовать итә. Дөнья хәтле мәкаләгә никадәр тапкыр сүзләр, тәгъбирләр сибә, шуның бөтенесе бер бусагасыз газетага кереп тә китә...

Әхәт университетның соңгы курсында укыганда аны штатка алу турында сүз чыкты. Ниса аның юлын кисәргә тырышып төн чапты, көн чапты, тик Рәкыйп редактор иде инде, ул Әхәтне эшкә якынайтты, редакциягә алды.

Бергә эшли башладылар. Ниса Чәймилова беренче булып Әхәтне котлады, зеленхоз кибетеннән бер бәйләм ак хризантемалар алып кайтты... Төкереген эчкә йотты Ниса, зәһәр төкереген...

Әхәт редактор белән якынлыгын берчакта да үз файдасына бормады, элеккедән дә тырышыбрак эшләде, яз-көз димәде, карлы-бозлы янгырларда да командировкасына чыгып китте, тынмады, ерак-ерак районнарда да эзен суытмады. Аны бүлек мөдире итеп күтәрделәр.

Ниса, корбанын сагалаган диңгез төбе балыгы сыман, төсен үзгәртеп комга яшеренде, посты һәм көтте, онытмады...

Милициядән калын гына пакет иң элек аның кулына керде. Кичә Тәүфыйктан ишетелгән сүзләр, ах, бик кирәкле сүзләр, хак булып чыксалар, бүгенгә аның кояшы чыга түгелме?!. Ул пакетны, хөрмәтләп, аягүрә басып ачты, калын ак кәгазьгә машинкада зәңгәр лента белән сугылган юллардан иң элек фамилияне эзләп тапты.

«Әхәт Нуруллин» дигәнне аергач, калтыравыклы вак-вак адымнар белән редактор бүлмәсенә йөгерде. Вак-төяк дәлилләр белән Рәкыйп янына керми башлаганда гына Нисаның җәтмәсенә кителгән алтын балык килеп капты!

Рәкыйп аулак калган кай минутларында һаман-һаман шигырьләр тырмаштыра. Болай үзе өчен генә, күңел яктылыгында сүнми калган утны җанландырыр өчен генә яза...

Бүген аның шундый илһамлы, күңеле нечкәргән чагы. Зур кызына ун яшь тулды... Өстәлгә йодрык белән кага-кага ритм сиплэп утыр-

ганда ишекне шакымыйча-нитмичә генә Ниса Чәймилова килеп керде Аның серле кыяфәт чыгарып ишек төбендә катып калуы кызык иде.

— Производство гимнастикасы ясарга чакырасызмы, Ниса апа? — диде Рәкыйп, кәгазен учы белән каплап.

Чәймилова тырпайган тырнакларын яшерде, эшлекле, тәкъва суфы кыяфәтенә керде һәм, ике куллап, пакетны редакторга сузды:

— Күңелсезлек, соң дәрәҗәдә күңелсезлек, Рәкыйп Шәкүрович.

Редактор, төбенә тоз сала-сала, милициядән килгән язуны укыды Парк хезмәткәрләре һәм милиция вәкиле кул куйган бу актта сөенер лек хәбәр юк иде. Нисаның елмаеп торуына ачуы килеп, Рәкыйп:

— Тычканга үлем, мәчегә көлке,— диде.

— Минем алдан күрүемнең раслануы,— диде Чәймилова, елмаюын яшереп тә тормастан.— Әйтә килдем, үзегезгә мәгълүм, кисәтә тордым Чарасын күрмәдегез. Хәзер бөтен шәһәргә фаш булдык, рисвай булдык

Бу хатын белән сөйләшкәндә редактор үзе дә авызын үлчәп ача чөнки Нисаның үз логикасы, үз сиксәне сиксән, бөтенләй кителмәгән яктан җеп очы китереп чыгарып аптырашта калдыра торган гадәте күптән мәгълүм... Шулай да Рәкыйп Әхәтне якларга кереште:

— Баш китәрлек гаеп күрмим, Ниса апа... Гаебе зурдан булса милициядә үк җәза бирерләр иде... Дөрес, безнең егет каш ясыйм ди күз чыгара язган... Җәмәгать урынында тәртип бозган... Шулай да аның усал ниятенә күңел ышанмый.

— Ничек ышанмый? — диде Ниса, зәһәрләнеп. — Потенциаль җинаятьче булуы аның бөтен кыяфәтенә чыккан! Менә шул расланды да сиздегезме?

— Сез Италия криминалисты Ломброзо теориясе ягындамы? — диде Рәкыйп, юри сүзне чуалтып. Нисаның сайда йөзәргә яратканы ул күптән белә.

— Мине политик сукырлыкта гаеплисезме? — диде ул кинәт төшенке тавыш белән.

— Кешеләрдә потенциаль җинаятьчеләрне күрү — хаталанырга илтә торган зарарлы теория,— дип аңлатты Рәкыйп.

Ниса, кулларын җәеп, тәрәзәне ачып җибәрде:

— Әнә, карагыз! Бауман урамын тутырып халык йөри. Аларны җинаятьчеләр дип атыйммы мин? Совет кешеләре, гади хезмәт ияләре. Үз ишләрем... Ломброзо-моброзоны ишеткәнем дә юк, теләмим дә!

Ул, местком председателе буларак, бүген үк редакциядә җыелыш җыюны һәм Әхәтнең җинаятен тикшерүне таләп итте. Болай гына котылырга мөмкин түгеллегенә ышанган Рәкыйп, ниһаять, шуңа ризалашты.

Идрис редактор янына керергә дип ике-өч тапкыр талпынып кара ды. Иртән Рәкыйп яныннан килем-китем өзелмәде, аннан ул ялгызы гына бик бирелеп язып утырды. Инде керәм дип тәвәккәлләсә, бу юлы бүлмәдә Ниса бар иде. Чәймиловадан соң редактор янына керүдән мәгънә юк, Ниса теләсә кайчан, теләсә кемнең кәефен бозып чыга Күтәргә туры килде.

— Сүз бар иде, Рәкыйп абый.

Редактор аңа сынап карады.

— Утыр, утыр, картлач. Сөйлә.

— Теге детсадны тикшердем.

Рәкыйп сул кашын күтәрә төшеп чак кына уйлап торды.

— Я, ниләр бар?

Идрис җыенысын бер тирәгә туплап Жаденко, Булавина, Гринберг белән очрашуларын сөйләп бирде. Редакторның берничә кат аны бүләргә талпынуын күреп, сүзен кыскарак тотарга тырышты.

— Фаина Наумовнаның кызык кына күзәтүләре бар. Бәлки аларны җыештырып, сиплэп газетада бирербез?

Гадәттә һәр яна тәкъдимне хуплап диярлек каршылый торган редактор бүген таркау гына:
— Уйлашырбыз, яхшы,— дип куйды.— Җәйге дачага чыгаралардыр бит?
— Бүген-иртәгә.
— Ярый...
Сүзе бетсә дә, Идрис ымсынып Рәкыйпкә караштырып утырды. редакторның да әйтер сүзе бар кебек иде, тик ул да нигәдер башламады, икесе дә кемнедер көткән кебек ишеккә караштыргаладылар.
— Ярый,— диде Рәкыйп, маңгай пеләшен кашып.— Турысын гына әйткәндә, мин сине башка бер сүз белән кергәнсеңдер дип уйладым.
— Нинди сүз белән, Рәкыйп абый?
— Я, ярар, бар... Якшәмбедә паркта булган күңелсез хәлгә сине шаһит диделәр. Фикерләреңне ачыкла, төштән соң җыйналып алырбыз.
Нинди фикерләрне ачыкларга? Нигә Рәкыйп шулай кырыс сүз әйтте? Идрис аптырашта калды. Әхәтнең эштә күренмәве иртәдән бирле борчып торган иде, редакторның кисәтүе аны тәмам чуалтты. Ул Әхәтләр өенә ике тапкыр шалтыратып карады, икесендә дә трубканы алмадылар.
Өченче кат номер җыеп маташканда Әхәт үзе килеп керде.
— Сине эзләп җан кыям, кая югалдың?
— Каршыңда басып торам.
— Монда җыелыш оеша диләр.
— Сөенчегә ни сорыйсың?
— Кәмитләнмә, зинһар.
— Булса — хәер, булмаса — сәер. Ниса юлбашчымы?
— Белгән юк. Миңа шеф-мөхәррир җиткерде.
Аны-моны сөйләшкәләгән арада бүлмәгә Ниса килеп житте, Әхәт белән шат кына күреште һәм икесен дә җыелышка чакырды.
Җыйналдылар.
Яшел постау ябылган дәү өстәл артына утырган бәләкәй Ниса, алты кырлы күзлеген кылыч кынысы кебек юка сыртлы борыны өстенә элеп, милиция актын укып чыкты. Акттагы имзаларны аерым-аерым тезеп чыкканнан соң, үзенең дә шушы кешеләр — гаепләүчеләр белән беррәттән икәнлеген расларга ашыккан сыман, сүзен башлады:
— Менә, кадерле дусларым, газетада эшләвенә хөрмәт йөзеннән Әхәт Нуруллинны унбиш тәүлеккә утыртмаганнар, гәрчә ул аңа мең тапкыр лаек булса да... Әйе, әйтик, бусы шулай... Чара күрү өчен кәгазьне безгә җибәргәннәр.
— Монда чара күрүне сорамаганнар ич,— диде Әхәт.
Ниса аңа күтәрелеп тә карамады, дәвам итте:
— Безнең әхлак сафлыгы сагында торучы принципиаль кешеләр икәнлегебезне дә истә тотканнар булыр, милиция хезмәттәшләрен әйтәм... Ягез...
— Мин ун сум штраф түләдем инде,— дип ачыклады Әхәт.
Редактор гөжелдәшкән хезмәттәшләргә карап:
— Тынычлык саклыйк, иптәшләр,— диде.
— Чынлыклап исәпләсән, мондаен зур җинаять кылган өчен унбиш тәүлек кенә нәрсә ул?.. Милиция кешеләре әхлак нормаларын бозучыны безнең кулга тапшырып сизгерлек күрсәткәннәр, минемчә. Иптәшләр мине яклаларлар дип ышанам... Моның белән алар гүяки әйтергә теләгәннәр: менә сезнең иптәшегез, сез барыгыз да аның тормыш сафлыгы өчен җаваплы... Мин үзем шулай аңлыйм. Без тагын бер кат үзебезнең кем булуыбыз, кайда эшләвебез хакында тирәнтен уйланыйк, ялгыш адымнар ясаудан коллектив белән сагаеп тиешле чараны күрик. Ә чара күрергә кирәклегенә шикләнүче кеше безнең арада юктыр дип

ышанам... Мепә безнен арабызда хөрмәтле житәкчебез, редактор Рәкыйп Шәкүрович Шәкүров утыра, һәм башкалар да монда... Әхәт Нуруллин моңарчы да үзенең юньсез фокусларын күрсәткәләп килде.

Кемдер көрсенеп куйды, урындыклар шыгырдады, бу урында Нисаның тавышы үзгәрде, ул, күзлеген маңгае өстенә менгереп, ашыкмыйча, иренмичә, бутамыйча Әхәтнең ничә тапкыр соңарып килүен, эш вакытында барлыгы ничә минут югалып торуын, буфетта ничә шешә сыра эчүенә кадәр берәмтекләп санап чыкты.

— Әгәренки минем фактларны шик астына алсагыз, рәхим итеп, редактордан белешегез. Местком рәисе буларак бу тәртипсезлекләрне мин үз вакытында теркәп, житәкчелеккә хәбәр итә килдем. Үз вакытында әшәкелекнең тамырына балта чаба алмадым, бусы минем йомшаклыгым. Шул зур гаебемне тану белән бергә Рәкыйп Шәкүровичның да авызын тәмсезләргә яратмавын искәртәсем килә. Катырак була белмәде!..

Катылыкның жанлы мисалы итеп, ул тагын бер кат актны селкеп күрсәтте.

Ул сөйләгәндә чышын-пышын утырган хезмәттәшләр тындылар.

Рәкыйп тыныч кына, бер яктан икенче якка күз йөгертеп, бүлмәдәгеләрнең сүз башлавын көтте. Ул Нисаның кысыр болыт кебек күкрәп маташуын мыек астыннан гына елмаеп тыңлады һәм сүзнең бик тиз бетәчәгенә шикләнми дә кебек иде. Кыеп сүз башлаучы күренмәде. Башкалар кыенсынып урыннарында кыбырсыганда бүлмәдә иң пошмаган кеше Әхәт үзе булды. Укыйсы вагазьне аңа милициядә укыдылар, ул үз гаебен таныды, штраф түләде. Лида белән Тәүфыйктан ул чын күңелдән гафу үтенде. Шул житмәдемени инде?

Жыелыш куркынычтан бигрәк кызык иде. Еллар буе бергә эшләгән иптәшләреңне гаепләүчеләр сыйфатында гел-гел күреп булмый! Ягез әле, яңа яктан күренеп китегез!.. Нигә дәшмисез инде?..

Рәкыйпнең эче пошты, ул, озакка сузылган бу ямьсез һәм шикле тынлыкны бүлергә теләгәндәй, иптәшләренә караштырды.

— Сөйләүчеләр бетеп киттеме? Бәлки кайберәүләр шәхес өстеннән, кыз баладан көлүне жинаять дип санамыйлардыр?..

Нисаның йомшак кына әйткән ирониясе сискәндерде, кемдер иңбашларын уйнатты, кемдер алдында яткан кәгазьгә тагын да иелә төшеп адәм башлары, кәжә мөгезләре сызгаларга тотынды.

Рәкыйп ашыктырырга булды:

— Ягез, иптәшләр,— диде ул.— Берәр фикер әйтик тә таралышыйк. Берьюлы гөжләшеп алдылар.

Кинәт әллә нәрсә булды, кешеләрнең күзләрен бүдылармыни, әле генә күңелләрендә бу хурлыклы хөкемне оештырган Нисага нәфрәт тоеп утырган Әхәткә теләктәш кешеләр журналистларның бурычлары, аның мөмкинлекләре, халык арасында тоткан урыны турында еракераклардан уратып сүз башладылар. Беренче чыгып сөйләүченең фикерен анлау шактый кыен булса да, «Әхәт гаепле икән» дигән нәтижәне чыгарып була иде. Чәймилова шунда ук тернәкләнде, кәйри башлаган хөкем учагына бер-ике коры дәлил ыргытты: яшьләрне тәрбияләүне өсләренә алган кешеләр үз житешсезлекләренә кискен бүлырга тиешләр! диде.

Учак пыскыды, кабынды, дөрли башлады һәм Әхәтне ялмап йотты. Чыгып сөйләүчеләр Әхәтнең тырнак астында бер кер дә калдырмадылар. Һәркем үзенең саф, намуслы икәнлеген башкаларга исбатларга тырышты, моның иң жинел юлы иптәшеңне тетеп салу, аны кичермәс гөнаһларда гаепләү иде. Беренче чыгыш ясаганнар янадан сүз таләп итеп соңгылардан да уздырып егетнең тетмәсен теттеләр.

Ике генә кеше сөйләмичә калды: Рәкыйп белән Идрис.

Әхәт өстенә җинел генә наһак бәлаләр ява башлагач, Идрис, тукта, минә хәзер чәчрәп чыгам да барын әйләндереп ташлыйм дип йодрыгын кесәсендә тотты. Һич көтмәгәндә кешеләр Әхәтне дөмбәсләргә тотынгач икеләнә калды.... Янды малай, я каты шелтә бирәчәкләр, я эштән үк куачаклар... Якласаң-якламасаң да коллектив фикерен үзгәртә алмассың, кара табы сиңа сыланып калыр. Әле шушы кешеләр белән эшисе, эшлисе бар... Әле генә квартира бирделәр... Анда Дилә авырып ята... Иптәшләр белән, шул исәптән Ниса белән, араны кискенләштерүнең һич зарурлыгы юк... Әнә, Рәкыйптән үрнәк алырга кирәк, җитәкче булса да яклап чыкмый, сагая...

Җилкенеп-җилкенеп куйды Идрис, Әхәтнең тынычсызлана, нервлана башлавын абайлап, урыныннан кыймшанып-кыймшанып алды, әмма дәшәргә батырчылык итмәде. Сөйләүчеләр тәкъдимнәргә күчеп. «Нуруллинны эшеннән алырга кирәк!» дип кычкырына башлагач, Рәкыйп торды.

— Сез бераз кыздыгыз, иптәшләр... Кызулык безнең ярдәмчебез түгел... Нуруллинга алай каты бәрелерлек сәбәп юк, моны барыбыз да аңлыйбыз. Тормыштагы һәр ялгыш, һәр уңышсызлык өчен талантлы иптәшләрне урыныннан куа башласак, тиз барып чыгарбыз. Акыллы булыйк, андый дуамаллык күрсәтмик.

Эх, Идриснең сүзләрен авызыннан өзеп әйтте редактор.

Рәкыйптән соң чыгыш ясау уңайсыз кебек тоелды, йодрык кесәдән чыкмады...

Әхәт редактордан да, Идристән дә шуңа охшаганрак сүз көтте.

Идрис ни булса да әйтергә тиештер бит!.. Ләкин ул эндәшмәде... Ярсып, ләкин ярсуын тирәнгә яшереп, Әхәт тә урыныннан купты:

— Тыңладым сезне, иптәшләр. Рәхмәт. Күземне ачтыгыз. Куасызмы, юкмы, анысын үзегез хәл итәрсез, әмма мин газетадан китәм... Келәймәле ат ерактан күренә, дагаланган куян ерак чаба алмый... Уртак баудан ычкынган альпинистның хәле мөшкел... Сөйләүчеләргә дә, дәшми калучыларга да рәхмәттән башка сүзем юк.

Аның көтелмәгән бу чыгышын чираттагы дуамаллыгы санап шаулаша башлаган халыкны Рәкыйп туктатты.

Берниндн карарга килмичә таралыштылар.

Утырдашлар суынып, үзләренең ахмак, куркыныч психозга бирелеп китүләренә оялалар иде...

Әхәт бүлмәгә чыкты, шул минуттан урынына утырып та карамады, диванга чумып, тезенә катыргы тыш куеп гариза язды, өзлексез тәмәкесен пыскытты, телефоннан сораучыларга «юк» дияргә кушты.

— Нигә ашыгасың син гаризаң белә? — диде Идрис, ниһаять.

— Телең ачылуы белән котларга рөхсәт ит,— диде Әхәт, кадап.

— Син... минем хәлгә дә кер инде...

— Ничек?

— Шушы коллективта эшләргә кирәк ич миңа... Син ялгызак, җилкәндә нибарысы үз язмышың, куркырлык кешең юк. Кая барсаң, шунда эшли аласың!

Әхәт аны, беренче тапкыр күргән сыман, җентекләп карап утырды.

— Нигә дәшмисең? — диде куркынып, Идрис.

— Уйланам... Институттан сине Себергә укытырга җибәрделәр. Аннан газетага сине мин алдырдым...

— Минем моны онытканым юк, Әхәт.

— Гадәт-холкың тагын да начаррак дигән сүз!.. Хәзерге заманда әдәбиятта, сәнгатьтә классик хыянәтче Иуданың популярлыгы узды... Турыдан-туры аяк чалучы, хыянәтче образы яңалык түгел хәзер. Заманыбызның иң куркынычлы шәхесе итеп Понтий Пилат алына... Әнә шул белмәмешләр, күрмәмешләр, кешенеке кештәктә, үземнеке үзәктә дип читтән-чоттан кул юып йөрүчеләр куркыныч... Рәкыйп мине җибәр-

мәскә тырышачак, шулай да мин китәм!.. Башкаларның мине чәйнәклэп утыруына исем китмәде. Ниса тәэсирле сөйли ала, өйрәнгән!.. Әмма син... Син!.. Бергә бер бүлмәдә утырасымны уйласам, эч-бавырларым сыза...

— Нишләргә тиеш идем мин? — диде Идрис, гәрчә оятыннан тотлыгыр дәрәҗәгә җитсә дә.

— Ни булса да әйтергә тиеш идең... Нәрсә генә булса да, валлаһи!.. Син генә барын да белә идең: мине дә, Лиданы да, Тәуфыйк иблисне дә...

— Рәкыйпнын яклавы җитмәдеме? — диде ярым кычкырып Идрис.

— Мин яклауга мохтаҗ түгелмен. Мина синен, дусның сүзе кирәк иде, Понтий Пилат!.. Сыек буынлы икәнсең, кавырсының катмаган. Моның бик куркыныч ягы бар: берәрсе сине үз кулына төшерер!..

— Төкерден битемә,— диде Идрис, әрнеп.

— Дөнья бит!

Рәкыйп, Әхәтнең гаризасын кире кертеп, кал, дип үгетләде. Тик Әхәт килешмәде дә, сөйләшмәде дә.

## 19

Әхәт эшкә телевидениегә китте.

«А» классындагы командадан «Б» классына уйнарга күчәм... Мин кара эшче... Әле алфавитның башын гына үттем, класслар да, хәрефләр дә җитәрлек анда... Барысын да татып карыйк!» дип шаяртты ул саубуллашканда.

Идриснең кәефе шаярырлык түгел иде. Әхәт барында кайнап торган бүлмәдә ул бер ялгызы.

Дуслары да, таныш-белешләре дә күп иде Әхәтнең. Университетта бер чордарак укыган иптәшләре, курсташлары аерата онытмыйлар: бер генә көнгә Казанга юлыксалар да, мөһим бурычлары санап Әхәткә сәлам бирергә керәләр. Тышкы яктан дәртсез генә каршыласа да, Әхәт гаять ярдәмчел, йомыш-юлны җиренә җиткерүче вәгъдәчел тәгәл кеше...

Идрис исә бердәнбер якын дустын югалтты түгелме?

Ичмасам, янда Дилә юк, эч серләрен аңа сөйләп җиңеләеп булыр иде... Ә хәзер зуп-зур бүлмәдә ялгыз каргадай кагаеп утыр инде менә!

Көндезге уннарда Рәкыйп керде, Әхәт урынына утырып, өстәлдәге кәгазьләрне караштырды.

— Нәрсә бу? — диде ул кинәт.

— Кайда? — диде Идрис, үрелеп.

— Якын Көнчыгышка җибәрүләрен сорап гариза язган булган ич. Менә копиясе!

— Гариза илткән иде шул...

Редактор, бүлмәдән чыгып барганда гына, Идрискә борылды:

— Бүлекне алып барырсың, приказ язармын.

— Берәр кеше куйсагыз икән, Рәкыйп абый.

— Кеше... Табарга кирәк әле аны!

Редактор, эч пошуны арттырып, чыгып китте. Басарга материаллар керткәч, машинистка кыз да Идрискә сәер генә карады. Курьер хаты бөтенләй күрмәмешкә салышып узды... Бераздан, үзе хәтле папкасы кыстырып, Ниса Чәймилова керде. Иреннәренә сигарет ябышкан. Ул Идрис кырына ук килде, елмаеп аркасыннан какты.

— Эшләп утырышмы?

— Эссе! — диде Идрис, газета белән җилләнеп.— Чыдар әмәл юк.
— Тырышыбрак эшлә, бу көннәрдә үзеңне күрсәт. Мин дә синнән ярдәм кызганмам. Иң кызыклы, иң әйбәт хатлар синең бүлеккә керер. Менә «Сердәш»кә хат. Бер яшь укучы кыз «артистка булыр идем» дип хыяллана.
Аның хат өчен кермәгәнлеге көн кебек ачык иде. Хатны кулына алгач, Идриснең шиге бөтенләй расланды: бер атна элек килгән хат ич бу! Ул, колакларын торгызып, Ниса тагын ни әйтер икән дип көтә башлады.
— Бүлек мөдире итеп бөтенләйгә калдырабыз үзеңне.
Һич уйламаганда Идриснең көләсе килде, ул тыелып-тыелып торды да шаркылдап ук җибәрде.
— Нигә ярыласың, синнән дә кулай кеше юк!
Ниса авызыннан «кулай» сүзе чыгуга, Идриснең яңагы тартышты, ачуы кабарды.
— Әхәтне алыштырырлык кеше дип саныйсызмы мине?
— Синең кисеп ташлаган тырнагына да тормый иде ул нигилист!
— Аның сөякләре өстендә тормышымны корырга теләмим,— диде Идрис кыска гына.
Ниса чигенеп куйды.
— Кире! — диде ул сөйләшүнең файдасызлыгын аңлап.— Бик кире икәнсең!
— Алайса нигә мине мөдир итмәкче буласыз? Гомерем буе «ләббәйкә!» дип сыгылып-бөгелеп торсын өченме?
Ниса яшь кызның хыялларын сөякчел йодрыгына йомарлады да кәс-кәс чыгып китте.
Шушы бәрелешү Идриснең сызлаган күңеленә чак кына җиңеллек, җиңү тантанасы китергән кебек булды. Ул бүлмәне тутырып, күкрәкләре киңәйгәнче көлде:
— Кулай кеше кирәктеме?.. Учактан утлы күмер чүпләтергә чамалыйсыңмы?.. Абынырсың!
Шулай да күңелсез... Әхәт юк, җәйге ял якды. Диләә янына җибәрмәячәкләр... Тел әрәм итеп сорасы да юк... Студентлар җәйге ялга таралып бетмәсәләр, берәр тирәк егетне ярдәмгә утыртып куясы иде дә, Рәкыйп риза булмас...
Телефон шалтырады. Ул калтыранган куллары белән трубкага үрелде. «Әхәтне сорыйлардыр инде!»
— Идрис Булатович!
— Мин, мин! — диде Идрис, үзе икәнлеген расларга теләгәндәй каты кычкырып.— Тыңлыйм, Фаина Наумовна.
— Бездә үзгәрешләр булып алды... Шәһәр советыннан комиссия килде...
— Шулаймы?
— «Тын күл»не яңадан тикшерделәр... Скважинаны яңарттылар, кар базын чистарттылар, суыткыч таптылар... Мәж килдек! Бер сәгатьтән балаларны алып китәбез.
— Ә Жаденко?
— Аңа бераз эләкте... Балаларны «Тын күл»гә урнаштыргач, мин берничә көнгә кайтам. Ремонт бит, үзегез беләсез...
— Мәкаләгез ни хәлдә? Без аны планга кертеп куйдык.
— Бер нәрсә сызгалый башладым, вакыт җитми, Идрис Булатович... Вакыт табып кереп чыга алмассызмы?
— Кылны кырыкка ярабыз, Фаина Наумовна... Бер хезмәттәшне, дәресрәге, минем иң якын дустымны эштән китәргә мәҗбүр иттек...
— Ба-а, сездә шундый күңелсез хәлләр булгалыймыни?.. Уйламаган идем...
— Килеп чыга икән шул...

— Мин дә шул чамадарак сүз башларга уйлаган идем, Идрис Булатович... Булавинаны...

— Алло, алло!..

Шушы урында аларның сөйләшүен Үзәк станция өзде: Идрисны Сарманнан шалтыраталар икән. Сарман белән элемтә тәмамлангач, у Гринбергка шалтыратып карады, трубканы алмадылар. Әллә детсадтан шалтыратты ул, әллә башка җирдән. Кызганыч, Нина Михайловна турында нидер әйтергә теләгән иде шикелле. Китәргә бер сәгать калганда шалтыратуы тиккә булмас, әйтер мөһим сүзе булгандыр... Чынлап та, Булавина нигә югалды әле?.. Идрис аңа шалтыратырга да уйлаган иде, көндәлек ыгы-зыгы аны бөтереп алып кереп китте. Секретариатта макет карадылар, ике районга шалтыратты, корректуралар, юеш полосалар...

Кайтышлый телевидение тукталышында тагын Әхәт хәтергә төште: «Белмәмешләр, күрмәмешләр — заманыбызның иң куркыныч кешеләре... Понтий Пилатлар!»

Төшеп калып янына керәсе инде әллә?

Ни йөзең белән кердең дисә?.. Дөрес әйтәчәк, йөз ертып керергә ярамас, оят...

Үз яннарындагы кафеда ашагач, ул иплән кенә болын ягына китте. Күләгә якка чыкты. Борылышта Айдарның әти-әнисе белән очраштылар. Ул баш кагып узарга уйлаган иде, Ренат Кәрамов аны тотып алды:

— Вәгъдә ителгән мәкаләгез күренми бит!

— Мин вәгъдә биреп тә өлгердеммени?

— Әллә оныттыгыз?

— Айдарны озаттыгызмы?

— Сез минем улымны беләсезмени? — диде Луиза, бераз куркынып.

— Бер урамда яшибез ич.

— Озаттык, озаттык,— диде кыланып Луиза.— Җәлләп калдым вакытында ашаталармы аны, вакытында йоклаталармы...

Идрис тизрәк китәргә ашыкты, хушлаштылар.

— Сезнең Займищеда журналистлар дачасында бакчагыз юкмы? — дип сорады Луиза кинәт.

— Юк.

— Оттыргансыз! Шикарный урын! Без бер танышыбызга кунакка барып йөрибез. Тихоновны беләсезме?

Пашка Тихонов рус газетасында эшли иде.

Ни өчен дачаны белешә әле бу ханым?

Кешенең бәясен Луиза ханым да бик ансат билгели иде. Әгәр утызяшькә кадәр әйбәт квартирасы, дачасы, җиңел машинасы булса — бу кеше арыслан, прима, супермен! Әлбәттә, бу нәрсәләргә кандидатлык дәрәҗәсе яки атказанган титулы комачауламый, киресенчә, кешенең байлыгының гомерле һәм нигезле икәнлеген раслый.

Утызга хәтле шуларга ирешә алмаган ир — нуль. (Болар арасында иң элек аның ире Ренат керә!) Барын да белгән күк төрәлеп катып торучы бу журналист кисәге дә шундый ук сорттан икән! И ходаем, шул да ир булып, сакал асып йөри диген... Берәр бәхетсезе кияүгә чыккан булып шуны ялап ятадыр әле, бичара...

Әхәт китте...

Диләә өйдә юк...

Лида нишли икән? Әгәр адресын белсә... Хәер, фамилиясен дә белми ич Идрис Лиданың... Айдар «Тын күл»дә...

Әнә, сулда алачык... Ясап куйган сын кебек, җыелма урындыгында карт утыра. Аның янында ал аякларына башын салып Рекс ята... Шактый тернәкләнгән, күзләренә ялтыравык чыккан кап бүксәле ике көчек

икесе ике яктан, дус кына кыланып, сөт эчәләр. Картның өр-яңа чалбарына, ачык якалы ак күлмәгенә игътибар итте Идрис. Ул каядыр барамы, әллә кайтканмы, монда ашыгып кына, этләрне ашатырга гына килгәнгә охшый.

Сәламләштеләр. Картның кырыслыгына иялəшә башлаган Идрис беркөнге вакыйгалардан соң аннан ягымлырак мөгамәлә көткән иде. Ә ул Идриснең хәлен һич аңларга теләмичә дәшми дә, елмаймый да...

Шундый тын, кешесез, мазасыз иде монда...

Шәһәр шау-шуы килеп житми...

Миллионга якын кешене берләштергән, аларга уртак тормыш, уртак көн биргән Казан әнә ул... Болыннар яныннан башланып киткән тигез урамнар өстендә кичке нурлар уйный... Анда ыгы-зыгы, анда кеше язмышлары берсе-берсе белән чарпалышып, кисешеп, чәлмәшеп беткәннәр... Ә монда тын... Әнә алтын сары күк... Әнә кызгылт яфраклы тал куаклары... Әнә кош сайрый, чын кош! Картның эндәшмәве дә гажәп түгел, аларның икесен дә шушы илаһи тынлык, шушы болын, шушы сихри алачык, шушы ак муенлы көчекләр берләштерә... Мең, миллион еллар элек яшәгән борынгы бабалары шикелле, алар табигать балалары... Алар монда җирне-күкне, шушы гарип Рексны уртак итә алалар...

Син дә эндәшми тор, Идрис, син бит тегеннән, мең тәрәзәле таш пулатлар арасыннан, шау-шулы, ыгы-зыгылы урамнар дөньясыннан килдең. Юньлегә килдеңме син, әллә шушы тынлыкны юксынып кына мы?..

— Теге сипкелленең энисе килдеме? — диде ул бераздан.

— Юк,— диде карт, үн кулы белән Рексның муенын сыйпап.— Үзем эзләп бардым.

Әһә, бу карт тынлык белән канәгатьләнеп кенә яшәми икән, гаугасы эзләп, чуалчык эзләп үзе дә бара икән... Кем әйди аны? Үткәнеме, киләчәгеме? Кем ул?.. Читтән генә шаһит буласы иде: ничек сөйләштеләр икән?.. Ә теге сипкелләне дөньяга бүләк иткән хатын кем?

Кемнәр алар?..

Кешеләр нигездә бертуганнар, кан кардәшләр... Менә бу сүзсез карт та, сипкелләне Идрис янына мылтык тоттырып чыгарган хатын да аның ин-ин якын туганнары...

Тик нинди ләр алар?

Тормышка Айдарны әзерләп чыгарган Луиза да аның туганымы?..

Әйе, боларны белер өчен тынлыкка посып кына булмый, ялтыравык көпшәле салкын мылтыкны күтәреп кемнеңдер ишеген кагарга да кирәк: «Әй, сипкелле Чал синең улыңмы, ана?»

Әй, аналар! Куеннарыгызда кемнәрне үстерәсез?.. Фашистлар, палачлар, үтерүчеләр, талаучылар, көчләүчеләр дә ана күкрәген имәләр бит... Сезнең күкрәкләрне... Сак булыгыз, аналар!..

— Бу араларда Нина Михайловна күренми.

— Ул сиңа шалтыратмадымы?

— Кайда соң ул?

— Белмәмешкә салынасыңмы?

— Ничек?

«Белмәмеш» сүзе аңа корт чаккан кебек тәэсирле булды. Гринбергның ярты юлда өзелеп калган сүзе искә төште.

— Больницада Нина.

— Кайсы больницада?

— Унбишенчедә.

— Ничек алай?..

Көчекләр, сөтне ашап бетереп, карт тирәсендә әүмәкләшә дә башладылар.

— Дөньяда бер нәрсә дә кинәт тумый... Күзәтергә сәләтсез яки ялкау акыллы кешеләр генә тәге яки бу күренешне кинәтлек белән аңлаталар. Бер дә кинәт түгел. Кешенең яшәеше кайгы һәм шатлыкны күңеленә җыюдан гыйбарәт... Бер заман үлчәү табасының бер ягы баса... Чирләде Нина... Былтыр дүрт яшьлек улын, ирен күмде...

— Менә ничек икән...

— Автомобильдә... Җыен белер-белмәсне утырталар да... Берәүләргә һәлакәт, икенчеләргә хәсрәт... Быел дача өчен күпме йөрәк мае сарыф итте... Бер дә кинәт түгел... Түгел!..

## 20

Идрис, троллейбустан трамвайга күчеп, бер сәгать дигәндә шәһәрнең икенче читенә, Совет районына, Казанка елгасы буена урнашкан дүрт катлы яңа больницага барып житте. Кышкы бураннарда яңа больницаның палаталарында чыдамаслык суык дип, авырулардан хат килгәч, монда булганы бар иде. Кар көртләре арасында утырган бинаның палаталары чыннан да салкын иде, бу турыда газетага да яздылар, чара күрелдеме, белмим, ул арада яз житте...

Хәзер ничек икән?

Шушында, палаталарның берсендә, Нина Михайловна ята. Ни булды?

Вестибюльдә Жаденконы күреп баш какты, коры гына күрештеләр.

— Берәр кешегез авырыймы әллә? — диде Виталий Петрович инде таныш тавышы белән.

— Нина Михайловна Булавина,— диде кадап Идрис.

Жаденко хушлашмыйча да чыгып китте.

Вестибюльнең уң ягында, аралык артындагы нәни бүлмәчектә чак сыеп юантык сестра утыра. Ул чәчәкләнгән почмаклы, таушалган дәфтәрен актарып, кемнең кайсы палатада булуын ачыклый, чиратта торучылар белән кычкырып-кычкырып сөйләшә.

— Кем? Булавина? — диде ул, Идриснең чираты житкәч.— Врачтан рөхсәтегез бармы?

— Мин рәсми йомыш белән. Фамилиям Бакиров.

— Рөхсәтсез ярамый. Рәсми кешеләр ятмый биредә, монда авырулар!

Ул кемгәдер шалтыратып сорады, аннан соң гына кечкенә талон сузды:

— Икенче кат. Йөз дә жиденче палата. Менгәч тә сулга.

Редакциядән дигәч, икенче каттагы кизү сестра ягымлырак каршылады:

— Холлга керә торыгыз, хәзер чакырам,— диде ул.

Икенче кат холлында зур кисмәкләрдә пальмалар, фикуслар, чәчәксез чәй розалары утыра. Озакламый тычкан тиресе төсле, аяк йөзенә житкән озын халатка уранып Булавина килеп керде. Агарынган яңаклары, тагын да каралып күренгән чәчләре аны үтә чибәрләткән иде.

— Сез икәнсез,— диде ул, шатланып.— Көтмәгән идем.

— Саулармысыз, Нина Михайловна. Моңарчы ишетми йөрдем. Бүген очраклы гына кайнатагызны күрдем, ул әйтте...

— Һинд сариена төренгән юк иде,— диде Нина Михайловна, халат итәген тарткалап,— аңа да ирештек. Әткәй ни хәлдә?

— Әйбәт күренде. Үзегездә ни куанычлар?

— Әлегә билгесез... Анализлар тәмамланмаган... Нейрохирургия бүлегенә алып килгәч бик пошынган идем, хәзер азрак аңга килдем бугай. Врачлар бик карыйлар, юаталар... Югыйсә бик яманатлы бүлек. Эш иткәнегез юк идеме?

— Бәхеткә каршы димме?.. —

— Сөенегез. Баш, арка миләре зарарланган бәхетсезләр ята.

— Анысын беләм...

Нина Михайловнаның йөзеннән куләгә сирпелеп үтте.

— Сез хәзер генә Виталий Петровичны очратмадыгызмы?

— Очраштык. Сәлам да алыштык.

— Гаризамны кире алырга үгетләп килгән,— диде көрсенеп Булавина.

— Нинди гариза ул?

— Сез белмисез дә бит әле... Мин китәргә гариза бирдем.

— Нигә алай?

— Бу эшемнән китәрмен дип һич уема китергәнем юк иде, Идрис... Әйбәт кешеләр арасында уралдым, эше дә, урыны да таныш, дигәндәй. Районга кергән предприятиеләрдә дә холкымны беләләр, ике сөйләшеп тормый идем...

— Бәс, шулай булгач!..— дип күтәреп алды Идрис.— Тотарга да гаризаны кире алырга кирәк.

— Сез дә шул киңәшне бирәсезме? — диде уйчанланып Булавина.

Идрис, Әхәт белән булып узганнарны хәтерләп, тырышып-тырышып Нина Михайловнаны үгетләргә кереште, үз дәлилләре белән үзе мавыгып Булавинаның яралы күңелен рәнҗетүен сизми дә калды.

Нина Михайловна «Тын күл»дә очрашканнан соң Идрисне ошатып калды. Көннәрнең берендә ул Булавинага Айдарның тарихын сөйләде. Ят бер ирнең нәни чит малайга шундый якын, эчкерсез дуслыгы хатынның йөрәгенә уелып калды. «Тын күл» дәгъвасы олыга киткәч, ул сер сыя торган дусларыннан беренчесе итеп Идрисне хәтеренә төшерде. Аз-маз хәл алгач аңа шалтыратып киңәш-табыш итәргә дә уйлап куйган иде. Көтелмәгәндә Идрис үзе килеп керде һәм алдын-артын сорашасы урынга, гаризасын кире алырга капыл-копыл үгетләп утыра...

Әхәт белән булган мажараларны белмәгәнгә, Нина Михайловна Идриснең киңәтлеген аңламады, бу ашыгуны кичермәде.

— Сез бик өстән-өстән генә фикерлисез... Ни булганын белмисез дә ич,— диде ул, халатына тагын да ныграк төренеп.

— Сорашырга уңайсызланып утырам...

— Комиссия килүен беләсездер? — Идрис ым какты.— Шул. «Тын күл» вакыйгасы зураеп китте.

— «Давыллы күл»гә әйләндеме?

Булавина сизелерлек елмайды.

— Алай дисәң дә була... Райбашкарма утырышына куйдылар да райздрав мөдиренә һәм Виталий Петровичка шелтә бирделәр. Мине хуплап, «шул юнәлештә контрольне көчәйтергә» дип карар чыгардылар.

— Әйбәт карарга килгәннәр ич!

— Анысы шулай,— диде әрнеп Булавина.— Тик тора-бара таякның юан башы минем җилкәдә бии башлады!.. Бәла үземә әйләнеп кайтты. Миңа үчегергә тотындылар.

— Кемнәр?

— Былтыр еш кына авыргаладым мин... Кыен чаклар була бит, әйеме? Хәзер шуларны казып чыгардылар... «Еш чирли... Гел больничныйда... Характеры авыр...» Китте сүз, китте гайбәт! Үзең турында аркылы-торкылы гайбәт таралса, йөрәк әрни... Аннары, ирсез хатынны яралаудан да җиңел нәрсә юк... Болай да, җәрәхәтле киек кебек, чак атлыйсың... Сине тешлесе-тешсезе чәйнәкләргә тотына!.. Күп чүп-чарны ишеттерделәр...

— Ә яклаучылар? Үзегез искә алган «ару кешеләр?»

— Башым тинтерәгәч, киттем шәһәр эпидстанциясенә... Баш врач Дударевны ишеткәнсездер инде... Райбашкарма белән «Тын күл» өчен конфликтка кергәч, гел мине яклап килде, акыллы абзый... Беләсезме шул кеше миңа ни диде?

Хатынның тавышы калтырады, керфекләре дерелдәп китте.

— Нина Михайловна, бәлки сөйләшүне кичектереп торырбыз?

— Тыңлагыз сез, тыңлагыз!.. «Сезнең райбашкармадан шалтыраттылар... Вакчылланып ялган принципларның колына әйләнгәнсез!» ди бу. Ничек аңларга бу сүзләрегезне димен... «Тарихта Булавиннар булган инде, алар заманы узган, баш күтәреп, буталыш тудыруның хаҗәте юк... Мөгаен, сезгә ул эштән һәм ул районнан китү кирәктер», диде... Гариза язарга да ул киңәш итте.

Идрис бик уңайсыз хәлдә калды. Бая беркатлыланып, кызып-кызып үгетләп утыруы өчен ул читенсенеп гафу үтенде.

— Менә кая таба бара икән эшләр!..

— Гаризамны тотып Мохов янына кердем. Башка чакларда аның фикер йөртү сәләтенә соклана идем... Ул булып ул да... «Юк нәрсә өчен безнең райбашкарманың яманатын чыгардыгыз», диде... Шунда аның кабинетында башым сызларга тотынды...

Баягы медсестра керде.

— Булавина, процедура вакыты җитте.

— Хәзер...

Медсестра чыгып китүгә, Булавина җавап көтеп Идрискә текәлде. Аның уйланып торуын абайлап:

— Шикаять итеп сөйләмәдем,— дип өстәде.— Тик шунысы кыен... Күзне күтәреп карыйсы килми, бил бөгелә, баш иелә... Офык үз аяк очыңнан гына уза... дөнья тарая...

Икесе дә берьюлы урыннарыннан тордылар.

— Нина Михайловна,— диде Идрис, коридорга чыккач.— Башта эмоцияләргә бирелеп алдандым... Үземнең дә соңгы вакытларда кәефнең ызанга кергәне юк... Мин ыклап уйлармын, иптәшләр белән киңәшермен... Ләкин үтенеп сорыйм — китәргә ашыкмагыз! Кыскасы, булдыра алган хәтле тынычланып дәваланыгыз...

Булавина берсүз дә әйтмичә генә аңа кулын сузды.

— Шушы көннәрдә генә кичермәслек хата ясадым, Нина Михайловна!.. Инде бу юлы сезне бирмәбез дип уйлыйм!

Ул тагын килергә вәгъдә куеп чыгып китте. Ишек алдында колонналар күләгәсендә тәмәке тартып торучы Җаденконы күргәч, ул бер дә гаҗәпләнмәде.

— Сезне көтәм,— диде Виталий Петрович, папиросын җиргә сытып.— Әйдәгез, машина белән кайтыйк.

Кереп утырыштылар, көяз шофер да Идрисне хәтерли икән, беретын күтәреп һәм нигәдер каш сикертеп аны сәламләде.

— Нина Михайловнаның китүенә ничек карыйсыз? — диде Идрис, турыдан-туры.

— Шуны юллап йөрисездер дигән идем...

— Юк, бүген генә ишеттем, хәзер генә...

— Бәйдә тотарга киңәш итәсезме?

— Эпидстанция кебек җаваплы бер участогыгызда шундый таләпчән, белемле кеше утырганда, сезгә, район хуҗаларына, чат файда гына түгелме? Ул өлкәдә сез тып-тыныч...

— Бармак башы хәтле факттан политика ясарга уйлыйсызмы? — диде Җаденко, эре генә.

— Мин әлегә берни дә әйтмәдем.

— Райбашкарма «Тын күл»гә чамасыз көч салды.

— Беләм.

— Республикада андый дача юк.

— Анысына да риза.
— Балта чапканда йомычкалар очмыймыни?.. Шуларны белә торып райбашкарманы тәнкыйтьләргә кем батырчылык итә ала?
— Ә-ә,— диде Идрис, башын чайкап.— Хәтәр сез...
Жаденко йөзе белән аңа борылды:
— Инструкциянең һәр хәрефенә ябышып ятарга без формалистлар түгел, иптәш Бакиров.
— Әгәр эш файдасына инструкция хәрефенә ябышып яту формализм дип бәяләнә икән, мин — формалист. Әйбәт башланган эш, начар тәмамланса, мин — формалист... Кешене гаделлеге, беркем алдында каушап җебеп төшмичә хаклыкны яклаганы өчен җәзалыйлар икән, мин — формалист.
— Нинди җәза? Кем уйлап чыгарган әле анысын?
— Яраткан эшеннән китәргә мәҗбүр итү җәза түгел инде?
Идрис кызарга ярамаганлыгын белә иде, үз фикерләрен ачып саларга тиеш түгеллеген дә чамалады, әмма тыела алмады.
Урамнарда берән-сәрән генә утлар кабыздылар. Кольцога җиткәч, ул машинадан төшеп калды.
— Газетага язардан элек бер күрешәсе иде,— диде Жаденко.
— Мөмкин... Сездә безнең телефон бармы?
Нина Михайловна Жаденко кергәч бөтенләй сөйләшеп тормады, китергән бүләкләрен дә алмады. Газетадан килгән егет белән аның шулай озаклап гәп сугуы Виталий Петровичка бик шикле тоелган иде, шиге расланды, бу егет чүп өстенә чүмәлә өяргә йөри икән.
Шелтәгә таҗ итеп аны газетага да бастырып чыгарачаклар. Хәерле булсын! Идарә аппаратында, хуҗалык сферасында шөгыльләнүчеләрне журналистлар тешләргә яраталар, эшләмәгән кешегә генә җил-янгыр тими.
Болай булып чыгар дип уйламаган иде Виталий Петрович... Һич! Ул Булавинаның хаклы икәнлеген беренче көнне үк аңлады... Әмма өр-яңа дачаны ремонтларга ничек тотынасың?.. Комиссия членнары актка кул куйгач, «Тын күл»дәге вак-төякләрне үз җайлары белән көйләрләр дип ышанды... Нина Михайловнаны үз кеше санап аның белән исәпләшмәде.
Әйе, әйе, үз кеше санап!
Нина Михайловнаны яратып йөргәнгә, аның үзенеке булачагына ышангангa, Виталий Петрович аңа дәүләт кешесе итеп түгел, гап-гади врач итеп карады, дәгъваларын көлемсерәп тыңлады, эх!.. Булавина боларны сизенмәгәндер дисенме?..
Сизенгәндер, югыйсә шушы хәтле ятсынып каршыламас иде. Бәгырьдә каткан икән...
Аның уйларын бүлеп, шофер:
— Кая барабыз? — дип сорады.
Шофер йөз очрактан туксан тугызында Жаденконың кая барасын белеп тора, бер очракта гына аптырап кала, бүген исә әнә шундый болгавыр, аңлашылмаган көннәрнең берсе иде.
— Өйгә,— диде Жаденко.
Квартирасына кайтып ишек ачканда ук ул телефон шалтыравын ишетте. Ишек катында туфлясын салды, башмагын киде, «мин өйдә юк, әйдә, туктар» дип уйлады. Бүлмәсенә керде, телефон өзмәс бимазалап торгач, ачу белән трубкага үрелде.
— Я, я... Тыңлыйм!
Аның чырае кинәт үзгәрде, кулындагы журналы идәнгә шуды. Райбашкарма председателе Мохов шалтырата икән.
— Виталий Петрович, хәзер генә хәбәр иттеләр: Казанга Германия Демократик Республикасыннан туристлар килә. Шулардан яшь бер архитекторны безнең районга беркетәләр. Аны каршы алырга,

кунак итәргә һәм озатырга кирәк. Алынырсың бит? Мин анда си тәкъдим иттем. Телең үткен, шәһәрне бишбармагың күк беләсең...

— Тел ягы гына...

— Тәрҗемәче бирәләр... Элекке кебек булыр. Килештек алайса?

— Каршыларбыз.

Телефоннан житди хәбәр турында сөйләшсәләр дә, аның күңелеі нән «Тын күл», Нина Михайловна, больницада аның чәчәкләрен кир этәргән озынча ябык кулы китмәде... Соңыннан да ул аның турынд гына уйлады.

Телевизордан футбол ярышы тапшыралар иде. Аның яратка командасы Киев «Динамо»сы уйный. Диванда ятып карый башлад да, күңеле борсаланып, аны да өзде.

Телефон кенәгәсен актарып унбишенче больницаның икенче кат нс мерын эзләп тапты, кабаланып шалтыратты:

— Зинһар... Булавинаны... Йөз дә жиденче палата... Бик үтене сорыйм...

Булавина йоклый дип җавап бирделәр...

## 21

Егерменче гасыр кешеләренең характерларында уртаклык бар алар барысы да ашыгалар. Өйдә аш янында кабаланалар, урамд транспортка тизрәк эләгергә чабалар, инде утыргач та тынмыйлар — зарланалар: «Нигә шулай акрын кыймылдый бу троллейбус!» «Трам вае ташбака белән ярышка чыккан!»

Эш беткән сәгатьләрдә үзәк урамнарда кыямәт... Ата улны, ан кызны белмичә чабышалар. Шимбә-якшәмбе көннәрдә базарларда вокзалларда, кино-театр алларында, кибет яннарында ерып чыккысы ботка быгырдый...

Идрис арып-талып кайтып егыла да йокыга китәр алдыннан «Болай ярамый, болай булмый, иртәгәдән бу шашкын ритмнан ычкы нам, кабаланмыйча, салмак кына яши башлыйм», дип уйлап куя...

Иртәгә тагын шул ук хәл...

Кырынганда ук ашыга. Бритвасын тоташтырырдан элек кухняд таба белән я күкәй куырырга куя, я бәрәңге кыздыра. Инде бритв гөжли башлагач күзе сервант өстендәге көзгегә төшә. Көзге янынд ук кара стрелкалары белән кисәтеп сәгать тора. «Газны көчәйтерг кирәк, тизрәк кызсын бәри-шәри!».. Йөгереп кухняга барып килә. Инде иплән кырыныйм дисә, ишектә звонок. Коридор җыештыручы карчыкка алтмыш тиен акча кирәк. Ул бөтен кесәләрен бетереп ва тәнкәләр эзли. Чөнки җыештыручы карчык бер сум бирсәң дә зарлан мый, өч тәнкә эләксә дә кайтарып тормый... Аннан котылып эшк тотынганда гына дуылдап чәйнек кайнап чыга... Чәй пешерергә. Бәрәңгегә суган турап салырга... Ботинка бавы өзелгән... Балко ишеге калшайган, ябылмый...

Укылмаган газета-журналлар Урал тавы хәтле өелгәннәр...

Ашап-эчеп, савыт-сабаны юып ишектән чыкканда ул бугаз өсте капшап карый: кытыршы!.. Яңак асларында да уйдык-уйдык кыск төкләр тырпаешып калган, тагын ашыгылган...

Шуннан башлана... Китә... Кыза... Сабырлык вәгъдәләре төте булып күккә очалар, тараладар...

Редакциядә дә бүлектә бер үзе. Әхәт киткәннән соң шактый еге ләр урын белешеп карасалар да, Рәкыйп аларны бер сүздән кир борды. Арада шактый еллар редакция белән даими элемтәдә торга өметле генә язышучылар да бар иде юкса.

Үзгәрде Рәкыйп. Идрис белән элекке кебек озын-озаклап сөйләшм

хәзер. Редактор гынамы?.. Башка хезмәттәшләр дә Идрискә мөнәсәбәтләрен үзгәрттеләр.
Әхәт үзе исә суга төшкән таш булды: бер тапкыр да шалтыратып карамады ичмасам! Бер көн телевизион тапшырулар вакытында исеме ишетелеп калды, «тапшыруның редакторы Әхәт Нуруллин» диделәр.
Югалмас ул малай...
Эшен дә табар, урнашыр, ерып та чыгар.
Тик кайчанга кадәр? Күпмегә житәр аның санаусыз егәре?.. Әгәр Ниса сыңары ишеләр аның юлына тагын аркылы ятсалар?.. Куян бар куаклыкта төлке була, диләрме?..
Ниса әйләнәсендә Идристәйләр табылмасмы?..
Күпмегә житәр аның көче?
Әнә ич, мисалга ерак жирләр гизәсе түгел. Нина Михайловна аяз көндә тәгәрәп егылган...
Бәлки Әхәт шуна өйләнмидер дә?.. Үзенең бер көнне, бәйгеләрдә чапкан ат кебек, тормаслыкка гөрселдәп егыласын сизенәдер?!.
Идриснең үзендә дә бер үзгәреш шәйләнде: газетада басылган материалларына исемен куймый башлады, гел псевдоним белән чыгарды. Моны барысы да күрделәр, дәшмәделәр.
Телефон шалтыратуга ул дерт итеп китә һәм йортлар, урамнар, жирләр аша узган чыбыкның теге башында Әхәт булуын тели иде.
Бүген дә шулай булды, яшертен өмет белән тәне кызышып трубкага сузылды:
— Тыңлыйм...
Шалтыратучы Лида иде.
Идриснең бердән тавышы үзгәрде, кыз моны сизде.
— Авырып торасызмы әллә, Идрис абый? — дип сорады.
Бу стандарт сорауны ишетү ана тагын кирегә тәэсир итте. Чынчынлап, хәлгә кереп сорамый ич инде, юри-марый маташтыра кызый актыгы, ана үз кайгысын кайгыртырга, үз йомышын үтәргә генә Идриснең сау булуы кирәк!
— Мин монда сездән якында гына,— дип гөрелдәде кыз.— Рөхсәт итсәгез, сезнең янга кереп чыгар идем.
«Кермәгез» дип өзеп әйтергә бик теләде Идрис, әлеге дә баягы авыр акылы гаепле, жайлы сәбәп табып өлгермәде:
— Кер, кер, Лида,— диде, ярым тотлыгып.
Күңеленнән исә «башлана!» дип сукранды. «Тагын Әхәт турында допросларга керә!.. Җәзалау минутлары житә!»
Ни әйтсен дә, ничек юатсын ул кызны?..
Лиданың өстендә билсез теккән үтә кыска мини-күлмәк. Кофе төсендә. Алгы яктан шактый түбәнгә, бот ерыгына кадәр «яшен» төшкән. Чәчләрен ике якка аерып тараткан. Зур күзләрендә — үз матурлыгына үзе соклану. Томырылып тора. Бер дә Әхәт өчен борчылып кергәнгә охшамаган...
Идриснең шиген арттырып борынга тәмле, кыйммәтле хушбуй исе килеп житте. Ясмин чәчәк аткандагы кебек...
Ай-һай чибәр бу дип уйлады көтмәгәндә Идрис. Күркәм, бөтен яшь-жилбезәкне жәлеп итәрлек сылу хатын булачак. Холкы-фигыле дә күнелгә ятышлы, йомшак. Усаллык дигәннең заты да сизелми...
Яшьтән үк үзен ямьсез дә, булдыксыз да дип хисаплаганга, Идрис матурлыгы чәчрәп торган кызлардан ерактарак чуалды. Матур кызлар аны каушаталар, шәхес буларак түбәнсетәләр иде. Менә хәзер дә, чит-ят булса да, Лида аны малайлар кебек кызарта төсле...
Бер заман телләре чишелеп киткән мизгелдә, алар Әхәт белән хатын-кыз матурлыгы турында бәхәскә керделәр. «Сылу хатын-кызны очратканда мин аларның үзләреннән битәр, алар янәшәсендәге ирләтларны күзәтергә яратам... Шундый күркәм ханымны гомерлек яр

итәрлек булгач, үз рухының көченә ышанган бик батыр кеше инде ул!.. Болын уртасындагы матур чәчкә кебек бөтен кешенең күз явын алып, кызыктырып-ымсындырып торган кызга өйләнү — киләчәк тормышында ир буларак үз өстенә гаять зур җаваплылык алу лабасы!» диган иде ул.

Дөрес, Идриснең шушы фикерләрен ишетеп Әхәт кычкырып көлде:

— Син нәрсә? Фрейдизм сиңа да йоктымы?.. Хәлең мөшкел, дускай... Психоаналитик казынулар белән җаныңны интектерә башласаң, урта матур белән гомер итүең дә җәһәннәмгә әйләнер, сноб! Вот еще мне комплекс неполноценности!..

Идриснең сәбәпсез кызаруын күргәч, Лида шундук житдиләнде, күзләренә уйчан моңсулык чыкты, ашыгып-ашыгып:

— Мин азга гына кердем, Идрис абый,— диде.

— Алай да ярый,— диде Идрис, алдында яткан кәгазьләргә күз төшереп,— минем мәшәкатьле, болгавыр көннәрем.

— Минем сезгә бер сүзем бар иде,— дип башлады кыз кыюсыз гына. Аның озын керфекләре идәнгә кадалдылар.

— Сөйләгез соң,— диде Идрис коры, ят тавыш белән.

— Монда уңайсыз...

— Кемнән?

— Үземә уңайсыз... Монда редакция, дәүләт оешмасы... Ә мин үзем турында сөйләмәкче булам!

Идрис аптырап як-ягына каранды.

— Әгәр болай итсәк,— диде кыз, кыюланып,— Эштән соң мин сезне көтеп торырмын. Берәр бакчага кереп утырырбыз.

Идрис башта ык-мык килебрәк торса да, ризалашты, кыз белән Ленин бакчасында очрашырга сүз куештылар.

Лида ишекне сак кына ябып, ишетелер-ишетелмәс адымнар белән чыгып киткәч, Идрис, аптырый төшеп, диванга барып утырды.

Нәрсә булды әле?.. Нигә аны Лида чакырды?.. Нигә ул барам диде?.. Әллә шул ук урынга, шул сәгатькә Әхәтне дә чакырмакчымы? Очраштырып аларны татулаштырырга уйлыймы?.. Башкача алар арасында нинди уртак сер булырга мөмкин?.. Киңәш ди икән, киңәшне Лида башка төплерәк кешеләрдән дә ала алыр иде...

Чаянчылар шалтыратты:

— Су керергә барабызмы?

Идрис, алар белән алдан вәгъдәләшкән булса да, баш тартты:

— Үзегез генә атлагыз инде, Кәрим малай, саесканның койрыгы сумалада...

Бар ихтыярын җыеп мәкаләсен язып бетерде, секретарьга кертеп бирде. Эшен тапшыргач тынычланды, салкын акыл белән Әхәт, Лида турында уйлады. Диләне сагынып хәтеренә төшерде...

Нигә чакырды әле аны бу кызый?.. Тукта, ни дөресе — Әхәткә шалтыратып, аның белән киңәшеп карарга кирәк. Өзелгән араны ялгарга күпер дә шул булыр, шуннан аңышып китәрләр. Баш ярылып, күз чыкмаган ич, килешмәс кешеләр түгел!

Әхәт эш урынында юк иде. «Хәзер керер, кем сорый?» диделәр. Беренче кызулык үткәч, ул Әхәтнең туры килмәвенә куанды. «Картлач, монда имезлек кибете түгел, ялгыш шалтыратасың!» дип җибәрсә, нишләрсең?.. Әлек шулай булгалады бит!

Эше бетсә дә, ул таралып, оеп утыра бирде, бүлмәгә Рәкыйп керде.

— Китмәгәнсең икән...

— Кузгалып маташам.

— Ял сорап гариза биргән идең.

— Янамы, Рәкыйп абый?

— Читенрәк булса да кичектерергә туры килер, түз.

— Бу... жәзамы? — диде ул, редакторга төбәп карап.
— Логика,— диде кулындагы ачкычлары белән уйнап Рәкыйп.
Идрис нәүмизләнүен яшерүне кирәк санамады:
— Нигә берәр кеше алмыйбыз соң, Рәкыйп абый? — диде ул, ачынып.
— Кемне? — Редактор аңа сынап карап торды.— Әйтеп кара... Килгән хатларны әвеш-түеш китереп утыручылар үзебездә дә бар, шөкер!.. Яшьләрне ияртерлек, ышандырырлык, үзбаш сүз әйтерлек, аларның рухына тәэсир итәрлек көчкә ия төпле егетең бармы?
Әһә, менә нинди сыйфатлары өчен ярата икән шеф Әхәтне! Рәкыйп сүз белән әйтмәсә дә: «Аны алыштырырлык кешең бармы?» дип сорады да куйды.
Әхәтнең житешсезлекләрен алар икесе дә тигез беләләр, әмма бүген сүз ул турыда бармый. Егетнең асыл сыйфатлары өстенлек алды. Идрис тә, Рәкыйп тә аның турында бары яхшыны гына уйлады-лар. Тик Әхәтне алыштырырлык егетне Идрис белми иде.
Матбугат йортыннан бергәләп чыктылар, корырак кына саубуллаштылар. Рәкыйп Идристән канәгать түгел иде, күренеп тора. Ни өчен?
Кушылган эшен — детсад мәсьәләсен жентекләп тикшерде Идрис, ата-аналарга хат язды. Гринберг бала тәрбиясе турында мәкалә әзерләп ята. Булавинаның язмышын ике-өч тапкыр кереп «Социалистик Татарстан» егетләре белән ныклап сөйләште. Аларның авторитет та зуррак, колач та киң, шәһәр эпидстанциясенең баш врачы Дударевны, Жаденконы, хәтта Моховның үзен дә бераз кыйшырга кирәк, «тәнкыйть кирәкле шәйдер» дигән Тукай бабаң... Яшьләр газетасында бу мәсьәләне күтәреп чыгарга читенсенде Идрис, бу турыда Рәкыйпкә дә әйтеп тормады. Бар гаебе шул гына... Шуны ишетеп шефның кәефе кыйгайдымы?.. Булмас, Рәкыйп тар күңелле кеше түгел...
Әй, барына төкереп, Иделгә су коенырга китәргәме әллә?
Шул чагында аның хәтеренә Лида килеп төште, ул, кырт борылып, ашыга-ашыга Ленин бакчасына юнәлде.
Кыз бәләкәй фонтан янындагы эскәмиядә утырып китап караштыра иде, Идрисне күргәч күтәрелеп кул болгады, әдәп белән генә елмайды.
— Идрис абый,— диде ул, иркәләп,— иплә дә кеше инде сез!
— Сонгарак калынды, кичер.
— Зарар юк, зарар юк... Ашыгыч эш түгел, һава әйбәт, көн матур... Кичкә кадәр әле... Менә дельфиннар турында укыйм. Сез алар турында күзәтәсезме?
— Туры килгәнен караштырам.
— Ә мин, Идрис абый, дельфиннар турында ни очраса шуларны жыеп барам... Моннан ары дельфиннар турында яңалык ишетсәгез, минс хәтерегезгә алыгыз. Сез немец матбугатын калдырмый укып бара диләр...
— Кая инде,— дип көлде Идрис, кыз янына утырып.
Лида өенә кайтып килгән, аның өстендә жыйнаграк та, арзанлырак та күлмәк, чәчләре дә көндезге кебек күпереп тормыйлар. Ике егет былагайланып, күзләрен тасрайтып алар яныннан узды, тик Лида аларның чәнечкеле карашларын бөтенләй сизмәгәнгә салышты.
— Кузгалдыкмы, Идрис абый?
— Без сәяхәткә барабызмыни әле?
— Аулаграк урынга барырбызмы әллә дигән идем.
Лида, юл күрсәткән кебек, алгарак чыкты һәм кеше күрмәгәндә генә түтәлдән бер чәчәк өзеп алды. Аның аяк атлавында, чәчәк иснәвендә, бөтен хәрәкәтләрендә наз, иркәлек һәм назакәт тулышып тора, сүзендә, кыяфәтендә бернинди ясалмалык, кылану юк. Идрис, аның стихиясенә шик-шөбһәсез буйсынып, жиңел генә ияреп китте. Лида белән бакча сукмагыннан атлау гажәп хозур иде. «Дөнья бәясе

АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ ◆ УРАМНАР АРТЫНДА ЯШЕЛ БОЛЫН ◆

торырлык кыздан баш тартып йөри!» дип күнеленнән генә ул Әхәтне әрләп алды. Лиданың Тәүфыйк белән булган кыҗыр-быҗырлары искә төште дә онытылды.

— Нәрсә, Лида?

— Сезгә күнелсезме, Идрис абый?

— Киресенчә.

— Миңа да бик рәхәт. Сезнең янда җан ял итә, тыныч.

Нидер сөйләргә, аулак бушлыкны тутырырга кирәк иде. Идриснең Әхәт турында сүз кузгатасы килмәде, ул бик ерактан чалдырып алып китте...

## 22

— Авылда, өченче классны тәмамлагач, Магниткадан бер малай кайтты.

— Үзе генәме? — дип кызыксынды шундук Лида.

— Юк, әти-әниләре белән. Хәтәр малай, әкәмәт. Беләкләрендә шәрә кызлар, очлы ук тишеп үткән зәңгәр йөрәкләр... Кесәсеннән тәмәке өзелми... Кунакка дип кенә кайткаңнар иде, торып ук калдылар. Бөтенләйгә. Әтисе шофер иде монын, әнисе җөйче, тегү тегә. Безнең күршедәрәк буш кураны сатып алдылар, башта ятсынышып торсак та, урамдаш һәм күрше булгач, малай белән бик тиз дуслаштык. Русча да, немецча да теттерә генә бу. Магниткада немец малайлары белән уйнаган. Татарчасы гына такы-токырак. Әнисе мине чакырып кертте дә конфет белән сыйлады. Беренче тапкыр шоколадны шунда авыз иттем. «Бергә-бергә, тату гына уйнагыз, наныем, татарча өйрәнсен, укырына әллә кая илтеп йөрмәбез, көзгә тикле телне берүк белсен иде», диде. Көндез аерылмыйбыз, анысын әйткән дә юк, төнлә дә сарай түбәсендә печәнлектә бергә йоклыйбыз.

Телне өйрәнүе ни дәрәҗәдә булгандыр, хәтеремдә калмаган, мин үзем немецчаны да, русчаны да хәтәр генә сукалый башладым. Иң әвәл бик шәплән төрле телләрдә сүгенергә өйрәндем.

Бирелеп тынлап барган Лида рәхәтләнеп көлде.

— Мәктәпкә бер класска килдек. Дуслар идек, малай — баш бармак! Чиллә суыкта да түштәге бөркетне ачып йөри!.. Бер кыш укыдык, гел бергә йөрдек... Икенче көзгә тагын да шәбәеп килдек. Берәүгә дә махы бирмибез, русчалатып, немецчалатып шәп кенә сүгенеп тә йөрибез. Дан китте безнең. Малайлар курка башладылар, тегс иптәшем сугышырга бик яман. Тәбәнәк кенә нәрсә, астан баш белән дык итеп корсак өстенә генә бәрә бу, алыптай егетләр тынсыз тәкмәрлиләр... Минем яна һөнәрләр энигә дә ишетелде. Чоланга алып кереп каеш чөелдерек белән нык кына пешерде. Кая ул, утырып бер еладым да тагын шул малай белән кәпәренеп йөрим. Директор Якуб абый иде, Нанкиев. Әйбәт кеше!.. Хәзер Диләләр авылында укыта... Бер көнне укытучы Зәйнәп апа миңа язу кертеп тоттырды. Курка-шүрли генә алдым да ачып укыдым. Якуб абый язып җибәргән. «Бүген дәресләр беткәч, көндезге сәгать икедә директор кабинетына кер». Язуны иптәш малай белән укыйбыз инде. «Йөрмә дә, кермә дә»,— дип үгетли бу. Бик йөрмәс идем, директордан да куркам, әнидән дә. Телгә йомшак булса да, кулы шактый саллы әнинең... Укытучы Зәйнәп апа икеләнүемне сизде. «Кушкан җиргә бар»,— дип кисәтте бу. Куркуым тагын да арта төште.

Өйгә кайттым. Башым чатный дигән булып чоланга кереп яттым. Ятам да торам, чыгам да сәгатькә карыйм. Ике тула дигәндә борынны мышкылдатып директор янына киттем. Кабинетында бер үзе утыра бу. Коридорда да бер җан юк. «Килденме?» — диде. Усак яфрагы күк

лептердәп, ишек катында торам. Якуб абый шкафын ачты, нидер эзләнде, яшертен генә кесәсенә нидер тыкты, шкафны бикләде, форточканы япты. Эшләпәсен басып киде. Каршыма килеп басты. «Миннән калма. Як-ягыңа каранма. Кая баруны сорашма. Кеше-кара очраса, дәшмә. Тының чыкмасын!» диде бу. Эчкә тәмам курку төште. Очкылык тотарга ябышты, жып-жылы көнне туңып-катып директор артыннан терек-терек йөгерәм. Тыкрыктан барабыз. Эх, мин әйтәм, иптәш малай арттан нярсә ярар иде... Якуб абый әйләнеп тә карамый, озындыр торыклары, әлдерә генә. Ул атлый, мин йөгерәм, су буена төштек. Кардалар яныннан уздык. Кешеләр очрап абыйга сәлам бирәләр, мина, төшеп калган каз каурыена, караучы да юк. Буйга да бик кәй, өтек идем... Ятим баланың өс-башы да үзе төслерәк булгандыр инде. Баләкәй кәжә бәрәне сыман, башны томанага салып теркелдим дә теркелдим...

Тауга менә башлагач түзмәдем, борылып-каерылып, авыл ягына карадым... Жылыйсы килә, тавыш чыгарырга куркам. Авылга бичара әнием янына кайта алмам төсле. Тау башында ук кара урман. Мари ягында урман да урман бит анда!.. Мендек тә урманга кереп киттек. Тыела алмый шыншырга керештем. Шактый жир үттек, борылабыз, сарылабыз, һаман барабыз... Аяклар талды, эчне кату алды. Бер заман аланга чыктык. Миләшләр кызарып утыра. Шомырт куагында песнәкләр сикергәли. Уртада бәләкәй генә печән кибәне. Якуб абый мине шуның янына бастырды. «Монда урманга кергәнне берәү дә күрмәдеме?» диде. Юк, дим, дер-дер калтырап. «Мин чакырганны берәүгә дә әйтмәденме?» Баш чайкыйм... «Тирә-якта кеше-мазар шәйләнмиме?» Үкереп жылыйм үзем, шушы икән, мәйтәм, башкайларымның әрәм булуы!.. Үтерә дә печән кибәненә тыгып куя бу... Якуб абый бер читкәрәк китте, куен кесәсенә кулын тыкты, текәп-текәп карап торды... Жаным үкчәгә тәгәрәде мескенкәй... Акырып жылыйм, оялып тору бетте. «Яхшы... Менә шушындарак бас, Идрис... Тәк... Монда бер үзен... Телең кутырлап талганчы, башың түмәрләнеп инкегәнче рәхәтләнеп сүген! Немецчалап та, русчалап та жибәр, татарчанны да онытма. Син бушангач мин килеп житәрмен»,— ди.

Урман уртасында ялгыз башымны калдырып китте бу. Утырсам да куркам, басып торырга да хәл бетте. Торам, торам, печән кибәнендә тычканнар чыелдый... Песнәкләр өздереп сайрап жибәрә... Миләш тәлгәшләре кызыктырып яналар... Саескан тавышының шөкәтсезлеген шунда белдем. Ботактан ботакка сикерешеп акырышалар явызлар... Бер заман караңгы төшә башлады, кошлар тынды, салкынайтты. Япа-ялгызым һаман кибән саклыйм, үзем мышык-мышык жылаштырып та алам. Күз тәмам бәйләнгәч, куаклар арасыннан, газетасын бөкли-бөкли, Якуб абый килеп чыкты. Шатланырга да, кайгырырга да белмим, әрекмән яфрагы төсле ләпшердәп торам. «Булдымы?» дип елмая абыем. «Берәү дә калмадымы?» «Юк, димен, бетте»... Тау башына чыккач елмая, күлә бу. «Менә бусы Иләк йолдыз, тегесе булыр Арктур, бу якта Кассиопея, штурманнар өчен бик кирәкле навигация йолдызлары», дип аңлатып бара. Күккә карарга да куркам, жиргә дә күзем төшми, өйгә чем карангыда гына кайтып элэгештем. Менә әни туздыра, менә туздыра, ишек янындагы чөйгә элэнгән каеш чөелдереккә карап-карап ала. «Кайда эт куып йөрдең, пырдымсыз сунарчы?» ди. «Якуб абый белән тау башына менеп йолдызлар өйрәнеп йөрдек», дип чак-чак котылып калдым... Директорның «тәжрибәсен» әйтмәдем, иптәш малайга да серне ачмадым.

— Хәзер кайда ул иптәшегез?

— Югалды... Әтиләре сыман читкә китте дә кайтмады...

Алар сузгә мавыгып бакчаны ике-өч кат әйләнеп чыктылар. Идриска танышлары очраштыргалады, ул читенсенмичә генә аларга баш

орып, сәламләп китте. Дзержинский урамына таба аулак эскәмия табып шунда барып утыргач, Лида шукланып сорап куйды:

— Аңлашылмаган бер нәрсә калды, Идрис абый. Нигә бу тарихны миңа сөйләргә булдыгыз?

— Кызык түгелме?

— Бик кызык... Яшь педагог буларак мин моны үз активыма алам.

— Нигәме?.. Менә син мине, Лида, бик серле итеп свиданиега чакырдың... Бакча тирәли йөртәсең дә йөртәсең. Ни гаебем бар икән дип баш ватам. Тәүбә иттерергә, арт сабагымны укытырга җыенмыйсызмы икән?

Ул тагын Әхәтне, аның белән булган күңелсез саубуллашуны хәтеренә төшерде. Ах, нигә кешеләр юк җирдән бәхәс, ызгыш чыгарып бер-берсен бимазалап яшиләр икән?!

— Мин усал директорга охшаганмы?

— Түгел... Якуб абый да усал кеше түгел... Шул көннән мин авызымны чамалап ача башладым.

— Сез курка калдыгыз, Идрис абый. Күңелегездә шик-шөбһә утырадыр, мөгаен...

Ул уйчанланды, җавап бирмәде.

— Лида,— диде ул бераздан,— тукта әле, нигә Лида?.. Нигә син Ләйлә яки Ләйсән түгел... Лида, ни әйтсән дә, мөселман исеме түгел.

— Ә сез минем фамилиям ничек дип сорагыз.

— Сорыйм, ничек?

— Крячко.

— Сез дә керәшен кызымыни?

— Тагын кем ул керәшен кызы?

— Бар берәү... Безнең йортта, күршем.

Лида наянланып аңа бармак янады.

— Крячко,— диде ул, уйланып.— Әнием генә татар. Әтием украиналы булган.

— Ул хәзер кайда?

— Ил буйлап җил куа!.. Йөридер шунда азып-тузып! Бик юксынган, өзгәләнеп көткән чакларым бар иде, хәзер ике ятып бер төшемә дә керми.

— Синең белән без ятимнәр алайса?

— Шулайрак... Идрис абый, әнинең фамилиясе тагын да кызыграк.

— Булыр инде?..

— Шальтис... Анын әтисе — минем бабам — литва татары булган.

— Нинди маҗаралы шаҗәрә! Син бик нәселле токымнан булып чыктың алайса, Лида Крячко. Кызык, ифрат кызык.

— Һе, кызыгы алда әле анын.

Идрис сизелер-сизелмәс кенә итеп Лидага якынрак күчеп утырды.

— Мин, Идрис абый, нәкъ шушы турыда сөйләшергә, бераз киңәшергә дип сезне күрергә теләдем дә...

— Мин пәйгамбәргә тартым кешеме?..

— Белмим, нигә шулай уйлаганмындыр. Ләкин сезнең сүзегезнә ышанасым килә.

— Сөйлә, Лида.

— Бу тарихта миңа аңлашылмаган бер нәрсә бар. Минем әби дә, әни дә бик чибәр булганнар. Әни хәзер дә сокланырлык. Бик яшьли кияүгә чыкканнар, берәр кыз бала тапканнар да тол калганнар.

— Авыр язмыш,— дип килеште Идрис.

— Сез монда ниндидер бер закончалык, хәтта явыз рух, язмыш каһәре бардыр дип уйламыйсызмы?

Идрис чак көлеп җибәрмәде, Лиданың борчылулы йөзен күреп, елмаюын тиз-тиз яшерде, башын аска иде. Түбәнтен генә ИЛ-18 само-

леты узды. Хәтергә бер генә мизгелгә Дилә, ерак юллар, поездлар, вокзаллар килеп кунды.

— Сез мине әйбәт тыңламадыгыз, ахры, Идрис абый?

— Син миңа рәнжедеңме?

— Беләсем килә, кеше гомере белән кайчакта язмыш шаярмыймы?

— Алай ямьсез уйларлык синең берниндн нигезең юк.

— Әни белән әби язмышы нигез түгелме? Хак, хак, безнең нәсел өстендә ниндидер яшертен каһәрләү ята!

— Бу бит әкият! — диде ул, ниһаять, көлемсерәп.— Чын әкият.

— Бер дә әкият түгел,— диде турсаеп кыз. Идриснең сүзне уенгарак алуына ул рәнжи иде.— Алайса аңлатыгыз миңа: нигә юк кына кызлар менә дигән егетләргә чыгалар да көнләшерлек гомер итәләр. Кайда шуның сере?.. Нигә минем әби ятим, әни ятим, мин ятим... Нигә әнием ялгыз?.. Нигә ташлаган аны ире?.. Әнием унган, чибәр, аш-суга оста, кешелекле... Минем гомердә дә берьюлы ике егет белән йөргәнем булмады. Берсен дә ташламадым, хыянәт итмәдем. Нигә алар мине сөйгән булып кыланалар да башкаларга өйләнәләр?.. Гарипме мин, ямьсезме?.. Аннары, шунсы куркыныч: мин дә, кияүгә чыксам, әбием, әнием язмышына дучар булмаммы?..

Шушы ук сорауны аның Тәүфыйкка да, Әхәткә дә биргәне бар иде инде. Алар икесе дә төчеләнеп аның матурлыгын мактарга тотындылар, бәхетле, ваемсыз киләчәк, гаилә бәхете юрадылар... Менә Идрис нәрсә әйтер икән?.. Әхәт сөйләвенчә, ул гаҗәп дәрәҗәдә гадел, хатын-кызга хөрмәтләп, олылап караучы итагатьле кеше. Ул нәрсә дияр икән?.. Нигә дәшми ул?

— Идрис абый?

— Ни бар, матурым?

— Сез минем сорауны игътибарсыз калдырдыгыз.

— Нәрсә әйтим соң сиңа, Назлыгөл?

— Ичмасам, башкалар төсле алдагыз, юатыгыз.

— Син аларның берсенә дә мохтаҗ түгел, Лида.

— Менә шулай, менә шулай, алдалагыз!

— Алайса, сөйләшүнең мәгънәсе калмый бит, Лида.

— Сөйләгез,— диде ялварып кыз.

— Нигә гаепне егетләрдән генә эзлисең? — диде Идрис.— Бәлки син үзең шулай уйлап егет халкын шиккә төшерәсеңдер?

Ул кызга мәхәббәт турында, бер-береңә чамасыз ышану турында озаклап сөйләде.

— Үзеңнең бирәү белән бәхетле буласыңны тәгаен беләсең,— диде Лида.— Әмма кавышырга мөмкинлек юк... Хатын-кыз өчен иң кыены шул, Идрис абый. Сайлый алмый кыз бала, үз сүзен әйтә алмый! Әйтсә, аны кәнтәйгә санныйлар. Югыйсәм, мин кемнәрдер куйган тозакка барып кабар идемме?

— Алай түгел,— диде ашыгып аны бүлә-бүлә Идрис.— Табигать монда да бер зирәклек күрсәткән. Хатын-кызлар тел белән әйтмәсәләр дә, ир-атны үзләре сайлыйлар... Хатын-кызның ирләрне карату мөмкинлекләре шулкадәр бай, төрле-төрле, санап бетергесез... Ул каш-керфекләр, нәзкәй биләр, күңелне кымыржыта торган аяклар, иияк чокырлары... Күз карашын, елмаюны әйткән дә юк инде. Давыллы күңелгә күл өсте кебек, меңгә төрләнә хатын-кызның күз карашы... Ир-ат арсеналында нәрсә?.. Әлбәттә, ир-ат — һавалы зат, үзем сайладым дип куана... Чынлап уйлаганда, асылда, һәрвакыт диярлек әнә шул ияк очыиың сай гына сихерле чокырына төшеп чума, бата, югала... Бәлки ир-атның бәхете шуннандыр?

Бу фикерләр Идриснең башына хәзер генә килде, аның гомердә дә бу турыда уйлаганы, мондый уйларны хатын-кыз белән уртаклашасы

фараз кылганы юк иде. Әмма ул аларны мөмкин кадәр ышаныч белән, күптән сыналган фикерләре итеп кызга сөйләде.

— Сез хатын-кызда мәкер күп димәкче буласызмы?

— Юк, Лида, мин аларның тышкы матурлыгының төрлелеген, күңел матурлыгының байлыгын гына санап киттем. Тик хатын-кыз бар булганын, акылын, зиһенен, матурлыгын булыр-булмас кешеләр алдында чишеп ташламасын иде дим!

— Шәфкатьсез булмагыз инде, Идрис абый!

— Мин бөтенләй сине күздә тотмаган идем. Сине аңладым мин, Лида!.. Дөресрәге аңларга тырышам... Бу канун матриархаттан ук калган булса кирәк. Сүз — сүз, дисең син... Мәхәббәттә сүз өстенлек итәме? Сүз — тары кибәге ул, бәләкәй генә җил дә аны очырып тарата... Сүз белән генә ныгытылган мәхәббәтне чыпчык җиле дә өреп җимерә.

— Нишләргә соң мина, нишләргә?

— Акыллырак, ныграк, катырак булырга! Ин мөһиме: кыйнама үзеңне юк-бар шикләр белән!.. Үзең турында үзең шикләнденме, үз бәяңне үз алдында төшерәсең... Ә егет халкы кызларның бәясе югары йөргәнне ярата! Горур бул!

Кыз озак кына эндәшмичә утырды.

— Сез миңа үпкәләмисезме, Идрис абый?

— Бүгеннән соң без дуслар түгелмени?

— Сезнең кебек кешене очратуыма куанам. Тормышка, киләчәгемә ышанычым артты.

— Ир-ат халкына дамы?

— Аларга да!

Бергәләп троллейбус тукталышына киттеләр. Идрис Ленин районында Лиданы озата төште.

— Син бу сихерле бөҗраны өзәрсең, чияләнгән йомгакны сүтәрсең. Дилә белән мин синең иң якын дусларың, киңәшчеләрең булырбыз, Лида!

Кыз озын керфекләрен лепелдәтеп, рәхмәтле күзләрен кысып аңа карады.

* * *

Бүген Әхәт эштән туп-туры Лидаларга кайтты. Озак уйланганнан соң ул Лида белән ныклап сөйләшергә, үзаралай аңлашылмаучылыкка чик куеп, кыз ризалашса, әнисе рөхсәт итсә, язылышып аны Казанда алып калырга ниятләгән иде. Өч-дүрт сәгать көтеп утырса да, Лида кайтмады. Ул зарыгып, борчылып троллейбуска чыгып утырды һәм каршы як троллейбусыннан җитәкләшеп төшеп килүче Лида белән Идрисне күргәч телсез калды...

## 23

Рәкыйп өлкә комитетыннан кайтты да үтешли Идрис бүлмәсенә кагылып аны үзенә дәште.

Бергәләп редактор кабинетына керделәр.

— Эшләр ничегрәк бара синең анда?

— Болай... әйбәт сыман!

— Студентларның практикасы турында материал әзерме?

— Нокта куйдым. Секретарьда.

— Яхшы.

— Берәр күңелсезлек бармы әллә, Рәкыйп абый? Хата җибәргәнбезме?

— Юк. Шушы араларда Германия Демократик Республикасыннан кунаклар килә. Шулардан бер группага сине тәржемәче итеп билгеләделәр.
— Озаккамы?
— Җиде-сигез көнгә.
— Ә газета?
— Газета да чыгарга тиеш,— дип көлде Рәкыйп.— Картлач! Синең тырышлыкны, көчне беләм... Тик хәзер мең куллы Шивага әйләнергә туры килә. Син ризалашсаң, иптәшләрне чакырып сөйләшәм. Авырлыкның берәзын бүлешербез, әмма төп башы синә! Дөрес, бер котылу чарасы бар. Немецларның Казанда булуларына кирәк туктальірбыз. Кунаклар, нигездә, яшьләр. Без Европа яшьләренең, бигрәк тә Германия яшьләренең дөнья киләчәге турында ни уйлауларын ачык белергә тиешбез. Ә алар безнең фикерне белеп китсен! Үзенә мәгълүм, Якын Көнчыгыштагы ут уйнатулар безне тагын бер тапкыр кисәтте. Германия яшьләре уен түгел, киләчәк Европаның язмышын билгеләгәндә аларның роле, урыны зур булачак. Очрашуларда булсын, шәхси әңгәмәләрдә, син шул якка да игътибар ит.
— Тәржемәченең роле бик бәләкәй инде аның,— дип башлаган иде Идрис, редактор аны туктатты:
— Барыннан да элек син — журналист. Яшьләр газетасында эшләүче татар журналисты. Зур бер халыкның вәкиле.
— Килүчеләр кемнәрдер бит.
— Килүчеләр — дуслар. Без аларны шулай кабул итәрбез дә. Августның икенче яртысында Халыкара дуслык лагеренда япон яшьләренең күп санлы делегациясен каршылыйбыз. Бу шуңа нәни генә репетиция дә булыр... Татарстан яшьләренең халыкара элемтәләре елдан-ел ныгаячак.
— Мин әзер.
Эш авырайса авыраер. Идрис редакция кысасыннан ычкынып торырга, һава үзгәртеп алырга бик риза иде.
Бүген иртән генә Диләгә хат язып, «Әхәт киткәннән соң редакциядә кырын карый башладылар», дип зарланган иде, әле дә ярый, өйдә конверт булмады, хат китеп бармады! Рәкыйп чыгып китүгә, ул хатны вак-вак кисәкләргә ерткалап ыргытты.
Идриснең тәржемәче сыйфатында кунаклар каршыларга тиешлеген ишеткәч, хезмәттәшләр арасында төрле сүз купты.
Берәүләр:
— Кунак каршылый беләмени ул тәкъва-суфый?.. Хәмер эчми, дөкан чикми... Суган кыягы тешләп утырып кунак күңелен күрәләрме? — дип җорландылар.
Икенчеләр:
— Сак бул, араларында шпионнар бардыр,— дип өркеттеләр.
Өченчеләр:
— Үзебезнең союзниклар килә, дуслар. Ирекле союз яшьләре! — дип дәртләндерде.
Икенчеләр тынмадылар:
— Немец немец булып калыр!.. Хәтерлибез әле, алар Казанда әсирлектә байтак булдылар. Опера театры төзелешендә эшләделәр. Чибәр генә русча пупылдаучылар да бар иде. Арада: «Без Россияне большевиклардан коткарырга кайтырбыз!» дип янаучылар юк идеме?
— Андыйлар әллә кайчан Боннга качты.
— Бонн айда түгел, җирдә... Димәк, сак булырга кирәк!
Германия турында сүз кузгалгач, кайберәүләрнең бу илне, гомумән чит илләрне, чит халыкларны бик сыек, өстән-өстән генә белүләре ачыкланды. Идрис немец газета-журналларын тоташтан укыштырып килсә дә дәүләт, хуҗалык системасына, идарә аппараты мәсьәләләренә

күз йомыбрак барып, башлыча әдәбият, сәнгать, культура якларына игътибар иткән икән. Сүз дәвамында үз йомшаклыгын ул шундук сизенде. Әрсез генә арага кысылып акыл өйрәтергә тотынган Ниса Чәймилованың исә хәтта ГДРның яшьләр оешмаларын белмәве дә билгеле булды. Ниса, тупикка кертүләренә ярсыган иске паровоз төсле, пуф-пуф килеп ыжгырып, барысы белән ызгышып чыгып китте.

Сүз кунаклардан эчке эшләргә, редакциядәге бурычларга күчте, Нисадан соң тыныч кына, эшлекле әңгәмәләшеп алдылар.

Иптәшләре таралышкач, Идрис тирән уйда калды.

Чит ил.

Чит дәүләт.

Яңа социалистик система... Өченче рейхның һәлакәтеннән соң туып килгән дәүләт... Беләме ул аны? Аңлыймы?.. Гомумән, чит җирләрне, ят илләрне алар очраклы караган бер-ике кино-журналдан чыгып кына аңлатырга тырышмыйлармы?.. Кешеләргә, аерата яшьләргә күп беләмлек чире комачауламыймы?..

Немец халкы... Аның вәкилләре... Эрих Мария Ремарк... Аның «Өч иптәш» романын ул егерме тапкыр укып чыккандыр... Генрих Белль да укылган... Брехт та таныш. (Биш томлыгын сатып алды.) Брехт театры турында да фикере бар... Аннан күңелгә сугыш, нигәдер Паулюс килде... Кеше характеры эволюциясенең мөмкинлеге чиксез... Уй йөгереп тагын әдәбиятка күчте... Әдәбиятта — халыкның күп кырлы тормышы... Гореф-гадәте... Характеры... Көрәше... Омтылышы... Әдәбиятта халык мәңгеләшә... Берта Ватерштадт... Отто Штритматтер... Аннан үзебезнең иң якын дуслар Небенцаль... Эрих Мильштадт... Атаклы Анна Зегерс...

Аз! Бик аз!.. Шагыйрьләрне ул белми дә диярлек.

Ә килүчеләр... Татарларның, Казанның кемен, нәрсәсен белеп киләләрме?.. Югарыдан аска гына карап тормаслармы?..

Ул республика китапханәсенә менеп бер кочак китап-журнал алып төште. «Турист», «Горизонт» журналлары фактларга бик бай...

Вакыт дигәнең тагын да азайды. Ашыгырга кирәк, ашыгырга. Диләгә хат язасы урынга телеграмма гына сукты: «Яшәү матур! Көннәр очалар! Сагынам!»

Телеграмма кабул итүче кызның аксыл салам кибәне хәтле чәче Лиданы хәтерләтте.

Ике көннән Лида үзе шалтыратты:

— Имтиханнар тәмам, Идрис абый... Сезне күрергә зар-интизармын.

— Мин — кыяга богауланган Прометей. Кыймшана да алмыйм... Телем генә бәйләнмәгән: котлыйм, фәлән-фәсмәтән... Ләкин, күрешергә дисәң — юк!

— Кайчан? — диде ялынып кыз.— Сез миңа бик, бик кирәк... Әхәт...

— Атна-ун көнсез Син-син ишеге ачылмас!

— Шулай озакка сезне кем кузгалмас итте?

— Бер атнага ирекле баштан коллыкка төштем.

Лида көлде. Трубканы куйгач, Идрис аны кызганды. Ни гаебе бар аның?.. Киләчәгеннән курка, шуңа күрә чапалана, төрле якка ташлана... Башкалар теләсә ни дисеннәр, ул Лида турында бары яхшыны гына уйлый һәм алар шулай эчкерсез дуслар булып калырлар да.

Рәкыйп шалтыратты.

— Син әзерме? Киләләр дигән хәбәр бар, картлач.

— Һәрвакыт әзер! — дип шаярткан булды Идрис.

— Курыкма, мин дә сезнең белән уралырмын...

Эш бетәр алдыннан тагын звонок.

— Нихәл, Диоген?

— Әхәт, шайтан, бу синме?

— Сез, галиҗәнап Идрис бине Бакирны, вәкаләтле югары кунакларны каршылау свитасына керткәннәр икән.
— Каян белдең?
— Сөембикә манарасына язып элгәннәр. Тик үзең белән мине дә алырга онытма... Син... үзең генәме, Диоген?
— Кем белән булыйм ди мин?
— Белмәссең, син хәйләкәрне... Минем координатларны тыңла: «Җилкән» рестораны. Хәзер үк килеп җит.
— Хәзер барам, көт.
Әхәт эчкә кермәгән иде, телефоннан шалтыратканда да дамба өстендә яңа цирк төзелешендә кайнашкан машиналарны, эшчеләрне тамаша итеп тора. Идрис троллейбустан төшүгә аны күрде, шатланып кычкырды:
— Әхәт!
— Нихәл, картлач,— диде Әхәт кул бирмичә, иңбашларын бөреш-тереп.
— Эштән бушаган юк.
— Ишәк һәм чүлмәк берчакта да бушамыйлар. Үз чаманны бел.
— Беләм дип киртә җимерер хәл юк.
— Серне кайчан ачасың? — диде Әхәт бераз арткарак киерелеп.
— Нинди серне? — Идрис тып-тыныч иде.
Аның тынычлыгы Әхәтне бераз икеләндерде, әмма ул һөҗүмен туктатмады:
— Мин усал кайнана түгел, син дә тыйпак киленгә охшамагансың. Тел яшереп азапланма, ничек тә аңлашырбыз. Ирләр булыйк...
Ресторанда елга ягындагы урыннар буш түгел иде, дамба ягына караган тәрәзә эргәсендә утырдылар.
— Нәрсә алабыз? — диде Әхәт, менюны аннан-моннан актаргалап.
— Нәрсә барын карыйк...
— Иң хаҗәте бар сыман күренә,— диде Әхәт күзе белән официантканы эзләп.— Ашыкмыйсыңдыр бит? Свиданиең юкмы?
— Бая да чагарга тырыштың?.. Син нәрсә?
— Һаман койрыкны бот арасыннан чыгармыйм дисең алайса... Яшел помидордан салат... Шикәр комы сибелгән җиләк. Шә-әп!
— Бәясе, бәясе? — диде Идрис, менюны карап.— Бишләтә каералар!
— Үзем түләрмен, саранбай.
— Акчаң булса, мине чакырып маташыр идең микән, ярар инде, үзем түләрмен!
— Карышмыйм,— диде Әхәт, юри тамак кырып.— Инсафлы икәнлегенне күрсәт шулай олыларга! Азрак кәгәбезләр?
— Син җан теләгәненне эч, миңа ярар шунда берәр торна!
Күрше өстәлдә генә өч кыз озын торна шешәдән ак «Мискет» эчәләр иде.
Әхәт, Идрис караган якка борылып, кызларга күз кысты, официантка килгәч, йодрыгын йомарлап өстәлгә куйды да иренмичә ризыкларны санап чыкты.
Аш килгәнче аны-моны сөйләшеп утырдылар. Әхәт гадәттәгедән бераз житдирәк иде. Ул бер караганда арып таушалган да сыман, икенче караганда кинәт кайгы кичереп сабырын җыя алмаган кешегә дә охшый иде.
— Яңа урында ничек? — дип сорады Идрис, Әхәтне җәлләп.
— Төрле кешеләр... Коллектив зур... Фикердәшләр дә, башкалар да бар... Эшләсәң яраталар, эшләмәсәң кайда да бер... Кызлар күп... Театрлар, филармония белән аз-маз бәйләнештә торабыз. Гастрольләргә киләләр дә сәлам биреп телевидениегә чабалар. Тамашачы театрга килгәнче, аның үз өенә үтеп кереп кыстыйлар, чакыралар. Реклама, туган, сәнгатьтә дә зур нәрсә!..

Өстәлгә әле генә суыткычтан чыккан вино килде. Әхәт рюмкаларга салды, кабымлык килгәнне дә көтеп тормастан:

— Исән булыйк,— дип эчеп җибәрде.

Салат килгәч, аны бик яратып ашадылар. Помидорлары кызыл, сусыл, тозы да таман булып, каймагы да шәптән иде.

— Сине көткәндә цирк төзүчеләргә карап тордым.

— Бәйрәмгә өлгертәләрме?

— Мәсьәлә анда түгел... Нәрсәгә охшаган ул? Нине хәтерләтә?

Идрис, авызын кәгазь тастымал белән пөхтәләп сөртеп:

— Гөмбә инде... Гөмбәгә охшаган,— диде.

— Сафсата,— диде Әхәт.— Оча торган тәлинкәгә охшаган!

— Минем бит синең шикелле андый тылсымлы тәлинкәгә утырган юк, картлач.

Әхәт тәмле итеп, таза тешләре белән тиз-тиз чәйнәп ашый иде.

— Синең утырганың да, күргәнең дә булмау тормыш күренешләрен аңлатканда бик бәләкәй үлчәүләр, шулай түгелме?

— Әкият! — диде Идрис, чәнечкесе белән өстәлгә шакып.

— Моннан ун ел элек бездә кибернетиканы «буржуаз уйдырма», «зарарлы идеализм» дип атыйлар иде. Шул заманның философик сүзлекләрен актар... Ә хәзер кибернетикадан башка юньле бер фән дә яши алмый.

— Бусы хак. Әмма оча торган тәлинкәләр көнбатышның чираттагы мавыгуы гына. Лохнесс күлендәге әкәмәткә ышаналар, моңа да вакытлыча табынырлар, аннары ялыгырлар. Көнбатыш сенсациясез яши алмый.

— Ә нигә Көнбатыш кына?

— Берәр нәрсә белсәң, сөйлә, Әхәт.

— Сиңа сөйләү куркыныч... Кискен хөкемдар Идрис... Син — усал прокурор. Яклаучыга сүз бирмисең, аны хөрмәтләмисең. Ләкин хакыйкатькә ирешү юлында ике якта ике көч торган. Отрицание отрицания үзе шул ич инде.

— Син читкәрәк тайпылдың.

Казанка өстеннән су трамвайлары, олырак көймәләр узганда ресторан сизелерлек чайкалып кала.

— Шушы циркны проектлаштырганда архитекторлар оча торган тәлинкәләрне хәтерләрендә тотканнар... Болак өстеннән, теге баштан күпер өстеннән аермачык күренә бу. Иртәнге сыек томанда, яки кояш баеганда гаҗәп инде... Мин вокзалга кадәр трамвайда киләм дә җәяү элдертәм... Карыйм да уйланам... Син җирдән тыш цивилизацияләргә каршы түгелдер ич?

Идрис елмаеп башын чайкады.

— Әһә, килешәсеңме?.. Беләм, чөнки пульсарлар, квазарлар кешелек дөньясы алдында конкрет проблемалар куйды. Җирдән тыш цивилизацияләр бар дисәк, аларның фән казанышлары бездән өстен дип фараз кылсак, аларның без гөнаһлы бәндәләр белән кызыксынуы мөмкиндер ич?

— Нигә оча торган телсез тәлинкәләр? Нигә ин әүвәл радио, телевидение түгел? Башка юллар да бар...

— Син җир җанвары — кеше булып фикер йөртәсең. Адәм логикасы белән галактик табышмакларын да чишмәкчесең. Әгәр җирдәге мораль, социал законнар алар өчен бөтенләй ят һәм кабул ителмәслек булса?.. Җир синең өчен генә җир... Галактиканың тузан бөртекчәсе.

Әхәт, башын ике кулы белән кысып, Идрискә карамыйча гына уйланды.

— Җир, җир,— диде ул бераздан.— Француз язучысы Робер Мерльның «Гакыллы җанвар» романыннан өзекләр укыдыңмы?.. Әйе, бергә актардык бит... Фа һәм Би исемле акыллы дельфиннар... Сүздән

сүз чыгып дельфин: «Кайда соң ул оҗмах?» дип сорый... Күктә диләр аңа. Шуннан Би сөйләп китә... «Кайчандыр без дельфиннар җирдә гомер сөрә идек... Җир нигъмәтләре белән туена идек... Әмма безне җирдән диңгезгә сөрделәр... Безгә җирдән читтә бик кыен, дельфиннар гомерләре буена җирне сагыналар, җиргә якынрак йөзәргә тырышалар, күптәнге дусты Кешене очратканда шатланалар», ди ул...— Ул тукталып вино йотты.— Ишетәсеңме, картлач, Җирне һәм Кешене сагыналар... Сине һәм мине! Шуннан репортерларның берсе сорау куя: «Би, дельфиннар яки китлар вакыт-вакыт ярга ташланалар, аларны көчләп диңгезгә кайтарсаң да барыбер җиргә ыргылалар, көтүләре белән һәлак булалар. Шуның серен аңлатчы...» — ди.

— Дельфинның җавабы хәтеремдә калмаган,— диде Идрис, кызыксынып.

— Ә-ә, картлач, күңел биреп укымаган син алайса! «Җирдә үлсәк, без үлгәч тә җирдә яши калабыз. Җир — безнең оҗмахыбыз, кеше — безнең аллабыз»,— ди дельфин...

Официантка кайнар солянкалар китерде.

— Рәхмәт, рәхмәт,— дип, Идрис аңа баш какты.

— Кешеләр оҗмах өчен урынны күктән сайлаганнар, Дельфиннар акыллырак булып чыга түгелме?.. Бармы әле ул күктәге оҗмах?.. Кемнәргә аны күрергә язган?.. Ә дельфиннарның оҗмахы — менә ул, тирә ягында... Аллалары — Кеше. Идрис — алла, Иван — алла, Җан, Джон, Радж — алла... Җир бик бәләкәй бит. Ә анда тереклек итүче аллалар күп. Аллалар дельфиннарның оҗмахын саклап калырга тиешләр...

— Хак, әмма сәер фикер белән сүзеңне тәмамладың,— диде Идрис һәм сүзне икенчегә борды.— Син редакциягә кире кайтырга уйламыйсыңмы?

— Нәрсәм калган анда? — диде кабарынып Әхәт.— Омниа миа, мецум порто. Все мое ношу с собой дигәннәрме әле?

— Шулай. Тик мецум порто түгел, мекум порто.

— Төкер, тел төбемә төшенденме?.. Әйе, ни турында гәпләшә идек әле, бүлдерден.

— Җир турында. Тик син әүвәл солянканы аша, суына.

Ул ашны татып карады.

— Син миңа карама, шуыт.

— Ә,— диде Әхәт тәрәзәгә карап.— Оча торган тәлинкәләр турында сөйли идек... Румыниядә дүрт милиционер юлдан баралар икән, алларында гаҗәп сәер хикмәт күреп туктап калалар. Киңәшәләр. Нишләргә?.. Кинәт шул әкәмәт вертикаль сызык буйлап күккә күтәрелә... Бераздан барып карасалар, асфальт юл янып-көеп беткән, имеш. Белеш егет сөйләде, Мәскәүдә номерной институтта эшли... Зур бер киңәшмә уздырганнар... Галимнәрне, очучыларны, ракетачыларны җыйганнар да оча торган серле тәлинкәләр турында сөйләшкәннәр. Ул каһәр суккан савыт-сабаларны байтак кеше күргән икән!.. Бер летчик яңа самолетка сынау ясаганда үз юнәлешендә сәер предмет күрә. Җиргә хәбәр итеп тәлинкәгә якынаерга рөхсәт сорый. Рөхсәт алынгач, якыная башлый... Шунда аның гаҗәп бер хасиятен ача: тәлинкәнең күләмен дә, аның ераклыгын да билгели алмый летчик.

— Шушы факт ук аның әкият икәнлеген раслый.

— Ашыкма, ашка пешәрсең... Оча бу, оча, җир белән сөйләшеп тора, сүзләрен магнитофонга яза баралар... Кинәт ул: «О, тимер икән ич», дип кычкырып җибәрә...

— Гарпунын «Наутилус» сыртына ыргыткан Ленд...

— Көлкегә алма,— диде ачуланып Әхәт.— Шуннан самолет юкка чыга... Җыелыштагылар сорау биреп караганнар. «Тәлинкәләргә раке-

талар белән һөҗүм ясап карадыгызмы?».. Андый очраклар да булган, ләкин берннди нәтиҗәгә дә ирешелмәгән.

— Галимнәр бу күренешне ничек аңлаталар?

— Галимнәр? Гомуми психоз белән... Испаниядә Изге Себастиянның күктән җиргә иңүен күрдек дип берьюлы унбиш мең кеше расла-ган бит...

Идрис бераз аптырашта калды. Әхәт ышанып, үз эффектына үзе бирелеп чынлап сөйләде.

— Әле алай гынамы? Оча торган тәлинкәләр бик борынгыдан билгеле булганнар. Кадими китапларда шуны күрү очраклары тер-кәлгән. Нагасаки белән Хиросимадагы шартлаулардан соң гына алар Җир тирәли орбиталарда ешрак күренгәли башлаганнар.

— Синеңчә, алар җирне махсус күзәтү астына алганнар инде?

— Шулай булып чыкса?

— Әкият бу.

— Әкият булса ни?.. Кырык ялган булса да шушы хәбәрләр минем күңелгә ятты, картлач... Элекке заманда ичмасам гаҗәп кызык бул-ган: бәкеләр, тугайлар тулы су аналары, күктә аллалар, урман тулы шүрәлеләр... Атлаган саен кешене куркынычлы дию,ләр, җен-пәриләр сагалаган, албастылар буып уяткан... Зыярәт өстеннән тубал булып убырлар тәгәрәгән... Хәзер нәрсә? Бөтенесе ап-ачык... Ионосфера, био-сфера, микромир, мокромир... Адәм баласына мавыгырга әкиятләр, риваятьләр, мифлар да кирәк ич!

Идрис көлеп җибәрде:

— Албастыларны, су карчыкларын оча торган тәлинкәләр белән алыштырып яңа әкиятләр иҗат итәме кеше?

— Я, әйт!.. Әйт син!

— Нигә әле без мифларны сагына башладык? — диде Идрис.

— Нигәме? — диде күзләрен калайландырып Әхәт.— Бәлки мин синең белән җирдәге хәлләр турында сөйләшергә теләмимдер?

— Ансы синең эш,— диде Идрис, җәберсенеп.

— Хәтерең калмасын... Әйдә, үзебезнең җирдәге вак, бәләкәй эш-ләребезгә күчик... Мин, картлач, Лидага өйләнергә булдым.

— Ничек, ничек?

— Авызы йомык, борыны тишек!.. Син, кайчандыр, ячы булып алынган идең... Сайра, макта кызны, әйбәт диген, саф диген...

— Чыннан да шәп кыз, Әхәт!

...Әхәт мәзәк кенә чалышаеп үзенең элекке хезмәттәшенә, элекке дустына карап торды, аннары аягына басты да, аскы катка төшеп китте. Идрис аны туалетка-мазарга барадыр дип уйлаган иде, шактый көтте, бер заман тәрәзәгә караса, дамба буйлап җил-җил китеп бару-чы Әхәтне күрде. Ул акча түләп анын артыннан бастырып чыкса да, трамвай тукталышында да, троллейбус көтеп торучылар арасында да Әхәт юк иде.

Саубуллашмады, тыңлап бетермәде...

Рәнҗетте Әхәт Идрисне...

## 24

Әхәт күпер төбендә такси туктатырга тотынды. Тизрәк моннан китәргә иде!.. Бәхетенә каршы, Федосеев дамбасы ягыннан ике генә юлаучы утырткан такси килеп чыкты. Ашыгырга кирәк, ашыгырга...

Кояш баеп бара.

Сул якта, Казанка өстендә, көчле моторлы көймә пыр туздырып су чаңгысын тарта... Пляж тирәсендә кызыл флаг эленгән ап-ак коткару каеклары йөренәләр...

Дамба өстендә җәяүлеләр дә ишле. Яшьләр генә түгел, картлар да байтак... Әхәтнең юлдашлары да шуңа игътибар итеп баралар икән, бөкерәя башлаган бер картның тыр-тыр баруын күргәч, шаркылдап көлештеләр:

— Инфарктган кача бу, йөгерә.

— Нигә, Яңа Зеландиядә «Инфарктган йөгереп кач» дип аталган клублар бар,— дип сүзгә катышты шофер.

«Тәүфыйк та, Идрис тә, башкалар да минем өйләнүемнән көләчәкләр,— дип уйлады Әхәт.— Ояттан кача, йөгерә»,— диячәкләр...

Булса ни!

Гореф-гадәтләр, кануннар үзгәрмимени?

Элек кешенең вафат булуы гаять зур фаҗига итеп кичерелгән. христианнар мәетне чиркәүгә куеп аның белән өчәр көн бәхилләшкәннәр, махсус елаучылар, догачылар тотканнар... Ә борынгы Мисырда?.. Фиргавеннәр алтын каекларда бу дөньядан мәңгелеккә кичкәндәниләр кыландырмаганнар?.. Ацеклар, Пасха утравының Озын колаклары... Уксигезенче, унтугызынчы гасыр... Европа... Кара атлар җигелгән кара катафалкларга салып, матәм маршлары уйнап, кайгылы процессияләр шәһәр урамнары буйлап узганнар... Чиркәү чаңнары гүләгән...

Ә хәзер?..

Табутларын тотып туганнары, якыннары крематорийга чиратка басалар да кеше урынына бер савыт көл генә алалар...

Мәхәббәткә, хатын-кызга, гаиләгә мөнәсәбәтләр үзгәрмәдемени?

Лиданың үткәндә кем булуында ни эшләре бар?.. Идриснең дә, башкаларның да...

Мәктәп тукталышында ул таксистка акрынларга кушты, кесәсеннән вак-төяк көмеш акчаларны учы белән сөзеп алды, санамыйча шалтыратып шоферның учына салды. Эче авырткан кеше төсле бөгелеп, машинадан чыкты, иелебрәк атлап тар тыкрыкка туп-туры кереп югалды.

Монда урам авыл урамы кебек. Зыңгылдап торган трамвайлары, чожт-чожт үтеп торган троллейбуслары белән эт эчәгесе кебек борыла-сарыла сузылган Декабристлар урамы артта калды... Биек-тәбәнәк коймалар. Аларда торучыларның характеры, байлыгы чагылган. Ишек алларында лапас-куралар, чиннекләр, мунчалар... Төрле тавышлар белән эреле-ваклы мактанчык әнчекләр капка асты саен ләң-ләң өреп калалар.

Саф, салкынча һава, тиз-тиз йөрү аның аракы мәлҗерәткән тәнен җиңеләйтте, ул барган уңайга елбыр чәчләрен тарады, ак күлмәгенең бөселгән итәкләрен сыерып чалбарына тутырды.

Тиздән зур шәһәр монда да килеп җитәчәк. Әнә, Савин янындагы сазлыкларны күмеп, земснаряд ком өя.

Лидалар йорты.

Ул туктап тын алды.

Нинә тапкыр булганы бар аның бу йортта?..

Почмаклары ингән алты почмаклы сәрхүш йорт. Тол хатын йорты. Ихата да, капка да йортта ир-ат юклыгын шәрран ярып торалар. Капка келәсе купкан, аны мунчала белән бәйләгәннәр. Ишек алдында түбәсе купшакланган тәбәнәк утын сарае. Өйгә терәп җәйге веранда салганнар. Ансы янарак, тик такталарының каян әлэкте шуннан җыелганлыгы күренеп тора. Йортлар алар тышкы яктан гына бер-берсенә охшашлар. Ишекләре бар, тәрәзәләре, почмаклары, наличникләре...

Һәр йортта, һәр ишек артында кешеләрнең үзгә язмышлары яшәлгән. Кешеләр күп вакыт кайгы-хәсрәтләрен, гомерләренең чарпалышкан ураулы юлларын әнә шул ишекләр артында калдыралар да халык арасына тормыш сайлап тоттырган битлекләрен киеп чыгалар...

Әхәтнең Киров районында, Милиция урамындагы йортта, мәгълүм бер ишек артында үз тормышы бар. Ул анда чакта менә шушы каксаган питләле ишек катына килгән егет түгел...

Ишек артларында кешеләр үзләре булып яшиләр, монда тормыш дип аталган театр тәмамлана. Менә монда Шальтис фамилияле татар хатыны белән Крячко фамилиясен йөртүче татар кызы яши.

Зур күзле, үзенең артык шәфкатьле, ышанучан булуы аркасында усал кунелләрдән җәбер-җәфа күрүче Лида Крячко...

Үзенең ресторанда, эштә, урамда күнегелгән битлеген салып, тол хатын йортына юаш кына Әхәт Нуруллин кереп бара.

Чү, тукта!

Капкадан ишеккә әле ун адым...

Ныклап уйладынмы? Ашыкмыйсынмы?.. Монда кергәч уйнарга ярамый! Бу йортта әрнү, түбәнсенү, мәшәкать һәм кешеләрдән кимсенү даими кунак!.. Коймалары тәбәнәк бу йортның җинел ишегеннән каерып хәлсез, алама хәсрәт тә керә ала. Өчәр-дүртәр йозак эленмәгән бу йортның как ишекләренә. Алтын медальләр таккан көр этләр дә каршыламый... Бу йортта «каһәрләнгән язмышка дучар булды безнең токым!» дип ышанган тол хатын яши... Толлык яши... Тынлык яши... Артык тынлык... Сагаю яши...

Чү!

Веранданың сайгак такталары шикләндереп шыгырдады. Әхәт куырылып, йомшаграк басарга тырышты. Мондый ямьсез шыгырдавык тавыш чыгарып түгел, иртәнге нур кебек тын гына, песи баласы сыман йомшак кына керәсе килә иде аның.

Өй алды ишеге ачык... Өй ишеге дә бикләнмәгән. Бу йортта шундый гадәт.

Алгы бүлмәгә иртән генә кояш төшкәнгә, рәхәт, салкынча.

Чисталык, идәннәргә аллы-кызыллы чүбек паласлар, кижеле алача сузма җәелгән...

Ул йомшак кына тамак кырды.

Эчке яктан:

— Кайттынмы, кызым? — дигән йокымсыраган тавыш килде.

Әхәт сул кулы белән ишек яңагына тотынды. Ишек яңагы шома, сап-сары, Әхәтнең кул сырты йонлач, бармаклары озын...

— Бу мин йөрим.

Диван янына корылган чаршау чожтырдады, ачылды һәм халат изүләре ап-ачык Мәрьям күренде.

— Син икәнсең, Әхәт,— диде ул, изүен томалап.— Эштән кайтып чәй эчтем дә хәл җыярга яткан идем...

— Кузгалмагыз, Мәрьям апа, кузгалмагыз...

Хатын диваннан җитез генә төште, өй башмакларын киде.

— Уз бу якка, бусага төбе саклама.

— Лида өйдә юк икән,— диде Әхәт, тынланып.

— Юк шул...

— Кайда ул, Мәрьям апа.

— Кем белгән аны? — диде хатын, теләр-теләмәсрәк.— Әнә, кинога барам дип язу калдырган.

Әхәт кызмачалыгын яшерергә тырышып иреннәрен кысты, шым гына эчкәрге бүлмәгә узды. Пөхтә, җанга ятышлы итеп җыештырылган бүлмәнең һавасы саф, ян тәрәзә ачык, тәрәзә каршысында гына сирень куагы бөдрәләнеп утыра. Түрдә комод өстендә трельяж, шул турыда стенада Лиданың зурайтылган фотосы.

Әхәт көзгедә үзенең чагылышын күрде. Чәчләр чәбәләнгән, күз дә тоныкланган, йөзе әллә клушаудан, әллә винодан агарып каткан. Ул үзен-үзе яратмады...

— Мин килгәнне күрә торып чыгып кача диярлек... Ничә килсәм, өйдә юк.

— Көтеп утыр дип әйтмәгәнсеңдер ич?..

Хатынның тавышын артык йомшак дип әйтеп булмый... Шулай да Әхәт:

— Кем белән киткән ул? — дип сорамыйча булдыра алмады.

— Син әзрәк тегеләй бугай? — диде Мәрьям, аңа текәлеп.

Ул башын артка ташлап авызын ерды:

— Тегеләй түгел, Мәрьям апа, болай!.. Бәйрәм бит бүген.

Ул көлгән арада Мәрьям янә бер кат чаршау артына кереп чыкты. Хәзер аның өстендә килешле генә тегелгән зәңгәрсу күлмәк, чәчләре дә төйнәлеп баш түбәсенә җыеп куелган.

— Тәмәкече-бөкечегә көн дә бәйрәм. Сине эшеннән куганнар икән.

— Үзем киттем,— диде кинәт айнып Әхәт.

Хатын Әхәтнең килүен дә, кыланышын да хупламады. Бар иде аның өметләнгән чаклары! Әхәтне үз баласыдай якын күреп каршылый, түренә утыртып аларның Лида белән көлеп-уйнап гөрләшүләрен чаршау артыннан куанып тыңлый иде... Хәзер нәрсә? Ватык чүлмәкне ямарга йөриме? Әллә, эш юктан, эткә дуга белән печән чабамы?..

Әхәт, Мәрьямнең кырыслыгын күрсә дә, «тәмәкече-бөкечене» колагына элмәде, үз куанычына үзе чумып, тик авызын ерып утырды.

— Мин, Мәрьям апа, өйләнергә булдым.

Хатын мизгелнең бер өлешендә тынсыз калды, аннан агарынды-күгәренде, көчкә җыелып:

— Котлы булсын берүк! — диде. Аннары кызып ук китте.— Өйләнәсең икән, өйлән. Тигезлек, бәхет белән гомерең узсын. Тик шундый көндә нигә безнең ишекне кактың? Ни катышың бар бездә?.. Кызымны мыскылларга килдеңме? Куып чыгарырлык ир-атлары юк дип уйынасыңмы?.. Бик ирәймә, буш баш, әнә ишек, идән такыр, аттыр моннан!..

— Мәрьям апа,— диде Әхәт, аптыраудан көлеп.

— Бүксәсен аракы белән заправить итә дә безнең якка кыешлый, бәндәчек.

Әхәт бар көчен җыеп аягына басты.

— Сез ачуландыгыз, эх! — диде ул, әрнеп.— Лида кайда? «Октябрь»дамы?

— Белмим.

— Ансын язмаганмы?

— «Октябрь» да булмас. Чиркәүгә йөрергә яратмый...

Ул басынкы кыяфәт белән ишеккә атлады. Хатынның эчке сиземе егетнең тиктәскә генә ишек бавына тотынмавын сиздерде, ул егетне ничек туктатырга аптырап:

— Чәй-мазар эчәсең килмидер бит? — дип сорады.

Инде ишек бусагасын атлаган Әхәт:

— Мазары кирәкми, чәеннән баш тартмыйм,— диде.

Аз-маз чәй ашлары тешләштереп, сүзсез генә, берәр чынаяк чәй эчтеләр. Акрын гына караңгылык инде. Ишек алды да, урам да, өй эче дә тып-тын. Почмактагы репродуктор гына бер терелеп, бер үлеп таракан кыштырдаган авазлар чыгарып куя. Төзәтергә ничә тапкыр сүз бирде Әхәт, һаман кулы тигәне юк.

Эчтән кайнап, тыштан аны-моны сиздермәскә тырышып Лиданың әнкәсе утыра.

Кыз әнкәсе!.. Башка хәсрәтләре өстенә җилкәсенә мең-мең мәшәкать, кызының язмышы дигән авыр мазаны алган кеше...

Кич булды. Кыз өйдә юк. Кайда ул? Кемнәр белән? Нишли?.. Аның күңелен рәнҗетмиләрме, намусына тәкәнмиләрме?.. Үзең ашамыйча аны тәрбияләсең... Үзең кимәгәнне кигертәсең... Тугач та тол хатын-

нын шатлыгын, бәхетен бетереп ташлаган ятим бала. Һәм шул мең борчылулы төннәрнең, мәшәкать кайнаган көннәрнең җимеше саф күңелле, саф тәнле кызың артыннан менә шундый тозсыз егетләр килеп йөрсен инде.

Мәрьям апа кузгалырга авырсынып, ут кабызырга иренеп утыра иде, Әхәт үрелеп включательгә басты.

— Шулай да, нигә гел өйдә юк ул?

— Үзең уйлап кара, Әхәт, мин әшкә китәм дә югалам. Көн озын кемне монда сакласын?..

— Нигә мин киләсен сизенеп китми?..

— Ай һай, нәфес дигәнең үзеңдә, тартә буе тагын...

— Их, Мәрьям апа, мин бит Лидага өйләнергә телим.

Бу соңгы сүзләрне акрын атлап өйгә кереп, урта ишек яңагына сөялгән Лида да ишетте.

Әнисе аны күрмәде, шактый озакка тынсыз калды, аннан түзмәде, шыпырт кына еларга тотынды:

— Алай ук кыланма инде... Ятим дигәч тә ул хәтле мыскыллама. Артык кызым юк... Гарип-горабамы? Укымаганмы? Кулыннан эш килмиме? Нигә алай уйныйсың, исерек баш?

— Мин Лиданы яратам, Мәрьям апа, бик яратам.

— Әнкәйне тинтерәтеп утырасыңмы? — диде яхшы ук кычкырып Лида. Бүлмәдәгеләр сискәнеп аңа борылдылар.

Әхәт шатланып:

— Лида кайтты! — дип кычкырып җибәрде.

Кыз, биек үкчәле туфляларын салып ташлап, ялан аяк килеш өстәл янына чапы-чопы узды, ышыкланган кебек, әнкәсе артына басты.

— Тәмам изәсең килмәсә, яхшы чакта кит, Әхәт,— диде ана, башын иеп.

Әхәт, торып, сый-хөрмәт өчен хуҗаларга рәхмәт әйтте.

— Лидага мине озатырга рөхсәт итегез, Мәрьям апа,— дип сорады.

Аналы-кызлы бер-берсенә караштылар да Мәрьям «бар!» дигәнне аңлатып ым какты.

— Озаер әле,— диде Лида, өстәлдәге вазадан бер кисәк кактөш алып.

— Озат, кызым. Йокыны алып китмәсен,— диде Мәрьям.— Чәй савытын онытып кына бетермә!

— Ярар.

Өреп каршылаган этләр капка төпләрендә аумакай гына койрык болгап озатып калдылар. Озын аяклы, кыска күлмәк кигән Лида шәһәрнең бу урамнарына ничектер йогышмый, аны шушында туып-үскән дип бер дә уйламассың, ул чит-ят илдән ялгыш, адашып кергән турист кыз кебек... Декабристлар урамына житәрәк кыз адымнарын акрынайтты.

— Житсен. Чит биләмәләргә керәсем килми.

— Мәрхәмәтенә рәхмәт.

— Хуш бул.

— Нинди картина карадың? — диде егет, кызның кулына кыяр-кыймас үрелеп. Тик Лида кулларын артына яшереп өлгерде.

— Шырдый-бырдый. «Костер»га барган идем. Тынчу, эссе...

— Нигә шулай турсаясың? Исереккә саныйсыңмы?

— Аек баштан син безгә килмисең.

— Ялган!

— Сәрхүш булмаган кеше шундый тузга язмаган сүзләрне лыбырдап утырыр идеме?

Әхәт көч белән кызның иңбашларыннан эләктереп алды, үзенә таба тартты. Лида карышмады, тик аның күзләрендә дәрт тә, хис тә юк, ни барысы салкын нәфрәт кенә ялтырый иде. Ул уң кулының бармаклары

белән кызның керфекләрен, күзләрен сыйпады. Лиданың тулышкан иреннәре чак кына калтыранып китте:

— Кызыкмы? — диде ул, мыскыллап.

— Ямансу.— диде Әхәт, кызны ычкындырып. Аннары саңгырау ухылдап өстәде: — Кума син мине. Чак кына сөйләшик.

— Әни көтә. Ишеттең ич.

— Ул аңлар...

— Юкка кыланасың, Әхәт... Боларның беребезгә дә хаҗәте юк.

— Лида!

— Нәрсә булды?

— Ни булганын да, булырын да белмим, әмма хәзер, шушы минутларда мине ташлап китсәң, без бер-беребезне югалтабыз.

Кыз «бу артык зур фаҗигаме?» дип көләргә уйлаган иде, тыелды:

— Кайда утырыйк соң? — дип сорады.

— Балалар паркына керик.

— Анда гөжелдәвек. Эшлиләр, Культура сарае салалар... Син бүген мине ресторанга сөйрәмисеңмени?

— Синең җәберсенергә тулы хакын бар, Лида...

Алар Лидалар йорты турына борылып кайттылар.

— Әнкәңә әйтәбез дә чыгабыз,— диде Әхәт, катгый итеп.

— Син кермә,— диде кыз йомшак кына.

Ул капка саклап серәеп калды, күңеле боек, ямансу, җылыйсы килә иде.

Урам саран гына яктыртылган, йортлар эчкәре, тәрәзә утлары тротуарга төшеп җитми, караңгырак...

Ни сөйләшәләр икән өй эчендә?

Аның янына кин-киң картузлар кигән өч егет килеп басты.

— Тартырга бармы? — диде аларның берсе тупас кына.

— Нигә булмасын? — диде Әхәт исе китмичә.

Өчесе дә берәм-берәм үрелеп папирос алдылар, чөләеп аның йөзенә карадылар. Бишбалтада үсеп, урам сугышларын күп күргән Әхәт малай-салайдан гына шүрләп торганнардан түгел иде, ул елмайды, үсмерләр дә көлгәндәй иттеләр.

— Безнең фронтта ни эзлисең? — диде арадан берсе.

— Син ни эзләсәң, мин шуны.

— Миңа дигәнне син тапсаң?

— Кем алданрак өлгерә, дус кеше!

— Ашыккан ашка пешкән диләр, абзыкай!

— Соңга калган... нәрсә диләр әле?

Үсмерләр китеп бардылар, берсе кәпәренеп кенә жиргә төкерде: «Ул түгел!»

Мәрьям, кызын көтеп, борчылып утыра иде. Ни сөйләштеләр икән, егетнең нияте чынлыкта булды бугай, кинәт сүз әйтеп эшләрен бозып ташламадыммы дип хафаланды ул... Икенче яктан килеп, Лида моңсу мут күз белән бәхетле була алмас, бәладән баш аяк дип тә уйлады.

Юаш кына атлап Лида кайтып керде.

— Озаттыңмы, кызым?

— Әйе, әнкәй.

— Эчкәнме?

— Түгел сыман.

— Буена сеңдереп өлгергән... Китүе әйбәт... Утыр, чәенне эч. Көндезге шулпаны да ашамагансың. Җылытып бирим булмаса?

— Тамагым тук... Мин йөреп керер идем, әнкәй.

— Беркая да чыкмыйсын, ишеттеңме?

— Ярар, алайса.

Лида шикәрсез чәен калак белән болгата-болгата байтак кына утырды.

— Анын беләнме?
— Әйе, энкәй.
Мәрьям апа, өстәл янына килеп, кызының муеныннан сөйде.
— Үзең беләсең инде, кызым, үзең беләсең...
Лида сикереп торды:
— Озак тормам!..

25

Кыз чыга-чыгышка кадап алды:
— Мин югында синең башына буталчыклыгы белән гениаль фикерләр керeп тулдымы?
— Кулыңда нәрсә? — диде Әхәт, каранып.
— Бусы ни дигән сүз? — дип елмайды кыз.
— Пычак-мазар тотмадыңмы? Усалланып чыккансың.
— Уйларга вакытны күбрәк биреп ташладым. Уйлау сиңа зарарлы...
Әхәт Лиданы җилтерәтеп:
— Үз коралым белән үземне тукмыйсыңмы? — дип сорады.
— «Кинәт һөҗүм тактикасы» кайчаннан синең милеккә әйләнде, кадерле иптәш?.. Парктагы батырлыгыңнан соңмы?
— Син мине эссе табада куырасың.
Алар җитәкләшеп Декабристлар урамына чыгып баралар, әче-әче генә бәрелешсәләр дә, телдә чынкый мыскыллау, үртәшү юк, икесе дә бер-берсен рәнҗетми генә сынашалар.
Әхәтнең як-ягына каранып эзләнүен сизенгән кыз җитдиләнеп борылды:
— Сиңа нидер җитми?
— Телефон юкмы дим...
— Телефон?.. Аның өчен «Нарат урманы» кафесына барырга кирәк. Хәйлә корасыңмы?.. Тагын кафега керергә кыстарга ниятме? О, алайса ярдәм юк. Кайттым-киттем.
— Урамыгыз караңгы. Куркырсың.
— Кемнән?
— Аучылар йөри, мылтыклары корулы.
— Аучылар үзләре миннән шүрлиләр.
Кыз карышкан сымак итсә дә, басынкы гына атлап кафега таба киттеләр. Барып җиткәнче янадан эндәшешмәделәр. Лида нык-нык итеп кул кысуыннан егетнең дулкынлануын, кул хәрәкәтләренең үз ихтыярыннан тыш, әчке киеренкелекне җиңеләйтергә теләүдән килеп чыгуын төшенде, шуңа күрә берни сорашмады да, кулын да тартып алмады. Егеткә күңеле каткан дип йөрсә дә, исе китте, аңа Әхәт янында күңелле, җаны ял итә, борчылулары онытылып тора иде.
Ул телефон будкасына кызны кертмәде.
— Гафу ит, мин хәзер,— дип ишекне томалап япты, трубканы алгач, арты белән борылып башын аска яшерде. Кызның кәефе кырылмады, ни сәбәпле аларның бар серләре уртак булырга тиеш ди?.. Әхәт белән күңелле булса да, аларның киләчәк юллары бер-берләреннән бик еракка аерылмыйлармыни?. О, начар егет түгел түгелен, ләкин алар үз арадагы дуслык җепләрен әллә кайчан, төрлесен төрле очракта өзеп бетерделәр инде. Икәвен дә шул үткәннәр генә берләштерә, киләчәккә карамыйлар да, аны телгә дә алмыйлар... Җаны теләгәне белән сөйләшсен, күңеле тартылган чакта очрашсын, хәзер ул чыгуга Лида кайтып та китәчәк...
Кабинадан чыкканда Әхәтнең авызы ерык, күзләре көлә иде.
Кыз үзенең чак кына көнләшүен сизенде, алар бер-берсенә карашып алдылар. Сүрән яктылыкта моңаеп торган кыз искиткеч матур иде.

— Лида, булды! — диде Әхәт, сөенеп.— Хәзер Идрисләргә генә кагылып үтик тә...
— Мөгез чыгарасыңмы?
— Шунсыз ярамый... Бүген без аның белән бик начар аерылыштык...
Кыз кайтыр якка тартылды.
— Кыстама, Әхәт. Син теләгәнне генә эшләп, син сызган божра эчендә генә бөтерелеп булмас. Безнең мөнәсәбәтләрнең шаярудан узганын сизәсеңдер?
— Үзем дә нәкъ шуны әйтергә торам.
— Кермим Идрисләргә. Нигә быткычланып йөрергә? Ул безнеңчә яшәми, аның максаты ачык, гомере кызык, тулы...
— Бүгенгә мине тыңла, Лида. Бүгенгә генә! Шулай кирәк. Иртәгәдән ни телисең, шуны кыланырсың. Ризамын.
— Нинди кеше син? Кызык әзлисең...
— Эзләмим...
— Нигә кирәк сиңа Идрис?
— Әйтсәм, ышанмассың... Тик ялгызымны калдырма! Мин ул минуттан куркам. Әйдә Идрисләргә!
Башы каткан кыз тәмам кәефсезләнеп трамвайга керде. Арткы ишек турында бөялешкән егет-җилән тасыраешып Лидага челәюгә, Әхәт аны стена янына ук китерде дә ят күзләрдән каплады. Идриснең матур хатыннарның хәвефле ирләре турындагы фәлсәфәсен хәтерләп елмайды.
— Нигә ыржаясың?
— Бәхетлемен.
— Белергә рөхсәтме, каян яуды әле андый бәхет?
— Менә ич... Икәү барабыз...
— Юк, без икәү генә түгел.
Әхәт күзе белән генә тирә-якка карап:
— Һә! — диде.
— Безнең белән нәкъ уртабызда тагын бер кеше бара.
— Кем ул?
— Син телефоннан сөйләшкән кыз.
— Алайса безнең арада бер кеше генә түгел! — диде шатланып Әхәт.— Алар күп... Тик берсе дә арада комачаулаучылар түгел, алар як-ягыбызда, менә күрерсең.
— Берәүләр серле булып кыланырга яраталар...
Идрис йокыга китеп кенә азаплана иде, звонок тавышына сискәнеп уянды, кайда ятуын аңышмыйча гөрселдәп идәнгә егылды.
— Кем бар? — диде ул, бармагы белән чәчен аралап.
Әхәт кызга нидер пышылдады, Лида:
— Телеграмма,— диде.
— Әһә, ярый,— дип каударланды Идрис. Чалбар балагын кия алмыйча интекте, ишек артында көлештеләр. Ул шикләнеп ачкычны борды, ике куллап ишекне тотып, үрелеп карады. Әхәт белән Лида аның йокылы, каушаган чыраен күреп тагын көлештеләр.
— Сез йөрисез икән, ябалаклар,— диде Идрис, кызып.
— Үзең син йокылы ябалак! — диде Әхәт Лиданы бүлмәгә этәреп.— Юл бир!
Ут яндырдылар, Идрис күлмәк сәдәфләрен төймәли-төймәли сукранды:
— Иртәрәк килсәгез ярамаганмы?
— Тавык графигы белән яшәргә сиңа кем кушкан? Ак күлмәк ки. Әйбәт костюмыңны, яхшы ботинкаңны да җәлләмә.
— Булуың житкән икән! — Идрис, туалетка кереп, суык су белән битен юды.

— Тик карышырга уйлама. Лиданы үгетләп тә кадерле вакытны әрәм иттек.
— Болай вакытсыз кая өндисез? — диде Идрис Лидага карап. Лида инбашларын сикертте:
— Әхәтнең юләр башына тиле уй килгән икән, барыбер тынычлык-та калдырмас!
Идрис шикләнә-шикләнә генә киенде.
— Мина ышанмый башладыңмы, картлач? — диде Әхәт.— Син дә кирәк мина бүген!
— Монарчы мин генә кирәк идем,— диде Лида,— сездермичә генә көзгегә караштырып.
— Икегез дә кирәк.
— Без ерак барабызмы?
— Бик үк якын түгел...
— Авантюрист,— диде, ниһаять, көлеп Идрис.
Өчәүләшеп ишектән чыктылар. Идрис бикләп ачкычны кесәсенә салды.
— Утны сүндерергә оныттык, әй, серле сәяхәтчеләр!
Борыла башлаган Идрисне Әхәт туктатты:
— Калсын. Кермә кире. Я эшебез уң булмас!
Лида белән Идрис карашып алдылар. Өйдә чакта Идрис Әхәтне исерек дип уйлаган иде, егет алай күренми, димәк, бу төнге ябырылу бер уен гына түгел, егетнең күңелендә нидер төйнәлгән...
Восстания урамы чатындагы сәгать төнге унберенче яртыны күрсәтә. Әле кешеләр урам тулы. «Маяк» ресторны ягында гармун тавышы яңгырады. Беләкләренә кызыл бәйләгән дружинниклар бер-берсен әйдәкләп шул якка ашыктылар. Троллейбус килде.
— Утырыштык,— диде Әхәт.
Үлек күмәргә барган кешеләр шикелле күңелсезләнеп, вагонга керделәр.
Әхәт Идрис белән Лидага карап көлеп тә куйгалый, борчыла да. Бишбалтада төшеп, тимер юл астыннан тар туннельне үтеп, Милиция урамына юнәлделәр.
— Урамның исеме куркыныч,— диде Идрис.
— Гөнаһлылар күптән ташлап качканнар...
Лида, Әхәтнең култыгыннан ычкынып, Идрискә арткарак калырга ымлады:
— Берәр нәрсә аңлыйсызмы, Идрис абый?
— Томан эчендә йөзгән көймә кебек барам.
— Әй, пышылдашмаска!
Аулак урамга керделәр. Өч-дүрт йорт узгач, Әхәтләр өе. Идрис элегрәк монда килгәли иде. Әнә олы капка. Капка төбендә өч каен оеп утыралар. Каеннар янына житкәч, Әхәт Лиданы туктатты.
— Кызый, безгә Идрис белән сөйләшеп алырга иде.
— Сер капчыгы һаман чишелмимени? — диде ялыккан кыз.— Рөхсәт.
Ул капка алдындагы салкынча эскәмиягә барып утырды. Койма ярыкларыннан күзне чагылдырып якты төшә, ул ишек алдына карады. Алты почмаклы таза йортның бөтен тәрәзәләре келпеп тора, өй эчендә хәрәкәт, ыгы-зыгы сизелә. Күңеленең бер тамыры белән кыз бу мажараларның тиктомалга түгеллеген төшенде, үзенчә нәтиҗә дә чыгарды, тик әлегә бу фикер бик зәгыйфь, көчсез эмбрион халәтендә калды.
— Картлач,— диде Әхәт, Идриснең иңенә кулын салып.— Син шушы минутта үзеннең кемлегенне беләсеңме?
— Беләм,— дип тачылдатты Идрис.
— Кем?

— Тиле чанасына утырган юләр.
Әхәт ят тавыш белән сәер генә көлде.
— Кияү егете син, белдеңме?... Өйләнәм, картлач. Лида минем кәләшем.
Идрис сызгырып җибәрде:
— Мин баядан сизенеп киләм, тик ул берни дә аңышмый ич.
— Хәзер әйтәм.
— Эх, егет! Җайсыз корасың тормышны!.. Тере кеше бит, кыз бала.
— Темп, картлач, темп! Үземә дә, аңа да икеләнергә урын калдырасым килми... Беләсеңдер, бу ноктага шактый чәбәләнгән юллар аша якынайдык...
Әхәт Лиданың кискен баш тартуыннан курка иде. Шуңа күрә ул Идрисне иптәшлеккә алып та килде. Идрис исә, бу юләр башны өметсез адымнан ничек саклап алып калырга, дип баш вата иде. Тик ничек? Кай арада?..
— Алайса, аллонс энфантс де ла патрие?!
— Немецча төтенем йөрми, картлач.
— Французча ул, гөмбә баш. Марсельезаның беренче юлы. «Алга, ватан уллары!»
— Лида!
— Әллә уйлашабызмы, Әхәт?!.
Кыз, урыныннан кубып, аларга якынлашты.
— Бик күңелсезгә киткәнче таралышабызмы?
— Юк,— диде киреләнеп Әхәт.— Хәзер сон... Өйгә рәхим итегез.
— Монда сөйләшик, Әхәт,— дип ялынды Идрис.
— Сүз өйгә кергәч кенә булачак. Анда беләләр.
— Мин болай кермим,— диде Идрис.— Керә алмыйм.
— Озатыгыз мине дамба өсләп,— диде Лида.
— Лида, син барын да аңлыйсың,— диде ялынып Әхәт.
— Нәселебездә чегән каны юк, күрәзәлегем җитми.
— Әниең белән сөйләшкәнне дә ишеттен.
Лида уеннан узуын аңласа да:
— Ах, әлеге дә баягы күз бәйләш-сукыр тәкә дәвам итәмени? — дими булдыра алмады.
— Түгел, Лида... Уен күптән тәмам!.. Төшендең, аңладың. Әнә безнең өйдә утлар яна... Әти-әниеӊ килен көтүен беләсең. Әйдә, Лида, бир кулыңны миңа!
Кыз чайкалып китте, калтыранган тавыш белән:
— Нигә болай, нигә болай? — дип пышылдады.
— Ярамыймы?. Без барыбыз да сиңа шәфкатьсезлек күрсәттек, Лида... Бигрәк тә мин... Синең дустанә сузган кулыңа таш салдык. Менә хәзер ялгыз калдыммы, сине генә уйлыйм. Ялгыз калырга куркам.
— Шуның өчен бүйдаклыгыңны корбан кыласыңмы?
— Юк... Мин сине күптәннән яратам, беренче күргән көннән бирле! Ләкин барысы да чуалчыграк иде бит. Хәер, хәзер аларның әһәмияте калмады.
Лида кулын селтәп баягы эскәмиягә барып утырды, учлары белән йөзен яшереп, тезенә капланды...
— Балалыгын чыгып бетмәгән синең! — дип пышылдады Идрис Әхәткә.
— Лида, сине яратуымны беләсен.
— Кеше төсле генә яратсан ярамаганмы?
Идриснең күңеленә җылы йөгерде, ул, үзенең хәзергә артык кеше икәнлеген сизеп, Идел дамбасына таба китте. Кешесез калган буш урамнарга караңгы ишек алларыннан чәчәк исләренә катнашып тәм-

сезрәк, ямьсезрәк исләр дә чыгып тулган иде. Ул йөгереп диярлек дамбага менде. Иделнең түбән ягыннан, меңләгән күзләрен яндырып, зур пароход менеп килә. Ул, Әхәтләр ягына колак сала-сала, дамбада шактый озак торды. Салкынча сыман тоелды, чүгәләде, сикергәләде. Кайтырга кирәк булса да ашыкмады, монда өченче кешенең бары комачау гына икәнлеге ап-ачык иде.

Тупылдаган аяк тавышлары яңгырады.

— Идрис, син кайда?

Ул Әхәт кенә килгән дип уйлаган иде, алар икәү йөгерәләр икән, ул чабып дамбадан төште:

— Сезне котларгамы, сезне котларгамы? — дип пышылдады. Әхәт аның касыгына төртте. Лида эндәшмәде, әйлән-бәйлән уйнагандагы кебек түгәрәк ясап өчәүләшеп сикерештеләр...

Капкадан керүгә өй алды ишеге шыгырдап ачылды, болдырда тәбәнәк шәүлә күренде, шундук аның баш очында ут кабынды.

— Кайтып җиттек, әнкәй...

— И улым, и улым... и балалар...

Карчык, болдырдан җитез генә төшеп, Лиданы кочаклады.

— Атасы, атасы,— дип кычкырды ул, еламсырап.— Төкле аягың белән, килен... Әткәгез дә көтә... Туганың апа белән җизнәгез дә килде... Озаграк тордыгыз, әйдә, зыяны юк, төн үзебезнеке. Бусы кем тагын? Идрисме?

— Кияү егете,— диде Идрис, авызын ерып.— Исәнмесез, Мәрфуга апа.

Эчтәгеләр, тавышны ишетеп, шыбырдашып каршыларга чыктылар, аларны камап алдылар, Лидага сүз әйтергә җай да, вакыт та калмады. Ул, күз яшьләрен чак тыеп, түнеп китмәс өчен Әхәткә тотынды, үзе һаман: «Беркемнең дә кияүгә шушылай чыкканы юктыр!» дип кабатлады. Эчкәреге якта елмаюлы йөзләр, шатлык катыш күз яше җемелдәп кысылган күзләр ялтырады. Кемнәрдер нык-нык итеп иркәләп аның кулын кыстылар, берәү җамаяк белән май, савыт белән бал алып килде, көмеш кашык ялтырады.

— Авыз ит, килен. Май кап... Балыннан авыз ит.

Каршылаучылар кунакларга юл биреп тайпылыштылар, кыз үзенең шушы йортка, шушы кешеләргә шатлык, куаныч китерүен тойды. Әхәт ап-ак агарынган иде, тик моны Идрис кенә абайлады. Эчкә үттеләр.

Ризык тезелгән ап-ак эскәтерле өстәл, табын тирәсендә мәж килеп йөрүче, татарча итеп ак яулык ябынган, ак алъяпкычлы хатын күзгә чалынды. Барысы да котлашалар, Әхәтнең бик хәвефле көттереп шундый күрекле татар кызы алып кайтуына чиксез дәрәҗәдә сөенешкәннәр иде. Лида гына: «Ах, бу хәлләр элегрәк булса...» дип, чамасыз кыйнала иде.

Гомуми тантана ана да йокты, ул кемнәрнедер кочаклады, кул кысты, балыннан-маеннан авыз итте, күз яшьләрен озын керфекләренең очыннан сыпырып та тормады.

Идрис өстәлдән шампан шешәсен алды, бөке шартлап түшәмгә бәрелде. Яшь кияү белән яшь кәләшне түргә чакырдылар.

## 26

Синоптиклар ике-өч көн рәттән: «Арктикадан салкын һава агымы килә, Җирнең метереологик юлдашлары көчле циклон котырынуын хәбәр иттеләр» дип, кунелләргә шом салып торганнар иде, ниһаять, явымлады. Төн буе өзә-төнә салкын җил исте. Яңгыр шыбырдады. Идрис туңып уянды, барып тәрәзәне япты.

Иртән дә һаваның кәефе кырылган иде: яңгыр сибәләп тора, салкынча...

Көтелмәгән кунаклар бүген киләләр. Идрис, ашыгып кына Матбугат йортына кереп, Рәкыйпне күрим дисә, ул турыдан-туры аэропортка барам дип шалтыраткан икән. Көннең сытыклыгы ачуны бер китерсә, Рәкыйпне очрата алмавы Идрискә ярсу өстәде.

Аэропортта иң беренче очраган танышы Виталий Петрович булды. Нина Михайловнаны нык яклаган мәкалә «Социалистик Татарстан»ның кичәге санында басылган иде. Гәрчә мәкалә астында Идриснең үз имзасы тормаса да, Жаденко төтеннең кем учагыннан чыкканын белә иде. Ул Идрискә кызыксынып карады.

— Килеп життекме? — диде ул, горгылдык тавышы белән.

— Безнеке ансат, менә кунаклар килә алырлармы?..— Күк томаланган.

— Очарга тиеш,— диде Виталий Петрович, самолетларга күккә күтәрелергә үзе рөхсәт биргән сыман.

Ленин районы башкарма комитеты, шул җөмләдән Виталий Петрович, вәкил буларак, ГДРның Нойштадт шәһәреннән архитектор, Ирекле яшьләр союзы члены Курт Карлны кабул итәргә тиеш. Яшь архитекторга яшь журналист дип, табигый төстә, Жаденкога тәрҗемәче итеп Идрисне билгеләделәр.

Әзерлек чаралары барган арада Виталий Петрович Булавина белән Идриснең бер көйгә җырлаша башлауларын күз алдына китермәгән иде. Кичә секретарь Роза Юрысланова мәкаләне русчага тәрҗемә итеп укып биргәч, ул беренче чиратта Нина Михайловнага шалтыратты. Сөйләшү ул уйлаганнан да кискенрәк, корырак булып чыкты. Виталий Петрович ярты юлда сүзен өзде, гафу үтенде, ләкин тиз генә тынычлана алмады...

Идрис хәзер дә Жаденко газета турында, һич югында, Нина Михайловна турында сүз кузгатыр дип көткән иде, Виталий Петрович ул җәһәттән авыз да ачмады.

Яңгыр өзә-төтә, кайтып-кайтып явып китә иде.

Виталий Петрович белән килеп-килеп күрешүләреннән аэропорттагы кайберәүләрнең, үзләре кебек, кунак каршылаучы икәнен Идрис сизенгән иде, арада аның танышы да килеп чыкты. Үзәк музейда эшләүче нечкә сыйраклы, чәчен малайларныкы төсле итеп кистергән, үзе дә шук малайга охшаганрак бу ханымны Идриснең чит ил туристлары белән очратканы бар. Житез телле бу ханым немецча да, французча да бердәй яхшы белә.

Яңгыр ныграк сибәли башлауга, очу кырын аерып торган тимер коймалар тирәсенә таралышкан халык бөялешеп эчкә керде. Туристлар каршылаучыларны депутатлар бүлмәсенә чакырдылар. Өч-дүрт кеше белән иң элек Жаденко шунда барып керде. Алар, ак чехоллар белән төрелгән тирән-йомшак кәнәфиләргә чумып, сөйләшә башладылар.

Радио пытырдады, алар көткән самолетның төгәл ике сәгатькә соңга калачагын хәбәр иттеләр.

Барысы дәррәү урыннарыннан кубып, көлешә-көлешә аэропорт алдына чыгып машиналарга төялештеләр, берәм-берәм китеп тә беттеләр. Идрис, троллейбуска кереп утыргач, Булавина турында уйлады. Ике сәгатьлек буш вакыттан файдаланып нигә аның янына барып кайтмаска? Ичмасам, кирәкле бер бурычы өстән төшә торыр!

...Нина Михайловна коридорда сестра белән сөйләшеп утыра иде, Идрисне күргәч, ике кулын сузып урыныннан торды.

— Кемнедер юксынып, көнелем җирсеп тора иде, менә рәхмәт!

— Саумысыз, Нина Михайловна.

— Шөкердән башка ни әйтим?

— Алайса, куанышыйк!
— Ничек болай иртәләдегез? — диде ул, гаҗәпсенеп.— Райбашкармадан сезгә дә һөҗүм башланмагандыр бит?
— Сезнең канат астына сыенырга килгәнгә охшаганмынмы?
— Бу иптәш редакциядән, Зоя,— диде Булавина, кызыксынып тынлап торган сестрага баш кагып.
— Бернинди һөҗүм дә юк, каушамагыз. Аэропорттан килешем. Кунаклар каршылый идек, яңгыр аларның юлын бүлде...
Коридорның түр башыннан, тавышсыз тәгәрәтеп, ак җәймә белән муенына тикле төрелгән авыруны алып килделәр. Зоя җәһәт кенә күтәрелеп аларны каршылады.
— Холлга керәбезме? — диде агарынып Булавина.
— Рөхсәт итәләрме?.. Минем вакыт бар.
Зоя аларга карамыйча гына:
— Врачка күренмәскә тырышыгыз,— диде.
Урындыкларны тәрәзә каршысына тартып китереп, дуамал эре ботаклы фикус артына ышыкландылар. Нина Михайловна һаман тынычланмады:
— Тизрәк чыгасы иде, Идрис... Төннәрен керфек ормыйм... Палатадагы бер хатынга операция ясадылар... Өченче тәүлеген туктаусыз ыңгыраша... Булса да була икән кешедә көч!.. Палатага кермәскәрәк тырышам... Тизрәк котыласы иде моннан!..
— Озак тотарлар сыманмы?
— Тотмыйбыз диләр... Куркырлык әйбер әйтмиләр. Нервлар какшаган, йөрәк тузган, ми тамырларының басымы үзгәргән.
— Заман чире, Нина Михайловна... Ял кирәк, тынычлык, узара татулык.
Булавина тоныкк кына елмайды:
— Калды ди хәзер тынычлык!.. Газетаны укыдым да котым чыгып ятам... Шул оешмага, шул иптәшләр янына кайтасы бит... Тәнкыйтьне яратам дигән кешеләргә ышанмыйм мин!
Идрис аны юатырга кереште:
— Алай булмас... Тәнкыйтькә реакцияләре нибары үчегү генә икән, андый житәкчеләр үзләре утырган ботакны үзләре кисәләр.
— Төшәрдән элек сине төртеп ексалар? Яки үзләре белән сине ияртсәләр? — диде кызып Булавина.
— Газета ошамады дип туп-туры әйтмисез инде?
— Куркуымны гына әйтәм! — диде кабаланып Нина Михайловна.— Әткәйгә хуш килгән, сөйләрлек түгел, газетаны алгач та чабып килеп житте... Ярты сәгать тын алалмый утырды! Фаина Наумовна шалтыратты, дачада җыелышып укыдык ди... Иптәшләрнең күбесе телефоннан котладылар.
— Мөнә күрәсезме? — диде шатланып Идрис.
— Сукыр түгел,— диде пошынган Булавина.— Хуҗалар ни әйтер?
Булавина хуҗалардан ул кадәрле үк курыкмый иде, аның үзен чак кына жәлләтәсе дә, Идрис белән киңәш-табыш итәсе дә килде. Чыннан да, үчләшү дәвам итсә, колакны томалап утыру ярамас, абай булырга кирәк!
— Хуҗаларыгыз гаделлек тантанасына кизәнәләр дип уйламыйм. Әйтик, Виталий Петровичның бик кымшаныр исәбе юк сыман.
— Кайда күрдегез аны?
— Әйтмәдеммени? Кунакны бергә каршылыйбыз, мин аның тәржемәчесе.
— Агылый белән тагылыйга әйләнгәнсез алайса,— диде йомшарып Булавина.— Фаина Наумовна әйтеп торды, теге дус малаегыз сезне бик юксына икән!
— Айдармы? — дип кычкырды Идрис.

— Барыбер дачадан качам ди икән.
— Вакыт житкерә белмәү бәласе, Нина Михайловна... Иптәшне өйләндереп йөрдек, тегесе-бусы...
— Барып кайтыгыз бер, күңеле булыр... Олы мәшәкать димәсәгез, минем әткәй янына кереп утыргалагыз... Бер башына читендер... Иске квартирада чакта күрше-күләндә аны белмәгән кеше юк иде, монда читектер аралашып китә алмады...
— Керермен, Нина Михайловна. Күзгә-башка күренгәне юк, больница юлыннан бушанмый торгандыр...
— Архивта утыра. Музейларга йөри. Мемуарлар яза.
— Мемуарлар. Бусы кызык.
Булавина бу турыдагы сүзне тирәнгә җибәрергә теләмәде, ахры:
— Бусын ул үзе әйтер... Диләдән хат аласызмы? — дип сорады.
— Язып тора. Тик аның да кәефе әйле-шәйле... Санаторийны да бик мактамый... Югалгач кына бәяләнә торган кыйммәтле нәрсә икән бу саулык дип уфтана.
— Үзең теләп алмыйсың да бит, тормыш вата. Шагыйрь әйтмешли, әле сөя, әле чөя!..
Больницадан ерак та түгел тимер юл уза. Тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып поезд үтте. Арча поезды. Тәрәзәләргә кешеләр сарган, ишекләрдә аяк асылындырып малай-салай утырган.
— Шулай ваемсыз гына утырып ерак-еракларга китәсе иде,— диде кинәт Булавина.— Гомернең икенче яртысын ваклый башлаганда бөтенесе зир-зәбәр килеп бетте! Киләчәгемдә бәхетсезлек дыңгычлап тутырылган дип уйлап караганым да юк иде!..
— Шагыйрьләрне телгә алгач, борынгы кытай шагыйре Ду Фу искә төште.
— Кем дисез?
— Ду Фу. Шул язган... Русча гына әйтәм инде... «Я не люблю большие города, где люди не сочувствуют друг-другу!» Әгәр чын булса, нинди зур фаҗига... Күп кешеле шәһәр уртасында кем дә булса теләктәшлек, дуслык тапмыйча, фикердәшсез япа-ялгыз калса — бусы һәлакәт бит... Ә сез юкка офтанасыз... Сезнең үткәннәрегез якты, киләчәгегез үз кулыгызда...
— Юатасызмы?
— Нигә юатыйм? Кирәк икән, сезнең өчен сугышачакмын.
Булавина дәшмәде, сәер генә аңа карап алды.
Кинәт Идриска беркадәр оят булып китте: Нина Михайловнаны яклап чыгу һичкайчан артык көч сорамаячак бит, чөнки ул дөрес яшәгән, кыек-мыек эшләрдә аны берәү дә гаепли алмый, саф намуслы кеше...
Кинәт аның күңеле боекланды, үзенең болай күңелдән гайрәт чәчеп утыруы урынсыз бер эш булып тоелды, ул, урыныннан сикереп торып, капыл-копыл гына саубуллаша башлады.
— Нигә кабаландыгыз?
— Көн ачыла кебек. Я самолет иртәрәк килер...
— Ярдәмегез өчен рәхмәт.
— Куегыз сана,— диде Идрис, чын күңеленнән гарьләнеп.
Аэропортка кайтып житкәч, вокзал алдындагы павильонда бер стакан кофе эчеп, өчпочмак ашап чыкты. Элек ялгыз ашаганда тамагына ризык үткәрә алмый изалана иде, менә ялгызы ашарга да күнегеп килә...
«Интурист» автобусы янында тәбәнәк кенә вездеход туктаган, шуның кырында ике егет папирос тартып торалар. Телевидениечеегетләре ич болар, машина да шуларныкы! Идрис ашыгып шулар янына юнәлде.
— Идрис, сине Әхәт эзли,— диде егетләрнең берсе.

— Шулаймы? — диде ул, шатланып.— Кайда ул?
Йөгереп диярлек кереп барганда ишектә Әхәт белән бәрелешә яздылар.
— Галиҗәнап тәрҗемәче әфәнде, маңгаегызны саклагыз. Кирәге чыгар.
— Салют, картлач. Свитага син дә эләктеңме?
— Сезнең төксе чырайларыгызны мәңгеләштерергә исәп...
— Лида ни хәлдә?
Алар вокзал алдындагы буш диярлек мәйданда йөренәләр.
— Көлә башлады Лида.
— Сине дә көлдерәме?
— Университетта дус бар минем. Беләсең ич инде җирән сакаллы Нурулла Чанышевны? Доцент! Хәләл җефете сырхаштыра аның. Шифаханәләргә дә кергәли. Бер заман шактый күрешми торгач очраштык та: «Хатының ни хәлдә?» — дип сорадым. Ләләнең больницада икәнен ишеткән идем. Көлә Нурулла. «Ләләң ызгыша башлады», ди... Димәк, савыккан дигән сүз...
Идрис аңа бармак янады.
— Сине үз яныбызга алабыз. Виталий Петрович белән сөйләшәм.
— Монда минем кирәгем дә юк. Өлкән тәрҗемәче килгән. Оста барда телне тыябыз.
— Кем ул асыл сөяк?
— Галия Халикова. Музейдан.
— Аксак песнәк кебек сикергәләп йөри торган ханыммы? Немецча беләме?
— Музей кошы булгач, ансын гына сайрар инде!..
Алар, үтеп йөрүчеләргә юл биреп, колонна төбенәрәк тартылдылар, иртәнге вак самолетлар очмаганга вокзал эче зур-зур чемоданнар, кәрҗиннәр тоткан авыл агайлары, апалар белән шыплап тула бара иде.
Солтанатлы кыяфәтле бер ир, бик текәлеп карап, алар яныннан узды.
— Кем бу? — дип сорады Идрис.
— Казандагы бөтен снобларны белеп бетерсәм, мин астролог булып китәр идем!
Киң бетон юлларга бер-бер артлы самолетлар куна башлады. Моторлар шаулады, репродуктор өзлексез диярлек татарча-русча сөйләп тора, күгәрченнәр кешеләрнең аяк араларында гамьсез генә җим чүпләп йөриләр. Иртән генә эчне пошырып җыелып яткан болганчык күлләвекләрне җил ялап бетерде. Султан, биек-биек, үтә күренүчән ангарлар ягыннан, шар-зонд очып чыкты да яңгырларын коеп җиңеләеп калган күгелҗем-аксыл болытлар янына тирбәлә-тирбәлә менеп китте.
— Лида көлә башлады,— диде, шырпысын куш учы эчендә кабызып Әхәт,— Мәрьям апаны гына ипкә китереп булмый.
— Бәхетсез язмышы кабатланудан куркамы?
— Син боларны каян беләсең?
— Беләм,— диде Идрис, Әхәтнең күзенә текәлеп.— Лида үзе сөйләде.
Әхәт ышаныр-ышанмас башын чайкады:
— Уңай герой шундый-шундый булырга тиеш дип, гади халыкны жансыз-кансыз таш сыннарга башырырга өйрәтеп бетергәнбез. Минем кебек аз-маз чуар күңелленең ару киләчәге булуына Мәрьям апа ышанмый. Аңа юып куйган, таслаган, ыспайлаган, иннек-кершән ягылган тәти кеше кирәк!
Идрис көрсенде.
— Үзеңдәниләр? — диде Әхәт.

— Эшлибез шунда...

— Кунакларны кабул итү программасын карап чыктым. Атна буе заводтан фабрикага, мәктәптән балалар бакчасына, артельдән мастерскойга кушаяклап чабып йөрер өчен Германиядән Казанга килеп йөрмәс идем мин. Кунаклар сәхнәдә, казанлылар залда. Шулай аралашып буламы?.. — Картлач, мин Рәкыйп белән сөйләштем...

— Әйе...

— Кайт, ди. Чакыра.

— Менә бусы акыллы киңәш.

— Исәп кайтыргарак... Җилкәнне иртәрәк төшергәнмен мин... Су асты рифлары бик еракта икән.

— Беткә ачу итеп тунны утка яктың.

— Лида да кайт ди.

— Акыллы хатын сайлап алган ир кем була?

— Егеттер инде?

Депутатлар бүлмәсеннән каршылаучылар бүселеп чыкты. Виталий Петрович, кул изәп, Идрисне чакырды...

— Бик ерак йөрмәгез...

Жаденко да борчыла икән. Бу уртаклык аларны якынайтты, Идрис аңа сер чишкән кебек итеп:

— Нина Михайловна янында булдым,— диде.

— Тизме азат итәләр үзен? — диде Жаденко, читкә карап.

— Шушы көннәрдә.

— Кереп чыгарга кирәк иде дә...

— Кәефе чибәр сыман...

— Аны тышкы кыяфәтеннән белеп буламыни?! — дип ычкындырды Жаденко.

Рәкыйп тә шунда уралган икән, килеп күреште, өчәүләшеп һава торышы, шәһәр яңалыклары, гастрольләр турында сөйләшкәләп тордылар. Аргы баштан мәһабәт, күз явын алырлык сылу ИЛ-18 самолеты тәгәрәп килде, күгәрченнәрне өркетеп, кешеләрне саңгыраулатып, тирә-якны шау белән күмде. Мотор гүелдәүләре тынды, бу яктан трап алып киттеләр, аэровокзалның сул ягыннан дәү-дәү чәчәк бәйләмнәре тотып кызчыклар йөгерешеп чыкты, алар каршылаучы өлкәннәрдән байтак алда самолет янына барып җитеп трапның ике ягына тезелештеләр. Ишек ачылды, зифа буйлы стюардессалар чыгып басты, баскычтан, сәламләп, берәм-берәм кунаклар төшә башлады. Кинокамералар җуылдады, Әхәт, операторларны ияртеп, отышлырак ракурс эзләп бер яктан икенче якка чапты, гомуми хәрәкәт, җанланыш, ыгы-зыгы купты. Русча, татарча, немецча сәламнәр яңгырады. Галия Халиковины уртага алып ике яктан сүз ялгадылар. Беренче тантаналы минутлар узды, чәчәк бәйләмнәре кочаклаган кунакларны култыклап шәһәр ягына өндәделәр. Шактый сузылып, аэропорт алдындагы мәйданга чыктылар. Колонналарда безнең кызыл байраклар белән янәшә ГДР флаглары җилферди. Җыелган юлаучылар бик кызыксынып кунакларны тамаша итте, анда да, монда да кул чабулар яңгырады.

Автобусларга утыра башлаганда бая Әхәт белән Идрискә күз текәп узган солтанатлы озын кеше Виталий Петрович янына урта буйлы, коңгырт күзле, немецтан бигрәк Идел татарына охшаган мөлаем бер иптәшне алып килде.

— Танышыгыз, Виталий Петрович, кунагыбыз Курт Карл иптәш шушы була,— диде ул.— Уңайлылык өчен, Курт Францович дип эндәшә аласыз.

Жаденко нәзакәт белән баш иде, татарлардан өйрәнгән гадәте буенча кунакны олылап ике кулын сузды.

— Хуш килдегез безнең Казан каласына! — диде.

Идрис кабалана-кабалана немецча беренче җөмләсен әйтте, Курт аның да кулын кысты.

— Мин сезнең тәрҗемәчегез булам. Үзем журналист. Яшьләр газетасында эшлим,— диде Идрис һәм, Курт аның немецчасын аңлый микән дигән сыман, сынап карап торды.

Курт аны бик яхшы аңлады һәм, бер мәлгә генә Виталий Петровичны көеп торып, Идриснең кайда, ничек укуын, немецчаны болай яхшы нинди мәктәптә өйрәнүен сорады. Идриснең татар теле факультеты бетерүен, немецчаны балачактан өйрәнә башлап, югары мәктәптә ныгытуын, соңыннан үзлегеннән өзмәс укуын тәкъдир иткән кебек тагын бер кат кулын кысты.

— Без чынлап торып танышырга да, дуслашырга да өлгерербез,— диде Курт.

Гәрчә бу сүз аның үзенә генә юнәлтелгән кебек булса да, Идрис аны русчага тәрҗемә итте, Виталий Петрович елмаеп:

— Әлбәттә, әлбәттә,— дип хупларга тотынды.— Без барыбыз да тулаем сезнең карамакта. Ни күрергә телисез, сезне нәрсә кызыксындыра, барын эшләргә тырышырбыз.

Күнелләр кутәренке, минутлар шатлыклы иде. Автобусларга бер-бер артлы кунаклар керде, алар сабыр гына урнаштылар. Идрис таныш «УАЗ»га, Виталий Петрович янына кереп утырды, машиналар юып чыгарылган кебек чиста, яшеллеккә күмелгән урамнар буйлап үзәккә юл алдылар. Машина тәрәзәсеннән ургылып кергән саф һаваны сулый-сулый Идрис куанып:

— Бик шәп яңгыр явып үтте! — дип куйды.

— Да-а,— дип сузды Виталий Петрович.

## 27

Кремль тукталышында арткы ишектән троллейбуска бала нарткән яшь хатын керде. Егерме дүрт-егерме биш яшьләрдәге чибәр генә бу ханымның озынча ак йөзе, куе зәңгәр белән мул сөрмәләнгән миндаль күзләре, ике кулында да бармагы саен дип әйтерлек ахак кашлы калын-калын йөзекләре, озын тәкәббер муены, текә күтәрелгән башы вагондагыларны шундук җәлеп итте. Тик аның косметикада унганлыгын тулаем бәяләп өлгермәделәр, ханым итәгендәге дүрт-биш яшьлек малай ишек ябылуга:

— Утырам! — дип бакырып җибәрде саф татарча итеп. Әллә малайның тавышында чыңгырдап торган усал таләпчәнлек сискәндерде инде, Идрис иелеп малайга карады. Малай әнисеннән чак кына алгарак узып, ялт-йолт карана, маңгаен җыерып, юеш авызын турсайтып үзенә урын бирүчене эзли иде.

Алдагы урыннарда гына түгел, артка да гел өлкәннәр утырган. Башка вакытлардагы кебек, мондый очракларда: «Кил, кил, улым, сыярбыз!» дип җәмиеп тәтелдәүче дә табылмады. Салонда ул хәтле үк тыгыз түгел, малай да бүрек белән бәреп егарлыктан узган, хәйран үк исәйгән борча күренә, хәерле булсын, әнисенең тездән нәкъ бер чирек өскә күтәрелгән итәгенә уралып кайтсын, дип уйладылар, ахры. Тик малай мондый бердәм каршылыкка фетнә күтәрде:

— Утырам, утырам,— дип акырды ул.

Әнисе, озын бармакларын укмаштырып, малайның тузанлы чәчен ышкыды:

— Кычкырма, урыннар юк.

— Утырам! Әнә бар! — дип жикеренде малай күзләрен унга-сулга тәгәрәтеп.

— Анда картлар утыра,— дип пышылдады әнисе,— эби-сәбиләр.

— Утырам! — дип кәҗәләнде малай, троллейбусның тузанлы идәнен бәләкәй үкчәләре белән төеп.

Аның әрсез шыксызлыгы, шөкәтсезлеге, энисенең янтыгына шапышопы бәргәләп тукмарга керешүе монарчы ваемсызрак утырган, җәмәгать урыннарындагы гаугалардан читтәрәк йомылырга яраткан мышт.ыбыйларны да кузгатты, алар «эһем-эһем, кем анда җәнҗал кузгата?» дип, тамак кыргалап, кайсы каян муеннарын сузып малайга карадылар.

Ханымның елтыр күзләреннән мондый игътибар ычкынмады, ул, кызыксынучылардан юбка итәге белән улын томалап:

— Аю биетәләрме әллә? Цирк ачылмаган,— диде.

Итәк тә бик кыска, малай да бик елгыр, ул, этле балыгы сыман, шунда ук уртага шуып чыкты, идән тузанын баягыдан да яманрак туздырып:

— Утырам! — дип кычкырды.

Вагонны сасытып бармасын, урын бирергә кирәк бу фетнәгә, дип икеләнеберәк утырган бер татар апасы, энкәсенең дә малай яклы икәнен сизенеп:

— Чамасыз иркәләгәнсез бу җәфаны,— дип әйтеп салды, түзмәде.

Куплэрнең күнелләре ачы балдай кымырҗап, телләре кычытып килә икән:

— Тотып суяр бу!

— Шушы кадәр тавыш кай төшеннән чыга? — дию ештеләр.

Инде соңгы сүзне энисе әйтер, теле белән тыя алмый икән, һич югында, малайның тикторма с йомшак җиренә бер-икене кундырыр дип өметләнгәндә, ханым яшелле-мөшелле тавыш чыгарып вагондагыларны чукырга тотынды:

— Нәрсә булган минем улыма? Ни лыгырдап барасыз?

— Артык усал дию ебез... Үскәч кем булыр, нишләр...

Бая башлап сүз каткан апа (салмак хәрәкәтләренә, түземле тавышына карап Идрис аны күптән түгел генә пенсиягә чыккан укытучыдыр дип юрады) ханымга иплән кенә, татарчалап:

— Үзең җәфаланасың ич, сеңелем... Алдагы көнендә үкенмәгәен... Терсәк тиз ерагая... Чыбыкны пеше чакта бөгәләр... Борынгылар моны белми әйтмәгән... Үсәр, тора-бара казасы безгә дә төшә башлар,— дип шелтә катыш теләктәшлек белдерде.

Тәҗрибәле өлкән кешенең җайга әйткән йомшак сүзләре ташка төшкән борчак булдылар, башкалар да укытучының фикерен җупләгәч, ана кеше улын җилтерәтеп үзенәрәк тартты да, әле русчалап, әле татарчалап вагондагылар белән пармә-пәр әрепләшергә тотынды. Халык ныграк гөжләде, хатын тәтә-тәтә чәпәләнде, малай, һаман тибенәтибенә:

— Торсыннар, торсыннар! Утырам! — дип нәгъерә орды.

— Үз артыгызны гына белегез! — диде зәһәрләнеп ханым.— Үз балаларыгызны күзәтегез!.. Кичләрен урамга чыгарга куркыныч... Кибет, ашханә төпләрендә кем ауный? Кем балалары анда, ә?..

Ленин районына житеп бер-ике тукталыш уздылар, малай һаман тыйлыга алмады, ханым үзе дә ярсулы усал сүзләренә буыла-буыла:

— Кем балалары кеше үтереп йөри, кызлар көчли? Талый!.. Сезнеке! Җәелеп утырганнар да бер сабыйга урыннарын җәлләделәр... Җитмәсә, телләшеп баралар!

Ниһаять, берәүнең чыдамы сынды, үзе торып, бәләкәй җәнҗалчыга урын бирде, малай ялт итеп менеп утырды.

Байтак пассажирлар төште, яңалары кереп утырды, тимер кассаларда зең-зең бакыр акча чылтырады, малай кызыл теле белән тузанлы соры тәрәзәне яларга тотынды, татар апасы иплән кенә ханым янынарак килде.

— Рәнҗетер өчен сөйләдекме сиңа, юкка тузынасың... Житмәсә улың катында... Ул барын да белеп-күреп тора. «Ата-аналар, сак булыгыз, балалар сезнең рольне уйный» дигәннәр хакимнәр... Безнең балаларны хәкарәтләдең... Кибет төбендә аунаган хәшәрәтләргә карап дөньяның дүрт ягын үлчиләрме?.. Дөрес, андый хинҗирларның булуы барыбыз өчен дә уртак хурлык... Тик безнең балалар турында шундый гыйбрәтне, кара яланы сөйләргә ничек телең барды?..

Аның күңеле тулды, ахры, ул аскы иренен тешләп башын иде, бераз гына тын торды.

— Минә минекеләр... Өчесе Германда ятып калды... Икесе менә дигән урыннарда эшлиләр...

Купшы ханым сару кайната торган төче, тәмсез тавыш белән сузды:

— И-и-и, апакаем-алмакаем!.. Нишлим соң? Туар-тумаста атасы дәҗҗал ташлап китте... Икәүләшеп унбиш тәнкә түләп фатирда, кеше бусагасында интегәбез... Яслегә урнаштыра алмыйм, үзем белән кибеткә, эшкә йөри. Ни күрә дә, ни ишетә бу бала?.. Көне буе кибет ызгышына шаһит булып утыра... Улым алдында матур була алмадым инде, ходай хәерле итсен берүк... Получка алып эчкәч, әтисе карачкы кылә... Аны куам. Фатир хуҗам белән көн аралаш талашабыз... Колынлы бия бер аранга сыямы?..

Идрис аларга якын гына урында басып тора иде:

— Сез кайсы кибеттә эшлисез? — дип сүзгә катышты.

Яшь хатын кырку гына күз ташлады:

— Анысы ниемә тагын?

— Болай гына сорадым. Улыгызны яслегә урнаштырырга ярдәм итә алмаммы дигән идем.

Ул шушы минутта Гринбергны хәтергә алып, Жаденко белән сөйләшеп карарга да булыр дип уйлады.

— Һе,— диде ханым, авызын ямаи җәеп.— Андыйларны да күрдек, ходаем! Тагын бер тәкъва, ярдәмчел Хөзер Ильяс!.. Искергән ысул бу, чибәркәй!..

Идрис ник сүз башлаганына үкенеп, Гагарин тукталышында төшеп калды. Сулдагы китап кибетенә керде.

Аннары «Көз» кафесына кереп сыра эчте. Шуның ишек төбендәге автоматтан Әхәтләргә шалтыратты.

— Яшь кияүгә сәлам.

— Карт кияүгә — теше беткән игәүгә сәламнәр һәм каләмнәр диер иде минем Сибай дус!.. Син нәрсә, ни ултара, ни пултара дигәндәй, кич тә түгел, иртә дә имәс...

— Сагындым. Кәеф юк, картлач.

— Кил безгә,— Әхәт шат кына хихылдады.— Коданың туган көне, мәҗлескә җыенып ятабыз... Хатын ике сәгать буе көзгенең сыйфатын тикшерә... Ике дә уйлама, кил, син кайда?

Идрис җавап бирергә өлгермәде, Әхәт ягыннан ыгы-зыгы ишетелде. Бераздан трубкада Лида тавышы яңгырады.

— Идрис абый, нигә бер дә күренмисез? Ичмасам менә бу юньсез малайны азрак акылга утыртыр идегез.

— Үземә дә житәр-житмәс акылымнан коры калыр хәлем юк.

— Көзге саклый дип яманатымны сата, ә үзе бүген өч кырынды! Өч!

Әхәтнең көлгәне ишетелде.

— Идрис, хатыннарны тыңла, ирләргә ышан! — дип кычкырды ул.

Тагын трубка өчен тарткалаша башладылар, Лида җинеп чыркылдады:

— Кодаларга бүләккә ни алдың дип сорагыз үзеннән, Идрис абый... Адәм көлкесе.

— Нәрсә алды?
— Туган көн — коданыкы... Ә бүләккә хатынына төнге күлмәк!
Тартыша торгач, трубкага Әхәт хуҗа булды.
— Нинди тост әзерләгәнне белсәң син, архигениально!.. Әйтеп күрсәтимме? Хәер, үзең кил, ишетерсең... Мәҗлестәгеләрне аяктан егам!
— Әйтеп кал, монда телефонга чират...
— «Кадерле, бердәнбер кодам!» дип сүз башлыйм... «Синең үзенә генә яраулы бүләк аласым килде... Хатыныңны да, балаларыңны да искә алып тормадым, бары сине куандырырга теләдем! Сиңа гына күңелле һәм рәхәт булсын дидем!».. Шул чагында тегенә төнге күлмәкне тапшырам, шәпме?..
Лида чыркылдады, Әхәт нидер кычкырды, Идрис, хәерле бәйрәм теләп, трубканы элде.
Ары сугылды, бире бәрелде, күңеле кемнедер эзләде, кем беләндер утырдаш, фикердәш буласы килде. Күңелен ачып салырга, җиңеләергә теләде. Ләкин мондый чакларда аның утырдашы, фикердәше була торган җанга якын кешесе бик еракта, еракта иде...
Өенә кайтып үз этажларына менгәндә икенче каттагы Булавиннар ишеге төбендә тукталып звонокка үрелде. Звоноклары үтә йомшак тавышлы икән, әчтән чак-чак кына, тирән базда черки безләгән сыман аваз килде, ул, түземсезләнеп, ишек шакыды, көтте, бүлмәдә кемдер кыштырдады, протез шыгырдап алды.
Карт ишекне киң итеп ачты, Идрисне күргәч, авыз чите белән елмаеп ишарәләде:
— Әйдүк, әйдүк, менә рәхмәт, әйдүк!
— Хәерле кич,— диде Идрис башын иеп.
Җиһазларга артык мул булмаса да, ике бүлмәле квартираның зал ягы зәвык белән җыештырылган иде. Пианино өстендәге хрусталь вазада кып-кызыл пионнар... Чәчәкләр янында дүрт-биш яшьлек бөдрә чәчле малай фотосы... Булавин үзе дә яшь чакта бөдрәч булгандыр, ахры?..
Идәндә озын аяклы кыйммәтле радиоалгыч. Кызыл агачтан ясалган. Стенада алтын сыман сары рам белән каймаланган рәсем. Кара җирлектә салам турап ябыштырып Варшава шәһәренең гербы — кылыч күтәргән ярым хатын, ярым балык рәсеме ясалган. (Якынрак килгәч, Идрис андагы язуны да укыды: «Варшава баһадирларына» дип язылган. Полякча. «1939—45 еллар» дип куелган.)
Карт бер көн алачык буендагы киемнәреннән иде, Идрис шуны хәтерләп:
— Каядыр барырга җыена идегезме? — дип сорады.
— Вәгъдә куелган урыным юк,— диде карт.— Узыгыз.
Идрис, ботинкаларын салып, залга оекчан гына үтте, рәсем алдында тукталып торды, фотоны кулына алды.
— Онытым,— диде карт аңа карамыйча гына.— Улым белән икесен бергә җирләдек..
Карт, чыгарга җыенып, тәрәзәләрне япкан икән, хәзер ачып җибәрде:
— Чәй белән сыйлыйммы үзегезне?
— Рәхмәт, берүк мәшәкатьләнмәгез. Ашап-эчтем инде.
— Чәйдән дә куәтлерәген тотмыйм, яшьрәк чакта аз-маз шаяргалый идем... Спиртны стаканы белән каплаган чаклар да булды, хәзер чәй белән генә дус... Кофены бик яратам да, ярамый... Картлар организмына карап медицина китаплары язарга була.
— Бирешердәй түгелсез,— диде Идрис, картның исемен белмәвенә кыенсынып.— Казакълар әйтмешли, ажарыгыз әйбәт күренә!
Карт игътибар белән:

— Казагыстанда торганыгыз бармы? — дип сорады. Аның бу сорауны юкка гына бирмәве күренеп тора иде.

— Студент чакта ике ел рәттән чирәм җирләрдә булдым. Берсендә Көкчәтауда. Казакълар белән аралаштык, аз-маз сукалый башладык.

— Ярый, ярый, ил күрүнең зыяны юк,— диде карт нидер уйлап. Сүз бетеп киткәндәй булды.

— Газетага син яздыңмы? — диде карт бераздан.

— Мин.

Кухнядан мыраулап зур йөнтәс койрыклы себер песие килеп чыкты, картның протез аягына килеп сырпаланды, җылы тапмагач, исән аягы ягына күчте.

— Мурзик, эх, Мурзик,— диде карт, мәчене иркәләп.— Я, хуш, Идрис туган... Атың шулай бит? Эш ни белән бетәр дисең инде?

— Мин кемнедер куркытырга, җәзаларга теләмәдем. Беркадәр Нина Михайловнаның күңеле күтәрелсен дә башкаларга сабак булсын дип яздым.

Идриснең җавабы ошады, карт сүрән генә елмайды.

— Үзең ни эзләп кактың инде минем ишекне?

— Кайтып барышлый,— диде Идрис тә, иелеп песине иркәләп.

— Ул да бер эш... Рәхмәт, искә алуыңа. Мин менә шушы чиглектә яшәп ятам... Эш урыным да, ялым да, йокым да шушында... Нина өйдә чакта сизелмәгән иде, бик кин, артык зур икән безнең бүлмәбез... Ә Нина... Нилләр генә әйтсәң дә килен кеше... Бүген бар ул, иртәгә юк дигәндәй... Син кереп күңелне күтәрдең. Кергәлә, ирекмәсәң гел кер! Китапханәм зур гына минем. Тарихи китаплар байтак кына... Мәсәлән, мине 1552 елда дөньяда нилләр булуы кызыксындыра. Илләр ничек яшәгән, халыклар кайсы баскычларга менеп җиткәннәр. Франциядә кемнәр булган? Майя дәүләтендә ул чакта ни булган?.. «Шәрыкнең югалган культуралары» дигән сериядән китаплар алып торам. Мәскәүгә язам, Фәннәр академиясенең китап кибетенә... Фашизмның килеп чыгу сәбәпләрен өйрәнәм... Яшьләр арасында берәрсенең «Фашизмга каршы көрәштә татарлар» дигән китап язарга җыенганы ишетелмиме?

— Ишеткәнем юк.

— Язарга кирәк андый китапны!.. Татарлар турында тегене-моны чәйнәп йөрүчеләр күрсеннәр... Петр Гаврилов, Муса, Бакый, полковник Мөҗәй... Синең колагыңа чалындымы икән, атаклы Карбышев та татар токымыннан килә бугай...

— Шулаймыни?

Картның күп белүенә, хәтеренең ачыклыгына хәйран калды Идрис, вакыт узганы да сизелмәде, алар ярты төнгәчә әңгәмәләшеп утырдылар.

Троллейбустагы очрашу турында гына сөйләшергә дип кергән Идрис, бөтенләй яңа кеше белән танышып, ахыр чиктә аның исемен дә белмичә чыгып китте.

Үз бүлмәсен ачып кергәч ул һаман шушы карт турында уйланды. Яңа килгән газеталарны диванга таратып ташлагач кына фикерләре бераз читкә таралды, тагын шул тирәгә әйләнеп кайтты, газеталар хәвефле хәбәрләр белән тулы иде.

Израил үзе басып алган гарәп җирләреннән баш тартырга уйламый... Димәк, монда яман шеш тулышып кала...

Вьетнам... Кытай... Куркынычлы фашизмга әйләнеп барган маоизм...

Күпме яман шешләр сарып алган җир шарын?!

«Нейес Дойчланд» соңгы номерларында Көнбатыш Германиядә фашизмның балалык биләвеннән чыгып аякка басуы, дәүләтнең эчке

һәм тышкы сәясәтен билгеләүдә куркынычлы көчкә әверелүен күп фактлар белән дәлилләп язып чыккан.

Тагын Германия... Тагын сыраханәләрдә ташый башлаган милләтчелек, фашизм... Тагын «Дойчланд, Дойчланд, юбер аллес!»

Кайчандыр Европаның механика мастерское дип аталган Германия...

Тельманнар, Либкнехтлар иле... Әле бик бәләкәй чакта Идрис Вилли Бредельнең татар телендә басылган «Сыналу» романын укыган иде. Фашизм белән беренче танышу... Икенче танышу әтисенең үлемен хәбәр иткән кара пичәтле кәгазьне алгач булды... Ленинградның Пискарев зиратында булганнан соң, ул өч көн сөйләшә алмыйча йөрде...

Бер гасыр эчендә бөтен илләрне ике тапкыр дер селкеткән, җир шарындагы бар халыкларның үсешенә йогынты ясаган көчле дәүләт. Тагын синең кырларыңда шытып чыккан кара чума илдән илләргә җәелерме? Тагын кайсы буыннарны көлгә әйләндереп Европа кырларында таратырга көч җыясың син, Германия?..

Идрисне юаш диләр...

Әнкәсе шулай ди торган иде, Әхәт тә шулай дип атый.

Аны юаш иткән дә Германия... Юк, Фрейд бу юлы ялгышкан, Идристә берниндиди «комплекс неполноценности» түгел, анда ни барысы «комплекс сиротства» гына...

Менә шушы Германиянең вәкилләре Казанда йөриләр. «Хуш килдегез дә хуш килдегез!»

Сүзләр генәме болар?

Юк, болар өмет, ышаныч, ныклыкны сынау. Германияне бары Германия генә тыя ала!

Киләчәк...

Бала...

Дилә терелеп кайтыр да Идриснең үз улы булыр. Үсәр. Бая очраган башкисәр малай кебекләр белән бер парта артына утырыр.

Идрис аны нечкә күңелле, матурлыкны һәм гаделлекне ярата торган бала итеп тәрбияләргә тырышыр. Ул, һичшиксез, басымчак, сүз тыңлаучан, вәгъдәчел малай булыр...

Ә күршедә генә, яки кайдадыр, кемнеңдер сыңар кара канат астында бер башкисәр үсеп өлгерер...

Идриснең улы отличнога укыса, теге аны түкмар...

Җәмәгать эшләренә актив катнашса, «ялагай» дип күзен ачырмас...

Бәдрәфтә бикләнеп тәмәке тартмаса, «манка» дип мыскыллар...

Матурлык тудырырга юнәлтелгән малай ике дөнья, ике мәгънә, ике фикер арасында кыйналып үсәр.

Укып, һәйбәт кеше булгач та, аны берәүләр яратмас. Троллейбуста аның кабыргаларына төртергә тырышырлар. «Күзлек!.. Эшләпә кигән салам сыйрак... Интеллигент аламасы!» дип астыртын да, өстертен дә һаман аны кысарлар.

Димәк, балаларны яхшылыкка гына түгел, шул яхшылык өчен көрәшергә дә өйрәтергә кирәк икән. Ләкин ничек?

Китаптан укыпмы?

Тормышта үзен бәхетсезлекләр, сугышлар, бәрелешләр, фашизм, атом бомбалары көткәнен балаларга ничек аңлатмак кирәк?.. Ничек телең барыр?

Газета-журналларда «яхшы балалар тәрбиялик!» дип бер-беребезне үгетлибез. Яхшы кеше булачак балалар белән рәттән эгоист, карак, палач, бюрократ буласылары да көч җыеп ятмыймыни? Яшьтән үк балаларга моны ничек аңлатасың?

Командировкаларның берсендә Идрис Сарман районына барып чыкты. Теләнче Тамак авылында элеккеге икмәк сәүдәгәрләре, атаклы бояр Хәлфиннәрнең бакчалар эчендә утырган таш пулатларында за-

гыйфь зиһенле балаларның урта мәктәбе урнашкан икән. Зәнгәр чынаяк белән тышланган мичле, түшәмнәре бизәкле кияү бүлмәләрендә төрле чикләрдән җыйналган балалар яши. Тормышның төрле катаклизмнары тудырган бу яшь кешеләргә мастерскойлар, уку, ятак бүлмәләре, китапханәләр, тәрбиячеләр, укытучылар бирелгән.

Киләчәктә, үз буын вәкилләре бөтен тармакта хәлиткеч көч булып әверелгәндә, болар да үз чордашларының җилкәсендә имгәк булып ятмаслар, файдалы берәр хезмәткә ярарлар.

Фашизм мондый балаларны кырып бетерә. Фашизм — эвтаназия яклы.

Социалистик дәүләт мондый балаларның киләчәген хәл итү юлын тапкан...

Ә яшертен дегенератлар, караклар, үтерүчеләр белән нишләргә?

Аларны кая куярга?

Әйтик, мылтыгын кеше кукрәгенә төбәргә чирканмаган сипкелле малайны ничек кеше итәргә? Булавин карт әйткәнчә, яхшылык белән тәрбияләргәме?

Яхшылык барын да җиңәме?..

## 28

Идрискә бүген йокы тимәскә язган икән, мендәргә башын төртеп изри башлауга, ишек дөбердәттеләр, бүлмә шомлы тавышлар белән тулды. Тозакка эләккән кош кебек, звонок чырылдады, аңа ияреп тагын кактылар. Таяк белән төяләр сыман, ишек саен алпан-тилпән ышкылып, сәрхүш-сукбай йөрмидер бит?

Ул, торып, диван астыннан чүкеч алды, киереп ишекне ачып җибәрсә, коридорда калын йон свитер кигән Булавинаның әтисе тора.

— Йоклый булгансыңдыр,— диде ул, уңайсызланып.

— Яткан идем,— диде Идрис, чүкечен артка яшереп.

Карт чатанлап эчкә үтте, тар коридорда аның йомшак свитеры Идриснең ялангач тәненә тиеп сискәндерде.

— Киен әле, тиз бул!

Идрис, ут яндырмыйча гына, чалбарын киде.

— Ятьрәк, ятьрәк,— дип кабаландырды карт.

Иелеп туфляларын эзләгәндә ул тагын картка орынды, чүкечен ташларга онытып тора икән, аны ыргытты. Беренче эләккән аяк киеме — үргән каеш чабаталарны ялан аякка элеп, карт артыннан коридорга чыкты. Аска төшә башладылар.

Ни булды икән тагын?

Карт икенче катта тукталмады, авыр чатанлап, аска төшеп китте.

— Ашыгыйк.

Ишек алдыннан урамга ук чыктылар.

— Теге якка чыгыйк,— диде карт, кулы белән изәп.— Әйдә!.. Күрәсеңме?

Болын ягында күктә сыек кына кызыл шәүләләр уйный.

— Әнә! — дип кычкырды карт.— Йөгер!

— Кая?

— Ачкычны ал да чап тизрәк.

Идрис һаман анышып җитми иде, орчык төсле түгәрәк, борау башлы авыр ачкычны тоткач кына ул капкын төсле борынгы хәтәр йозакны хәтерләде.

— Мөгаен, алачык янадыр,— диде карт.

Ул җан-фәрманга чабып китте, бәйләмәгән чабаталары, куркынган кошлар кебек, үзен узып очып чыктылар, ул чапкан шәпкә иелеп аларны кулына алды да бара бирде.

— Этләрне коткар! — дип кычкырды аның артыннан титаклап килүче карт.

Ике-өч йөз метр чабып узгач, аның эчен кату алды, ул мышкылдап адымнарын сирәгәйтте, шул чакта аны янгын машинасы куып житте. Ул, нур көлтәсенә эләккән кыр куяны кебек арлы-бирле сикеренгәләп, ачкычын күтәрде:

— Туктагыз, тукта! — дип кычкырды.

Кая ул туктау, тегеләр төнге дымык һавага ачы бензин исе бөркеп узып та киттеләр.

Алачык яна!

Ул барып житкәндә янгынчылар әллә кайчан килгәннәр, машиналарын бер кырыйда туктатып, тыныч кына тәмәке көйрәтеп басып торалар иде.

— Этләрне... Рексны коткардыгызмы? — диде ул, көчкә тын алып.

— Нинди этләрне?

— Анда... эчтә!.. Рекс!.. Балалары белән...

Алачыкны түбәсеннән нигезенә кадәр ут чолгаган иде, Идрис өтәләнеп ары-бире каранса да, утка якын атларлык түгел, ул, битен куллары белән каплап, янгынчылар янына чигенде.

Чытырдап янган алачык аның күз алдында янтайды һәм, көлтә-көлтә очкыннар чәчеп, бер якка ишелде.

— Соң иде инде,— диде янгынчыларның берсе.

— Токымлы, әйбәт этләр идеме?

— Яхшы хужа әйбәт этне монда асрыймы? — дип каршы төште янгынчыларның озыны.

— Түгел лә... Жан иялəре бит,— диде әрнеп Идрис. Ул Айдарны, Рексны хәтерләп күзен йомды...

— Кем курасы бу? Безгә акт төзәргә кирәк!

— Хужасы юк аның.

— Ә этләр кемнеке?

— Ул хәзер килеп житәр.

Идрис күзе күнеккәч кенә абайлады: якын-тирәдә янгынчылардан тыш та кеше байтак икән. Элегрәк тә бер машина килгән булган. Яшь-жилбәзәк, үсмер кызлар-егетләр бармаклары белән төртеп күрсәтеп көлешәләр. Янгынчыларның берсе вакыттан файдаланып анекдот сөйләп маташа:

— Бер авылда үтә чыккан фәкыйрь бәндә яши икән. Йорты да шул, кем әйтмешли, эт оясыннан чак кына калкурак, имеш. Бер заман кече учагыннан идәнгә ут төшеп өе яна башлаган бу бичараның. Бөтен авыл жыелып пожарны тамаша итәләр икән... Өе тәмам янып беткәч, теге кеше авылдашлары катына килгән дә: «Үпкәләштән түгел инде, жәмәгать, пожарым да кешенеке төсле рәхәтләнеп карарлык булмады» дигән.

Аның тирәсендәгеләр көлештеләр.

Идрис тагын бер кат алачыкны әйләнеп чыкты. Янгынчыларның берсе — ул башлыклары булды, ахрысы:

— Кайда соң синең хужан? — дип йөдәтте.

— Килер, килер,— диде ул, аныклап тормыйча.

— Шәһәрдә бер синең иске тартмаң гына яна дип уйласаң, ялгышасың.

— Чак кына көтегез. Инвалид ул, аяксыз.

— Ә-ә,— диештеләр янгынчылар.— Алайса иртәгә үзе депога титакласын. Кайдалыгын беләсезме?

— Табарбыз.

— Иртүк керсен. Әйтергә онытма.

— Ярар, ярар.

Машиналар шатыр-потыр кузгалдылар, тамашачылар таралды, юашланып ингән учак кына ара-тирә тавыш биреп яна, картның килеп җитә алганы юк. Идрис аптырап аңа каршы китте. Монда килеп йөрүдән мәгънә дә юк иде, борып алып кайтырга кирәк.

Ут җылысыннан чыгуга, аны салкынча һава бөтереп алды, юеш уләннәр «чабата» ачыгыннан кереп ялан аякны кытыклады. Идрис янгыратып кат-кат төчкерде. Шәһәр ягыннан кара күләгә кыймылдавы күренде.

— Идрис!

— Барып җитеп булмады,— диде Идрис.

— Эх, мескеннәр, мескеннәр... Үкереп машина узгач та күнелемә шик төшеп утырды бит... Акылны җыеп, сине иртәрәк кузгаткан булсам!..

Карт йөгәнгән, туктаусыз гыжлый, кул белән бугазын, аяк асларын капшый, күкрәгеп уа.

Ул Идрисне уятып алып чыгуның да, хәзер кире борып китүнең дә уңайсыз икәнлеген аңлый, әмма алачык янына ялгыз барырга теләмәү аның оятын җиңде. Алар мыштырдап барып җиткәндә алачык тагын да ингән, ялтыр-йолтыр җемелдәшкән вак күмерләр яткан ат хәтле генә өемгә әйләнгәннәр иде.

— Абзый,— диде Идрис,— һаман исемегезне сорарга онытам.

— Һашим минем исемем,— диде карт сихерләнгән кебек уттан күзен ала алмыйча.— Авылча әйтсәк, солдат Һашим.

— Сез дә авылдан килдегезмени?

— Шунда тудым.

— Ни өчен солдат дәрәҗәсен бирделәр?

— Анысын кем белсен,— диде Һашим ачыкларга теләмичә.— Эх, көчекләр җәл... Этләрдән бигрәк малай җәл!.. Чак кына торыйк әле шушында, Идрис! Аякны чак кына рәткә китерим инде. Чиләндердем.

Ул кин генә такта кисәге табып шуны учак янынарак китерде, таягына тотынып утырды, чалбар балагын сыдырып протез каешларын ычкындырды. Тубырлы ярасын җилгә куеп, тездән югарырак киселгән ботын ике куллап күтәреп торды.

— Бәйләшимме? — диде аның яраларына карарга читенсенеп Идрис.

— Үзем. Серен белмисең син аның...

Карт кесәсеннән чиста кулъяулыгы чыгарды, аны учы белән таслап дүрткә бөкләде һәм мөмкин кадәр күпертеп ярасына каплады.

— Берәрсе тәртмәде микән, Һашим абый?

Протезын бәйләп бетергәч, ул иплән кенә калкынды, чалбарын какты.

— Анысын беләбез,— диде ул әрну катыш.

— Теге малайлар үчегәме?

— Шулар булмыйча... Кичә мин алачыкта кунган идем...

— Менә явызлар! Иртәгә үк милициягә хәбәр итегез, Һашим абый.

Карт күзләрен кысыбрак аңа карады:

— Нәрсә дип хәбәр итәргә?

— Җәзасыз калдырып булмыйич! Бүген ут төртәләр, иртәгә пычак тотып караңгы тыкрыкка чыгарлар.

Һашим аны куәтләмәде, каршы да төшмәде, ашыкмыйча гына, картның титагы җаена кайта башладылар.

— Беләм мин ул малайларны, байтактан күзәткәләп йөрим... Этлеккә маһирлар, шөбһәсез... Ярар, төрмәгә тыктырдык ди... Нинди нәтиҗә булыр?.. Аннары синең уйлаганын бармы, безнең халык гаҗәп миһербанлы, шәфкатьле бит ул... Аның асыл сыйфатларының берсе шул... Бик бәләкәй чакларда ук хәтеремдә калган... Авылның иң очын-

да. Имән урамында, Гыймади абзыйлар яши иде. Бала баскан фәкыйрьнең фәкыйре, башында как түбәтәй, аягында өч йөз мыеклы чабата... Гомергә нужадан башы чыкмады. Авыр еллар, керосинны әҗәл даруы күк кенә тоталар, кругом кытлык, әнә шул Гыймади абзый буран-кыянда, көзге явымлы кара төннәрдә басуга караган ян тәрәзәсендә бер чакта да ут сүндермәгән... Хәлдән таеп, дөньяга кул селкеп авә-түнә кайткан чакларда шул чак-чак кына җемелдәгән утны күрер идек тә, эчкә җылы керер иде, дип әткәй мәрхүмнең сөйләгәне бүгенгедәй хәтеремдә... Ә мәрхәмәтсез, саран, кансыз кешеләрне тирә-юньгә бер итеп данга чыгаралар иде. Бусын да үзем яхшы беләм... Гражданнар сугышы бетеп килә, авыл юлларында карга өерләре сыман котү-котү хәерчеләр йөри... Авылыбыз уртасында таза хәлле Салихҗан бар иде. Каралты-курасы кош очып чыгалмас... Үзе үтә чыккан бер карун! Кунакка дәшмәс, үзе дә йөрмәс, карангы төшүгә капкасын бастырык белән терәтер дә янына арба кендеге салып ятып йоклар... Хәерчеләр шуның капкасына сиздермәстән кара тамга салганнар... Юлда бер-берсен очраткач хәбәр алышалар икән. «Фәлән авылда, фәлән карунның капкасына шундый-шундый тамга булыр, ана кереп йөрмәгез!».. Үзе күптән гүр иясе булды. Шуның улы, нәсел-нәсәпкә, тилчә-тамырга дигәндәй, әткәсенә бик охшаган иде! Кулы гарип булгач, сугышка да бармады... Әле былтыр авылга кайткач шуны ишеттем... Әтисе сыңары, гомер-гомергә түренә кунак уздырмаган карун, алтмыш яше тулгач, шаукымга ияреп, юбилей оештырырга ниятләгән. Ике сарык чалып кунак өндәгән.

— Һәм берәү дә килмәгәнме?

— Ашыкма! Өендәге лампочкаларга хәтле алыштырган, тәрәз пәрдәләрен күтәргән, сакал сыпырып шәбәеп кенә кунак көтә... Капка да шыгырдамый, ишек кагучы да юк, мунча алдына кертеп бәйләнгән усал эт тә өрми... Ярты төнгә хәтле көтәләр тегеләр, аш-су әзерләүчегә кергән күрше-күләннән башка берәү дә килмәгән... Капкаңа салынган кара тамга онытылмый ул, Идрис, кара сакалны юып кына агарта алмассың!

Урамга керделәр. Айдарлар өе яныннан узганда Идрис тукталды:

— Малайга нәрсә диярбез?

— Дөресен әйтербез... Дөньяның бар ягын да белеп үссен!

— Белеп үсүе кирәкме икән? — дип сорады Идрис үзенең күптәнге шикләнүләрен хәтерләп. Карт җавап бирмәде, бераздан:

— Театрларга баргалыйсыңмы? — дип сорады.

— Кышын яңа спектакльләрне калдырмыйм.

— Болай, кушканга, газета өчен генә йөрисеңме, әллә күңелеңдә ихтыяҗың да бармы?

— Яратып йөрим.

— Әйбәт. Мин дә йөрим. Менә син «Кояш илендә» дигән спектакльне карадыңмы икән?

— Газетада рецензия бирдек.

— Шулай укмыни? Үзең карамадың алайса?.. Алай... Ә, минемчә, нигез фикере начар ул пьесаның... Чак кына хәл алыйк. Тыңлачы... Бер башкорт хатыны немецларга әсир төшә. Фронтта була бу хәл. Нурия исемле... Батыр хатын була башкорт Нурия, хәтәр, Салаватлар токымы! Мең хәйлә, мең җәфа белән концлагерьдан кача!.. Немецтан качу, ай-һай, зур эш ул, Идрис!.. Тагын әләгә бичара, каптыралар тегене... Тынмый бахырҗан, җәһәннәмнең тугыз боҗрасын өзеп, тагын ирекә чыга. Шулай бер заман яраланып, канга тузып җан биреп ятканда, елга ярыннан моны тегермәнче бер итальян табып ала. Фашистлардан яшереп өенә алып кайта, дәвалый, ашата-эчертә, тәрбияли, кыскасы, үзенең батыр, кешелекле икәнлеген күрсәтә... Нурия аякка баса, җәрәхәтләре төзәлә, тегермәнче тол кеше икән, тора-тора мәхәб-

бәтләре төшеп, болар өйләнешеп тә куялар... Сугыш бетә, Нурия ире белән Италиядә яшәп кала, бала-чага үстерә, ләкин ямь тапмый, бер мизгелгә дә туган илен, анда калган кызы Айнурны онытмый... Көн талпына, төн талпына туган иленә, бер заман ирен иртәп, сагынып-саргаеп «Кояш иленә» кайтып әлгәшә... Өендә бертуган абыйсы, җитеп килгән кызы яшәп яталар... Яшьли авылда бергә уйнап үскән ахирәтләре дә исән-сау... Нуриянең шатлыгының чиге юк... Шуннан спектакльдә адәм акылы ирешмәслек, кеше күңеле кичермәслек могҗизалар башлана. Авылдашлары, туганнары ничә еллар тәмуг газаплары кичергән, аерылу сагышыннан саргайган, тәнен немец-фашист яралары чуарлаган Нурия белән юньләп сөйләшмиләр дә, тыр-пыр килеп борын чөеп йөриләр! Гаеплиләр мескен Нуриянe, ник туп-туры туган иленә кайтмадың дип күзен дә ачырмыйлар... Шунда бер урын бар, Идрис туган, залда утырганда чәчләрем үрә торды... Теге авылдагы дүрт ахирәте, яшьлегенең җан дуслары «капиталист күрергә» дип Нурияләргә киләләр. Нурия янына түгел, юк, капиталист карарга ниятләре. Хуш, килсәләр, чыннан да аның ире өйдә... Кунак каршылап өтәләнеп йөри бичаракай, өтәләнеп. Нурия чит-ят җирләрдә үз илен сагынып, ахирәтләрен, аларның гореф-гадәтләрен гел телгә алып торган икән. Итальян боларның барысын да хәтеренә сендереп барган, шуңа күрә хатынының дусларын үз итеп, якын итеп каршы алам дип торганда, гап-гади авыл хатыннары бөерләренә таянып, шифырт-мифырт сәхнә әйләнергә тотыналар. Әби патша заманындагы чөйгәк борынлы вельможалармыни! Нурия кайтып керә, теге хатыннар бер авыздан: «Юк, безнең мондый ахирәтебез юк, сине танымыйбыз», дип чатнатып йөзгә бәреп торалар... Безнең кояш илендә шундый шәфкатьсез, мәрхәмәтсез кешеләр яшимени?.. Дус-дошманны яхшы аерырга кирәк, анысына иманым камил. Дошманга мәрхәмәтсез була белү — егетлек. Әмма кулың төз атмый икән, дошман дип дусның күзен чыгарып куюың да бар. Бусы инде яманнан да хәтәррәк, Идрис туганым!

Якында гына этәч кычкырды. Идрис гаҗәпсенеп як-ягына каранды.

— Ә, бу әнә теге, бишенче йортта бер Хуҗа Насретдин балконында этәч асрый. Көндез йөрергә алып чыга.

— Кызык кеше.

— Шулай... Күп сөйләп вакытны алдыммы?

— Киресенчә, Һашим абый...

— Менә баягы сүзгә куәт: шуны гына сөйлим дә йокларга бик вакыт... Арча ягына сабан туена бардым быел... Ат чабышын карарга яратам!.. Җиде ат китте. Берсеннән-берсе сылу, зифа атлар, су сөлекләре сыман менә!.. Чабыш узды, баш килгәнгә дә, икенче, өченчегә дә мул-мул бүләкләр тапшырдылар... Монысы гадәттәгечә, анысын үзеңнең дә күргәнең бар. Менә бервакыт мәйданга ахыр калган җиденче ат кайтты. Бар халык, аерата карчык-корчык, кыз-кыркын шуны камап алмасыннармы... Сөяләр, ялларына чәчүргеч бәйлиләр, атменәргә хушбуйдыр, сабындыр, яулыктыр бирәләр... Малайның башына укалы кәләпүш тә менеп утырды, алган бүләге кочагына сыймый... Ахыр калган атка дип дөнья хәтле бүләк адарынып куйганнар икән... Ни өчен дисеңме?.. Хикмәте дә шунда аның, Идрис туганым, артта калганны җәллиләр, ул бахыр, аның да күңеле борлыкмасын дип телиләр. Менә нинди юмарт бит ул безнең халык!.. Мин халкыбызның ачулы чагын да беләм, ләкин быелгы сабан туен хәтерләсәм, күңелемә чык куна... Шушындый халыктан әнә теге сипкелле малай килеп чыккан... Йогышсыз, хулиган бала. Менә сизәм, утны кем төрткәнен дә аңлыйм. Әле ярый бүген анда куна калмаганмын! Алар бит мина яман усал янадылар... Барын белеп йөрим... Тик алар белән ниш-

ләргә кирәклеген генә төшенеп җитмим... Бәлки син беләсеңдер, әйт?.. Дөнья хәлләре бик катлаулы, бик авыр...

Идрис Һашимны икенче катта калдырып тыныч төн теләде. Акрын гына өченче катка менде. Су җылытып аякларын тыгып утырды, барыбер тиз генә җылынып, йокыга китә алмады.

Кояш чыгып килә иде инде. Якында гына бик куанып тагын әтәч кычкырды.

— Фетнә! — дип көлде Идрис йокы аралаш...

## 29

Кунакларны түземсез борчылу белән көтсәләр дә, әллә ничек кенә булып чыкты: Курт Карл өченче көнен Казан каласында йөри, автобус ишеге төбендә кул кысышып күрешкәннән бирле Идрис белән аларның очрашканнары да юк.

Оргсинтез заводына да, дөньяга атаклы мехкомбинатка да, продукциясен кырык илгә чыгара торган сантехприборлар заводына да туристларны группалары белән алып бардылар. Мехкомбинаттан чыккач, аларны Боровое Матюшино белән — Иделнең иң гүзәл урыннарының берсе белән таныштырганнар. Монда Яшьләрнең Халыкара лагере төзелеп ята. Бусы Курт өчен яраган. Үзе архитектор кеше, чигеш үрнәге кебек сихри бизәкләр белән чорналган ял итү йортларын күреп куанып кайткандыр. Идел матур, табигате искитмәле, чөгә ухасы белән дә сыйлаган булсалар...

Шушыларны сөйләп Рәкыйп Идрискә авызын ерып карап тора:

— Беренче тәэсирләреңне уртаклашып мәкалә бирер идең, картлач!

Идрис, чебен куган төсле, кулын болгады:

— Кунагымны очрата алмавым турында зар-интизарлы бәет чыгарсам гына инде!

— Нигә тузынасың?

— Соң, Рәкыйп абый, тоталар да я заводка, я фабрикага алып китәләр. Жаденкога аңа нәрсә, шатлана гына.

— Завод-фабрикаларга йөртмәс идеңмени?

— Йөртер идем, ләкин өер белән түгел. Болай автобуска утырып выжлап килеп керәләр дә парадтагы сыман күренеп кенә калалар. Буржуй-мазар килсә, ярар инде, күзенә тотен җибәрер идең дә вәссәлам. Болар бит дуслар, фикердәшләр, коммунистлар, комсомоллар. Өер белән йөреп ничек фикер алышмак кирәк?

— Кыскасы, мәкалә булмый дисең инде?..

Җитмәсә Лида үртәп, үчекләп шалтырата:

— Интуристлар белән эшләү кыенмы, Идрис абый? Мине музейга гид булып урнашырга кыстыйлар...— ди.

Үз хәле үзенә көлке тоелды Идриснең. Аны соңгы көннәрдә эштән берникадәр азат иткәннәр иде, егетнең борчылуын күреп Рәкыйп аны чакырып кертте:

— Рәхәткә чыккансың, картлач, койрыкны сыртка салма, иртәгә «Саф баш» булырсың. Нурания чирләп тора,— диде.

«Саф баш» — газетаның иң соңгы кеше булып укып, бүтәннәр күрми калган хәреф һәм мәгънә хаталарын чүпләп, төнге берләргә кадәр редакция белән типография арасында чабучы кизү. Ул газета басыла башлагач кына өенә кайтып китә...

Көндезге эшләрне тәмамлап, «сафбашлык» вазифасына керешәм дигәндә генә Жаденко шалтыратты:

— Сәлам, матбугат уңганнарына!

— Исәнмесез, Виталий Петрович, туристлар алласы!

— Шаяртмагыз, иртәгә кунак безнең карамакка күчә. Сәгать унга «Волга» гостиницасына килегез.

— Сәфәр кая?

— Иң әүвәл шәһәр советына визит... Чак кына иртәрәк килсәгез дә ярар, киңәшеп куярбыз...

— Тырышырмын.

Эш арасында ул Диләгә, әнисенә озын хатлар язды...

Эшенә нокта куеп Матбугат йортыннан чыкканда төнге ике иде. Кызык, ике төн рәттән инде ул таңны аяк өстендә каршылый. Яп-як-ты... Кольцо ягына карап троллейбус юклыгына ышангач, ул сызгы-рына-сызгырына трамвай тукталышына юнәлде. Цирк төзелешендәге төнге смена эшчеләре кыймылдыйлар, сыртлап такта төялгән лесовоз янында өч-дүрт ир ялкау гына тәмәке тарта. Трамвай да күренмәде. Тик торып аны йокы басты. Ул чайкала-чайкала Кремль күпере төбенә китте, ябыша-ябыша таш койма аша чыкты, тиз-тиз шыр ялангач кал-ганчы чишенеп ташлап суга йөгереп төште. Шыпыр-шопыр йөзә баш-лады. Федосеев дамбасы астында берән-сәрән бөкшәйгән балыкчылар күренде. Идрис кырыннан борынына дүрткел җәтмә эленгән көймә пыр-пыр узды. Шактый йөзгәч, инде судан чыгарга ниятләгәндә яр өстеннән килгән тавышларга башын күтәреп караса, таш койманы буеннан-буена ап-ак күлмәк кигән кызлар һәм кара костюмнарын иңнәренә салган купшы үсмер егетләр сарганнар. Арада берәү гитара чиртә, башкалар Идрискә кул болгый-болгый Идел дулкыннары, кояш нурлары турында күңелле генә җырлап җибәрделәр.

Унынчы класслар ич болар!

Чыгарыш кичәсеннән соң мәктәп белән, үсмер чаклары белән төн ката саубуллашып йөриләр. Нурания шулар турында репортаж яз-ган ич!

— Әһә-һе-һей!

Ул, яр буйлап арлы-бирле йөзә-йөзә, яшьләргә кычкырды.

Идриснең төнге икедә япа-ялгыз су коенуын мәзәк иткән укучылар, шукланып бии-бии, һаман җырлашып тордылар.

— Һәй, абый, унбиш тәүлектән котылып чыктыңмы?

— Гонаһларны юасыңмы?

— Хатын өйгә кертмәдеме?

Тын су өстен зыңгылдатып, Ленин дамбасыннан вокзал ягына трамвай узды, ул вокзалдан әйләнеп килгәнче Идрис судан чыгып кие-нергә, тукталышка барып өлгерергә тиеш. Яшьләр һаман өстә тапта-налар. Ул туна башлады, ярга карап басты да куырылып тик карап торды. Ниһаять, егетләрнең берсе сизенеп нидер әйтте, җыйнаулашып акырышып көлештеләр дә гитара чиртә-чиртә дамба өсләп китеп бар-дылар.

Ерагайган саен аларның җырлары моңлырак ишетелде, үзләре дә иртәнге тоныкъ яктылыкта әңгер-меңгердә илереп йөргән йокы белмәс ниндидер гаҗәеп сыннар сыман серлеләнә баралар иде.

Ул тиз-тиз киенде дә таш койманы сикереп чыкты. Озакламый, буп-буш вагоннарын чайкалтып, трамвай килде. Идрис сикереп менде, борыны белән тезен чукый-чукый утырган кондукторларны уятырга те-ләмәде, елмайды да дәшмичә барып басты.

Урам себерүчеләр, төнге эзләрне көндезгеләр күзеннән бөтенләй югалтырга теләгән сыман, чыжтыр-чыжтыр тротуарларда селтәнәләр. Кешесез урамнар, тәмле икмәк исе таратып узган машина-фургоннар, эленке-салынкы гына янтаеп утырган такси шоферлары...

Шуларны күзәтеп кайта-кайта озын юл кыскарды.

Көнчыгыш офыкта каурый сыман болытлар! Таң туа, көн килә!..

Яту белән эреп, нәвен базына чумган Идрис иртәнгә сигезгә кадәр кыймшанып та карамады.

Иртән автоматтан Рәкыйпкә шалтыратты:

— Хәер-фатихагызны җәлләмәсәгез лә, тәкъсир.

— Ә, синме бу Идрис-хаҗи? Сәяхәт башланамы?
— Бисмилласын әйттек.
— Акыллы йөр димим, ышанам... Мөмкинлек барда әзеңне дулкын астына яшермә, координатларыңны, хәлеңне без дә белеп торыйк.
— Кулдан килгән хәтле, тәкъсир...
— Газетаны карап утырам.— Трубкада кәгазь кыштырдаганы ишетелде.— Әйбәт кенә чыккан!
— Мәгънәсезрәк эшкә тарымадым микән мин, Рәкыйп абый? — диде Идрис, чигәсен кашып.— Яргыч чыгырына бәйләнгән ат шикелле бер урында таптанасы килми... Чыгыр әйләнсә дә ат бер урында тора! Тора-тора да сукырая. Яргыч атына күз кирәкми, рудиментка әйләнә.
— Юк-бар белән кыйналма, менә күрерсең, кәефеңә хуш килер... Моны кинәш дисәң дә кинәш!..
Гостиница вестибюлендә аны Жаденко көтә иде. Идрис Рәкыйп белән башлаган сүзен дәвам итте:
— Виталий Петрович, мин яңа яралып чыккан чебеш сынары... Иңмасам сезнең чит ил кунакларын кабул иткәнегез бармы? — дип сорады.
— Сезне нәрсә борчый? — диде Жаденко, үз чиратында.— Программа кунакларның рухи ихтыяҗларын, теләкләрен күздә тотып, аларның вәкилләре катнашында төзелгән. Безнең Казан — эш шәһәре, эшчәннәр шәһәре, студентлар шәһәре. Сезнең белән безнең бурыч шуннан гыйбарәт булыр, иптәш Бакиров, шул программага максимум турылыклы булып калып, немец иптәшләргә халкыбызның тормышын ныграк ачып күрсәтик. Сез ризамы?
— Боларына риза.
— Ә инде детальләргә килгәндә, көтелмәгән чигенешләр, үзгәрешләр булыр. Һәммәсенә әзер торыйк.
Өстенә жинел куртка кигән житез, көләч Куртның яхшы саргылт күннән тегелгән сумка-портфелен селки-селки баскычтан төшеп килүе күренде. Икесе дә аңа каршы киттеләр.
«Р» хәрефен йотып, Курт Жаденкого эндәште:
— Чак кына көттердем шикелле, кичерегез, Виталий Петрович.
— Кунак өчен бездә вакыт житәрлек,— диде үзенең горгылдык, әмма килешле тавышы белән Жаденко.— Шәп йокладыгызмы?
Идрис, Куртның кулын кысып, Жаденконың сүзләрен тәржемә итте.
— Мәгарәдәге кебек! Яттым да онытылдым... Кичә дүрт урында очрашу узды... Тәэсирләр күп, ләкин нык арылды.
— Шәһәребез зур, тормышы күпкырлы... Аның каравы бүген очрашулар өч кенә урында.
Курт кулын жәеп көлеп куйды:
— Без армия булып йөргәндә баш күтәрергә кыймый идем, өчәү генә чакта тәвәккәлләргә туры килер, ихтимал!.. Минем үз планнарым да бар иде...
Виталий Петрович Куртка әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде:
— Бүген без иркенләп, ял итеп йөрербез. Хәзер шәһәр советына барабыз. Сезне анда коллегаларыгыз көтә, Курт Францович.
Гостиница ишегеннән еракта түгел, куләгәдә торган өр-яңа «Волга»га үз артларыннан барырга ымлап, Жаденко Куртның янәшәсенә басты. Идрис аның сул ягына чыкты.
Спорт сараеның тәрәзәләре кояшта елык-ялык киләләр. Зур-зур чуар афишаларда Париж «Мюзик-холл»ы артистларының көләч йөзләре балкып тора.
— Мерей Матье? — диде Курт, ижекләп укып.— О, Германиядә тыңларга туры килгәне юк иде, өлгерсәк, Казанда очрашуга мин каршы түгел.
— Уйлашырбыз,— диде Виталий Петрович.

УРАМНАР АРТЫНДА ЯШЕЛ БОЛЫН ◆ Аяз Гыйләжев ◆

Өчәүләшеп баскыч-тротуардан Беренче Май мәйданына менә башладылар. Өстән гаҗәп манзара — Идел, Казанка киңлекләре, Ослан таулары ачылды. Тукталып бераз тамаша иттеләр.

— Герой-шагыйребезгә һәйкәл,— диде Виталий Петрович горурлык белән Муса Җәлилгә күрсәтеп. Идрис аңа өстәп:

— Маутхаузенда генерал Карбышевка куелган һәйкәлне беләсездер инде? — дип сорады. Курт раслап башын иде.— Муса Җәлил һәйкәлен дә шул ук бер оста — скульптор Цигаль эшләде.

Курт Муса Җәлилне белә икән. Берлин телевидениесе буенча «Кызыл ромашка» исемле телефильмны караган. Советлар Союзына килергә җыенгач, аның шигырьләр китабын табып җентекләп укыган.

Идриснең эченә җылы керде, кунак белән күрешкәнче үк арада якынлык, туганлык булган икән! Курт эч пошудан урын үзгәртергә йөрүче бюргер түгел ул, эзләп-белеп, изге җирләргә — Ленин Казанына, Муса Казанына килгән!

Муса янында Җаденко планлаштырганга караганда озаграк тукталдылар. Куртның сөйләшми генә һәйкәл тирәсендә әйләнгәләвендә аның хуҗаларга мәгълүм булмаган уе барлыгын да сөйли кебек иде.

— Герой шагыйрьнең музеенда булырга теләр идем, Виталий Петрович,— диде Курт.

— Зур кызганычка каршы, андый музейны әле ачып өлгермәдек. Сезнең икенче килүегезгә инде,— диде Җаденко нәкъ шушы сорауны көткән кеше сыман.

Курт вестибюльдә тагын тукталды, китапларын киң өстәлгә таратып ташлаган ханымга түбәнчелек белән баш иеп, Казан, Татарстан тарихына багышланган берничә китап сатып алды.

— Икенче килгәндә, кадерле Виталий Петрович,— диде ул үзенең мөлаем елмаюы белән бар кешене дә тигез бүләкләп,— русчаны өйрәнгән булырмын инде мин!

— Сез мине икмәксез калдырырга җыенасызмы? — диде Идрис, шаяртып.

— О, мин сезгә көнләшеп карыйм. Өч-дүрт телдә сөйләшәсез!..

Җаденко немец тәгәллеге турында сүз кузгатмый чыдамады, алар адымнарын кызулаттылар, бизәкле-бизәкле борынгы чуен баскычтан икенче катка күтәрелделәр. Буталчык коридорлардан борыла-сарыла үтеп, саргылт дерматин белән тышланган, чуар эшләпәле җиз кадаклар сырлаган биек ишек каршысына килеп тукталдылар. Ишек тавышсыз гына ачылды, чәчләрен биек итеп ясаткан озын аяклы секретарь кыз:

— Алексей Архипович сезне күптән көтә, рәхим итегез,— дип аларны эчкә чакырды.

Киң, биек тәрәзәләре Беренче Май мәйданына караган бүлмәдә шәһәрнең баш архитекторы Астахов үзе генә түгел иде. Аның янында озын муенлы, бугаз төере бала йодрыгы хәтле булып бүлтәеп торган шәһәрнең өлкән художнигы Глеб Иванович Стородиус та бар иде. Глеб Иванович немецча шәп кенә сөйләшә икән, кунаклар керүгә аның бугаз төене терсәкле вал шикелле бер аска, бер өскә йөри башлады.

Гадәттәге рәсми танышулардан соң, хәл-әхвәл белешкәч, Астахов кунакларны күрше бүлмәгә чакырды. Зәңгәр витражлы тәрәзәләр, стеналарда дәү-дәү фотомонтажлар... Диаграммалар... Зур бүлмәнең уртасында Казан шәһәренең булачак үзәгенең макеты ясалган. Курт шундук яңа үзәкнең проектына ябырылды.

Кояш зәңгәр витражлы борынгы тәрәзәләрне ташлап китте, сүз шактый озынга сузылса да, беркем дә ялыккан сыман күренмәде, әңгәмә университетның яңа биналары турында кузгалгач, Курт аерата активлык күрсәтте, хуҗаларны сораулар белән күмде, блокнотына сызгалап, язгалап та барды. Дөнья күләмендә атаклы университетның

бөтен Идел буена ямь биреп торачак яңа биналары турында мондый квалификацияле, белеп сөйләшү Идрис өчен дә тәэсирле булды, ул, тәрҗемәче икәнен онытып, куанып сүзгә катышып китте, башкалар белән рәттән бәхәсләште, аннары бергәләп төзелешкә бәйләнешле бернинчә кызыклы анекдотны хәтергә төшерделәр. Курт тәм табып, башын артка ташлый-ташлый рәхәт итеп көлә иде. Хәтта Жаденко тавышы да бу күңелле компаниядә бик ятышлы яңгырады.

— Татарларда бер мәкаль бар... Юрганыңа карап аягыңны суз, диләр. Элегрәк елларда архитекторлар проект төзегәндә юрганнын кыскалыгына аһ итәләр иде... Тормыш үз төзәтмәсен кертте, планнар киңәйде, архитекторларның хыяллары көтекләнде, хәзер үзебез артта калабыз кебек! Стандартлык торгынлыгыннан котылуы кыен,— диде Астахов, кулларын ак кулъяулыгы белән сөртә-сөртә.

Янадан Астаховның эш кабинетына чыктылар. Стородиус Куртка Казанның аждаһалы борынгы гербын бүләк итте, кунак аларның барысын да Германия Демократик Республикасына, үзләренең Нойштадт шәһәренә чакырды. Астаховның Германиядә ике тапкыр булганы бар икән, уртак белешләр, уртак сүзләр, таныш проектлар турында кызыклы әңгәмә китте.

Астахов сөйләнә-сөйләнә чыгып китте һәм нечкә билле хрусталь чәркәләр белән бер шешә «Токай» тотып керде. Шәраптан авыз итеп, аны кофе белән аралаштырып байтак сөйләштеләр. Курт портфель-сумкасыннан үз шәһәрләренә багышланган төсле фото-альбом чыгарды һәм аны Астаховка бүләк итте. Оста граверлар тарафыннан эшләнеп, менә дигән офсет кәгазенә басылган, һәр сызыгы, һәр ноктасы нечкә төгәллек белән башкарылган бу альбом бик кадерле истәлек иде.

— Бер соравым бар,— диде Курт тыйнак кына, кофе эчү тәмамлангач.— Казан — борынгы шәһәр. Милли архитектураның хәзерге заман шәһәр төзелешенә тәэсире ни дәрәҗәдә?

Астахов ияген учлап уйлаштырып торган арада Стородиусның бугаз төене әллә ничә кат менеп-төшеп алды.

— Татар халкының борынгы архитектурасы сакланмаган диярлек...

Сүзгә Идрис катышып китте:

— Болгар хәрабәләрендә кызыклы гына эзләнүләр бара,— диде ул.

— Дөрес, борынгы Болгардан игътибарга лаеклы нәрсәләр калган... Кайбер элементлар, манаралар ул чордагы халыкның төзелеш зәвыгы турында сөйлиләр... Әмма Казан ханлыгы чорыннан бернәрсә дә сакланмаган. Сугышлар, аннан соң булган янгыннар ул чорга караган кыйммәтле истәлекләрне юкка чыгарганнар. Аннары, ул истәлекләрнең сакланмавы кемгәдер кирәк тә булган!.. Россиянең халыклар төрмәсе булганлыгын онытмыйк,— диде Астахов уйчан гына.

Сүзне шушының белән тәмам иттеләр. Астахов белән Стородиус кунакларны озатып урам якка кадәр чыктылар.

Кунак һәм аны озатып йөрүчеләр өчәүләшеп Кремль эченә керделәр, карап, ашыкмыйча гына танышып йөрделәр. Аннан җәяүләп университетка бардылар.

— Төштән соң без балалар бакчасында булырга һәм Ленин районының яңа төзелеш комплексларын карарга тиешбез,— диде Жаденко.

Курт баш чайкап көлеп җибәрде:

— Виталий Петрович,— диде ул ике кулын күтәреп.— Мин сезнең әсирегез. Балалар бакчасына керербез. Әмма төштән соң иң элек татар театрларын, татар музейларын һәм мәчетләрен карыйк,— диде.

Жаденко аптырап калмады:

— Бик әйбәт,— дип шундук күнде.— Ихтыярыгыз. Иң элек театрларны йөреп чыгарбыз. Мәчетләр дә еракта түгел... Кагылырбыз...

Курт, баягы кебек үк житез-житез атлап, лифтка кереп китте.

*Дәвамы бар.*

Шәүкәт Галиев

# СИГЕЗЮЛЛЫКЛАР

●

Бер карасаң, тормыш—цифрблат —
Гап-гадигә аны саныйсың,
Өстән-өстән күз төшереп кенә
Заманыңны гүя таныйсың.

Сәгать телләре күк анлаешлы
Тормыш ул шәт асат барадыр?
Нәрсә йөртә микән ул телләрне,
Сәгатьне син ачып кара бер!..

●

Бер авылда үстек... Бер мәктәптә,
Бер класста бергә укыдык...
Мәхәббәтне сиздермичә генә
Бер партада бергә утырдык.

Яшьлек бергә үтте... Беләм, шуннан
Аерылдылар диеп көтәсез?
Бер шәһәрдә, бер үк квартирда
Яшибез без — гафу итәсез!

●

Таш юлдан ул атын читкә борды,
Авыртмасын, диеп, аягы.
Энгер-менгер вакыт житте дип тә
Артык кумады ул, аяды.

«Аягына төшәр, ярамас» дип,
Кайткачтын ук бирмәс суны да,
Мал кадерен белә торган абзый!
...Ул ат алып кайта сугымга.

●

Чыршыларга кара, һаман яшел,
Булсын эссе, булсын чатлама —
Табигатьнең яшәү көчен раслап
Баскан алар горур сафларга.

Кай арада гына әмма алар
Койган җиргә сары ылыслар?
Авырлыкны ничек күтәргәнне
Сиздермиләр, ныклар-кырыслар.

●

Әткәй рәсмен илтсәм фотографка,
Ул әйбәтләп аны зурайтыр —
Галстук бәйләтер дә,
шомарткалар,
Якын сызыкларны югалтыр...

Һәр җыерчык миңа бик кадерле,
Онытуга килми бирәсем.
Стенада түгел, күңелемдә
Торсын, әйдә, һаман бу рәсем...

●

Дачасыннан халык чәчәк ташый,
Кәрҗин белән алган әби дә.
Көтелмәгән бер уй килә башка:
«Әбигә соң инде, я, нигә?»

Ишеттем мин китеп барган чакта
Шул әбинең йомшак тавышын:
— Бик ярата иде чәчәкләрне,
Картым каберенә барышым...

●

Ерак планетаның вәкилләре
Килеп төшсә җиргә, фаразан,
Ничек аңлашырбыз? диеп инде
Галимнәр баш ватып караган.

Төшенерләр иде дуслык ымын,
Туры килсә кулны сузарга!
Тик аңынчы, җирдә яшәүчеләр,
Аңлашалсак иде узара!

●

Биек кыяга мәшһүр осталар
Гаҗәп гыйбадәтханә корганнар.
Корганнар да, илаһларын зурлап,
Таш иләнгә башны органнар.

Текә кыя... Бөркетләр дә аста...
Нинди кыюлар бит табылган.
Юк, аллага табынмаган кеше —
Шулар иҗатына табынган!

●

Күңел сәхифәсен актарганда
Беркөнне мин калдым сагаеп:
Иске хатлар кебек тоныкланып,
Истәлекләр бара саргаеп.

Кайтмый калганнарның эшен, төсен
Бер җинаять булыр югалту,—
Һәйкәлләргә уйган сүзләр кебек,
Күңелне дә кирәк яңарту.

●

Кояш булгач, булмый калмый,
Төшми калмый күләгә.
Кайчак «күләгәле якны
Күргән өчен» эләгә...

Ә ник күрмәскә икән, ди,
Бакчы син дә, дус, кара —
Кояш күтәрелгән саен
Күләгәләр кыскара!

●

Һава белән су шикелле
Тәнкыйть кирәк, аңлыйбыз.
Кайчак һава саф булмый бит,
Шуны искә алыгыз.

Ә кемдер болганчык суда
Балык тотарга оста...
Һавасы, суы, тәнкыйте —
Һәммәсе булсын чиста!

●

— Атка хәзер азык такы-токы,
Сыерларны, әнә, сыйлыйлар,—
Ферма кызларыннан егетләр бит
Атларына печән сорыйлар...

— Почетта да сыер, отчетта да,
Файда китерә бит, ашаса!
— Шулай, энем, игътибарлар кими
Төпкә җигелеп тартмый башласаң!..

**Әмирхан Еники**

# ҖИЗ КЫҢГЫРАУ



ХИКӘЯ-ИСТӘЛЕК

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Кайчандыр моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында ул кара дугага тагылган килеш ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган... Әллә нидә бер мин аны кулыма алып, әкрен генә селкеп карыйм. Җиз кыңгырау шунда ук, телгә килгәндәй, дәртле тавышын чыгара: «Зың-зиң, зың-зиң!..» Нәкъ менә кара дугада чакта чыңлаган шикелле дулкынланып, яңгырап китә. Гаҗәп, вакыт дигәнең дә көчсез икән бу җиз кыңгырау алдында, вакыт аны әз генә дә, ичмасам, үзгәртә алмаган. Ул элеккечә яшь, дәртле, моңлы һәм нинди дер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма күчерә дә куя.

* * *

Әйе, яхшы хәтерлим, бу егерме дүртенче елның җәе иде. Нигъмәтулла абзыйкайларның яшел чирәмле иркен ихатасына килеп керсәм, ишек төбенә тарттырып куйган җигүле ат тора. Озын яллы сары ат җиз кыңгыраулы кара дуга һәм шлеяле камыт белән читән тарантаска җигелгән. Тарантасның артына салындырып чуар палас җәелгән, палас өстенә ике мендәр дә кабартып куелган. Моны күргәч тә мин: «Абзыйкайлар каядыр кунакка барырга җыенганнар икән», дип уйладым, һәм аулак өйдә калу мөмкинлеге мине шунда ук куандырып та җибәрде. Аулак өй безнең ише малай-шалайлар өчен үзенә күрә бер хөрлек инде ул... Шулай уйлап, өйгә кердем; керсәм, абзыйкай белән җиңгәчәй өсләренә киенгәннәр, чыгып утырырга гына торалар. Җиңгәчәйнең өстендә'кин итәкле озын кәшимир зәңгәр күлмәк, яшел камзул, башында көмеш тәнкәле тар гына калфак, калфак өстеннән чәчәкле яулык ябынган, юка шәлен иңенә салган, аягында сары читек белән кара галош. Нигъмәтулла абзыйкай кыек якалы сатин күлмәк өстеннән яңа көрән пинҗәген кигән, шундый ук көрән чалбардан, балакларын читек өстеннән салындырып төшергән, аягында — өр-яңа галошлар.

Башында шактый ямьшәйгән күк эшләпә, эшләпәсенең бер кырыеннан кара кәләпүшенең чите күренеп тора.

Мине күргәч, абзыкай гаҗәпләнүеннән кычкырып дәшә куйды:

— Пәрәмәч, син кайдан?

— Дәүләкәннән,— дим мин, авызны срып.

— Ничек килдең, үзең генәме?

— Үзем генә, Рәхмәтулла абзыйга утырып килдем.

— Шулаймыни? Кара син! Һе, кунакка кайттым диген... Ә без менә Абзанга чыгып китәргә торабыз.

Мин ни әйтергә белмим. Нигъмәтулла абзыкай озак уйлап тора торган кеше түгел иде. Ул шунда ук җиңгәчәйгә карап әйтә куйды:

— Син! Шәкертне үзебездән калдырмыйк.

— Теләсә,— диде җиңгәчәй.

— Безнең белән барасыңмы, бәбкәм?

— Кая соң?..

— Абзанга инде... Туйга барабыз.

— Туйга?! Белмим шул,— дидем мин, шактый икеләнеп.

— Я, нәстә тагын «белмим». Барабыз, вәссәлам! Туйдан тукмак та калмый.

— Туктале син,— диде җиңгәчәй.— Әхтәмнең өстен карыйк, кала кунагы, йөзенә кызыллык килмәсен.

Җиңгәчәй дөрес әйтә иде. Мин өйдән туйга барасымны белеп чыкмадым. Дөрес, минем өс-башым болай бик хөртидән түгел. Бик яңадан булмаса да пинжәк, чалбар, аякта ботинка, тик арбада кырык чакрым килеп, алар шактый таушалган һәм тузанланган иде... Җиңгәчәй минем өс-башымны күздән бер кичереп чыкты да:

— Алмашка күлмәгең бармы? — дип сорады.

— Бар,— дидем мин, кулымдагы төенчекне селкеп.

— Булды болай булгач,— диде Нигъмәтулла абзыкай, сүзне тизрәк бетерәсе килеп.— Ә Абзанга баргач, син аңа күлмәген каталап бирерсең[1].

— Синең гел шул ордым-бәрдем булыр инде,— диде җиңгәчәй, сукранып, аннары мич кашагасыннан миңа канат алып бирде: — Бар, өстеңдәге тузаныңны бераз чистарт.

Мин ишек алдына чыгып, башта пинжәгемне салып, аны канат белән чистарттым, аннары чалбарыма тотындым. Үзем чистартам, ә үзем эчемнән генә уйланам: барыргамы-юкмы бу туйга?.. Әлбәттә, туй бик күңелле, бик кызык нәрсә инде ул... Минем башкорт туен да, үзебезнең Каракош туен да күргәнем бар. Хәтта әткәйнең сеңелесе Сәрвәр апаны биргән чакта, кайнеш булып, җизнидән пәке дә алганым бар. Үзенә якын кешенең туе башка инде ул, андый вакытта өстеңә яңа кием дә тектереп кидерәләр, кулыңа әзрәк акча да бирәләр, кыскасы, берничә көн эчендә кинәт үсеп киткәндәй, күрше-тирә малайларының күзләрен яндырып, һаваланып йөри бирәсең. Ә бу туйда мин кем булып йөрермен?.. Монда, минем белүемчә, җиңгәчәйнең сеңелесен, ягъни Нигъмәтулла абзыкайның балдызын бирәләр. Аларга бит мин кода тиешле кешенең малае гына... Ничек каршы алырлар, ничек карарлар миңа, ят халык арасында арбаның бишенче тәгәрмәчедәй буталып кына йөрергә туры килмәсме?.. Аннары аулак өйдә калу да бик кызыктыра бит әле. Бусы да сирәк эләгә торган бер хөрлек... Нишләргә соң?.. Әллә бармыйча калырга микән?..

Ул арада өйдән җиңгәчәй белән Нигъмәтулла абзыкай кижеле ашъяулыкка төргән ике зур төенчек күтәреп чыктылар. Чыгуга, абзыкай миңа кычкырды:

---

[1] Мин бала чакта авылда үтүк дигән нәрсә юк иде. Керне юан уклауга урап, сырлы зур бәләк белән тәгәрәтә торганнар иде. Безнең тәмәннәрдә шуны каталау диләр. Ә. Е.

— Я, шәкерт, булдыңмы?

Мин торып калырга бер сылтау тапкандай ашыгып сорадым:

— Ә Зөләйха кайда соң?

— Зөләйханы апакае Өфегә алып киткән иде шул,— диде абзыкай.

Әйтәм җирле ул күренми. Зөләйха өйдә булса, бәлки калып та булыр иде. Хәзер нишлисең инде, бармыйм дип кәҗәләнә башласаң, абзыкай я тузып китәр, аның талканы һәрвакытта коры була.

Төеннәрнең берсен, печәнне кайтарып, кучер астына тыгып куйдылар. Аннары җиңгәчәй палас япкан мендәр өстенә киң итәкләрен җыештырып менеп утырды. Икенче төенчекне иңләп кенә үзенең алдына куйды — изәргә ярамый торган нәрсәдер, ахрысы... Абзыкай кучерга бер иске сырма салды.

— Кил, утыр, синең урының шушында булыр, очып төшмәссеңме? — диде ул миңа.

Мин, алгы тәгәрмәчкә басып, кучерга менеп утырдым. Шуннан соң абзыкай, күн бияләйләрен киеп, каеш дилбегәне кулына алды да, бер аягын читкә салындырып, җиңгәчәй кырына утырды һәм авыз эченнән генә: «Тапшырдык» дип, атын капкага таба борды. Жиз кыңгырау күңелле генә чыңлап куйды. Капкадан чыккач, абзыкай эшләпәсен күз өстенә тарта төште, җайлабрак утырырга теләгәндәй, селкенгәләп алды, аннары: «Яле, малкай!» — диде дә дилбегәсен кагып җибәрде. Сары ат кызу гына юртып китте. Жиз кыңгырау бердән дәртләнеп, «зың-зың, диң-диң» килеп, көмеш чыңлавын сибәргә тотынды. Нигъмәтулла абзыкай авыл урамыннан матур һәм кызу юртып узарга ярата иде. Хәзер дә ул ат чапмасын, ә юрттырып кына барсын өчен дилбегәсен ике куллап нык кына тартып тотты, атка нидер дәшкәндәй итте, һәм сары ат аның кулын тоеп, озын яллы матур башын аккоштай кырынрак бөгеп, кыска аякларын күз иярмәс тизлек белән юлны типчегәндәй вак-вак кына алыштырып, йомры янбашын тибрәтә-тибрәтә юргалап кына элдерергә тотынды. Урамдагы малайлар уеннарыннан туктап, ишек алларында йөргән агайлар башларын борып, житкән кызлар ачык тәрәзәләрдән сузылып безгә карап калдылар. Бер-ике эт тә, каяндыр атылып чыгып, ат аягына ташланганнар иде дә, ләкин тавышларына бик тиз буылып, читкә тайпылып калдылар. Без Каракошның озын урамын әнә шулай кешеләрне сокландырып, этләрнең ачуын китереп, матур һәм шәп кенә узып киттек.

Авылдан кырга чыккач, абзыкай дилбегәне миңа бирде. (Бу аның гадәте, авыллардан узганда гына ул дилбегәне үзе тота.) Ат та шунда ук дилбегәнең кем кулына күчүен сизеп алды булса кирәк, юргалап баруыннан туктап, гади юыртуга күчте. Мин тарткалап, суккалап карасам да, аны барыбер тыңлата алмадым. Каяндыр болыты белән вак чебен иярде, һәм сары ат башын селкә-селкә ялкау гына бара башлады.

Нигъмәтулла абзыкай тарантас артына киерелеп ята төште дә, тургайлар сайравына кушылгандай, «ихи-хи-хи!» дип бер сузып куйды. Без Сынны юлы белән барабыз. Көн бик тын, бик эссе. Ике якта да яшь игеннәр йокымсырап, оеп утыра. Иген арасыннан күзгә күренмәс чикерткәләрнең иренеп кенә чырылдавы ишетелә. Юл буендагы эт эчәгесенең кыңгырау чәчәкләре тирәсендә ак, сары, чуар күбәләкләр талпына. Ара-тирә иген арасыннан берәр кошчык пырылдап күтәрелә яки кәкре томшыклы карчыга тычкан эзләп түбәннән генә, канат какмыйча йөзеп кенә үтеп китә... Үр менәбез... Сары ат йомшак юл тузанына топ-топ басып кына атлый. Абзыкай башта ниндидер бер көйне исенә төшерергә теләгәндәй әкрен генә сызгырырга тотынды. Аннары күзләрен яртылаш йомып, тавышын калтырата төшеп, башта авыз эченнән генә сузып, тик соңгы сүзләрен генә ачык әйтеп җырлый башлады:

И-и-и-... яланнары сарылай кәрешкә-ә-ә-әү,
Тырышлыклар кирәк лә һәр эшкә-ә-әү.

Мин ул чагында бик нечкә күңелле идем, бик тиз тәэсирләнә идем, шуңа ачуым да бик килә иде, ләкин нихәл итим? Менә абзыкайның сузып җибәрүе белән үк минем күземә мөлдерәп яшьләрем килде. Әллә нинди шунда эчтәге бөтен нәрсәне бик төптән кузгата торган, бер үк вакытта бөтен җан иясен — адәмнәрне, кошларны, чәчәкләрне, бөҗәкләрне әрнеп кызганырга һәм өзелеп сөяргә мәҗбүр итә торган көй иде шул бу дәдәм көе! Һәм ул аны киң сулыш белән гаҗәп иркен, тирән, моңлы итеп җырлый белә иде. Җырлап бетергәч, тургайларны да үзенә кушылырга чакыргандай, тавышын тибрәтә-тибрәтә дәртләнеп бер «үлү... лү... лүү» дип сузып җибәрә иде. Һәм тургайлар, чынлап та аңа кушылгандай, тын, якты кырлар өстендә тагы да талпыныбрак, исеребрәк сайрарга тотыналар иде кебек.

Менә хәзер дә ул җырын әнә шулай әллә кайларгача җәелеп китәрлек итеп сузып бетерде дә, үзе дә шуңардан әсәрләнеп булса кирәк, кәефләнеп бер көлеп куйды. Җиңгәчәйгә таба борыла төшеп, кычкырып дәште:

— Ни әле син, якты көнем, уйга калдың. Әллә минем кияү булып янына кергән чакларым исеңә төшеп киттеме?

— Тилермә,— диде җиңгәчәй, сабыр гына елмаеп.

Мин дә, күземнән китеп бетмәгән яшьләрем аша елмаеп, аларга борылып карадым. Абзыкай кәефе килгән чакта җиңгәчәйне гел менә шулай көлеп шаяртырга ярата. Ә җиңгәчәй бер дә үпкәләргә тормый, күп вакытта сөйкемле-уйчан гына елмаеп, ачусыз гына җавап кайтара. Мондый чакларда алар миңа бер-берсен бик аңлыйлар, бик канәгатьләр һәм бәхетлеләр төсле булып күренәләр. Мин шуңа бик сөенәм, үземә дә ничектер җиңел, рәхәт булып китә. Гомумән мине, ундүрт яшьлек малайны, ул чакларда бәхет нәрсә ул, ярату нәрсә дигән сораулар бик борчый, бик уйландыра башлаган иде. Кешеләр ашыйлар-эчәләр, яталар-йоклыйлар, көн дә торып нужа куалар, ә бәхетләмә алар, яратышу дигән нәрсә бармы алар өчен — моны һич сизеп булмый иде. Бигрәк тә гади авыл кешеләренең бәхет һәм мәхәббәт турында уйларга вакытлары да юк, аларны кирәк диеп тә белмиләр шикелле тоела иде миңа.

Ярый, сүз бик озынга китте, без бит әле Абзанга туйга барабыз. Сынны авылын күптән уздык, инде Ивановка дигән зур рус авылына җитеп киләбез. Ивановканы үткәч, Абзанга да ерак калмый.

Яхшы атта җиңел генә барсак та, шактый җилектерде. Көн эссе, юлда бер дә урман-фәлән юк, гел ачык кырдан барабыз. Сүз бетте, барыбыз да тындык. Абзыкай ат юрткан уңайга талгып, азрак черем дә итеп алды. Мине дә вакыт-вакыт йокы басып киткәләде, ләкин кулда дилбегә булгач, бирешмәдем, кыңгырауның күңелле генә чыңлавын, юл буендагы чикерткәләрнең ялкау гына чырылдавын тыңлап, үз уйларыма йотылып бара бирдем.

Ивановканың ике-өч чакрымга сузылган урамын узганда Нигъмәтулла абзыкай уянып күзен ачты.

— Бәй, Ивановканы үтәбезмени? — диде ул гаҗәпләнеп, һәм эшләпәсен күтәрә төшеп, тураебрак утырды.

Капка-койма буендагы таза балтырлы ялан аяклы апайлар, ап-ак житен башлы малайлар, эскәмияләрдә текә генә утырган зур картузлы рус агайлары безне кызыксынып озатып калалар. Монда абзыкайның «знакомнары» да бар икән. Шуларның кайберләре белән ул, баш кагып:

— Ә Митрофан агай, сәлам!

Яки:

— Ә Ягур Иваныч, здрастуй! — дип исәнләшеп узды.

Тегеләр иренмичә картузларын күтәреп, башларын кат-кат селкеп калдылар. Арадан берсе тагын:

— Князь кая китеп бара? — дип тә кычкырды.

— Туйга инде, туйга! — диде абзыкай, көлеп.— Свадьба гуләем!

— Көлмә шул тикле, тиле кебек! — диде җиңгәчәй. ничектер бераз уңайсызланып.

Ләкин көлмәслек тә түгел икән шул. Нигъмәтулла абзыкай Ивановка урамыннан кыңгыраулы атта узып, менә дүртенчеме-бишенчеме балдызының туена бара, имеш. «Знакомнар» моны белеп бетергәннәр инде.

...Инде Абзанга да җитәбез шикелле... Алдагы сыртны гына менәсе калды. Шуннан Түреш буенда утырган авыл күренергә тиеш.

Бер сай чокырны чыккач, абзыкай миңа, юлдан читкәрәк борып, атны туктатырга кушты. Мин, ахрысы, кисәгрәк бордым, тарантас кинәт чалышаеп китте.

— Һай, шәкерт,— диде абзыкай, тиз генә сикереп төшеп.— Җиңгәчәңне өстемә аудара яздың бит...

Мин ни бары тик кызардым гына... Эчкәрәк узып, чирәмгә төштек. Тураеп, киерелеп, бераз сөякләрне яздык. Тузаннарны кактык, үләннең чистарак җиренә кереп, аякларыбызны ышкыдык.

Абзыкай, авыз эченнән генә сөеп, сары атның ялын тараштыргалады, тирләгән муенын сыпыргалады, тәртәсен селкетеп, аркалыгын тартып карады. Җиңгәчәй тарантастагы мендәрләрне каккалап, күпертебрәк куйды... Шулай бераз селкенгәләп алгач, яңадан утырышып, кузгалып киттек.

Сыртны менүгә, алдыбызда Түреш буе ачылды һәм ерак түгел Абзан да күренде. Нигъмәтулла абзыкай дилбегәне миннән алды, гадәтенчә, эшләпәсен күзенәрәк төшерде һәм: «Әйдәле, канатым!» дип бер кагып җибәрүе булды — сары ат озын яллы муенын текә генә бөгеп, йонлач бәкәлләрен вак-вак кына алыштырып, томырылып юрта да башлады. Җиз кыңгырау, тәңкәләр сипкәндәй, дәртләнеп еш-еш кына чыңларга тотынды. Кырлар уянып киткәндәй булды, тургайлар гүя сискәнеп тагы да югарырак күтәрелделәр.

Минем бик кечкенә чагымда Иске Абзанда булганым бар иде. Аны-сы бик зур авыл булган диләр. Мин аны белмим, хәтерләмим, тик зур кара тараканнан куркып елавым гына истә калган. Бусы моннан бернич ел элек кенә шул авылдан күчеп утырган Кечкенә Абзан. Барлыгы утызлап кына йорт булыр. Өйләр барысы да яңалар, тазалар һәм бер яклап кына утырганнар. Каршыларында гына буйдан-буйга киртә тоткан иген басуы башланып китә. Каралты-куралары, бәрәңге бакчалары болынга таба караган. Болын тип-тигез, чоп-чуар чәчәк кенә, Түреш үзе күренми дә, аның кай тирәдәнрәк акканын бары яшел талларга яки биек, карт тирәкләргә карап кына чамаларга була... Бик күңелле, бик сөйкемле җирдә утыра икән бу Кечкенә Абзан. Мин үзем нигәдер менә шушындый иркен, матур табигатьтә утырган кечкенә, җыйнак авылларны күбрәк яратам.

Без менә шул авылга шәп кенә юрттырып, дәртле кыңгырау тавышы белән сәламләп килеп кердек.. Авылның икенче очына җитәрәк, урам башын такта, эчкәре башын салам белән япкан йортның урыс капкасын безгә бер дәү, таза абзый ачып ук тора иде инде. Бу туй буласы йорт — җиңгәчәйнең әтиләре, ягъни кода бабайлар йорты. Капканы ачып торучы — җиңгәчәйнең агасы Хөбәйбулла кода иде.

Ишек алдына килеп керүгә, безнең тарантасны хуҗалар сырып алдылар. Куе чал төшкән түгәрәк кара сакаллы, базык бәдәнле, йомрысөйкемле генә карт — кода бабай, аның янында ап-ак чырайлы, юка гәүдәле карчык — кодагый әби иде. Тагын бик куанышып безнең тирәдә бөтерелүче ике житкән кыз — җиңгәчәйнең сеңелләре — миңа кодачалар. Шушы кодачаларның кайсындыр (ихтимал, әнә теге оялыбрак,

арттарак торганындыр, мин әле ачык кына белмим) кияүгә бирәләр — менә шунын түе булачак инде.
Нигъмәтулла абзыкай тарантастан егетләрчә тиз генә төшеп, башта ике куллап, иелә биреп, бабасы һәм әбисе белән күреште, аннары көлә-көлә балдызларының аркаларыннан кагып, алар белән күрешә башлады... Җингәчәйнең төенчекләрен алдылар, үзенә тарантастан төшәргә булыштылар... Билгеле, шунда ук миңа да игътибар итеп өлгерделәр. Кучердан җиргә төшүемә, кода бабай:
— Кара, бу Әхмәтҗан коданың улы түгелме соң? — диде, куанычлы гаҗәпләнгәндәй.
— Әйе, шул үзе инде, кече кодагыз Әхтәм,— диде җингәчәй.
— Бәрәкалла, бик кадерле кунак алып килгәнсез икән, рәхмәт төшсен! Әйдүк шәкерт, әйдүк! — диде кода бабай, миңа ике кулын сузып.
Бу хәтле зурлап дәшүне ишеткәч, мин шактый каушап калдым, кызарып киттем. Бигрәк тә яшь кодачаларның күзләрен елтыратып миңа кызыксынып карауларын күргәч, бик уңайсызландым, әллә ничек менә үземне котсыз, килбәтсез, ә өс-башымны ярлы, начар итеп тойгандай булдым. Алар миңа «каладан килгән кунак» дип карыйлар инде. Ә минем кай җирем генә каланыкына охшаган соң?!. Тал чыбыктай нечкә, озын бер малай гына ич мин... Шулай кызарып, уңайсызланып кына мин кода бабай, кодагый әби, Хөбәйбулла кода белән күрештем, әмма кодачаларга кул сузарга көчем житмәде.
Ыгы-зыгы килеп, исәнлек-саулык сораша-сораша күрешеп беткәннән соң, безне өйгә чакырдылар. Хөбәйбулла кода атны, йөгәненнән алып, туарыр өчен лапаска таба атлатты. Кодачалар чирәмгә тиз генә таз белән комган чыгардылар, рәшәткә башына озын сөлге элеп куйдылар. Абзыкай дәртле тавыш белән:
— Ягез, балдызлар, кайсыгыз уңганрак, безне юындырыгыз әле,— диде.
Ә мин һаман уйланам: бу ике кодачаның кайсысын бирәләр икән: шушы түгәрәк йөзле, соры күзле, тулырак гәүдәлесенме, яки әнә теге озын кара толымлы, коңгырт күзле, нечкәрәк буйлысынмы? Тулырак гәүдәлесе яшькә олырак кебек, бәлкем, шунысыдыр. Алай дисәң, нечкәрәк буйлысы ничектер уйчанрак кебек, үзен ул эрерәк, житдирәк тота да төсле... Безгә комганнан суны да түгәрәк йөзлесе салып торды, ә тегесе аз гына юанды да тизрәк кереп китте. Шуннан соң безгә бөтән күренмәде дә — һәм юрарга урын да калмады: шул озын толымлы, нечкәрәк буйлы Сәлимә дигәнен кияүгә бирәчәкләр икән инде.
Иртәгә туй киләчәк һәм никах укылачак икән. Бүген исә шуңа соңгы зур әзерлек бара. Әнә аш өенең тәрәзәләре ачык, ишеге ачык, мичен көненә икешәр ягудан тәмугка әйләнгән эсседә хатын-кыз кайнаша. Зур сәке өсте туп-тулы табак-савыт, тәпән-чүлмәкләр, мичкә тыгар өчен әзерләп куйган табалар... Ничәмә төрле туй ашлары пешмидер бүген анда!
Өйнен урам башында да шул ук тамаша: кызлар тәрәзә башларына кашагалар сузалар, тәрәзә араларына чиккән башлы озын сөлгеләр эләләр, өйнең бөтен түр башын алып торган сәкегә киез, паласлар җәяләр. Чирәмгә чыгарып, су бөркеп юдырылган, сөртелгән гөлләрне кире кертеп үз урыннарына куялар. Кыскасы, тавык та чүпләп бетмәс кызу эш бара.
Безгә чәйне дә бакчадагы каен төбенә чыгарып куйган өстәлгә әзерләделәр. Чәй янына кода бабай үзе генә утырды, башкаларның вакыты юк. Кода бабайның өстендә ике генә сәдәпле ап-ак кулмәк, кара камзул, башында яңа кәләпүш. Мин аның шушы бик пакь булып күренгән кыяфәтенә һәм түгәрәкләп кырыккан чал сакаллы алсу, тыныч йөзенә кызыксынып, хәтта сокланып карыйм. Ул миңа бик күпне белгән, бик акыллы, сабыр, кешеләргә мәрхәмәтле бер карт булып күренә.

Ничектер менә, ул дөньяда бик гадел торгандыр, беркемгә дә начарлык эшләмәгәндер һәм берәүне дә урынлы-урынсыз рәнҗетмәгәндер дип ышанасы килә. Ашыкмыйча гына чәй ясый-ясый, ул миннән әткәйәнкәй турында сорашты: «Әхмәтҗан кода ничек, тазамы, авырмыймы? Хакимә кодача сау-сәламәтме? Ярый, ярый, бирсен алла! Әнкәең — бик әйбәт, бик сабыр-акыллы хатын, тик, бичара, бала хәсрәтен күп күрде. Ничәү әле, сигезме-тугызмы баласы үлеп китте бит... Туган берсен ходай ала торсын әле, я, ана кеше өчен монардан да авыр хәсрәт бармы соң?! Син инде аның уннан берсе буласың, хак тәгалә үзеңә гомер бирсен, әткәң-әнкәңә картайган көннәрендә игелегеңне күрергә насыйп итсен».

Ахырдан минем үземә дә: «Укыйсыңмы? Бик яхшы, уку кирәк, укуда хәзер бар өмет!» дип әйтеп куйды. Мин моны үземчә дөрес аңладым шикелле: заманасы шундый, укып кына чын кеше булырга мөмкин дип әйтүе иде бу аның... Әйе, минем япь-яшь кенә башымны иң нык уйландырган мәсьәлә дә шул инде, шул!

Чәй янында озак утырмадык — вакыты ул түгел. Иң элек җиңгәчәй торып, чоланда гына өстен алыштырып, аш өенә кереп китте. Бераздан Нигъмәтулла абзыкай белән Хөбәйбулла кода да, кабык арбага ат җигеп, каядыр китеп бардылар. Мин ялгызым бер эшсез калдым. Өй тирәсендә хәзер җыен хатын-кыз гына — миңа нишләргә соң? Кунакка килгән җиреңдә үз эшең булмаса, шактый читен икән ул...

Мин шулай рәшәткә буенда ялгыз басып торган чагымда ике яшьрәк хатын өйдән каршыдагы ак келәткә түшәк-ястык, чыбылдык-чаршаулар ташый башладылар. Ни өчен, кем өчен бу дип уйларга өлгермәдем, келт итеп башыма килде: ак келәткә кыз урыны әзерлиләр. Кияүне кыз янына шунда ябачаклар... Юк, миңа бу тирәдән китәргә кирәк иде. Ераккарак, аулаграк җиргә, һәм мин абзарларга таба уздым да шундагы арт капкадан болынга, Түреш буена чыгып киттем.

Башта, уйланып барудан, ахрысы, ничектер тирә-ягыма күтәрелеп карарга да онытканмын. Күпмедер җир киткәч, үземне бил тиңке күе үлән эчендә күреп, гаҗәпләнгәндәй тукталып калдым. Алдымда шау чәчәктән торган тип-тигез болын җәйрәп ята... Шушымыни инде ул Түреш буе?.. Хәйран калмаслык та түгел икән шул!

Мин үзем дә Дим буенда үскән малай, болыннарны күп таптаганым бар, әмма моның кебек тоташ чоп-чуар чәчәкле, ерып йөри алмаслык куе үләнле, тын-якты болынны беренче күрүемдер. Күңелгә кинәт нур тулды, күзгә хәтта сөенеч яшьләре килде, һәм шул чакта табигатьнең кешегә газиз ана кочагыдай никадәр якын-кадерле булуын, кешенең аңа мең төрле җепләр белән бәйләнгән булуын, алай гына да түгел, кешенең бөтен хыялы-өмете, эше-гамәле шушы җылы, якты, тере сулышлы табигатьтән яралган булуын ихтыярсыз аңладым, тойдым, бельдем шикелле... Болар берсе дә яңа нәрсә түгел кебек, әмма кеше йөрәгенең табигать белән мондый гомерлек тирән якынлыгын кинәт бик ачык хис итүе дә, минемчә, еш булмый торгандыр.

Үлән каплап киткән иске арба эзенә төшеп, мин юри миңа сузылгандай ышкылып, сыгылып калган ал, кызыл, күк, сары чәчәкләрне учым белән сыпыра-сыпыра, болын түрендә кара-яшелләнеп торган агачлыкларга таба киттем. Барып җиттем. Бер карагай төбендә тукталдым. Менә елгачык үзе дә. Киң түгел икән, ярлары якын, ләкин тирән генә күренә. Суы зөбәрҗәттәй яшькелт, бик чиста, күләгә урыннарда караңгыланып китә, кояшлы җирләрдә җем-җем уйнакларга тотына, ә шулай да, үз дәрәҗәсен белгәндәй, ашыкмыйча уйчан-тыныч кына агып ята. Чыккан җире дә, барып койган урыны да ерак түгелдер инде бу тын-сөйкемле елгачыкның, әмма гомере аның хыял җитмәс озын булырга тиеш. Көнелнең нечкәргән чагы иде, карап тордым да шагыйрь сүзләре белән үзенә дәштем:

— Әй агым су, ни уең, ни хәсрәтең бар синең?Ниләр күрдең, ниләр беләсең син?.. Синең буйларыңда кызлар туалар, кызлар үсәләр, үсеп житкәч әнә кияүгә чыгып китәләр. Син аларның бит-башларын, апак тәннәрен югансың, зарларын, серләрен ишеткәнсең. Ни юрыйсың син аларга, ни телисең? Тормыш әллә нинди, тормыш бик серле, кызларыңны нәрсә көтә — алар үзләре дә белмиләр... Син аларга бәхет юра, син аларга чын мәхәббәт телә, әй агым су!

Ә агым су ага, миңа «әйдә» дигән сыман, бөтерелеп-уймакланып ага да ага. Мин ихтыярсыз аңа ияреп киттем. Яр кырындагы тар гына сукмак бормаланып куе таллыклар арасыннан, гөлжимеш, карлыган, зелпе куаклары яныннан уза, тип-тигез, ачык, якты аланлыкларга килеп чыга... Шулай агым суга ияреп йөреп, шактый вакыт уздырып, ниһаять, авылга таба борылдым.

Җәйге озын көн күптән инде төшлектән авышса да, кояш баерга ерак иде әле. Кайтып керсәм, өйдә хәрәкәт тагы да көчәйгән кебек — көн үтә, ә эшнең очы-кырые күренми, ахрысы. Яшь кызлар, яшь киленнәр тыз-быз йөриләр, өйдән нәрсәдер чыгаралар, нәрсәдер кертәләр, селкәләр, кагалар... Кайсы кое янында нидер чайкап-чайкап юа, кайсы рәшәткә буенда комлап, катыклап самовар, поднос агарта. Кар базының капкачы бертуктаусыз шап-шоп ачыла да ябыла — аннан өйгә чүлмәк-чүлмәк сөт, май, каймак ташыйлар. Аш өенең ачык тәрәзәсеннән мунча эссесе килеп тора,— мичнең ничәнче ягылуыдыр инде, җиңгәйләр урак өстендәге шикелле янып, кызарып беткәннәр.

Лапас астында Хөбәйбулла кода белән Нигъмәтулла абзыкай түбән салындырып аскан бер зур сарыкны тунап яталар. Бая алар ат җигеп, көтүгә киткән булганнар икән, менә шуннан бер кысыр сарыкны алып кайтып суйганнар. Мин килгәндә тунап бетереп торалар иде. Кода бабай да килеп карады. Хөбәйбулла кода үткен пычак очы белән сарыкның кабырга арасын берничә җирдән телеп җибәрде,— кара ите юк диярлек, торганы май гына.

— Сөбеханалла,— диде кода бабай, башын селкеп.— Җыйган икән майны үзе дә, ризыкка язсын.

— Хәзрәтләрнең эченә тимәсә ярый инде,— диде Нигъмәтулла абзыкай, көлеп.

— Тимәс, ашап өйрәнгән халык. Сигез капканчы, симез кап, дигән борынгылар... Каклаган ит белән җиңел үтәр, иншалла.

Кода бабай киткәч, Нигъмәтулла абзыкай комганнан җылы су белән кулларын юды да, җиргә чүгәләп, учына яшереп кенә тәмәке көйрәтергә тотынды. Хөбәйбулла кода да аның янына чүгәләде.

— Туйны кемнәр күтәрешә? — диде Нигъмәтулла абзыкай.

— Әхмәтсафа абзыйлар, Сабирҗан җизниләр, Галекәйләр... шул үзебезнең якыннар инде.

— Сәләхи абзыйлар?

— Юк, алар катнашмый.

— Пәрәмәч, ник?.. Бик якын туганыгыз лабаса.

Хөбәйбулла кода авыр гына сулап куйды.

— Туган да бит, һәркемнең үз исәбе, кияү... Әтәй дә, мин дә әйтеп карадык югыйсә. Быел елыбыз авыр, туй кебек зур мәшәкатьне күтәрә алмыйбыз, ди... Анысы инде берәүгә дә җиңел түгел дә бит, туганлык хакына күтәрәләр. Ә үзебезне әйтмим дә инде... Туй үткәрүнең нәрсә икәнен беләсең, кияү, әнә өсәкләребездә канат белән сыпырып алырлык та бөртек калмады. Ләкин җәл түгел, бетсен, тик баш кына сау булсын, ие!.. Сәләхи абзый бик карун кеше ул, ипиен дә иләтмичә генә салдыра, ә үзенең ындырында сукмаган эскерте тора... Әмма ләкин хикмәт анда гына түгел, хикмәт бүтәндә. Аларның да бит безнең Сәлимәдән олырак житкән кызлары бар. Мәфтүха... Менә Сәлимә китә, ә Мәфтүха калып

тора әле... Шуны бер дә күтәрә алмыйлар, кияү, көнчелек ашый үзләрен...

— Алай икән,— диде Нигъмәтулла абзыкай, сузып кына.— Хикмәте бар икән шул... Кайнагай, теге ни, Сәлимә балдыз, мин әйтәм, Мәфтүханың юлын кисмәгәндер бит...

— Алла сакласын! — диде Хөбәйбулла кода, ашыгып.— Андый нәрсә буламы соң?!. Язмыш эше, кияү, язмыш эше. Берәүнең дә монда гаебе юк.

— Аптырап кына әйтүем инде, әллә Мәфтүханың да ул егеттә өмете булдымы икән дип кенә...

— Өмет... өмет, ни, һәрбер җиткән кызда була инде ул... Әмма нишләмәк кирәк, язмыш!.. Хәзерге яшьләрне беләсең, үзләре бер-берсен табалар. Мунчаклап китереп булмый.

— Дөрес инде анысы, кайнагай, дөрес... Һай, Мәфтүха!.. Әйтәм җирле, ул сездә күренми.

— Чакырдык, бик чакырдык үзен,— диде Хөбәйбулла кода, ачынып.— Инәкәй үзе барып чакырып карады, юк, килмәде, чәкчәк пешерергә дә килмәде. Әтисе, Сәләхи абзый, инәкәйгә әйткән, үзебез туйны күтәрешә алмагач, Мәфтүханы да җибәрә алмыйбыз дигән. Я, шул да булдымы сүз?! Әлеге дә баягы, көнчелек... көнчелек ашый адәм баласын!

— Хәерле булсын! — диде Нигъмәтулла абзыкай, тәмәкесен җиргә басып.— Кызлы йортка кырык ат бәйләнер дигәннәр. Мәфтүха да утырып калмас әле, насыйбы табылыр.

Алар чүгәләгән җирләреннән тордылар.

— Кызлы йортлар күбрәк, егетле йортлар әзрәк шул хәзер,— диде Хөбәйбулла кода көрсенеп.— Канатлар чыкты егетләргә, еракларга оча башладылар... Их-ма, дөньясы!

Аларның бу кыска гына сөйләшеп алулары миндә шактый күңелсез уйлар кузгатты. Менә туй, бәйрәм, зур шатлык булырга тора, ә баксаң, аның эчендә дә әнә нинди каршылыклар, ризасызлыклар бар икән... Гаҗәп бу тормыш!

Ниһаять, кич тә булды. Тузан, сөт исе аңкытып көтү кайтты. Сыер, сарыкларны капкадан ук туры абзарга куып керттеләр. Җиңгәчәй белән кече кодача, чиләк күтәреп, шунда ук сыерларны саварга киттеләр. Әш бер дә бетәр кебек түгел иде, ләкин кода бабай, күз бәйләнгәнче халыкны ашатырга кирәк дип, кичке ашны тизрәк ашыктырырга кушты. Ике җиргә — берсен бакчадагы кечкенә өстәлгә, икенчесен, зур торыпша җәеп, ишек алдының тапталмаган чирәменә — табын әзерләделәр. Барлык эшләп йөрүче кызлар, җиңгиләр, апайлар арган аякларын сузып, чирәмдәге зур табынга урнаштылар. Бакчадагы кечкенә табын кунаклар белән хуҗалар өчен генә — без шунда утырыштык.

Безнең табынга графин белән бал да килде. Бу туйга дип әчеткән бал инде, бүген шуны ничегрәк булган икән дип эчертеп карыйлар. Кода бабай беренче башлап Нигъмәтулла абзыкайга салып бирде. Ул балның остасы — стакан кырыннан әз-әзләп кенә эчеп, авызын чәпелдәтеп торды да:

— Булган бу,— диде.— Әчүе дә җиткән, кыркуы да юк, ширбәт кенә... Әмма үзе, борыч салгандай, авызны яндырып бара. Шәп булган бу, шәп!

— Инәйнең балы беркайчан да начар булмый торган иде,— диде җиңгәчәй дә.

— Һи минем әби, минем әби бишенче кызын бирә шул, ничек итеп аның балы начар булсын ди. Күз яшьләрен тамыза-тамыза койгандыр әле ул аны.

Кодагый әби көләргә итте, көлә алмады, күзләренә яшьләре килгән-

дәй булды, ләкин аларны да күрсәтмәде, тик тирләгән битен генә яулык очы белән сөртеп куйды.

Кода бабай балны миңа да салып бирде. Мин, эчимме икән, юкмы икән, эчсәм — килешер микән дип, шактый аптырауда калдым. Кода бабай шуны сизгәндәй:

— Я, я, шәкерт, аз гына эчкәннән гөнаһ булмас,— диде.

Яртылаш кына эчтем, һәм чынлап та бал гаҗәп тәмле иде. Башта куәтен дә сизмәдем, тик соңыннан гына ул әкренләп бөтен тамырларыма җәелгәндәй булды.

Шуның тәэсиреннәндер инде, мин, өстәл тирәсендә барган сүзләргә колак салмыйча, кинәт Сәлимә кодачаны исемә төшереп, аның язмышы турында уйлана башладым. Минем бит әле аны юньләп күргәнем дә юк. Йөрми, чыкмый, менә безнең табынга да утырмады. Ярәшелгән кызлар бик оялчан булалар дип ишеткәнем бар, сизгер җәнлек шикелле, кеше күзенә күренергә бер дә яратмыйлар, имеш... Әйе, Сәлимә кодачаны да хәзер никахтан ярты гына тәүлек вакыт аерып тора, иртәгә ул кыз чагының соңгы сызыгын үтәчәк, икенче тормышка керәчәк, кеше кешесе булачак. Ни уйлый ул, ниләр кичерә, үзен ничек тотарга мәҗбүр,— менә шуны белер өчен генә мин аңа хәзер бер тутырып карар идем. Күңелемнән генә: «Мин сине кызганам, мин сине көнлим, әмма сиңа бик күп, бик күп бәхет телим»,— дип әйтер идем.

...Аш ашап, чәй эчкәннән соң, безгә ятарга куштылар. Мине, кунак дип, түр өйгә яткырмакчы булганнар иде, ләкин мин туй мәҗлесе өчен шулкадәр тырышып юган-җыештырган җиргә кереп ятарга бер дә теләмәдем. Рәхмәт Нигъмәтулла абзыкайга, ул гадәттәге өлгерлеге белән: «Я, мондый кичтә кем өйдә ятсын, без шәкерт белән печәнлектә йоклыйбыз»,— диде. Кунакларның атлары өчен лапас башына күп итеп печән китереп өйгәннәр икән, без шул, әле кибеп тә өлгермәгән, хуш исле печәнгә палас җәеп, ике мендәр ташлап, менеп яттык. Нигъмәтулла абзыкай башын мендәргә кую белән гырлап йоклап та китте. Мин алай тиз генә йоклап китә алмадым. Ишек алдында һаман кешеләр йөри, көлгән, сөйләшкән тавышлар ишетелә, лапас эчендә арбага бәйләгән безнең сары ат ашыкмый гына үлән кетердәтә, ара-тирә авыр гына сулап та куя, салдырылган авызлыгын әледән-әле чылтыратып ала. Ә аяз күктә миңа туп-туры карап тулган ай тора. Юк, тормый, китеп бара. Юк, китеп бармый, тора. Әллә тора, әллә китеп бара?! Ә тулган айга житез-тере генә бер йолдыз ияргән... Ул да тибрәнә-тибрәнә... тибрәнә-тибрәнә... Мин йоклап китүемне сизми дә калдым.

Төшемдә кояш чыкканын күрдем. Бер биек кенә калкулык өстеннән ерактагы кара-зәңгәр офыкка карап торам, имеш. Менә бервакытны шул зәңгәр караңгылык әкрен генә сыеклана-сыеклана алсуланып яктырды. Озак та үтми, чыгып килгән кояшның нечкә кавын телемедәй сары кырые күренде. Бераздан ярты калач хәтле булып чыкты бу, аннары, чыга торгач, төп-түгәрәк ут шарына әйләнеп, җирнең читенә үк чыгып утырды. Менә бер заман аның әйләнәсендә әллә никадәр алтын кыршаулар чайкалып уйнакларга тотынды,— һич карап та булырлык түгел. Һәм шул чакта мин дә күзләремне кытыклаган җылы яктыдан уянып киттем. Баксам, кояш шактый күтәрелгән, кечерәйгән, кызган, һәм мине, «Тор, малай!» дигән төсле, бик әйбәтләп пешерә дә башлаган. Ишек алдында шул ук кешеләр мәш килеп йөриләр,— кайчан ятып, кайчан торганнардыр, хода белсен!

Лапастан төшүгә мине коедан су чыгарып торган кече кодача күреп алды. Оялчан гына елмаеп дәште:

— Әхтәм, кил, салкын су белән юын!..

Үзе, рәшәткә буена тиз генә барып, чиләгеннән комганга су салды да мине көтеп тора башлады. Мин килеп комганга үрелгәч, ул ашыгып: «Юк, юк, үзем» диде һәм бик теләп миңа су салып торды. Аннары сөл-

ге бирде. Кече кодача!.. Миннән ничә яшькә олырак икән? Бу инде теге кияүгә китәчәк кодачаның сеңелесе, кода бабайларның төпчек кызлары. Менә апасы китә, ә ул шуны гүя үзенең иң зур шатлыгы итеп, канатланып, бөтерелеп йөри. Аңламыйм мин бу кызларны. Кияүгә чыгу алар өчен дөньяның иң зур бәхете микәнни? Сакланып кына сорыйм:

— Апаңны... кызганмыйсыңмы?

Кече кодача миңа бик гаҗәпләнеп карый:

— Нигә?

— Сезне аералар ич.

— Һии,— дип көлде кодача.— Аерсалар ни, ерак китми әле. Күрешә торырбыз.

«Ә син кайчан кияүгә чыгасын?» дип сорыйсым килде минем, ләкин тыелып калдым. «Әдәпсез» дияр, гәрчә бөтен кайгысы кияүгә чыгу булса да.

Ләкин шулай да минем аңардан егет турында бераз сорашасым килде.

— Кияү кем инде?

— Кем булсын, кеше! — диде кече кодача, мине үчекләгәндәй.

— Алаша түгел икәнен мин дә беләм,— дидем, үз нәүбәтемдә шаярткан булып.— Мин синнән кайдан, нинди егет ул, дип сорыйм.

— Түбән Абзаннан, Фазылҗан малае Шакирҗан... Я, белдеңме?

— Чибәр егетме?

— Чибәр, күргәч, гайрәтең чигәр,— диде кече кодача, шаркылдап. Нигәдер аның минем белән гел уйнап кына сөйләшәсе килә.

— Юк, мин чынлап сорыйм,— дидем мин, көлмәскә тырышып.

— Мин дә чынлап әйтәм. Ихлас, чибәр егет, тәтәй өчен бик тә чибәр...

— Йөреп өйләнештеләрме?

— Ничек... йөреп?

Мин азрак уңайсызланып киттем: әллә юри аңламаган була инде, пәри кыз!

— Ни... теге... алдан танышып, яратышып йөрделәрме дим?

— Ә-ә! — диде кече кодача, күзләрен хәйләкәр генә кысып.— Каян белим, аны кешегә сиздермиләр ич.

— Син бит сеңелесе, белгәнсеңдер әле.

— Белсәм ни, тәтәйнең гайбәтен сатарга мин юләр түгел лә.

— Өйләнешкәч, гайбәт булмый инде ул хәзер.

Кече кодача аз гына уйга калды һәм беравык миңа сынагандай карап торды. Аннары кисәк кенә:

— Ә син кешегә әйтмәссеңме? — дип сорады.

— Кемгә әйтим, мин бит монда берәүне дә белмим.

Кече кодача, тирә-ягына ялт-йолт каранып алды да, миңа нелә биреп, шыпырт кына әйтте:

— Мин алар арасында хат йөрттем.

— Шулаймыни? — дидем мин, бик кызыксынып. Аннары аптырабрак сорадым: — Хатны ничек йөрттең соң? Ул бит икенче авылда.

— Булса соң... Түбән Абзан аръякта гына... Болынга кичке уенга без моннан, ә алар теге яктан төшәләр. Менә шул чакта Шакир җизни, әем лә, ул чакта җизни түгел әле, ...шыпырт кына миңа хат төртә иде. Ә мин тәтәйнекен аңа...

— Алар үзләре бер дә очрашмыйлар идемени?

— Ник очрашмасыннар, очрашалар иде. Ләкин бит гыйшык сүзен телдән әйтеп булмый, хатка гына язып була... Син, шәкерт башың белән, шуны да белмисеңмени? — диде кече кодача, мине тәмам үтерердәй итеп.

Мин комачтай кызарып киттем: юк икән шул әле, гыйшык тотуның

серләрен белмим икән әле мин... Ләкин, дәрәҗәне саклар өчен, эре генә әйткән булдым:

— Хатны танышыр өчен башта гына язалар, ә танышкач барысын да телдән сөйләшәләр.

Кече кодача, «тиле син» дигәндәй, тагын шаркылдап көлде.

— Әйттең сүз! Аларга нигә танышып торырга, алар болай да берберсен би-ик күптән беләләр. Ә менә егет хат язмаса, аның яратуын кайдан беләсең? Вәт әйтеп кара!

Чынлап та шулай күрәсең... Минем бит үземнең дә бергә укыган Әминә исемле кызга «танышыйк» дип «гыйшык» хаты язып караганым бар, тик ул, юләр, тоткан да хатны әнисенә биргән, ә әнисе минем әнкәйгә әйткән: «Малаең иртәрәк аза башлаган түгелме, Хакимәттәй» дигән. Ай-һай шул чактагы хәлемне белсәгез иде, оятымнан перәме җир тишегенә керердәй булдым... Әмма шулай да яратуыңны аңлатыр өчен барыбер хат язу кирәк икән, акка кара белән язмыйча торып кызларны ышандыруы читен икән. Менә кече кодача миңа нинди сабак биреп куйды бит әле...

...Тагын аңардан ниләрнедер бик сорашасым килә, ләкин шул арада аш өеннән кемдер аны кычкырып дәште, һәм кече кодача, кәҗә бәтиедәй уйнаклап, йөгерә-йөгерә китеп тә барды.

Җиңгәчәй миңа ак сәдәпле кара сатин күлмәгемне каталап бирде. Мин, лапаска кереп, шул күлмәкне кидем, өстемдәге пинжәк белән чалбарымны сыпыргалап кына чистарткан булдым, аягымдагы ботинкаларны печән белән сөрткәләдем. Менә кала кунагы туйга әзер дә!

Бакчадагы әлеге кечкенә өстәлдә майлы коймак белән ашык-пошык кына чәй эчтек. Берәүнең дә озаклап утырырга вакыты юк, хәтта сөйләшү дә юк, санаулы гына сәгатьләр калды. Җомгадан соң хәзрәтләр килергә, туй килергә тиеш.

Ләкин миңа болай көязләнеп, туй көтеп, эшсез йөрү бик уңайсыз иде. Йомыш-фәлән кушучы да юк һәм, күрәм, минем монда хәзергә кирәгем дә юк. Әйләндем-тулгандым да, эш белән әвәрә килгән хуҗаларның күзләреннән бераз югалып торыйм дип, тагын болынга чыгып китәргә булдым. Китәр чакта гына түр өйнең ачык тәрәзәсеннән Сәлимә кодачаны күреп алдым. Ул тәрәзә төбенә куйган көзге алдында озын кара чәчләрен тарап утыра иде. Аның тирәсендә җиңгәчәй һәм тагын өч-дүрт кыз чуала. Үзара нидер сөйләшә-сөйләшә кызның әйберләрен — күлмәген, яулыгын, калфагын, тасмаларын, тагын әллә нәрсәләрен карыйлар, барлыйлар, куялар,— кыскасы, кәләшне киендерергә әзерләнәләр. Бу кызларны «ястыкчы кызлар» дип йөртәләр икән. Алар, туйга әзерлек башланган көннән алып кызны кияү куенына керткәнчегә кадәр, гел кыз янында булып, бөтен эштә аңа ярдәмләшеп, булышып торалар икән. Белеп кушканнар аларга «ястыкчы кызлар» дигән шундый матур исемне!.. Мин кодачаның түбән иелгән йөзенә бераз гына карап тордым. Әйтергә кирәк, бу тип-тигез кояш карасы төшкән бик чиста, чибәр йөздә моңаю, уйлану яки хәсрәтләнү кебек һич нәрсә сизелми иде, бары үз эшенә бирелгән җитдилек һәм беркадәр тынычсызлану, пошыну гына чагыла иде сыман... Менә ул минем онытылып карап торуымны сизеп алды булса кирәк, кисәк кенә башын күтәрде дә, нечкә кашларын җыерып, бик сәерсенеп, гаҗәпләнеп калды. Мин, тотылган караклай, гаять уңайсызланып, кызарып киттем һәм тиз генә борылып, ак-караны күрмичә, китеп тә бардым. Шуннан соң инде мин аны бөтенләй диярлек күрмәдем дә.

Бүген төнлә болынга бик мул булып чык төшкән икән, әле дә кибеп беткәне юк. Үләннәр юеш, ямь-яшел, чәчәкләрдә энҗе бөртегедәй түгәрәк тамчылар җемелди. Түреш өстендә ефәктәй юка гына ак томан тибрәнә. Көн тымызык, эссе-бөркү. Бөтен әйләнәдә тын гына, әмма өз-

лексез бер хәрәкәт сизелә. Үлән сабакларында ниндидер бөҗәкләр әрле-бирле ашыгып йөриләр, кайбер чәчәкләргә күбәләкләр ябышып сеңгәннәр дә, аерылырга теләмичә, бары канатларын гына җилпеп куялар, ә кайбер зуррак чәчәкләр эченнән төклетуралар, тузанга баткан йонлач тәпиләрен көчкә сөйрәп, ава-түнә чыгалар. Ләкин шулай да бу тын хәрәкәттә, колак салыбрак тыңласаң, тонык кына гүләү, нечкә генә безелдәү өзлексез ишетелеп тора.

...Барам, туктыйм, колак салып торам. Тагын кузгалып китәм, тагын туктыйм. Үлән арасында мәж килгән хисапсыз кортларга, бөҗәкләргә озак кына карап торам. Аннары күтәрелеп, ерактагы күксел киңлекләргә бер гаҗәпләнеп карыйм. Я, дөнья, нинди киң, нинди иркен син! Әмма шушы чиксез, нурлы иркенлектә, шушы иркә, назлы, йомшак табигать кочагында мин үземне нигәдер бик ялгыз тоям. Күңелемне ниндидер сәбәпсез сызлану, моңаю гел биләп тора кебек... Бөтен җанымда әллә нинди бер тирән кичереш бара... Нигә соң ул алай?!.

Минем ундүрт яшьлек чагым. Мин күп уйланам, бик аз беләм. Тормыш нәрсә, бәхет нәрсә, мәхәббәт нәрсә ул? Бигрәк тә мәхәббәт дигән сихерле ут, оят булса да әйтим, минем йөрәгемә үрмәли башлады. Тиздән шуның кабынып китәсен ничектер йөрәгемнең бөтен тамырлары белән тоеп торам, әмма мин әле аны һич аңлый алмыйм. Чынлап та, нәрсә соң ул рәхимсез һәм котылгысыз мәхәббәт?.. Кызны ярату, кызны теләү генә микәнни ул? Кыз үзе дә шулай егетне яратырга теләп тора микәнни?.. Бары шул гынамы ул мәхәббәт?.. Менә бал корты чәчәккә килеп кунды — чәчәк сыгылып төште. Бәлки, бу да мәхәббәт галәмәтедер. Бәлки, егет белән кыз да бер-берсен яратырга теләгәнгә күрә генә, бал корты белән чәчәк төсле, бергә кушыла торганнардыр. Ләкин мәхәббәтнең башымы бу, әллә ахырымы,— һич аңлый алмыйм мин моны... Егет белән кыз үзләре моны аңлыйлар микән? Нинди максат хакына, нинди өмет, нинди хыяллар белән алар кушылалар икән?.. Менә мин дә, вакыты җиткәч, өйләндерегез дип әйтермен, әмма бу мине куркыта. Миңа мәхәббәт кирәк, мәхәббәт телим мин, мәхәббәт бирегез миңа!.. Ә нәрсә ул — мин аны белмим, белмим...

Әйе, бу минем ундүрт яшьлек чагым. Мин гел нидер көтеп яшим. Хыялым бары киләчәктә генә... Киләчәк мине дәшә, чакыра, әллә ниләр вәгъдә итә, ләкин мин беләм, бу әле якты, томанлы рәшә генә, аңа әле барып җитәсе бар... Нәрсә ачылыр ул томан артында — миңа билгесез, мин күрмим әле аны. Менә шушы билгесезлек мине гел борчып, үртәп, җанымны ничектер ләззәтле сыкратып тора да шикелле... Күңелдә әледән-әле өмет белән өметсезлек чиратлашып туа, вакыт-вакыт үземне, кешеләрне, җирдәге бөтен җан иясен өзелеп кызгана башлыйм, берәүгә дә афәт килә күрмәсен иде, берәү дә бу якты дөньядан мәхрүм булмасын иде дип тели-ялвара башлыйм. Ләкин шуның артыннан ук миндә искиткеч бер көч, дәрт, өмет кабына ки, мин бөтен дөньяны ал да гөл итеп, бөтен кешеләрне тигез, шат, бәхетле итеп, үземне исә бәхетнең җиде кат күгендә итеп күрә башлыйм. Өмет, өмет, өмет!.. Мин аңа ышанам, мин аңа табынам, мин аның өчен диңгезләр кичәргә, таулар аша сикерергә әзер торам... Менә нинди тиле, хыялый «бала» чагым бу минем!

Мин кайтканда, бөтен әзерлек эше беткән иде булса кирәк. Иртәнге яктагы шикелле арлы-бирле чабып йөрүләр күренми диярлек. Хәрәкәт басылган, зур бер тантана алдыннан гына була торганча, нәрсәнедер шауламыйча, кабаланмыйча сабыр гына көтү сизелә. Ачык тәрәзәләрендә әкрен генә ак пәрдәләр җилфердәгән өйгә һәм бер чүп әсәре калдырмыйча себерелгән ишек алдына чын бәйрәм төсе кергән. Эшләп йөрүче хатын-кызлар да өсләрен алыштырып, киенеп-ясанып куярга өлгергәннәр. Ишек алдында яңа кешеләр — ир уртасы агайлар һәм кияз

егетләр дә күренә: болар туй каршы алырга килгән якын кардәш-ыру булса кирәк.

Ак келәт алдында ястыкчы кызлар кайнаша. Кызны киендереп бизәндереп ак келәткә кучергәннәр инде. Ә лапас астында иярле ат тора — никах укылгач та кемдер, шул атка атланып, егеткә хәбәр итәргә чабачак.

Егетнең авылы ерак түгел, моннан өч-дүрт чакрымда гына, Түрецарьягында. Туй җомгадан соң килергә тиеш. Мәчет тә шул ук авылда (Кечкенә Абзанның үз мәчете юк). Кода бабай белән Нигъмәтулла абзыкай, аның атында, җомгага киткәннәр инде. Димәк, күп көтәсе калмаган.

Таза гәүдәсенә озын кара казаки, зур башына бәләкәйрәк кәләпүш кигән Хөбәйбулла кода бер өйгә кереп, бер йортка чыгып, һаман нидер кайгыртып, тынычсызланып йөри.

— Әхтәм кода,— диде ул миңа бер үткәндә,— син тагын китеп югалма инде. Шушында гына бул!

Әллә ничек кызык та, уңайсызрак та булып китте миңа: «кода» дип бик зурлап дәшә һәм бер үк вакытка балага әйткәндәй югалмаска да куша.

Озак та үтми, кода бабай белән Нигъмәтулла абзыкай сары атта җомгадан кайтып керделәр. Шунда ук өйдә, ишек алдында хәрәкәт көчәеп китте. Ак келәт алдындагы ястыкчы кызлар тыз-быз килә башладылар. Капка төбенә бала-чага җыелды... Ул да булмый, икенче атта чалма-чапан кигән хәзрәтләр дә килеп керделәр. Кучерда утырган кара сакаллы абзый атын өйнең нәкъ баскычы төбенә китереп туктатты. Муллалар, тарантастан ашыкмыйча гына төшеп, сәлам бирделәр:

— Әссәләмегаләйкем!

Кода бабай, Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай өчесе бер авыздан бик тайяр рәвештә сәламнәрен алдылар:

— Вәгаләйкүм-әссәлам! Хуш килдегез, хәзрәтләр!

— Туйлар мөбарәк булсын!

— Амин, шулай булсын. Әйдәгез, рәхим итегез!

Юл биреп, муллаларны өйгә уздырдылар. Алар кереп утырырга һәм дога кылырга да өлгермәгәннәрдер, каяндыр ерактан, ап-ак арыш кырлары түреннән «зиң-зиң» чыңлаган кыңгырау тавышлары ишетелде. Бу тавыш ерак һәм әкрен булса да, капка төбендә торучы бер егет яман кычкырып җибәрде:

— Туй килә-ә!

Әйе, туй килә, туй! Бар да капкага ташландылар. Мин дә урамга йөгереп чыктым. Ләкин атлар күренмиләр иде әле, тик кыңгырау тавышлары гына отыры дәртләнебрәк, ашыгыбрак янтырый-көчәя бара иде. Бөтен капкалардан йөгерешеп хатын-кызлар, бала-чагалар чыкты. Алар белән бергә, «кайда, кемнәр килә?» дигән төсле, ялт-йолт каранып, койрыкларын үрә бастырып этләр атылып чыктылар. Юл буенда йөргән тавыклар, алдан ук керер тишек эзләгәндәй, муеннарын суза-суза читән буйларына йөгерештеләр... Ниһаять, авыл очындагы сай чокырдан бер пар ат атылып килеп чыкты, аның артыннан икенче пар ат, аңардан кала ялгыз ат җиккәннәре килеп чыга тордылар. Ничәү үзләре? Бишәү, юк, алтау икән... Һай, киләләр, агай, һай, киләләр дә соң! Җирен генә чыдасын!

Капка төбендәге бала-чагалар, чебиләр шикелле, читкә сибелделәр. Ишек алдына беренче пар ат шаулап килеп керде. Кучердагы егет, ишек алдын уратып, атларын баскыч төбенә үк китереп туктатты. Тарантастан, хатыны белән, кара сакаллы, таза гына бер абзый — баш кода төште. Аларны кода бабай һәм башкалар: «Әйдүк, хуш килдегез, рәхим итегез!» дип зурлап каршы алдылар. Беренче атлар кузгалгач, икенче пар ат ишек төбенә килеп туктады. Бусыннан егетнең әти-әни-

се — төп кода белән кодагый төштеләр. Төп кода — озын, җирән кеше — ир уртасы гына икән әле, күрәсең, беренче малаен гына өйләндерә торгандыр... Аларны аеруча зурлап каршы алдылар. Шулай итеп, атлар ишек төбенә килеп туктый тордылар, китә тордылар, ә төшкән кунакларны каршы алып, ирләрен түр якка, хатыннарын уртадагы салкын якка кертә тордылар.

Кунакларны каршы алып беткәч, хуҗалар да өйгә керделәр. Мине дә, билгеле, онытмыйча кунаклар янына чакырдылар. Без кергәндә зур сәкенең түренә, бөкләп салган юрганнар өстенә хәзрәтләр һәм кодалар менеп утырганнар иде инде. Калган кунаклар да, дәрәҗәләренә карап хәзрәтнең ике ягына тезелешеп утырдылар. Минем урыным сәке кырындагы тәрәзә янына туры килде. Кода бабай да, урындык алып, хәзрәтләргә каршы утырды. Урын җитмәгән кайберәүләр (кызның яшьрәк туганнары) ишек төбенә чүгәләделәр.

Түрдә тыныч кына көтеп утырган чалма-чапанлы, ак сакаллы карт хәзрәт зәгыйфь кенә тавыш белән:

— Я, утырышып беттегезме, җәмәгать? — дип сорады.

Кода бабай түбәнчелек белән генә:

— Ие, хәзрәт, барыбыз да әзер,— диде.

— Алайса, башлыйбыз?

— Аллага тапшырдык, хәзрәт! — диде кода бабай.

— Изге сәгатьтә! — дип куйды төп кода.

Өйдә, өйдә генә түгел, тышта, хәтта урамда да тантаналы тирән бер тынлык урнашты. Иң мөһим, иң киеренке вакыт җитте,— бөтен кеше җитди уйчан, аз гына моңсу бер кыяфәттә оеп калдылар. Хәзрәтнең никах укуы хатыннар ягына да ишетелсен дип, ак пәрдә корган өй ишеген чак кына ачып куйдылар. Ул якта да шылт иткән тавыш юк иде.

Шуннан соң хәзрәт аз гына тынып торды, бөгелә төште һәм күзләрен йомыбрак, зәгыйфь-моңсурак тавыш белән әгузе-бисмилласын әйтеп, ашыкмыйча гына никах укый башлады. Кешеләр уйлары белән каядыр бик еракка киткәндәй, алларына гына карап, һичбер селкенмичә тыңлап утыралар. Минем нигәдер кинәт кенә күңелем тулып китте, ирексездән күз төпләрем кымырҗый башлагандай булды... Кемдер бу минутта мина бик кызганыч булып тоелды, ләкин кем — кызмы, этиәниләреме — үзем дә белмим... Тәмам аптырадым инде бу калтыравык күңелнең һич юкка да нечкәреп китүенә...

Никах укылып бетте, хәзрәт һәм аның артыннан барлык кунаклар берьюлы кулларын күтәреп, озак кына дога кылдылар. Мин дә, кулларымны кушарып, нидер укырга тырышып карадым, ләкин ни сәбәптәндер бөтен белгән догаларымны онытып җибәргәнмен, бары өзек-өзек сүзләрне генә кабатлап, ахырдан «бәхет телим, бәхет телим» дип битемне сыйпап куйдым.

Дога кылып бетүгә, башта кода бабай торып, хәзрәткә, икенче муллага һәм мәзингә кәгазь акчалар сузды. Тагын озын гына итеп дога кылдылар. Аннары Хөбәйбулла кода, аның артыннан Нигъмәтулла абзыкай торып, сәдака бирделәр. Нәкъ шул чакта иярле атка атланган бер егет, тасыр-тасыр чабып, капкадан чыгып китте: кияүгә никах укылуын хәбәр итәргә.

Сәдака бирү, дога кылулар беткәч, кунаклар алдына ике-өч кулдан тәлинкә-кашыклар тарата башладылар. Кече яктан ике зур миски белән аш керттеләр. Нигъмәтулла абзыкайны оста табынчы дип әйтә торганнар иде. Менә ул, егетләрнеке сыман сылу гәүдәсе белән табын каршына басып, бик әйбәтләп бисмилласын әйтеп, иң элек никах укыган хәзрәттән башлап, бөтен кунакларга да аш салып чыкты.

Аштан соң ике таба бәлеш, бәлештән соң зур табакларда өеп туралган ит чыгардылар. Кунаклар шуларның барысын да сүзсез генә күңел биреп, бик тырышып һәм яратып ашадылар. Тик һәр аштан соң

хәзрәтләр, өлкән кодалар ашны олылап, өйгә бәрәкәт-муллык теләп, мактау сүзләре әйткәләп куйдылар.

Бушаган табакларны кире чыгаргач, агач тустаганнар белән өрек суы бирделәр. Кунаклар салкын ширбәтне шул савытлардан гына кашыклары белән алгалап капкаларга тотындылар.

Менә бер заман урам буйлап бик кызу сиптереп килгән кыңгырау тавышы ишетелде. Кунаклар бу тавышка аз гына колак салгандай булдылар, ләкин беркем бер сүз әйтмәде. Әдәп һәм тынычлык саклап, алларына карап кына ашый-эчә бирделәр. Кем килә, ни өчен килә — гүя аларның монарда эшләре юк. Ә бит кияү килә, кияү!.. Тик Хөбәйбулла кода гына ашыгып урыныннан торды да, сак кына басып, өйдән чыгып китте.

Ул да булмый, төпкә озын яллы кара ат, мичәүгә тимеркүк җиккән тарантас ишек алдына бик кызу гына килеп тә керде. Мин дә, бөтен әдәп-кагыйдәне онытып, тизрәк тәрәзәгә борылдым. Пар ат ак келәт алдына шып итеп туктады. Атларны бик көязләп җиккәннәр — яллырына ал, кызыл тасмалар үрелгән, калын кара дугада куш кыңгырау, тәнкәле йөгән, тәнкәле шлея, шлеянең каеш чуклары ике яктан асылынып тора... Тарантастан дүрт егет төштеләр. Егетләр барысы да карадан киенгәннәр, барысының да башларында кара кәләпүш, аякларында ялт иткән итекләр. Егетләрнең берсе култык астына, сары яулыкка төреп, бәләкәй генә гармун да кыстырган... Ләкин боларның кайсысы соң кияү тиешле? Әһә, әнә берсенең башында сай гына кырпу бүрек икән, кулында кечкенә саквояж... Шулдыр инде кияү дигәне, һичшиксез, шул!.. Калганнары — кияү егетләре.

Аларны келәт ишеге төбендә ястыкчы кызлар сырып алдылар. Аз гына ыгы-зыгы килгәннән соң, егетләр, кулга кул тотынышып, киек казлардай тезелештеләр. Алдан — баш кияү егете, аңа тотынганы — кияү үзе, калганнары — кияү егетләре. Шулай тезелешкәч, алар келәт ишегенә килделәр. Келәт ишеген тотып торучы бер җиткән кызмы яки яшь хатынмы, башын чөебрәк егетләргә нидер әйтте. Баш кияү егете аңа нәрсәдер дип җавап кайтарды. Тагын кара-каршы нидер әйтешеп алдылар. Әйләнәдә тыңлап торучы ястыкчы кызлар дәррәү генә көлештеләр. Шуннан соң теге кызмы яки хатынмы келәт ишеген ачып җибәрде һәм егетләр эчкәре уздылар.

Шушы минуттан минем дә бөтен күңелем-уем келәт эченә күчте. Бу вәкарьле, дәрәҗәле, йомык-салынкы картлар җыелган никах мәҗлесе минем күземә бөтенләй күренмәс булды. Бөтен хикмәт, бөтен кызык хәзер тегендә, ак келәт эчендә. Кияү егетләре, ястыкчы кызлар анда нишлиләр, нәрсә сөйлиләр, кияү үзен ничек тота, кыз ни хәлдә — шуларны минем үлеп күрәсем, ишетәсем килә. Ләкин мин менә шушы табында, шушы хәзрәтләр янында әдәпле, инсафлы, тыйнак бер шәкерт булып утырырга тиешмен. Кагыйдәсе шундый — кузгалырга ярамый... Ә олылар тыныч, олылар, берни булмагандай, гамьсез генә чәйләрен эчәләр, тик ара-тирә язмышлар, тәкъдирләр, гомерләр турында бик мәгънәле сүзләр әйткәләп куялар. Никадәр ерак та соң бу хыялый яшьлек белән акыллы картлык арасы, уйласаң!..

Ниһаять, мәҗлес бетте, хәзрәтләрне озаттылар, карт кодалар, хәл алыр өчен, утырган җирләрендә генә мендәргә таяндылар, ә кайбер яшьрәкләре тәмәке тартырга абзар артындагы бәрәңге бакчасына киттеләр. Мин дә, мәҗлес бетүгә, тизрәк ишек алдына чыктым. Кияүне китергән пар атны лапас астына тарттырып, тезгеннәрен чишеп кенә баганага бәйләп куйганнар. Ак келәтнең ишеге ябык, анда кияү үзенең егетләре белән генә чәй эчеп утыра. Келәт янына беркем бармый, хәтта ул якка карамаска да тырышалар. Бары кияү белән кызны карарга куелган бер елгыр-яшь хатын гына, озын чәч үргеченә таккан чулпаларын чыңлатып, тыз-быз кергәләп-чыккалап йөри. Минем белүемчә,

кыз әле үзе дә бу минутта чыбылдык эчендә генә утырып тора, кияү егетләре ашап-эчеп киткәч кенә ул кияве янына чыгачак.

...Нишлим, кая барыйм икән дип аптырап торган чагымда, мине Нигъмәтулла абзыкай үз янына дәшеп алды. Ул тирләгән, күлмәк якасын чишеп җибәргән, кулындагы зур чиккән яулык белән һаман битен-муенын сөрткәли.

— Син беркая да китеп югалма,— диде ул миңа.— Хәзер кодалар белән кунакка китәбез.

— Нишлим мин анда? — дидем мин, тискәреләнеп.

— Менә тиле. Син дә кунак бит. Кодалар белән йөрерсең.

— Кирәкми, йөрисем килми,— дидем мин, отыры үҗәтләнеп.

— Күп сүләнмә,— диде абзыкай, кискен генә.— Монда калып нишлисең?.. Ярамый, килешми...

«...Ярамый, килешми» — бу сүзләр мине ничектер сискәндереп, айнытып җибәргәндәй итте. Ни өчен дип мин, абзыкайдан гына түгел, үз-үземнән сорарга да оялдым, тик бер нәрсәне бик яхшы аңлап алдым: юк, ярамый, ярамый бу тирәдә йөрергә!

Озак та үтми, кунак өйнең ишек төбенә кыңгыраулы атлар килеп туктады һәм кодалар чыгып шуларга утырыша башладылар. Нигъмәтулла абзыкайның да аты җигүле иде, без шуңа өчәүләшеп утырдык... Билгеле булганча, кыз ягының якын туганнары чиратлашып «туйны күтәрешәләр». Никахтан соң менә шул туйны күтәрүчеләргә йөрү башлана. Без хәзер кода бабайның бер туган энесе Әхмәтсафа абзыйларга барабыз икән.

Барасы җир ерак булмаса да, кодаларны атта гына йөртәләр. Пар атлар, алар артыннан ялгыз атлар тезелешеп, артык кызуламыйча, урамны салмак кына бер әйләнеп, хуҗа йортына барып керәләр. Анда кунакларны бик зурлап каршы алгач, ирләрне бер табынга, хатыннарын икенче табынга кертеп утырталар.

Табыннарга аш-су килә, чирекләр белән бал килә, мәҗлес башлана. Бу инде эчке мәҗлесе, күңел ачу мәҗлесе. Монда аракы да була икән, ләкин аны ачыктан-ачык табынга куймыйлар. Яшьрәк кунакларны ымлап кына мич артына чакырып алалар да шунда гына кырлы стаканга салып бирәләр. Буена сеңдер, картларга сиздермә!

Мәҗлес башлангач та кияү егетләре үзләренең кара һәм тимеркүк җиккән пар атларында ишек алдына чаптырып килеп керделәр. Аларны да хуҗалар зурлап, шаулап каршы алдылар. Гадәт буенча, алар, кияүне кәләш янында калдырып чыккач, менә шулай кодаларга кушылып, мәҗлестән мәҗлескә йөриләр. Тик һәркөнне иртән иң элек кияү янына кереп, кодачаларның коймагын ашап, чәй эчеп чыгалар.

Кияү егетләре килгәч, мәҗлес бердән җанланып китте. Дәртле, шат күңелле егетләр — сәкегә менеп, аяк бөкләп утыруны белмиләр дә. Хуҗаларга каршы торып җырлау, җор-шаян сүзләр әйтү, мәҗлесне көлдерү — менә аларның бөтен эшләре шул. Шуның өчен дә алар кияү егетләре!

Кыз ягының яшьрәк туганнары — Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай, тагын бер, кара мыегын тәкә мөгезедәй бөтереп куйган, чандыр кеше — гел аяк өсте торып, кунакларны сыйлыйлар. Әле берсе, әле икенчесе бал тулы стаканны кодаларның әле берсенә, әле икенчесенә җырлап бирә. Җырны күбрәк Нигъмәтулла абзыкай белән әлеге тәкә мөгезедәй кара мыеклы кеше алмашлап җырлыйлар. Кайчагында исә икәүләп, билләреннән тотынышып һәм көй уңаена чайкала биреп, җырлап җибәрәләр. Кара мыеклының тавышы калынрак, Нигъмәтулла абзыкайныкы нечкәрәк, бергә кушылгач, гаҗәеп матур, ягымлы килеп чыга. Һәр җыр артыннан күңелләрне дәртләндереп җибәрердәй берәр кушымта әйтеп куялар:

Атлый-йөгерә килә күк юрга,
Безнең лә дуслык китсен күп елга.

Шулай үткәзеп җырлаганнан соң, кунаклар бер шаулашып алалар:
— Һай, ирләрнең асыллары!
— Рәхмәт, афарин, мең яшәгез!

Кияү егетләренең берсе кыстырып йөреткән кечкенә гармун да тик тормый. Егет аны бер тезе өстенә генә куеп, җәя бөккәндәй ике якка да тигез генә тартып, уйнап җибәрә. «Баламишкин», «Эрбет», «Сәфәр» кебек кыска көйләрне гаҗәп шәп сиптерә, парин!.. Көй уңаена иңбашларын да дәртле генә сикертеп тора, җитмәсә. Аңа карап, кунакларның да йөзләре, аяк-куллары ничектер үзлегеннән хәрәкәтккә килә башлый. Ә бию көен тартып җибәргәч, шунда ук берәр җиңел сөякле абзый бөеренә таянып, башын чөя биреп, уртага чыгып та баса һәм читеге белән идән тактасын «чош-чош» ышкый-ышкый текә генә йөзеп тә китә. Аннары урта бер җирдә, иңбашларын уйнатып, вак-вак кына тыпырдап тора башлый. Кунакларның моңа бик тә кәефләре килә, барысы да шаулап көлергә, ә кайберләре исә, этәч кагынган шикелле терсәкләрен җилпеп, «Һайт сине, сип шуны!» дия-дия такмакларга тотыналар.

Әнә шулай, әле озын көйгә сузып, әле гармун тартып, җырлап та биеп дәвам итә бу туй мәҗлесе... Миңа да бик күңелле иде, мин хәтта зурлар рәтенә кереп, үземнең малай гына булуымны да онытып җибәрдем.

Мәҗлес бетеп, кунаклар таралганда таң сызыла башлаган иде инде. Кодаларның күбесен туй күгәрүчеләр, бүлешеп, үзләренә алып киттеләр, ә төп кода белән башкода кыз йортына кайттылар. Анда аларны салкын итләр, әчегән бал белән чәй табыны көтә иде. Мин күргән-кичергәннәрдән бик арыганга күрә, чәйгә кереп тормыйча, мыштым гына лапас башына үрмәләдем. Лапаска үтешли, аш өенең ишеге төбендә басып торган кече кодачаны, тагын берничә кызны күрдем. Алар нәрсәдер көтәләр иде, ахрысы, миңа дәшмәделәр. Мин, нигә болар йокламыйлар икән дип, гаҗәпләнебрәк уздым.

Үткән төннән җыелмыйча калган, хуш исле печәндәге урынга менеп ятуым булды — бөтен талчыккан тәнем рәхәткә чумгандай изрәп оеп та китте. Ләкин чү! — Бу нинди тавышлар? Башымны кисәк кенә күтәреп, колак салып тора башладым: нечкә кыңгырау тавышына кушылып кызлар көлүе ишетелде, ул да булмый, сыздырып гармун уйнап җибәрде. Әнә нәрсә икән ул Кияү егетләре, пар атларына ястыкчы кызларны утыртып, урам әйләнәләр... Әнә алар киттеләр, буш, тын авыл өстенә тәңкәләр чәчкәндәй, җыр, моң сибә-сибә киттеләр.

Мин изелгән мендәремә тизрәк капландым — йөрәгемне кинәт нидер бик авырттырып, телеп узды. Нигә мин алар белән бергә түгел, нигә мин алар кебек түгел?!. Кызлар, кызлар, ни өчен минем бер үземне генә калдырып киттегез? Малай гынамыни әле мин сезнең өчен?..

Сызланып, сискәнеп күпме йоклаганмындыр, белмим, менә бер заман кемнеңдер аягымнан кат-кат тартуын сизеп уянып киттем. Күземне ачсам, лапаска менә торган баскычта җиңгәчәйнең башы! Бите кып-кызыл, чәче юеш, маңгаенда, борынында сыпырып алырлык тир бөртекләре.

— Әхтәм, бар тизрәк мунча кереп чык, дәдәң киенә калды,— диде ул миңа.

— Әй лә, бармыйм, йоклыйм әле,— дидем мин.

— Юк, бармыйча ярамый,— диде җиңгәчәй,— сансызлык була ул... Туйда озак йоклап ятмыйлар, кайткач йокыңны туйдырырсың.

Берни эшләр хәл юк, тордым да, чалбар белән ботинкаларымны гына киеп, мунчага киттем. Туй уңае беләндер инде, сиплән яңартылган мунча курчак өе кебек иде. Кечкенә тәрәзәсенә ак пәрдә корылган.

чишенә торган мунча алды чип-чиста, агач чөйләргә кызыл башлы сөлгеләр эленгән, киң сәкесенә зур ак җәймә ябылган... Шул сәкедә ычкырлы кызыл штаннан гына Нигъмәтулла абзыкай, тезләренә таянып, тәмәке тартып утыра. Какча тәне кара янган, беләк һәм күкрәк мускуллары таштай беленеп тора, сукса — җененне өзәр!

— Әйдә, шәкерт! — дип каршы алды ул мине.— Кияү мунчасында бер юынып чык.

Кияү мунчасы?! Их, ниләр генә күрсәтми бу туй мина! Хәер, минем бу хакта ишеткәнем бар иде инде. Иртән иртүк, кеше-кара аякка басканчы, кияү белән кызны мунча кертеп чыгаралар. Гадәттә бу җаваплы эшне берәр уңган-җитез, тәҗрибәле хатын башкара. Ул мунчаны өлгертә, мунчаны карый, саклый, ә вакыты җиткәч, келәт ишеген әкрен генә шакып, яшьләрне мунчага дәшә. Моның өчен аңа, билгеле, кияүдән зур гына бүләк тә тия.

Яшьләрне шулай кеше күзеннән яшереп кенә кертеп чыгаргач, мунчаның парын-суын яңартып дигәндәй, башта кодаларны, аннары безнен ише кунакларны кертә башлыйлар. Мунча туйда иң зур сыйлардан санала.

Мин чишенеп эчкәре уздым. Мунча әле май кебек җылы иде, чиста иде, казанында һәм зур агач кисмәктә суы җитәрлек иде, хәтта мич авызында чуен белән селтесе дә тора иде. Идәндә ялт иткән зур таз белән җиз комган, тәрәзә төбендә исле сабын. Ләүкәдә яшь каеннан бәйләгән ике себерке ята, ахрысы, шулардан мунча эченә җиңел генә, тәмле генә бер хуш ис таралган...

Өстемә тагын берәрсе килеп кермәсен дип ашыкканга күрә мин, чабынып-нитеп тормыйча, кечерәк бер табакка кайнар суны таманлап кына салып алдым да, ләүкәгә менеп, каткан чәчемне юарга тотындым.

Мунчадан чыккач та мине ак келәткә, кияү янына чакырдылар. Башта җиңгәчәй килеп әйтте:

— Хәзер бар инде, кияү белән күрешеп чык,— диде.

Мин аптырабрак калдым, ничектер тез буыннарым да хәлсезләнеброк киткәндәй булды. Кияү янына керү бик зур эш булып тоелды мина... Шул ук вакытта бу бик кызыктыргыч та иде, моңарчы минем хыялым гел шул кияү белән кыз тирәсендә әйләнде бит. Шулай да җиңгәчәйдән икеләнеп кенә сорадым:

— Ярар микән соң, җиңгәчәй, мин бит әле бик яшь, малай гына.

— Син инде егет исәбендә, үзең кунак кеше,— диде җиңгәчәй.— Керергә кирәк.

— Ә нишләрем соң мин анда?

— Кияү белән күрешерсең, никах белән котларсың... Син бит кала шәкерте.

Ул да булмый, безнең янга кече кодача очып килеп җитте. Мин аңа тагы да бер гаҗәпләнеп карадым: апасының кияүгә чыгуына бу кадәр дә исереп, шатланып йөрер икән сеңел дигәнең!.. Килеп житүенә, мине тотарга теләгәндәй кулын сузып:

— Әйдәгез инде, әйдәгез җизни янына, сезне көтәләр,— диде ул, кабаланып.

Көтеп үк торалар микәнни дип, борчылып уйладым мин эчемнән генә һәм, каршы әйтер сүз тапмыйча, лапас түбәсеннән пинжәгемне алып, каккалап кидем дә, кече кодача артыннан иярдем.

Көн яктысыннан келәт эченә килеп кергәч, башта бер нәрсә шәйли алмыйча тордым. Ягымлы хатын-кыз тавышы: «Әйдәгез, рәхим итегез!» диде һәм «Менә монда утырыгыз» дип бер буш урындыкны күрсәтте. Мин утырдым. Шуннан соң гына тирә-юнемне ачыграк күрә башладым. Келәт эче иненнән-иненә зур, чуар чаршау белән бүленгән булып чыкты, ләкин хәзер аны, көн яктысы төшсен дип, ике якка тартып куйганнар. Сул яклап бүрәнә стена буена эре чәчәкле ситса

чыбылдык корылган. Чыбылдык эчендә караваТ... Менә шул чыбылдыклы карават янына гына кызыл чүпләм эскәтер япкан кечерәк өстәл куелган. Өстәлдә бармак төртер урын юк: тәлинкәләрдә өем-өем төрле камыр ашлары, эреле-ваклы савытларда бал, май, чәкчәк, конфетлар, чирек белән әчеткән бал, нәкъ уртада таба белән коймак... Өстәл әйләнәсендә дүрт егет утыралар. Ә өстенә күпертмә инбашлы яшел сатин күлмәк, аягына сары читекләр кигән, күкрәкчәле ак алъяпкыч бәйләгән, ак батист яулыгын колаклары өстеннән генә кыстырып куйган, бер егерме биш-утызлар тирәсендәге чибәр хатын кунакларын аягүрә кыстап-кыстап сыйлый... Кияү белән кыз янына куелган хатын инде бу,— үзе бик алчак, җор булса кирәк, теле-телгә йокмый, гел нидер әйтеп, көлдереп кенә тора.

Минем күзем, билгеле, барысыннан элек чыбылдык авызында гына утырган егеткә төште. Шушы кияү үзе! Нәкъ үз өендә яңа гына урыннан торган хуҗа сыман утыра: кыек якалы сары сатин күлмәгенең изүен чишеп җибәргән, кара кәләпүшен арткарак этәргән, кулындагы кызыл башлы озын сөлге белән тирләгән-кызарган муенын-битен әледән-әле сөрткәләп ала... Мин аңа карадым да каттым, башымда әллә никадәр сораулар туды: кем ул, кемнең баласы, нинди кеше, яхшы егетме, белеме бармы, яратып өйләнгәнме, бәхетлеме?.. Заманның кемне үз, кемне үги итүен бик нык сизә башлаган чагым, шуңа күрә кемнең кем булуы мине үтә кызыксындыра иде. Сүз дә юк, бу кияү — чын авыл егете. Байданмы, ярлыданмы — ул кадәресен ачык белмим, һәрхәлдә, кода бабайларның үзләре кебек таза тормышлы кешенең баласы булырга тиеш дип уйлыйм. Ул инде бик яшьтән түгел, ким дигәндә бер егерме бишләрдә булыр. Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткан дип ишетеп калган идем, димәк, күпме-азмы чарланган егет!

Ул түгәрәк йөзле, киң генә маңгайлы, кысыграк күзле, туры гына борынлы, борын төбендә бер чеметем генә мыегы да бар. Юк, болай сөйкемле генә, Сәлимә кодача яратырлык егет, минемчә... Бәхетлеме ул? Хәер, бу бик балаларча уйлау инде. Бәхетле булмыймы соң! Әнә киң битендә елмаю катып калган, хәтта ашаган чагында да язылмый ул. Кысык күзләре аз гына түгәрәкләнеп, ничектер хәрәкәтсез карыйлар. Ул күзләрдә ниндидер хәйран калу, ис китү, хәтта бераз миңрәүләнеп калу да сизелә кебек... Өстенә шундый бәхет аугач ни, миңрәүләнерсең дә шул!

Мин утыргач, күпмедер ара авыр гына тынлык булып алды. Ахырда кияү телгә килеп, теге хатыннан йомшак кына сорады:

— Бу егетне кем дип беләбез инде?

Хатын, шуны гына көткәндәй, гаҗәп бер өлгерлек белән:

— Бу инде, кияү, Нигъмәтулла баҗаңның агасы Әхмәтҗан коданың улы Әхтәм була,— диде.— Безгә кече кода, кала шәкерте, зур кунак!

— Ә-ә! дип кенә сузды кияү моңа каршы.

Мин уянып киткәндәй булдым. Бурлаттай кызардым. Әлеге шул «кала кунагы», «кала шәкерте» дигән сүзләре белән тәмам җилегемә үттеләр инде. Өфедән түгел мин, Бәләбәйдән дә түгел, ә Дәүләкән дигән зур бер авылдан гына... Дөрес, Дәүләкән ул волость үзәге, аның бик шәп базары була, ярминкәсе була, анда зур-зур таш тегермәннәр бар, станция белән элеватор да бар, ләкин шулай да аның беркайчан да кала булганы юк әле. Мин үзем дә шәкерт түгел, укучы (урта мәктәпнең 7 нче сыйныф укучысы) — «шәкерт» сүзе бездә күптән төшеп калды инде, аны хәзер кода бабай шикелле картлар гына әйтәләр. Ә монда шуны белепме, әллә белмичәме, тоталар да я «шәкерт», я «кала кунагы» диләр. Үзләренчә миңа куштанланып, зурлап дәшүләреме соң бу?!. Әллә шулай исемләгәч, үзләренә күңелле буламы? — Янәсе безнең туйда, малай гына булса да, кала кунагы да бар бит әле!..

Шул арада унган хатын мине бик йомартланып кызларга тотынды:
— Ягез әле, кече кода, балдан, майдан, коймактан рәхим итегез. Ягез, я, тартынып тормагыз, кияү ашларын авыз итегез!
Шулай диде дә алдыма, стакан тутырып, әче бал да куйды.
Кылт итеп исемә төште: котларга кирәк ләбаса! Моңарчы кияүгә шаккатып утыру аркасында мин аны онытып та җибәргәнмен. Нишләргә хәзер! Әлбәттә, «кала шәкерте» була торып, миңа мокытлык, җебегәнлек күрсәтергә һич ярамый иде. Ахырда, үземне беркадәр кулга алып, бал тулы стаканны күтәрә төшеп:
— Сезне ни... никах белән котлыйм, не,— дидем мин, тотлыгып кына.
Барысы да шуны көтеп кенә утыргандай беравыздан:
— Ә рәхмәт, рәхмәт кода, рәхмәт шәкерт,— диештеләр. Кияү егетләре, тышаулары бушагандай, шактый җанланып та киттеләр. Алар барысы да тазалар һәм көязләр иде. Кәләш куенында яткан иптәшләренә җылы дуслык, куштанлык күрсәтеп, шул ук вакытта аңа ничектер яшерен бер кызыксыну-көнләшү белән карап, ләкин моны бераүгә дә сиздермәскә тырышып, күбрәк табынчы яшь хатынга уен-көлке әйткәләп кенә утыралар.
Хәер, минем уем аларда түгел, башкада иде: ни өчен табында яшь кәләш үзе юк — шуңа бик гаҗәпләнеп утырам. Хикмәт нәрсәдә икән? Әллә аңа гомумән кияү егетләре янына чыгып утырырга ярамыймы икән? Алай дисәң, кияү кырында гына эчелеп бетмәгән чынаяк тора, өлеш тәлинкәсендә ашала башлаган сыныклар ята. Болар аныкы булырга тиештер бит, югыйсә, кияү белән янәшә кем утырсын?! Димәк, Сәлимә кодача мин керә башлагач кына торып, чыбылдык эченә качкан. Ни өчен бу? Ни өчен ул ундүрт яшьлек малайдан кача? «Кала кунагын» санламыймы, өнәмиме, аңа юри күренәсе килмиме? Юк, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, бу мине соң дәрәҗәдә кимсетү булыр иде. Ышанмыйм, юк, ышана алмыйм. Әмма нәкъ менә шушы минутта мин кинәт бик ачык итеп, эчке бер калтырану белән эшнең серен аңлап алгандай булдым: Сәлимә кодача миннән ояла! Миннән, ундүрт яшьлек малайдан, оялып кача! Я тәнре, ул минем хәлемне аңлаган, ул минем артык сизгер, артык тиз җәрәхәтләнүчән йөрәгемне аяган!..
Әмма соң ул, кодача, минем күз алдымнан качса да, хыялымнан кача аламыни?!. Менә ул нәкъ каршымда, чыбылдык эчендә генә утыра. Мин хәтта аның чыбылдыкны аз гына төртеп торган тез башларын да шәйлим шикелле... Тез башларын гына түгел, бөтен кыяфәтен — сөрмәле күзләрен дә, хуш исле чәчләрен дә, уйчанлана төшкән, әмма бәхетле көлемсерәгән йөзен дә, ничектер үсебрәк киткән нечкә-сылу гәүдәсен дә ап-ачык күреп торам кебек... Юк, ул минем хыялымнан барыбер качып котыла алмый, котылу мөмкин түгел!
Ишек алдында кыңгырау тавышлары ишетелде, кодаларны тагын берәрсенә мәҗлескә алып китә торганнардыр. Тышта хәрәкәт көчәйде, кешеләрнең йөргән, сөйләшкән тавышлары ишетелә башлады. Кияү егетләре дә, сыйлаучы хатынга рәхмәтләр әйтеп, кияүгә, дусларча шаярту белән, кәләше янында күңелле вакыт үткәрүен теләп, урынnарыннан кузгалдылар. Алар да хәзер кодалар белән бергә мәҗлескә китәргә тиешләр.
Келәттән чыккач, егетләрнең берсе, үз иткәндәй, минем җилкәмә кулын салып, сорады:
— Я, Әхтәм, безнең белән йөрисеңме?
Бу дуслык ишарәсе миңа бик ошады, ләкин шулай да:
— Белмим шул,— дидем мин, икеләнебрәк.— Алай ярыймы соң?
— Һи, ник ярамасын,— диде егет, бер дә исе китмичә.— Син дә кунак бит, бергә-бергә йөрү күңеллерәк булыр.
Белмим, бәлки, бу кагыйдәгә сыеп та бетмәгәндер (мин бит кыз ягыннан туйга катнашучы), ләкин Нигъмәтулла абзыкай да, җиңгәчәй

дә мина ярамый дип әйтмәделәр. Шулай итеп мин кияү егетләре белән бергә, аларның пар атларына утырып, мәҗлесләргә йөри башладым. Атлар шәп, егетләр шәп, билләреннән алышып, аягүрә генә баралар, юлда берәр җәяүле күренсә, «һайт!» дип бер кычкырып кына салалар. Мине алар, бу шәкерт очып төшә күрмәсен дигәндәй, урталарына алып кына йөртәләр иде.

Мин инде ничә җирдә мәҗлестә булуыбызны сөйләп тормыйм, бик озынга китәчәк. Әмма берсен, гомерлеккә күңелдә уелып калганын тулырак итеп сөйләмичә булдыра алмыйм.

Туйның өченче көнендә иң соңгы мәҗлес тагын кыз өендә булды. Шушы мәҗлес белән кыз ягында туй тәгәлләнә, кодалар да, кияү белән кыз да, кызны озата баручы җиңгәләр дә моннан китәләр, туй кияү ягына күчә... Соңгы озату мәҗлесе булганга күрә, бирегә кызның бөтен агай-энесе һәм тирә-як күрше-күлән дә җыелган иде. Өйгә генә сыйдырып бетерерлек булмагач, үз-тирә гадирәк кунаклар өчен бакчага да бер табын әзерләнгән иде.

Өйдәге түр табынга, билгеле, кодаларны, кияү егетләрен, кызның өлкән туганнарын һәм кайбер мөхтәрәм кунакларны утырттылар. Шул «мөхтәрәмнәр» арасына, гонаһ шомлыгына каршы, мин дә эләктем. Бакчада гына торып калмакчы булган идем дә, Хөбәйбулла кода үзе чыгып мине чакырып кертте, янәсе, минем урыным монда түгел, тегендә... һай, эләкмәгән генә булсам иде!.. Башта ук бу мәҗлес минем өчен зур газапка әверелде. Бөтенләй хур була, оятка кала яздым. Кыска гына арада ниләр уйлап, ниләр кичерергә туры килмәде миңа...

Эш менә нәрсәдән башланды. Табынга кунаклар утырышып беткәч тә, ике кеше зур тәпән белән койган бал күтәреп керттеләр. Тәпәнне сәкедән читкәрәк, бер урындык өстенә куйдылар. Нигъмәтулла абзыкай, һәрвакытта беренче табынчы, кәләпүшен егетләрчә кырын салып тәпән янына басты. Аңа кечерәк өлеш тәлинкәсенә куеп, бер стакан бирделәр. Нигъмәтулла абзыкай тәпәннең өстен ачты, чүмеч белән бер шебердәтеп коеп карады, аннары кунакларга карап әйтте:

— Хөрмәтле кодалар, туебызның иң зур сые — кыз балы табынга килде. Сезнең рөхсәт белән шуны рәхим итеп башлыйк.

Шулай диде дә балны, чүмеч белән стаканга салып, иң элек кияүнең атасы төп кодага сузды. Төп кода: «Рәхмәт, котлы булсын килене-безнең балы» дип, иләп кенә стаканны алды да бетергәнче эчеп куйды һәм тәлинкәсенә өч сумлык акча салып, стаканны кире кайтарды. Анардан соң табынчы стаканны тутырып башкодага сузды. Башкода да, рәхмәт әйтеп, балны бетергәнче эчте дә, күпмедер акча салып, стаканны тәлинкәсе белән кире бирде. Шуннан соң инде Нигъмәтулла абзыкай стаканны рәттән йөртә башлады. Табынның түр очында утырган беренче кунакка, аннан икенчесенә, өченчесенә — шулай күчә-күчә китте кыз балы. Һәм эчкән бер кунак тәлинкәгә акча салып кире кайтара торды... Менә шушы хәлне күргәч, мин тәмам коелдым да төштем. Стакан миңа да килеп җитәчәк бит, мин дә акча салып кайтарырга тиешмендер инде. Йоласы шулай икән аның, ә йоладан котылу юк. Нишләргә? Минем кесәмдә бер генә тиен дә акчам юк ла'баса! (Мин бит туйга эләгәсемне белеп өйдән чыкмадым.) Менә кайда ул хурлык. Әгәр минем кем булуымны, кайдан килүемне белмәсәләр иде,— беләләр шул, барысы да бик яхшы беләләр. Белү генә түгел, «кала кунагы» кыз балына күпме төшерер икән дип көтеп утыра торганнардыр әле... Мин хәтта уттай яна башладым. Уйларым, читлеккә эләккән кош кебек, бәргәләнергә тотынды: нишләргә, нишләргә? Әллә мыштым гына чыгып сызаргамы!.. Юк, мөмкин түгел, бар да күрәчәкләр, беләчәкләр, эчләреннән генә көләчәкләр. Ә стакан якынлаша, отыры якынлаша...

Миңа җитәргә ике-өч кенә кеше калды. Булмый, булмый күрәсен

инде бу хурлыктан котылып... Соңгы өмет белән Нигъмәтулла абзыкайга карыйм, аңа ничек тә миңа бирмә дип ымлыйсым килә, ләкин ул минем якка сыңар күзен дә төшерми, ичмасам! Балны бутап-бутап стаканга сала, мактап-мактап кодаларга суза, әйтерсең, изге бер эш башкара. Шулай да ахыр чиктә генә миңа бер күз ташлап алды шикелле, ләкин мин аның карашын тотарга да, аңлашырга да өлгермәдем, билгеле.

Ниһаять, минем чират та килеп житте. Нигъмәтулла абзыкай, бөтен табын ишетсен дигәндәй, кычкыра биреп, бал тулы стаканны миңа сузды:

— Я, шәкерт, иплән кенә тот әле кодача тәтәңнен ширбәтен!

Стаканны ничек кулга алуымны, иреннәремә ничек китерүемне белмим, барысы да йокыдагы кебек эшләнде шикелле, тик бер нәрсәне бөтен тирем белән сизеп торам — кунакларның күзе миндә генә... Маңгаема салкын тир бәреп чыкты, ә үземә бик эссе кебек... Купмедер эчкәч, берни күрмичә, калтыранган стаканны кире сузуым булды, нәкъ шул мизгелдә Нигъмәтулла абзыкайның бик ачык итеп әйткән сүзләре ишетелде:

— Шәкерт акчасын миңа биреп куйган иде,— диде ул, тыныч кына, һәм түш кесәсеннән бер сумлык кәгазьне чыгарып, кунакларга күрсәтә биреп, тәлинкәгә дә салды.

Бу шулкадәр вакытлы һәм табигый килеп чыкты ки, кодалар төрле яктан:

— Һай афарин!

— Муладчина! — дип куйдылар.

Ә миңа... миңа ни, яшем тәгәрәп төшмәсен өчен бары иренемне тешләп, башымны гына түбән иргә калды. Юк, оялудан түгел бу, жиңеләеп китүдән, сөенечтән, рәхмәттән генә... Нигъмәтулла абзыкайга рәхмәттән. Мин дә адәм баласы, сизгерлеккә бик мохтаж адәм баласы!

Ә мәжлес кызганнан-кыза бара. Кыз балын акча салып авыз итү бетте, хәзер инде табында берничә стакан йөри. Нигъмәтулла абзыкай тирләгән-кызарган, чиккән зур яулыгы белән һаман сөртенеп тора, үзе бертуктаусыз сөйләнә, көлә, кайчак нечкә сары мыегының очын хәйләкәр генә бөтереп тә куя. Анардан жыр көтәләр,— ул моны белә, тик жаен гына көтә... Һәм менә турая биреп, тамак кыргалап алды да, пинжәк чабуын кайтара төшеп, әз генә калтыравык нечкә тавышы белән сузып жырлап та жибәрде:

> Утырдым ла көймәнең ай түренә,
> Карадым ла суларның төбенә.
> Су төпкәйләренда һич кара юк,
> Хак язганны күрми чара юк.

Мәжлес шундук тынып калды. Жыр һәркемнең йөрәген учлап алды. Кеше, мәрткә киткәндәй, сагышка, хыялга чумды. Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте, кемнеңдер күптән онытылган ярасы ачылды, әмма барысын да ниндидер бер искиткеч ләззәт-шашыну биләп алды.

Жыр бетүгә табын, аз гына өнсез торганнан соң, дәррәү хәрәкәткә килде. Әллә шатлыктан, әллә исәрләнүдән тыела алмыйча яман шауларга, көләргә тотындылар, кемдер сүз таба алмыйча: «Эх-х, Нигъмәтулла-а!» дип өзгәләнеп кычкырып куйды... Кемдер шунда ук яңадан жыр башлады — уздырырга теләп, тагы да ныграк исертергә теләп, дәртләнеп, кабынып жырлый башлады. Кайсылары жырга кушылды, кайсылары үз стаканын хөрмәт иткән кунагына сузып: «Кодакаем!», «Абзыкаем!» дия-дия, аны үтереп кыстарга тотынды. Кемдер миңа да стаканын төртте, атамны мактарга, анамны мактарга тотынды... Балдан, жырдан, шау-шудан минем башым әйләнде, һавага чыгасым килде, һәм, ыгы-зыгыдан файдаланып, урынымнан мыштым гына кузгалдым

Чыксам, ишек алдында да кунаклар, тыз-быз йөргән хатын-кызлар. Ак келәтнең дә ишеге ачык. Ул тирәдә дә ниндидер хәрәкәт сизелә... Мин тукталып тормыйча абзарларга таба уздым да арт капкадан гына болынга чыгып киттем. Яраттым мин бу Түреш буен. Тынлыгына, иркенлегенә, чәчәкләренә, бөҗәкләренә иядәшеп өлгердем. Монда ялгыз йөрү рәхәт, барысы да — якты-йомшак тынлык та, иркә-оялчан чәчәкләр дә сине әкрен генә, сөеп кенә юата кебек, уйларың-хәсрәтләрең үзлегеннән тына-басыла, ә ялгызлыгың үзе бер рәхәт, тансык юанычка әйләнә... Әйләнә дигәннән, минем башым чынлап та әйләнә шикелле... Әллә башым түгел, күз алдымда дөнья әзрәк әйләнәме?.. Алай дисәң, әнә-ә тегендә, кечкенә елгачык буендагы карт тирәкләр тик кенә, тын гына утыралар төсле. Алардан да ары, тау итәгендәге кечкенә авыл да үз урынында бик нык утыра кебек... Ләкин шулай да, күз алдында бер нәрсә селкенмәсә дә, бу чиксез дөнья үзенең кырлары-болыннары, таулары-сулары, авыллары-шәһәрләре белән я уңга, я сулга әкрен генә чайкаладыр төсле. Тик кенә тору мөмкин түгелдер инде ул. Һәм күңелгә гаҗәеп сәер бер уй килде: әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, дөнья болай чак-чак кына түгел, ә кинәт бик нык я уңга, я сулга чайкалып китсә, ни булыр иде икән? Җирдәге бөтен нәрсәнең асты өскә килер иде бугай... Алла сакласын! Юк, мин моны теләп, юрап әйтмим, тик уйнап кына, малай башым белән хыялланып кына әйтәм. Ә бәлки нидер сизенеп тәдер...

Бу туй арасында вакыт дигән нәрсә бөтенләй онытылып, буталып бетте. Бүген нинди көн, кайсы число — һич хәтерли алмыйм. Июль башы — шуны гына беләм. Кояшның зураеп, бик әкрен генә бата торган чагы. Әнә ул җир өстенә сузылып яткандай иренеп кенә сырт читенә төшеп бара...

...Шактый киткәнмен икән, кире борылдым. Ниндидер кызыкны күрми калырмын төсле, ашыгыбрак атларга тотындым. Шул ук арт капкадан гына ишек алдына кайтып кердем. Өй тирәсе гү-гү итеп тора, ишек алдында да, урамда да җигүле атлар тора, ә ак келәтнең ачык ишегеннән егетләр һәм кызларның җырлаганы ишетелә. Ахрысы нәрсәгәдер әзерләнәләр, нәрсәдер булырга тиеш.

Лапас яныннан узганда, күземә ике кеше чагылды. Бәлки игътибар итмичә узып та киткән булыр идем, ләкин караңгылана төшкән лапас эчендә берәүнең багана төбенә сәер генә чүгәләп утыруы мине туктата калды. Кем ул, нишләп утыра?.. Мышык-мышык борын тарткан тавыш та ишетелеп куя. Әллә елый инде шунда?.. Якынрак атлап, чынлабрак карасам, багана төбенә чүгәләп, башын учлап утырганы Хөбәйбулла кода булып чыкты, ә аның янында тик кенә басып торган кара кәзәкиле, озын кеше кемдер — аныксын танымадым. Хөбәйбулла коданың иңбашлары селкенеп-селкенеп куя, мыгыр-мыгыр нидер сөйләнә, үгезнекедәй калын тавышы сынып-сынып китә:

— Ух, Шәмсетдин абзый-й, белмисең, ...китә, йөрәк парәм китә! Тагын бер күгәрченебезне оч-очырабыз-з... Бишенчесен озатам бит, Шәмсетдин абзый, бишенчесен... Ят кулларга китеп бетәләр шулай, ох-ый!..

Дәү, таза кешенең әллә кайдан гына сыгылып чыккан саран күз яшьләре!.. Мин ник күргәнемә үкенгәндәй, йөгерә-атлый китеп бардым. Каршыма җиңгәчәй очрады. Туктатып сорадым:

— Җиңгәчәй, нәрсә бар монда?

— Тиздән туй китә,— диде җиңгәчәй.

— Сез дә китәсезме?

— Без дә җиңгәләр озата барабыз... Син инде монда калырсың, акыллым, яме! — дип өстәде җиңгәчәй, йомшак кына.

— Ярый,— дидем мин, тиз генә килешеп. Кияү ягы өчен мин ерак кеше — мин моны аңлый идем. Тик туй киткәннән соң бушап, боегып

калган йортта ялгыз каңгырап йөрүнен миңа никадәр авыр буласын гына уйлый белмәгәнмен.

Җингәчәй ашыгып келәткә таба китеп барды, ә мин, рәшәткә буенарак узып, тынычрак урыннан ишек алдында барган тамашага карап тора башладым.

Бу вакытта кияү егетләре келәттә җырлый-җырлый чаршау чыбылдыкны чишәләр, ә озата баручы җиңгәләр кызның урын-җирен җыялар иде. Кияү йортына баргач, шул ук кияү егетләре чаршау-чыбылдыкны яңадан корып, җиңгәләр кыз урынын җәеп куячаклар икән, йоласы шундый, имеш.

Менә келәт ишеге төбенә кабык арба җиккән ат килеп туктады. Шул арбага кыз артыннан барасы әйберләрне чыгарып сала башладылар. Ике егет өр-яңа яшел сандыкны ике башыннан күтәреп чыгардылар. Алар артыннан кызлар зур-зур төеннәрне чыгарып салдылар. Төеннәр өстенә зур гына җиз тазны каплап куйдылар. Җиз комган белән ак самоварны да төеннәр арасына ипләп кенә утырттылар... Барысын да шулай чыгарып, өеп бетергәч, йөкне озын бау белән аркылыга-буйга ныгытып бәйләделәр. Шуннан соң бу арбада барасы егет атын бер читкәрәк тарттырып куйды.

Биредә бөтен эштә билгеле бер тәртип булса кирәк. Мин, әйберләр чыгып беткәч, алар артыннан ук кияү белән кыз да чыгарлар дип көткән идем, ләкин алай булмады. Хәзер өй баскычы төбенә кыңгыраулы пар атларны берәмләп китерә башладылар. Халык та шунда җыелды. Беренче атка шактый мәлҗегән баш коданы ике ягыннан култыклап чыгардылар да, зурлап, юатып, тарантаска ипләп кенә утырттылар. Чирек күтәреп чыккан берәү шунда ук аңа, стаканга салып, бал сузды... Башкоданың аты кузгалгач та аның урынына икенче пар ат килеп туктады. Монысына төп кода белән кодагый менеп утырдылар. Төп кодага да бал салып бирделәр. Шулай итеп баскыч төбенә атлар бер-бер артлы килә тордылар, калган кодалар да утырышып, ишек алдыннан урамга чыга тордылар. Кодалардан соң кызны җиңгәли озата баручылар атларына утырдылар. Туй килгәндә алты ат булса, хәзер урамда унике җигүле ат тезелешеп торалар иде.

Бары менә шуннан соң гына келәт алдына кияүнен кара һәм тимеркүк җиккән пар атын китерделәр. Шунда ук келәт алдын ястыкчы кызлар һәм егетләр сарып алдылар. Мин дә күрми калмыйм дип, рәшәткә буенда яткан ташка бастым. Менә бер заман Хөбәйбулла кода сеңелесен (бишенче күгәрченен) таза беләкләрендә келәттән күтәреп чыгарды да тарантаска, күпертеп салган мендәрләр өстенә ипләп кенә утыртты. Кызның өстендә ак чүченчәдән җәйге жилән, башында ак ефәк шәл иде. Шул шәле белән ул, күзләрен генә калдырып, битен каплаган,— мин ни теләп тә аның йөзен тагын күрә алмадым... Кыз янына кара жиләннән, кырпу бүректә кияү үз эре генә менеп утырды. Кияү егетләренен берсе дилбегә тотып, икенчесе, гармунын тезенә куеп, кияү белән кызга каршы кучерга урнашты, ә өченчесе тарантас артына басты. Егет, кулларын сузып, дилбегәсен какты, атлар кузгалдылар, озатучы кызлар, егетләр, бала-чагалар, тарантаска орына-сугыла, шау-гөр килеп, барысы да капкага юнәлделәр. Мин дә, агымга эләккән йомычка шикелле, кысыла-кысыла халыкка иярдем.

Кияү атлары урамга чыккач, туй кузгалды. Иң алдан башкоданың пар аты, аның артыннан төп коданыкы, аннары кияү атлары, алар артыннан калганнары тезелешеп киттеләр. Иң арттан гына кыз әйберләрен төягән ялгыз ат, төеннәр өстенә каплап салган җиз тазы белән ялтырап, чаба-чаба китеп барды. Дәррәү кузгалып киткән атларның кыңгырау тавышлары кечкенә авылны тәмам күмеп, бөтен Түреш буйларын яңгыратып җибәрде. Әйе, бу искиткеч бер тамаша иде. Капка төбендә өелешеп калган егетләр һәм кызлар ераклаша барган кыңгырау

тавышларын сихерләнеп, онытылып, шылт та итмичә тыңлап тордылар. Туй китте. Туй белән бергә кемнендер яшьлеге китте... Тагын кемнәргә насыйп булыр икән бу кыңгырау тавышлары?!

* * *

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Ул шул Абзан туена, Нигъмәтулла абзыкайның сары ат башында, кара дугага тагылып барган кыңгырау икән, аны миңа күп еллардан соң Мәдинә җиңгәчәй биргән иде. Ул туйга катнашкан кешеләрнең бик күбесе — кода бабайлар, Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай — күптән бу дөньяда юк инде. Җиңгәчәй исән әле, сиксәнгә якынлашып бара, зур калада профессор киявендә тора. Аннары тагын Сәлимә кодача белән аның кияве дә исән-саулар икән — мин моны былтыр гына ишетеп белдем... Еш кына алар турында ничек яшәделәр икән, бәхетле булдылармы икән, дөньяда бармы икән үзләре дип уйлана торган идем. Гаҗәеп бер нәрсә, күпме еллар минем хыялымда алар, нәкъ әнә шул туйда күргәнемчә, яшь, чибәр кыз белән яшь, таза егет булып сакландылар. Ә бит кырык елдан артык вакыт узып китте — әйтергә генә ансат!.. Баксаң, алар үз авылларында тигез генә гомер итеп, уллар-кызлар үстереп, әби белән бабай да булганнар икән инде... Куандым да мин моңа, әллә нигә моңайдым да... Озын кара толымлы сылу кодача тик хыялда гына торып калды.

Әйе, дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә җиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә бер үзгәрми. Чак кына кагылдың исә, нәкъ теге вакыттагы шикелле, көмештәй саф, нечкә, дәртле тавышы белән бөтенне яңгыратып җибәрә. Һәм күз ачып йомганчы мине ундүрт яшьлек чагыма — үземә урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлегемә кайтара да куя. Барысын-барысын да үтә бер ачыклык белән терелтә ул минем хыялымда... Яңгырап җибәрүенә Нигъмәтулла абзыкайның җырын ишеткәндәй булам: утырдым ла көймәнең ай түренә... Юк, кирәкми, искә төшермик. Иясенә калсын ул...

Хәзер инде бик күп яңа җырлар туды. Яңа гадәтләр, яңа йолалар туды. Туйларга да хәзер кыңгыраулы пар атларда түгел, ә күбрәк «Волга», «Москвич»ларга гына утырып баралар. Егет белән кызны да өч көн буена ак келәттә ябып тотмыйлар, ә туйның түренә мендереп утырталар... Әмма мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калды: бу — кешенең яшьлеге, кешенең мәхәббәте!.. Һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа — аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана.

## Мөдәррис Әгъләмов

### Балам, бәгырем, диеп

Адашмаган кеше юл эзләми,
Юл табылмый әле тиз генә...
Ялгышларым белән җирдән китсәм,
Үз ялгышым калсын үземә.

Яман юлда йөр дип, начар бул дип
Үстермәгән мине әнкәем...
Байрак итеп йөртәм: «Халык юлы —
Иң изге юл»,— диеп әйткәнен...

Бу язмышым гел ялгыштан торса,
Әнкәм әрнеп искә төшерер...
«Балам, бәгырем», диеп каргар да ул,
«Балам, бәгырем», диеп кичерер.

1965

### Уфа юлы

*Җирседем дә, өмет баглап*
*Җирга иелеп салдым колак:*
*Кайсы яктан килә тавыш,*
*Аяк адымнары ерак...*

Уфа юлы, иске Уфа юлы...
Басып калган бары бер нарат,
Ике авыл уртасында калсаң,
Бураннарда шуңа йөр карап!

Колак салып авыл тыңлап калган,
Чабып үтсә почта атлары.
Туктамастан үтсә, җиңел сулап
Куйган картлар: «Алла саклады!»

Ак патшаның кара хатларын да
Китергән ул почта атлары...
Авыр яраларны ачкан сыман
Ачкан хатны илнең картлары.

Юкка гына җырламаган авыл:
«Заманалар бигрәк авыр ла».
Нәкъ боз сугып киткән иген сыман
Калган өйләр яңа набурда.

Тезелеп киткән, киткән бер-бер артлы
Ак билетлар, сары билетлар,
Патша мөһередәй кубарылган
Билетларда торган өметләр...

...Уфа юлы, иске Уфа юлы...
Нарат шаулый сыман шом салып,
Чабып үтсә атлар,
Каберләрдә
Картлар куяр сыман кымшанып.

...Ленин гасырында яши халык,
Узган еллар,
Калган бер нарат.
Халык йөрәгенә карагандай
Шул наратка карыйм мең кабат.

1968

## Каз канаты ак була

Авыл читендәге сары өйдә
Яшәде ул мишәр карчыгы...
Чишмә суы алып кайта иде
Коелганга кадәр таң чыгы.

Әкият булса, безгә — балаларга,
Аш онытыла... Туса яна көн,
Без жыела идек һаман шунда.
Ул эндәшә иде: канәтем...

«Канәт әби» диеп йөртә идек.
Уйлап карыйм хәзер мен кабат...
Егет булып житешкәнгә кадәр
Ул чыннан да булды бер канат.

Һәр баланың туган көнен белә,
Елаганын кайсы вакытта...
Бу кечкенә генә авыл өчен
Ул табип та иде, тарих та.

Чоланына керсәң чыгалмассың,
Бәйләм-бәйләм монда һәр үлән.
Үлән белән ул үлемнән саклар,
Сүзе белән — йөрәк әрнүдән.

Авылымда авыр хәбәр йөри —
Дөнья куйган мишәр карчыгы.
Әрни йөрәк, ник дәва юк аңа?
Күзләремдә яна таң чыгы.

Бер ягына Урал тавын салып
Үлчәнерлек кайгым бар минем...
Дөнья куып оныткангбыз, ахры,
Рәнжемәден микән әбием...

Рәнжемәдең микән? Каләм елый,
Өстәлемдә елый шигырем...
Канат-әби,
Җырлар белән ялгап
Булса иде кеше гомерен.

1967

## Ленин рәсеме

*Акылны еллар аркылы*
*Бик ачык күрә кеше...*
*Легендаларга кергәнче*
*Күңелгә керә кеше.*

Кешеләрдә хисләр чиксез ул,
Гомер үзе чикле булса да —
Яна җырга илтә һәр урам,
Уйландыра һәрбер бусага.

...Кердем ятим карчык өенә
Стеналар ап-ак, акшарлы...
Түрләмәләр, рамда догалар
Искә төшерә сабый чакларны.

Хаклык белән тәңгәл килмәсә,
Йолаларны халык белми дә;
Ленин рәсеме тора,
Төрелгән
Күгәрченнәр чиккән сөлгегә...

Халык белә күңел түренә
Нинди рәсемнәрне эләсен,
Олы җанга — олы иманга
Кануннар да көчсез, күрәсең.

1968

## Юлдашым

*Бу юл кемнеке?*
*Бу җир кемнеке?*
*Юлыннан атлыйм,*
*Җырын кабатлыйм.*

Толымнары суга чумган,
Чыланадыр тал чыбык.
Юлга чыксам иеләм суга
Тал чыбыктай талчыгып:
Елгаларым изге шул,
Әкияттәге көзге шул.

Кояш көйдергән көннәрдә
Күңел эзли күләгә,
Урманнары юлга чыга
Яндым инде дигәндә;
Урманнарым ак чатыр,
Оялмый кунак чакыр.

Ваем бар дип, кайгым бар дип,
Ярты юлда туктама!
Ваемыма дәва булып
Телләремә җыр тама:
Халык җыры — юл башым,
Халык җыры — юлдашым.

1967

## Кыңгыраулар эзлим

Белмәдем дә,
Сизенмәдем дә,
Нигә иртә төште сон кырау...
Урамда да, болыннарда да
Тынып калган соңгы кыңгырау.

Кыңгыраулар азмы чыңлаган
Туйларда, я сабантуйларда;
Урамнарда якты ут яна,
Утлар яна,
Йортлар өр-яңа...


Яуга чакырганда санатлар,
Урам инләп киткән солдатлар...
Кыңгыраулар тагып ураган
Шушы урамнарны пар атлар.

Кыңгыраулар эзлим мин һаман,
Шаулы Казаныма килеп тә...
Барып чыгам ерак базарга,
Кырык кереп чыгам кибеткә.

Кыңгыраулар эзлим мин һаман,
Далаларда атлар утлыйлар,
Уза туйлар, сандык төбендә
Кыңгыраулар гына йоклыйлар.

Кыңгыраулар эзлим мин һаман
Булса булсын юллар бик урау...
Кем күңелендә,
Кайсы киңлектә
Яңгырадың соңгы кыңгырау.

1967



## *ХЕЗМӘТЕ ЗУРНЫҢ— ХӨРМӘТЕ ЗУР*

*Нәкый Исәнбәткә 70 яшь*

**Сибгат Хәким**

# ИСӘНБӘТ—ШАГЫЙРЬ

Минем туган авылым Күлле-Кимедә, мин туып-үскән йортның күршесендә Ибраһим абый, әтинең энесе, атаклы балта остасы яши. Хәзер инде ул туксанга якынлаша. Мин аның Марида йорт эшләп йөргән таза чакларын беләм. Ара-тирә ул кәефләнеп тә кайткалый иде. Мондый вакытта ул почмакта торган гармонен ала, уйный һәм әкрен генә җырлый: «Ай урагың салып иңбашына...» Хатыны Гарифә апаның: «Карале, атасы, син әллә башка җырны бер дә белмисеңме», дип шелтәләгәнен дә хәтерлим. Гомере буе бер җыр... Бар бит шундый синнән беркайчан да аерылмый торган җырлар, үлми торган җырлар... Мин ул вакытта җырның авторын белми идем әле. Дөресен әйткәндә, авторларын искә төшерми торган җырлар миңа күбрәк ошый. Халыклашкан, халык байлыгына әйләнгән җырлар. Шагыйрьнең милли үзенчәлекле булуын күрсәтүче сыйфат — аның җырлары. «Уракчы кыз», «Бормалы су», «Гармонь», «Син сазыңны уйнадың» кебек җырларны халыктан аерып шагыйрьнеке дип әйтүе читен. Рухы, характеры, сүзләрнең сайланышы, агышы, янгырашлары белән алар халыкныкы...

Шул ук безнең тыкрыкта, Ибраһим абыйлар каршысында — Хәйрулла йорты. Авылда аны ялганчы Хәйрулла дип йөртәләр иде. Өе кечкенә, өендә җиде бала, җидесе дә кыз. Чабата ясыйлар... Хәйрулла абый, яшьлеге турында сүз чыкса, хатынны мин чыптага төреп алып кайттым ди торган иде. Бераз арттырырга, борчак сибәргә ярата. Күп тыңладым мин аны. Аннан түбәндәрәк Шәйхи карт. Монысы инде чын мәгънәсендә оста әкиятче. Бер әкиятен, бүлеп-бүлеп, өчәр көн сөйли. Аның да әкиятләрен ишетеп үстем. Күп иде алар безнең Казан артында тел осталары... Ишетеп үстем, ләкин үз вакытында язып алмавыма соңыннан бик нык үкендем. Бер вакыт шулай, менә безнең якта кемнәр бар иде дигән шикелле рәк, Исәнбәтне шаккатырырга уйладым. Әмма Исәнбәт бу кешеләрне миңа хәтле күптән белгән, әкиятләрен күптән язып алган булып чыкты. Ул аларны минем үземә яңадан сөйләп күрсәтте... Исәнбәттә күпме безнең як җырлары! Исәнбәт булмаган авыл, Исәнбәт кермәгән йорт юк. Җыр җыеп җибәрүче «корреспондентлар»ы аның һәр мәктәп саен иде... Шуңа күрә ахры Исәнбәт минем күңелдә халыкның бөтен рухи байлыгын үзендә туплаган шагыйрь булып басты. Җаны, рухы белән шагыйрь. Бер юл шигырь язмаса да, бу эшләреннән соң барыбер шагыйрь дип атарлар иде аны.

Исәнбәт үзенең шигырьләрен 1913 елларда яза башлый. Бу — татар халык шагыйре Габдулла Тукай иҗатының соңгы еллары. Тукайдан эстафетаны Нәкый Исән-

бәтләр, Әхмәт Фәйзиләр, Һади Такташлар алып китә. Эстафета чордан-чорга, Тукайның үзенә лаеклы кешеләр кулына күчә. Хәзер инде Тукайдан соң килгән буын турында ачык итеп әйтеп була: татар совет әдәбиятының нигезен шушы буын кешеләре салды, ул нигез нык!..

Исәнбәт үзе турында: «Зур шагыйрьләрдән Тукаев булса хәлфә, мин шәкерт», ди. Тукайның Исәнбәт иҗатына йогынтысы бик зур. Моны тою өчен шигырьләренең агышына колак салу да җитә. Шунысы кызык, Октябрь революциясе идеаллары белән рухланып, шагыйрьнең икенче настроение, икенче пафос белән язылган шигырьләренә дә Тукай үтеп керә, икенче социаль чорга күчеп, аның шигырьләрен үзенчә формалаштыра. Исәнбәт 1920 елларда иҗат иткән «Коммуна тимерлегендә» кебек шактый күтәренке, романтик, риторик шигырьдән бик тиз реалистик шигырьгә кайта. Гомумән, Тукай мәктәбе кешеләренең иҗатына реалистик ныклык, халыкчанлык хас. Шигырьне ясап кылану юк. Беренче чиратта гадилек, дөреслекне җырлау, хакыйкатьне сөйләү ярылып ята. Халыкның үз иҗатына, тарихына, рухына тоташкан тирәнлек... Исәнбәтнең шигырь томында беренче шигырь «Шүрәле». Соңгы поэмаларының берсе «Нужа бабай»... Ике арада кырык ел вакыт. Шагыйрь иҗатының беренче адымнары ук фольклордан башлана. Аның кайсы гына әсәрен укыма, шигырьнең һәр юлында фольклор рухы. Ул рух халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, традицияләре эченә алып керә. Сине үз җиренә, үз халкыңа якынайта, син кеше буларак кемлегеңне, үз урыныңны әйбәтрәк тоя башлыйсың. Менә кайда икән ул фольклорның нечкә, сихерле, тылсымлы көче.

Исәнбәтнең кинәт шигырьдән мәкальләргә юл салуының сәбәбен аңлау читен түгел. Мәкальләр — үзләре шигырь, иң тыгыз, иң кыска, иң яхшы шигырь. Исәнбәтнең бу фәкать бер шигъри формадан икенче шигъри формага күчүе генә. Кайсы өлкәдә генә эшләмәсен, ул — үрнәк, хезмәттә батырлык, фидакарьлек үрнәге. Язучы үз халкына шулай гына хезмәт итәргә тиеш.

Габдулла Шамуков,
РСФСРның атказанган артисты


# ИСӘНБӘТ ДРАМАТУРГИЯСЕ

Нәкый Исәнбәт — драма жанрында аеруча зур активлык күрсәткән һәм драматургиябез үсешенә аеруча зур өлеш керткән әдипләребезнең берсе. Үзенең берсеннән берсе гүзәл әсәрләре белән ул халкыбызның тирән мәхәббәтен казанды.

Революциянең беренче көннәреннән үк халыкка нык йогынты ясаган иң үтемле тәрбия чараларының берсе спектакльләр булды. Ул елларда клубларда уздырылган һәр политик чарадан соң, гадәттә, спектакль күрсәтелә иде. Шуңа күрә сәхнә әсәрләренә ихтыяҗ аеруча зур булды. Һәм заман таләпләре белән яшәгән Исәнбәтнең драма жанрына басым ясавы табигый иде.

1919 елда Исәнбәт үзенең «Сират» исемле трагедиясен бирә[1]. 1922 елда язган «Һиҗрәт» исемле комедиясен Башкортстанның Мәсгут кантонында һәвәскәрләрне җыеп беренче тапкыр автор үзе күрсәтә. 1924 елда яшь язучының бу әсәрен атаклы артист һәм режиссер Вәлиулла Мортазин Уфада башкорт театры сәхнәсендә куя. Спектакльне тамашачы яратып каршылый. Соңыннан «Һиҗрәт» комедиясе Казан

[1] Бу — Исәнбәтнең беренче драмасы түгел. Аның беренче сәхнә әсәре «Урнаш» 1912 елда, «Әмирхан хәзрәт» исемле икенче әсәре 1914 елда язылган.



Хөкүмәт орденнары белән бүләкләнгән бер төркем татар язучылары. 1957 ел.

сәхнәсендә дә зур уңыш казана. Шулай итеп, татар халкының Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин, Шәриф Камал шикелле өлкән драматурглары сафына яшь драматург Нәкый Исәнбәт килеп кушыла.

Шул кадәресен билгеләп үтәргә кирәк, бу елларда татар театр сәнгатенең, «Галиябану»дан башланып, драма белән музыканы берләштергән синкретик дәвере үтеп бара иде. Озакламый синкретик театрдан мөстәкыйль ике театр сәнгате — опера һәм драма театрлары үсеп чыга, «Сания», «Эшче» опералары языла. Драматургиябез тагын бер баскычка югары күтәрелә, драматурглар алдына жанр сафлыгы мәсьәләсе куела. Нәкый Исәнбәтнең театр сәнгате өлкәсендәге беренче адымнары әнә шул дәвергә туры килә. Бу аның сәхнә әсәрләренең характерына да мәгълүм бер эз сала.

Драматургның һәрбер әсәре дип әйтерлек билгеле бер жанр таләпләренә буйсына: я ул саф комедия, я саф драма, яки саф трагедия. Аның әсәрләре арасында соңгы елларда өстенлек алып киткән, тулысынча бер жанрга да керә алмый торган пьесалар юк дәрәҗәсендә. Нәкый Исәнбәт әсәрләренең тамашачы каршында зур уңыш казануына сәбәп булган факторларның берсе, бәлки, нәкъ әнә шул жанр сафлыгы белән аңлатыла торгандыр. Нәкый Исәнбәт драма жанрларының һәр төреннән күренекле үрнәкләр бирде. Ул үткен комедияләр, тирән дулкынландыргыч драмалар, җанны тетрәткеч трагедияләр тудырды. Профессиональ осталыкка ия булу ягыннан без аны татар халкының иң зур драматургларыннан дисәк тә ялгышмабыз.

Драматургның беренче әсәрләре заманның көн тәртибендә торган актуаль мәсьәләләргә багышланган. Ул революциянең беренче көннәреннән үк яңа тормыш төзү юлында каршылык күрсәткән, революцион барышка комачаулык китергән элементларны үткен сатира уты белән камчылый. Авторның кешелек дөньясы тудырган культура казанышларына кул селтәп, шәрә җирдә «әр-яңа» культура төзәргә хыялланган пролеткультчылардан көлгән «Культур Шәңгәрәй», базар корольләре — нэпманнарны көчле сатира уты белән көйдергән «Пикуләй Шәрәфи» комедияләре заманында Казан, Уфа, Мәскәү сәхнәләрендә зур уңыш белән бардылар.

Драматургның күп кенә әсәрләре дингә каршы көрәш мәсьәләләренә багышланган. Авторның бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузылган бу тема аның «Әмир-

хан хәзрәт яки указын ерткан» исемле беренче комедиясеннән үк башлана. Бу әсәр, кулдан кулга таралып, үзешчән драма түгәрәкләре репертуарында ныклы урын ала. Шигырь белән язылган «Сират» исемле трагедиядә яшь авторның дингә каршы ялкынлы протесты зур бер көч белән яңгырый. Анда исламның догматик кануннары кешене ниндн зур фаҗигагә китерүе турында сүз бара. Автор дингә каршы декларатив сүзләр сөйләми. Ул диннең реакцион асылын, геройлары кичергән фаҗигане күрсәтү аша фаш итә. Әсәрне укыганнан соң, егерме яшьлек авторның әдәби яктан шундый җанлы, тулы канлы образлар иҗат итүенә гаҗәпләнәсең.

Шул ук циклга кергән «Миркәй белән Айсылу» драмасы да образларының тәгаллеге, сюжетының җыйнаклыгы, вакыйгаларының драматик киеренкелеге белән аерылып тора.

...Вакыйга 1891 елда бара. Сыйнфый төркемнәргә һәм катлауларга бүлгаләнеп беткән татар авылы. Комсызланганнан комсызлана барып авылдашларын тереләй тунар чиккә җиткән авыл байгурасы; муеннан бурычка баткан, йорт-җирен закладка салып, кабалага кереп беткән мужиклар; бөтен мөлкәтеннән язып пролетарлашкан һәм шәһәргә эш эзләргә китүчеләр катламы; байгураларга халыкны таларга фәтва бирүче, бөлгән мужикларны фани дөнья газапларына түзәргә, явыз тәкъдиргә буйсынырга өндәүче диничеләр төркеме... Драматург әнә шулай аерымланып-катлауланып беткән татар авылының җанлы күренешләрен күз алдына бастыра.

Әсәрдә һәр социаль катламның типик сурәте, үз образы бар. Образларының тәгаллеге һәм тирәнлеге, оста итеп корылган сюжеты, вакыйгаларының киеренкелеге белән әсәр көчле тәэсир калдыра. Ислам дине белән агуланып, яраткан кызын шаштырыр дәрәҗәгә җиткергән Гофрай картның язмышы укучыны тетрәтә, аңарда шул фаҗигане тудырган авыл байгурасы Зәмир Дәүлиенә, дин козгыннары Хисби ишан, Хыялетдин хәзрәт, Мөфлихун суфи, Гыйният хәлфәләргә каршы нәфрәт хисе уята. Бу драма бүгенге совет яшьләре өчен аеруча әһәмиятле. Үткән тормышның шундый караңгы битләрен укыганнан соң, бүгенге тормышның яктылыгын, гүзәллеген тагын да тирәнрәк аңлыйсың.

«Миркәй белән Айсылу» драмасы күренекле режиссер Мәһдиев тарафыннан 1936 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган иде. 1967 елда яңадан куелып, ул бүген дә театрның репертуарында күренекле урын алып тора.

Фольклор материалларына нигезләнеп язылган «Хуҗа Насретдин» комедиясендә дә дингә каршы көрәш идеясе зур урын алып тора. Гаҗәеп бер осталык белән иҗат ителгән бу комедиянең 1939 елдан бирле сәхнәдән төшкәне юк. «Хуҗа Насретдин»ны уйнаучы артистлар картая, аларны яшьләр алмаштыра. Әмма комедия картаймый, һаман яшь килеш, тамашачыларга шатлык-дәрт биреп яшәвендә дәвам итә.

Нәкый Исәнбәт башлангыч әсәрләренең күпчелеген сатирик алым белән яза. Бу бик табигый. Чөнки ул үз алдына, заман таләбеннән чыгып, искелекне фаш итү бурычын куя. Аның геройлары шул чорның кире якларын гомумиләштереп эшләнгән өр-яңа сатирик образлар.

Нәкый Исәнбәтнең көчле сатира угы революциянең җиңүле адымына комачаулык итәргә тырышкан, тарих тәгәрмәчен кирегә әйләндерергә маташкан реакцион көчләргә, буржуаз милләтчеләргә каршы юнәлтелә. Контрреволюцион буржуаз милләтчеләрне фаш итү драматургның «Һиҗрәт» һәм «Болак арты республикасы» исемле комедияләрендә, шулай ук «Мулланур Вахитов» исемле драмасында ачык чагылды. «Болак арты республикасы» комедиясендә драматург контрреволюцион милләтчеләрне аеруча зур көч белән фаш итә. Казанда Совет власте яңа гына урнашып, ныгып килгән бер вакытта милли буржуазия, халыкның күзен томалау өчен «ислам», «милләт» әләмнәрен күтәреп, «Идел-Урал штаты» исемле дәүләт оештыра һәм ул «Болак арты республикасы» дигән исем астында яши. Драматург милли буржуазиянең, шулай ук милләтче зыялыларның халык интересларыннан ерак булып, тар карьеристлыктан уза алмауларын характерлы детальләр аша күрсәтеп үтә, авантюристлар «республикасының» җимерелеп юкка чыгуын тасвирлый.

Комедиянең сәхнәгә куелуы уңае белән язган рецензиясендә («Кызыл Татарстан» газетасы, 1940 ел, 22 февраль саны) шагыйрь Муса Җәлил, Исәнбәт теләнең үткерлегенә, типларының җанлылыгына тукталып, әсәрне драматургның уңышы дип бәяли.

Нәкый Исәнбәт халкыбызның атаклы кешеләре турында да күренекле әсәрләр

язды. «Мулланур Вахитов» драмасы шундый әсәрләрнең берсе. Анда әдип тарихи шәхесләрне күрсәтү һәм совет кешеләренең уңай образларын иҗат итү ягыннан тагын да алгарак китә. Ул биредә кире типларга каршы бөек идеяләр белән илһамланып, халык бәхете өчен җанын да аямыйча көрәшүче революция геройларын куя. Аларның рухи байлыкларына чын күңелдән сокланасың! Мулланур Вахитов үзенең уй-фикерләре, хисләре-омтылышлары, башкарган эшләре белән иң авыр хәлгә калганда да, ихтыярын җуймыйча, дошманның оешкан зур көченә каршы баһадирларча көрәшүе белән тамашачы күңелендә тирән мәхәббәт хисе уята. Дошман өеренә юлбарыстай ташланып, тигезсез көрәштә һәлак булган баһадир матрос Әҗем һәм чиксез зур тәвәккәллек белән эссе паровоз топкасына кереп бронепоездны хәрәкәткә китерүче эшче Тимербай образлары үзләренең типик булулары белән күңелне җәлеп итәләр. «Мулланур Вахитов» исемле бу героик драма тамашачы каршында зур уңыш казанды, ул рус театры сәхнәсендә дә барды.

Беренче татар артисткасы турындагы «Сәхипҗамал Волжская» исемле әсәре югары сыйфатлы драматургик әсәрләр булдыру максаты белән үткәрелгән ябык конкурста беренче урын алды. 1963 елда «Гөлҗамал» исеме белән Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелды.

Драматургның «Муса Җәлил» исемле оптимистик трагедиясе бу циклга керә торган әсәрләре арасында аерым урын алып тора. Автор сугышчы геройның рухи сыйфатларын, характерының авыр көрәш шартларында корычтай чыныга баруын эзлекле рәвештә ачып сала.

Татар әдәбиятында трагедия жанрының беренче үрнәге булган «Спартак» әсәре дә драматургиябез өлкәсендә күренекле урын алып тора. 1941 елда ул совет халкының фашист басып алучыларына каршы изге көрәшен тасвирлаган «Мәрьям» трагедиясен яза. Автор үзенең бу әсәрендә, совет кешеләренә хас югары сыйфатларны гомумиләштереп, ватан өчен батырларча көрәшүче совет халкының баһадир улларын һәм кызларын гәүдәләндерә. Без Мәрьям образында совет кешесенең дошманга ничаклы көчле нәфрәт хисе белән януын, аның күңелендә үз иленә, үз халкына ничаклы мәхәббәт яшәвен, шул мәхәббәт хакына, һич икеләнмичә, үлемгә баруын күрәбез. Бу әсәр күпләрнең игътибарын үзенә тартты. «Литература и искусство» газетасының 1943 елгы бер санында Нәкый Исәнбәтнең «Мәрьям» трагедиясе сәнгатьчә эшләнеше ягыннан үрнәк итеп күрсәтелә, драматургның шигъри алымы Шекспир алымы белән чагыштырыла.

Исәнбәтнең драматик әсәрләре үткен конфликтка корылган, һәрбер әсәрендә фикерләр, характерлар бәрелеше бар. Әнә шундый үткен конфликтка корылу аркасында, аның әсәрләре актерларга актив хәрәкәт итү өчен уңайлы материал була. Бай драматургик материал нигезендә актив хәрәкәт итүче характерларның бәрелеше аша кызыклы спектакль туа. Кыскасы, үткен конфликт, фикерләр, характерлар бәрелеше — драма әдәбиятының җаны. Драма аннсыз яши дә алмый. Моның шулай икәнлеген конфликтсызлык «теориясе» хөкем сөргән заманда барлыкка килгән бик күп драматик әсәрләрнең сәхнәгә менү белән, тамашачыны кызыксындыра алмыйча, бик тиз юкка чыгулары ачык күрсәтә.

* * *

Нәкый Исәнбәт үзен оста һәм иң талантлы драматургларның берсе итеп танытты. Аның һәрбер драма әсәре артистлар дөньясында зур куаныч тудыра. Драматург белән артистлар коллективы кушылып иҗат иткән спектакль тамашачыларга да шатлык китерә. Бер-бер артлы уйналган һәрбер спектакльдә зал тулы була. Караучылар тыныч кына утыра алмыйлар: алар, үзләренең шәхси тормышларын онытып, спектакльдә гәүдәләндерелгән тормыш белән, драматург кузгаткан фикерләр, хисләр белән яши башлыйлар. Мондый спектакльне караганнан соң, тамашачылар пәрдә төшеп залдан чыгу белән, сәхнәдә күргәннәрен онытып, теләсә нәрсә турында сөйләшергә керешмиләр. Киресенчә, сәхнәдә күрелгән мавыктыргыч вакыйгалар, үткен фикерләр, көчле хисләр аларны уйландыра, үзара фикер алыштыра, бәхәсләшергә мәҗбүр итә. Кыскасы, Нәкый Исәнбәтнең югары идея-художество көченә ия булган әсәр-

ләре тамашачыга зур йогынты ясый. Сәнгать әсәренең кыйммәте әнә шундый көчкә ия булуы белән билгеләнә дә.

Исәнбәт тарафыннан язылган характерларны үзләштереп, алардан сәхнә образы тудыруга ирешү җиңел эш түгел. Аның драматургик материалы актер алдында катлаулы бурычлар куя һәм актер шул бурычларны үтәп чыгу өчен барган көрәштә, кичерелгән иҗат газаплары аша үсә, күтәрелә. Аның драматургиясе бик күп артистларыбызга үзләренең сәхнә талантларын җәелдерергә бай материал булып хезмәт итә.

Татар сәхнәсендә кыска гына вакыт эчендә күтәрелеп, үзенең уены белән Казан тамашачыларын сокландырган Мифтах Әпсәләмов тудырган образлар, нигездә, Исәнбәт әсәрләре җирлегендә барлыкка килде. «Һиҗрәт» комедиясендәге Гайнетдин хәзрәт күренекле артистка талантының комедияле ягын бөтен тирәнлеге белән күрсәтерлек бай материал булып хезмәт итте. СССР халык артисты Хәлил Әбҗәлиловның да комедия таланты үзенең бөтен киңлеге белән «Хуҗа Насретдин» комедиясендә ачылды.

Нәкый Исәнбәтнең драматург буларак осталыгы нәрсәдә соң? Беренчедән, ул тормышта һәркемгә таныш булган иң характерлы нәрсәне эләктереп алып ачык итеп күз алдына китереп бастыра. Аның әсәрләрендә художество ягыннан формалашмаган идеяләр юк. Авторның әйтергә теләгән төп фикере әсәрдә күрсәтелгән вакыйгалардан, характерлар бәрелешеннән үсеп чыга. Икенчедән, Исәнбәт янадан-яна психологик үзенчәлекле, индивидуальләштерелгән күп кырлы характерлар тудыра белә. Ул иҗат иткән образлар исемнәрен алыштырып бер әсәрдән икенче әсәргә күчеп йөрмиләр. Һәрбер образ үзенчә сөйли, үзенчә хәрәкәт итә, һәм ул бер күргәннән соң онытыла торган төссез-тоныксыз булмыйча, хәтердә озак саклана торган образ булып яши бирә.

Фуад Ганиев,
филология фәннәре кандидаты

# ИСӘНБӘТ—ТЕЛ ГАЛИМЕ

Мәгълүм булганча, Нәкый ага Исәнбәтнең иҗади-фәнни эшчәнлеге гаять киң тармаклы. Башка күптөрле эшләр белән беррәттән, ул татар филологиясе өлкәсендә дә искиткеч киеренкелек белән эшләп килә. Татар халык мәкаль һәм әйтемнәрен җыю, аларны классификацияләү һәм аларга тиешле гыйльми аңлатмалар бирү кебек зур эш башкарып, Исәнбәт татар мәдәниятен бу өлкәдә дә фундаменталь хезмәтләр белән баетты. Шулай ук сүзлекләр төзү эше белән дә ул күп шөгыльләнде һәм хәзерге көндә татар теленең зур аңлатмалы сүзлеген төзи. Шуның белән бергә, аның эшчәнлегендә борынгы кулъязмаларны өйрәнү, әдәби текстларны тикшерү шактый зур урын алып тора.

Бу эшләрнең барысы да гомум тел белеменә, тюркология, татар теле белеме казанышларына таянып эш итүне, автордан билгеле бер лингвистик концепция булдыруны таләп итәләр. Шуңа күрә дә Н. Исәнбәтнең эшчәнлегендә филология, тел теориясенә караган эзләнүләр шактый урын билләп тора. Галим үзе язганча, аңа бу тикшеренүләрне алып бару, ягъни тел белеменә караган теоретик проблемаларны ачыклау практик мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәк була.

Аның мондый хезмәтләре Н. Исәнбәтнең зур әзерлекле лингвист булуы һәм тел белеменең югарыда әйтелгән өлкәләрен үстерү эшенә өлеш кертүе турында сөйлиләр.

Н. Исәнбәтнең татар теле грамматикасына караган хезмәтләрендә татар тел белеме өчен генә түгел, ә бөтен тюркология өчен дә шактый оригиналь булган кыю фикерләр бар. Н. Исәнбәт, әйтик, исемнәрнең бер сүз төркеме төшенчәсенә генә сыешып бетмәвен күрсәтеп үтә. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, күп кенә исемнәрнең сыйфат ролендә, сыйфат булып килүен ул телнең бер үзенчәлеге



Н. Исәнбәт башкорт әдибе С. Агиш белән.

итеп саный: «Исемнәр сыйфат урынында килгәндә, мондый бәйләнеш аңлатмада күрсәтелеп китә: тимер каләм (тимер — сыйфат функциясендә)» [1]. Үзенең морфологик мәгънәсе белән киң мәгънәле булган шундый тип исемнәрне тар мәгънәгә кайтарып калдырмау, һичшиксез, телнең үзенчәлегенә туры килгән оригиналь фикер булып тора.

Н. Исәнбәтнең л ы-л е, с ы з-с е з һ. б. төрдәге кушымчалар турындагы карашы да зур игътибарга лаек. Тюркологиядә бу кушымчаларның грамматик һәм семантик асылы һаман да анык билгеләнмәгән. Күпчелек галимнәр аларны сүз ясаучы кушымчалар рәтенә кертәләр. Мәсәлән, күренекле тюрколог профессор Н. А. Баскаков шул карашны яклый [2].

Әмма тел фактлары мондый төр кушымчаларның, сүз ясау сәләте белән беррәттән, күбрәк грамматик форма ясарга сәләтле икәнен күрсәтә. Әйтик, с е з кушымчасы я м ь с е з дигән вакытта яңа сүз, яңа лексик берәмлек ясый. Ә инде ө с т ә л с е з к а л д ы к тезмәсендә ө с т ә л с е з сүзендә ул кушымча бернинди дә яңа лексик-семантик мәгънә белдерми. Чөнки күрсәтелгән кушымча бер сүзне икенче сүзгә бәйләү өчен хезмәт итә. Сүзнең формасы исә яңа лексик мәгънәгә ия булган лексик берәмлек — исем дә, сыйфат та түгел. Бу күренешнең үзенең сәбәпләре һәм шартлары бар. Л ы-л е, с ы з-с е з кушымчаларының шундый нечкә үзенчәлеген, контекстка һәм сүзенә карап, яңа лексик берәмлек тә һәм грамматик форма да ясый алуын Н. Исәнбәт бик оста тотып алган һәм бу турыда 1949 елда ук инде язган иде [3].

Билгеле булганча, татар теле аналитик телләр төркеменә керә. Шуңа күрә, аның сүзләр байлыгында кушма сүзләр, кушма лексик берәмлекләр зур урын тота. Мәсәлән, кушма сүзләр фигыльләрнең иң зур күпчелеген тәшкил итәләр. Татар әдәби телендә актив кулланылган тамыр һәм ясалма фигыльләрнең саны 5 меңнән артык, ә кушма фигыльләрне кертеп исәпләгәндә, аларның саны 100 меңгә җитә яза. Башка төрки телләрдә дә шундый ук хәл. Ләкин ни өчендер төрки тел грамматикаларының күпчелегендә кушма фигыльләр исәпкә алынмый, һәм алар сүзлекләргә дә кертелми.

[1] Н. Исәнбәт. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге (проспект). Казан. 1949 ел. СССР ФА Казан филиалы архивы. 5 фонд. 19 язма.

[2] Н. А. Баскаков. Каракалпакский язык. Рус телендә. II нче кисәк. Мәскәү, 1952 ел. 188—194 битләр.

[3] Күрсәтелгән хезмәт, 16 бит.

Бу — тюркологиядә яшәп килгән иң зур гыйльми кимчелекләрнең берсе. Шундый структур типтагы кушма фигыльләр, мәсәлән, һинд, япон телләрендә дә бар. Һинд һәм япон теле белгечләре аларны аерым сүз, лексик берәмлек итеп карыйлар һәм сүзлекләрдә аларны аерым итеп бирәләр. Н. Исәнбәт тә нәкъ менә шулай эш итә. Күп кенә тюркологлардан аермалы буларак, кушма һәм тезмә фигыльләрне ул аерым сүз, лексик берәмлеккә кертә. «Кушма фигыльләр ике яки өч (бик сирәк очракта — Ф. Г.) сүздән кушылып яңа мәгънә барлыкка китерү ягыннан әһәмиятле урын тоталар. Аларда саннан сыйфатка әверелеш бар. Мәсәлән, ике фигыльдән ясалган *алып килү, эчеп җибәрү, белеп калу* кебекләр. Мондый кушма фигыльләр эчендәге сүзләр кушылмыйча аерым язылсалар да, мөстәкыйль берәр мәгънәгә ия булганлыктан, я бу сүзләр үз рәтләрендә урын алып аңлатылырга, я бер фигыль астында аерым сызык белән башланган юлларда бирелергә тиеш»[1], дип яза ул.

Н. Исәнбәтнең *әлифба төзү, дәреслекләр язу, орфография өлкәсендәге эшчәнлеге дә зур.* Совет властеның беренче елларында киң массаларны грамотага өйрәтү, культурага тарту иң актуаль һәм әһәмиятле эш була. Һәм шул вакытта яңа, рациональ методларга нигезләнгән әлифбалар, дәреслекләргә зур ихтыяҗ туа. Бу эштән татар укымышлыларының алдынгы вәкилләре читтә калмыйлар.

Шул чорда, укыту эшләре алып бару белән беррәттән, Н. Исәнбәт тә татар һәм башкорт мәктәпләре өчен әлифбалар, дәреслекләр төзи[2]. Н. Исәнбәтнең Һ. Сәгъди белән бергәләп язган башкорт әлифбасы ул вакыт өчен беренче дәреслекләрдән санала һәм башкорт теленең әлифбалары арасында күренекле урын алып тора.

Н. Исәнбәт татар теленең орфография мәсьәләләре белән күптән кызыксынып килә. Бу кызыксыну аның беренче төзегән әлифбаларыннан ук башлана. 1958 елда хәзерге татар теленең орфография проекты игълан ителгәч, галим «Хәреф һәм имлабызның гыйльми нигезләре хакында»[3] дигән зур мәкалә язып чыга. Монда ул татар теленең орфография тарихына кыскача туктала, татар теле орфографиясенең төп принципларын ачыклый һәм шул ук вакытта тарихи-традицион принципның да бөтенләй онытылырга тиеш түгеллеген әйтә. Аннан соң гамәлдәге орфографиянең төп кимчелекләрен билгели. Алынма сүзләрнең, кушымчаларның язылышын бердәйләштерергә һәм кагыйдәләштерергә тәкъдим итә. Автор орфография мәсьәләләрен хәл итү, дөрес язу кагыйдәләрен камилләштерү эшенең фәнни нигезгә корылган булырга тиешлегенә аеруча нык басым ясый.

*Мәкальләр — лингвистик тикшеренүләр өчен төп чыганакларның берсе.* Н. Исәнбәт татар мәкальләрен үз эченә алган 3 томлы зур капиталь хезмәт бастырып чыгарды[4]. Үзенең күләме һәм эчтәлеге ягыннан бу хезмәт *дөньякүләм танылган* шундый мәкаль сүзлекләре белән беррәттән тора. Китапта җыеп бирелгән мәкальләр татар рухи культурасының бай һәм күпкырлылыгын ачык күрсәтәләр. Бу гаҗәеп зур һәм фундаменталь хезмәт турында кайбер мәкаләләр басылып чыкты инде. Шулай да бу хезмәт лингвистик күзлектән чыгып тиешенчә бәяләнмәгән әле.

Җыентыкларда искиткеч күп тел байлыгы тупланган. Мәкальләрнең саны берничә дистә меңнән артып китә.

Бу хезмәттә татар теленең структурасын, системасын һәм синтаксик төзелешен өйрәнү-тикшерену өчен бик бай материал җыелган. Телнең табигый төзелеше беренче чиратта мәкальләрдә чагыла. Гасырлар буенча чарланып-эшкәртелеп килгән мәкальләрнең архитектоникасы татар тел төзелешенең иң нечкә үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә. Татар теле белгечләре сүз барган җыентыклардан телнең структурасына караган

---

[1] Күрсәтелгән хезмәт, 22 бит.

[2] Исәнбәт Н. һәм Сәгъди Һ. Яшь буын. Уку китабы. 64 бит. Мәскәү. Центриздат. 1926; Исәнбәт Н. һәм Сәгъди Һ. Яшь буын. Башкорт әлифбаһы. Мәскәү. Центриздат. 1926; Исәнбәт Н. һәм Сәгъди Һ. Яңа мәктәп. Татарча әлифба. Уфа. Башкнига 1927.

[3] «Совет Татарстаны» газетасы. 1958 ел. 14 октябрь саны.

[4] Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. Казан. I том — 1959; II том — 1963; III — 1967.

чын гәүһәрләрне бик күпләп табалар һәм табачаклар. Жыеп әйткәндә, хезмәттә тупланган мәкальләр татар теленең грамматикасын тикшерү өчен иң ышанычлы чыганакларның берсен тәшкил итә.

Шуның белән бергә, мондагы мәкальләрнең тарихи грамматиканы өйрәнү, лексикография һәм лексикология өчен дә кыйммәте бик зур. Жыентыкларда китерелгән мәкальләр диалектларны, бигрәк тә диалекталь лексиканы өйрәнү өчен үзенә бер төрле чыганак булып тора.

Галимнең лексикография өлкәсендәге эшчәнлеге турында берничә сүз. Билгеле булганча, төрле тип сүзлекләр арасында иң авыры аңлатмалы сүзлек төзү. Бу эш, югары фәнни-теоретик хәзерлек белән бергә, искиткеч күп материал туплауны сорый. Аңлатмалы сүзлек өчен сүзләр байлыгы һәм тиешле материал жыю бер кешедән дистәләрчә еллар буена дәвам иткән титаник хезмәт сорый. Н. Исәнбәт хәзерге көндә бу эшне башкарып чыккан.

Практик яктан уңайлылыкны күздә тотып, Н. Исәнбәт бу сүзлекне ныклы әлифба тәртибендә төзи. Сүзнең аңлатмасы исә иң әлек хәзерге мәгънәсен бирүдән алып, кире үткән заманга таба бару тәртибендә төзелә. Мәгънә аңлатмасы артыннан, аерым абзац белән, бу сүзгә бәйләнешле тәгъбирләр фразеология, канатлы сүзләр, идиомалар бирелә...

Н. Исәнбәт шулай ук 1950 нче елда басылып чыккан «Русча-татарча сүзлек»не төзүдә актив катнашкан авторларның берсе.

Галим әдәби әсәрләрнең **т е к с т ы н  ө й р ә н ү** буенча да шактый зур эшчәнлек күрсәтә. Бигрәк тә аның Г. Тукай әсәрләренең жыентыклары чыгу уңае белән язылган мәкаләләре игътибарга лаек[1]. Ул бу мәкаләләрдә Г. Тукай басмаларындагы житди кимчелекләрне ачып салып, аларны төзәтү юлларын күрсәтә. Галимнең текстология өлкәсендәге эшчәнлеген күз алдына китерү өчен, аның Г. Тукай басмасындагы кимчелекләргә анализ бирүенә күз салу да житә.

Басмадагы текстларны лингво-стилистик тикшерүдән үткәргәннән соң, Н. Исәнбәт анда күп төрле кимчелекләр таба, аларны классификацияли: шигырь калыбын һәм ритмын бозу, бер сүзне икенче сүз белән алыштыру, тыныш билгеләрен ялгыш кую, орфографик хаталар, морфологик хаталар, ялгыш аңлатмалар, хронологик хаталар һ. б.[2].

Басмадагы кимчелекләрне классификацияләп бирү үзе генә дә Н. Исәнбәтнең бик күп аналитик эш башкаруын сөйли. Н. Исәнбәт кимчелекләрне классификацияләп кенә калмый, бәлки ул кимчелекләрне конкрет фактлар китереп дәлилли. Әйтергә кирәк, галимнең дәлилләренең барсы да диярлек нигезле һәм ышандыргыч.

Мәсәлән, Г. Тукай басмасында «кәфаштатыюш» имзасы белән бирелгән материаллар бар. Н. Исәнбәт бу имза белән китерелгән мәкаләләрнең Г. Тукайныкы булуын шикле дип таба. Чөнки: 1) ул мәкаләләрнең тел-стилистик үзенчәлекләре Г. Тукайга туры килми; 2) бу мәкаләләрнең язылу вакыты Г. Тукайның үләр алдыннан Клячкин больницасында яту көннәренә туры килә, хәтта Тукай үлгәч тә бу имза белән «Ялт-Йолт» журналында мәкалә чыга[3]. Болар барсы да Н. Исәнбәтнең текстология өлкәсендә эшләвен, тексттагы бик нечкә үзенчәлекләрне тотып ала торган галим икәнен исбатлыйлар.

**Борынгы кульъязмаларны** (**манускриптларны**), **әдәби әсәрләрне өйрәнү буенча** Н. Исәнбәт шулай ук күптән шөгыльләнеп килә. Ул үзенең тынгысыз археографик эзләнүләре нәтиҗәсендә байтак борынгы кульъязмалар таба һәм алар хәзерге көндә аның шәхси китапханәсендә саклана. Әлбәттә, киң җәмәгатьчелек бу кульъязмалар турында галимнән тизрәк публикацияләр бирүне көтә.

Билгеле ки, Н. Исәнбәт Казан ханлыгы чоры шагыйре Мәхмүд углы Мөхәммәдъярның «Нуры сыдур» исемле поэмасын беренче булып таба. Моңа кадәр ул

---

[1] Н. Исәнбәт. Тукайның соңгы басмасы турында («Совет әдәбияты» журналы. 1945 ел. 5 сан); Н. Исәнбәт. Тукай прозасы («Совет әдәбияты» журналы. 1949 ел. 7 сан); Н. Исәнбәт. Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре («Казан утлары» журналы. 1969 ел. 4 сан).

[2] Н. Исәнбәт. Тукайның соңгы басмасы турында («Совет әдәбияты» журналы. 1945 ел. 5 сан. 60 нчы бит).

[3] Н. Исәнбәт. Тукай прозасы («Совет әдәбияты» журналы. 1949 ел. 7 сан).

әсәр фәнгә бөтенләй билгеле булмый. Дөрес, Мөхәммәдъярның исеме гыйльми тикшеренүләрдә очрый. Профессор И. Н. Березин шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» исемле поэмасын таба һәм үзенең тикшеренүләрендә аның авторы турында кыскача мәгълүмат бирә һәм ул әсәрдән өзекләр китерә. Әмма ни өчендер татар әдәбият тарихына Н. Исәнбәт публикациясенә кадәр Мөхәммәдъяр исеме кереп китә алмый.

Галим бу манускриптны табу уңае белән «Казан ханлыгы чоры әдәбиятыннан Мөхәммәдъяр Мәхмүд углы әсәрләре» дигән зур мәкалә яза [1].

Бу мәкаләдә Н. Исәнбәт поэманың авторын билгели, ул вакыттагы тарихи шартларга анализ бирә, әсәрнең төзелешен һәм телен ачыклый, мәкаләгә кушымта итеп өзекләр бирә. Әдәбият белемендә вульгар-социологизм чәчәк аткан чорда шагыйрь Мөхәммәдъярның «Нуры сыдур» әсәрен күтәреп чыгу һәм аны кыйммәтле әсәр дип билгеләү Н. Исәнбәттән үзенә күрә батырлык һәм кыюлык таләп итә. Моны билгеләп үтмичә булмый.

**Фатих Урманчеев,**
филология фәннәре кандидаты

# ЭНҖЕЛӘР БӨРТЕКЛӘП ҖЫЕЛА

Әдипләребез халык әдәбияты үрнәкләренә һәрвакыт тирән ихтирам белән карадылар. Каюм Насыйри мирасының зур өлеше ул үзе җыйган фольклор әсәрләреннән, алар турындагы фәнни тикшеренүләрдән тора. Габдулла Тукай халык җырларын: «Безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле һәм иң бәһале бер мирастыр...» — дип бәяләде. «...Бездә халык әдәбиятын җыю, тикшерү-тәртипләү эше тел-әдәбият мәсьәләләренең бик кирәкле бер тармагы буларак хәзерге көндәге гыйльми-әдәби эшләребезнең алдынгыларыннан итеп мәйданга куелырга тиешледер»,— дип исәпләде Галимҗан Ибраһимов.

Классик язучыларыбыз башлаган бу яхшы традиция бүген дә яши. Гомәр ага Бәширов, Афзал ага Шамов кебек язучылар, үзләренең төп эшләреннән тыш, халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм дөньяга чыгару белән дә шөгыльләнәләр.


Бөек әдипләребезнең күркәм традициясе зур галим һәм язучы Нәкый ага Исәнбәт эшчәнлегендә күп еллар буена һәм аеруча уңышлы дәвам итеп килә. Исәнбәт халык иҗатының бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булуын бик яхшы аңлый. Аның шигырьләрен, драма әсәрләрен бер генә мәртәбә күздән кичерсәк тә, без анда халык рухын, аның якты омтылышларын, чын йөрәктән чыккан тирән хисләрен тоябыз. Халык иҗатының асыл табигате әдип әсәрләрен искиткеч матур, тирән мәгънәле һәм бай эчтәлекле шигърият белән бизи. Әдип иҗатын фольклордан аерып карау мөмкин түгел.

Халык иҗаты әсәрләрен Исәнбәт бик иртә җыя башлый. Үзенең бу эшен ул хаклы рәвештә бөек Тукай традицияләренең дәвамы дип исәпли: «1911 елда Тукайның «Халык әдәбияты» дигән әсәре басылып чыкты һәм Тукай шәкерте буларак минем дә халык иҗаты әсәрләрен җыя башлавым шул еллардан башлана»,— дип яза ул. Ярты гасыр буена ул мөмкин булган барлык урыннарда халык иҗаты әсәрләрен кәгазьгә теркәп бара.

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1941 ел. 4 сан.

Әдипне татар халкының кайсы этник төркемнәре фольклоры күбрәк кызыксындыра соң? Бу сорауга өлешчә генә булса да җавап бирү өчен, халык иҗаты әсәрләрен җыю максаты белән ул узган юлларны күз алдына китерергә кирәк. Ул үзе күрсәткәнчә, 1911—13 елларда туган авылы Малаязда башланган бу эш 20—30 елларда Уфа белән Казанда һәм шул тирәдәге татар авылларында дәвам итә. Алга таба Исәнбәт йөргән җирләрнең географиясе елдан-ел киңәя бара. 1940 елда ул Себердә — Бараба, Тара, Ишемтамак, Тубол якларында булып кайта. Бу эшкә Исәнбәт укучы яшьләрне, укытучыларны һәм студентларны да тарта.



Н. Исәнбәт эш вакытында.

Әмма халыкның искиткеч бай шигъри хәзинәсен җыю өчен халык арасында йөрү генә җитми. Чөнки фольклор әсәрләренең барысы да бер үк вакытта халык телендә яшәми. Аларның зур гына өлеше һәм гадәттә җитди әһәмияткә ия булган борынгы әсәрләре онытылып, халык теленнән төшеп калган була. Татар халык иҗатының никадәр бай һәм катлаулы булуын күз алдына китерү өчен, Исәнбәт төрле характердагы язма чыганакларны җентекләп тикшерә, татар халкына, аның тарихына, мәдәниятенә нинди дә булса мөнәсәбәте булган чыганакларның бик күп өлешен өйрәнеп чыга.

Татар халык иҗаты төшенчәсен Исәнбәт киң мәгънәдә аңлый. Ул Урал, Казан, Себер татарларында, мишәрләрдә, элекгә керәшен дип аталган татарларда һ. б. этник төркемнәрдә таралган әсәрләрне язып бара. Халык иҗатын җыюның төрле юлларын берләштерү нәтиҗәсендә ул гаять бай, бер кеше гомерендә җыелуын күз алдына китерү кыен булган шигъри хәзинә туплый. Аның кул астында катлаулы фольклор фонды барлыкка килә, һәм ул яңа әсәрләр исәбенә байый тора. Халык арасында йөргәндә дә, күп төрле язма чыганакларны өйрәнгәндә дә Исәнбәт аларга фольклорчы күзлегеннән генә карамый, ә бәлки киң эрудицияле галим буларак якын килә. Әдипне халык тарихы, аның хәзерге тормышы, үткәне һәм киләчәге кызыксындыра. Шуңа күрә ул җыйган фольклор материаллары һәм алар турындагы фикерләр җитди фәнни әһәмияткә ия булып торалар.

Галим буларак, Исәнбәтнең төп игътибары татар халык иҗатының нинди мәсьәләләренә, нинди жанрларына юнәлтелгән соң? Бу сорауга бер генә сүз белән: «Һәммәсенә дә»,— дип җавап бирергә мөмкин. Беренче мәртәбә Исәнбәт имзасы белән басылып чыккан фольклор әсәрләре нәкъ әнә шуны раслый. Аларның гомуми саны шактый күп: халыкның борынгы ышанулары, йолалары, гореф-гадәтләре белән бәйләнгән әсәрләр, татар мифлары, дастаннар, бәетләр, җырлар, такмак-такмазалар, мәсәлләр, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр. Бу әсәрләрнең кайберсе газет-журналларда басылган булса, иң зур өлеше татар совет фольклористикасы тарихында әһәмиятле роль уйнаган җыентыклар рәвешендә дөнья күрде.

Халык иҗаты энҗеләрен бөртекләп җыю һәм аларның иң матур үрнәкләреннән торган җыентык чыгару бик күп, гадәттә озак елларга сузылган вакыт, тырышлык һәм махсус хәзерлек сорый. Фольклор әсәрләрен җыю әдип алдына җитди проблема-

лар китереп куя. Экият, дастан, җыр, мәкаль-әйтемнәрне фәнни принциплар нигезендә җыю өчен ул фольклор фәненең теоретик проблемаларын хәл итәргә, тирәнтен өйрәнергә, үз тәҗрибәсенә таянып үстерергә тиеш була. Исәнбәт тарафыннан чыгарылган шактый күп санлы җыентыкларны бер-бер артлы тезеп карый башласаң, галимнең үсеш юлын, тора-бара колачы киңәюен, фикерләре тирәнәюен, проблематикасы катлаулануын күз алдына китерергә мөмкин. Менә 1928 елда Казанда басылып чыккан «Әйдә җырлыйк (Революция чорындагы халык җырлары)». Бу — фәнни җыентык түгел, ә бәлки 20 еллар рухы белән сугарылган агитацион-публицистик характердагы китап, чор җимеше. Ул татар совет халык иҗаты һәм аны җыю-өйрәнү тарихының башлангыч чорын чагылдыра. Янсә менә шул ук елны Уфада дөнья күргән «Сүз табучы сукыр Фәррах әңгәмәләре». Биредә сүз халык арасында еш очрый торган тел осталарының хикмәт нияләренең берсе турында бара.

Болар — Исәнбәт тарафыннан төзелгән беренче фольклор җыентыклары. Аларга әдип туплаган әсәрләрнең кечкенә бер өлеше генә кергән. 30 елларның икенче яртысында исә Исәнбәт теоретик һәм практик яктан яхшы әзерләнгән галим булып формалаша. Аның тирән эчтәлекле теоретик тикшеренүләр, чын мәгънәсендә фәнни җыентыклар әзерләве һәм чыгара башлавы нәкъ әнә шул 30 елларның икенче яртысына, 40 елларның башына туры килә. 1941 елда Казанда Исәнбәтнең «Табышмаклар» җыентыгы басылып чыга. Татар халык иҗатының бу үзенчәлекле төрен өйрәнү һәм шактый күп үрнәкләрен бастырып чыгару ягыннан «Табышмаклар» безнең фольклористикада беренче һәм, кызганычка каршы, бүгенге көнгә кадәр принципиаль әһәмияткә ия булган бердәнбер фәнни хезмәт.

Кайчандыр халык йолалары белән бәйләнгән һәм магиячелек функциясенә ия булган табышмаклар безнең заманда балалар фольклорының бер төренә әверелү чорын кичерә. Халык иҗатының шул ук өлкәсенә караган һәм балачактан ук җыела башлаган фольклор әсәрләренең икенче бер өлешен Исәнбәт шул ук 1941 елда чыккан «Татар халкының балалар фольклоры» дигән китабына туплый. «Табышмаклар» кебек үк, «Балалар фольклоры» да — татар халык иҗатының моңа кадәр ныклап җыелмаган һәм рәтләп өйрәнелмәгән өлешенә багышланган җитди фәнни җыентык.

Татар совет фольклористикасы тарихында балалар фольклорының төп төрләрен эченә алган башка җыентык күренгәне юк дияр идек... тик 1967 елда «Нәниләр шатлана» китабы басылып чыкты. Аны да Исәнбәт әзерләгән. Гомумән, татар халык иҗатының бу үзенчәлекле төрен күп еллар буена нәтиҗәле рәвештә өйрәнеп килүче бердәнбер кешебез — Нәкый ага Исәнбәт.

Беренче җитди фәнни җыентыкларын әзерләгәннән соң Исәнбәтнең фольклористик эшчәнлеге тагы да киңрәк колач белән дәвам итә. Әледән-әле галимнең татар халык эпосы, фольклорның афористик жанрлары турында яңа хезмәтләре чыгып тора. Ә инде 1959, 1963, 1967 елларда басылып чыккан «Татар халык мәкальләре»н — әдипнең күп еллар буена дәвам итеп килгән фольклористик эшчәнлегенең бүгенге көндә иң югары ноктасы дип бәяләсәк, шаять ялгышмабыз. Искиткеч күп вакыт, тырышлык һәм түземлек таләп иткән бу эш турында ул үзе дә: «Минем тормышымда бу мәкальләрне төзү кадәр вакытымны алган вак һәм озак мәшәкатьле башка эш булмады»,— дип яза. Унынчы елларда башланып, соңгы елларга кадәр дәвам иткән эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак басылып чыккан һәм 40 меңгә якын әсәрне эченә алган «Татар халык мәкальләре»нә гомуми бәя бирү өчен татар фольклор фәне тарихын күздән кичерү җитә кебек. Әлегә кадәр татар халык иҗатының бер генә жанры да мондый бәхеткә ирешкәне юк иде. Үзенең тулылыгы, киңлеге, хезмәтнең беренче томына кергән фәнни тикшеренүе, авторның аерым әсәрләргә биргән ышандырырлык аңлатмалары белән бу җыентык — татар, киңрәк алганда, гомумән төрки халыклар фольклористикасында беренче хезмәт. Ул халык иҗатын өйрәнү фәненә күп яңалыклар кертә. Бу томнар нигезендә мәкальләрнең (өстәп әйтик, мәсәл һәм мәзәкләрнең дә!) тарихын, бик күп үзенчәлекләрен генә түгел (мәкальләр Исәнбәт тарафыннан төрле яклап өйрәнелгән инде!), ә бәлки татар халкының иҗтимагый, этик һәм эстетик карашларын, борынгы ышануларын, аерым гореф-гадәтләрен, милли йолаларын өйрәнергә мөмкин. Җыентык татар фольклорчылары алдына җитди яңа проблемалар китереп куя: халык иҗатын җыю, фәнни өйрәнү һәм бастырып чыгару принциплары;

аерым жанрларның тарихын, теориясен, милли үзенчәлекләрен өйрәнү; фольклор эстетикасы; төрки халыклар фольклоры арасындагы бәйләнешләр.

«Татар халык мәкальләре» турында Мәскәү һәм Казан матбугатында махсус мәкаләләр басылып чыкты. Язучылар, тарихчылар, телчеләр һәм фольклорчылар мәкаль томнарын тарихка керерлек фундаменталь хезмәт дип бәяләделәр. Хезмәт киң катлау укучылар, иҗади һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан зур канәгатьләнү белән каршыланды. 1968 елда ул бөек шагыйребез Габдулла Тукай исемендәге премиягә лаеклы дип табылды.

Мәкаль томнары татар фольклористикасы тарихында яңа этап — аерым жанрларның теориясен һәм тарихын җентекләп, һәрьяклап тикшерү һәм бер жанрга караган әсәрләрне мөмкин кадәр тулы итеп бастырып чыгару чоры башлануын күрсәткән хезмәтләрнең классик үрнәге.

Шулай итеп, татар халык иҗатының Исәнбәт тарафыннан күп еллар буена махсус җыелган һәм өйрәнелгән мәсьәләләре рәтенә татар халык эпосы, балалар фольклоры, табышмаклар һәм мәкальләр проблемаларын кертергә кирәк. Әмма Исәнбәт хезмәтләрендәге фәнни фикерләр, күзәтүләр, күтәрелгән яки өйрәнелгән мәсьәләләр бу проблемалар, халык иҗатының бу жанрлары белән генә чикләнми. Әйтик, бәетләр турында аның беркайчан да махсус тикшеренү язганы юк. Шулай да аның хезмәтләреннән һәм әсәрләреннән бәетләрнең Болгар чорында ук барлыкка килүе, XVIII—XIX һәм XX йөздә яшәү шартлары, аларның милли үзенчәлекләре, бүгенге язмышы турында гаять әһәмиятле фикерләр табарга мөмкин.

Исәнбәт хезмәтләре фольклор фәненең гомум теоретик мәсьәләләрен күтәрә, аерым жанрларны өйрәнүдә кулланылырга тиешле принципларны билгели. Шундыйларның берсен генә күрсәтеп үтик. Галим фикеренчә, аерым жанрларның тарихын халык тарихы белән тыгыз бәйләнештә тикшерергә кирәк. Һәм ул үзе шулай эшли дә. Табышмак һәм мәкальләрнең барлыкка килү чорын өйрәнгәндә, ул борынгы ыручылык җәмгыятенең тормыш шартларына, сәнгатьнең синкретик төре булган фольклор әсәрләрен иҗат итүдә коллективның һәм шәхеснең роле мәсьәләләренә шактый киң туктала. Халык иҗатының асыл табигате исә аның коллектив иҗат җимеше булуында. Исәнбәт фикеренчә, халык иҗатының авторы мәгълүм булмаса да, башта ул кем булса да берәү тарафыннан иҗат ителә. Шуннан соң бу иҗади эш гасырлар буена дәвам итә. Халыкның эстетик таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр халык телендә йөз еллар буе яши, вакыт үткән саен аны күп кешеләр тәҗрибәсе баета, матурайта. Халык телендә йөреп, искиткеч камилләшкән әкиятләр, җырлар, бәетләр безне бүген дә дулкынландыралар, онытылмас эстетик ләззәт бирәләр.

Хәер, ярты гасырдан артык дәвам итеп килгән фәнни эшчәнлекнең тарихи әһәмиятен кыска бу язмада гына ачыклап булмас. Киләчәктә «Исәнбәт һәм татар халык иҗаты» дигән гаять әһәмиятле һәм мавыктыргыч проблема буенча махсус хезмәтләр язылыр дип ышанырга кирәк. Бирелә исә йомгаклап шуны әйтик: татар халык иҗатын чын мәгънәсендә фәнни принциплар нигезендә җыючы һәм өйрәнүче Нәкый ага Исәнбәт фольклор фәненең катлаулы проблемаларын тирәнтен һәм төрле яклап өйрәнде. Үзенең нәтиҗәле хезмәтен ул әле бүген дә дәвам итә. Татар филологиясе тарихында аның фәнни эшчәнлеге гаять зур роль уйнады һәм киләчәктә дә уйнар. Чыннан да, Исәнбәтнең искиткеч бай һәм иҗади фикергә киң юл ача торган җыентыклары нигезендә язылган хезмәтләр бер-бер артлы басылып тора. Бу очракта Н. Юзиевның «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән» («Казан утлары» журналы, 1965 ел, 9 сан), профессор Х. Госманның «Халыкның үзеннән» («Казан утлары», 1967 ел, 11 сан) дигән теоретик мәкаләләрен күрсәтеп үтик. Алардагы тикшерү өчен алынган конкрет материал чыганаклары арасында Исәнбәт томнары төп урынны алып тора. Исәнбәт җыентыклары гаять бай чыганак булганга күрә, аларга нигезләнгән махсус тикшеренүләр әледән-әле языла торыр. Балалар фольклоры, табышмак һәм мәкаль томнары татар халкының тарихын, телен, этнографиясен, бигрәк тә халык иҗатын өйрәнүдә киләчәктә дә зур роль уйнар. Минә шуңа күрә Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә гаять зур уңышларга ирешкән татар филологиясенең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген Нәкый ага Исәнбәт исеменнән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

**Бакый Урманче,**
Тукай премиясе лауреаты

# ИСӘНБӘТНЕҢ УРЫНЫ

Безнең татар халкының мәдәни барышында Нәкый Исәнбәтнең үзенә хас юлы һәм, мәдәниятебезнең шанлы бер дәверенең вәкиле буларак, ихтирамга лаек зур урыны бар.

XX гасырның беренче чирегенә кадәр татар халкының мәдәни хәрәкәтендә күренекле хезмәте белән аерым игътибар казанган мәгърифәтче һәм матбугат сөючеләрнең барсы да диярлек мәдрәсә тәрбиясе белән аяк баскан азаматлар булуы билгеле. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Г. Кандалыйлардан башлап, Дәрдмәнд, Тукай, Ямашев, Галимҗан Ибраһимов кебек мәдәният өлкәсендә җуелмаслык — үчерелмәслек эз калдырган галим, җәмәгатьче һәм сәнгать сөючеләрнең исем-атларын саный башласак, шактый озын тезмә булыр иде.

Нәкый Исәнбәт тә — алдынгы татар мәдрәсәләренең дәресханәләрендә (аудитория) аякка баскан һәм гомер буе гыйлем һәм сәнгать өлкәләрендә ясаган күп хезмәтләрен мәдрәсәдә корылган фундамент өстенә нигезләгән абыз агаларыбызның берсе.

Мәдрәсәдә алынган белем белән Петербург, Казан университеты кебек дан тоткан югары гыйлемханәләрдә дәрес биргән Фәезхановлар, Мәхмүтовларны, хәтта Европа дәресханәләрендә дәрес биргән галимнәрне санап китәргә мөмкин булыр иде. Бу фактларга аерым тукталган вакытта һәрберсе аерым бер хезмәтне таләп итә.

Мәкаләнең башында мәдрәсәләрнең татар халкы тормышында тоткан урыны һәм бигрәк тә Нәкый Исәнбәтләр үскән вакытта мәдрәсәнең нинди хәлдә булуын объектив рәвештә аңлатып үтсәк, файдасыз булмас. Файдасыз булмас кына түгел, шунсыз безнең әйтәчәк сүзләребез аңлашылып та бетмәс кебек.

Бәс, рөхсәт итсәгез, мәдрәсәнең хәлен тарихи аспектта кыскача ачыклап китик. Мәдрәсә гарәпчәдән алынган «белемгә өйрәтә, дәрес бирә торган урын» дигән сүз. Мәдрәсә кемне хәзерли? Аның халык тормышында нинди кирәге булган? Анда нәрсәгә өйрәткәннәр?

Халык, милләт, мәмләкәт сүзләренең эчтәлегендә күп шәхесләрдән торган җәмгыять мәгънәсе дә бар. Бу шәхесләрнең үзара мөгамәлә һәм мөнәсәбәтләрен тәртипкә салып рәтләү өчен, гореф-гадәт, йоладан башка, бер канунга нигезләнгән хокук системасы корылган.

Бу хокук нормалары һәр илдә кабул ителгән законнар кодексы белән беркетелгән була.

Көнбатыш университетларының юридик факультетларында Европа илләрендә эшләнгән юриспруденция өйрәтелгәне кебек, безнең мәдрәсәләрдә дә (мин классик мәдрәсәләрне күздә тотам) фикъһе, ягъни шул ук юриспруденция өйрәтелгән.

Классик мәдрәсәләрнең программасы гомумән шулай төзелгән:

1. Гарәп-фарси телләрен өйрәнү.

Хокук китаплары гарәп-фарси телендә язылганлыктан һәм хөкем эшләре шул телләрдә йөртелгәнлектән, казыйлар (судьялар) һәм хокук белемлеләре өчен гарәп, фарси телләрен укырдай, язардай яхшы белү зарур булган. Хәзерге заманда һәр укымышлы кешегә русча укый-яза белү кирәк булган кебек, ул заманда гарәп-фарси тел-



Н. Исәнбәт, проф. М. Мәхмүдов, Х. Туфан. 1961 ел.



ләрен белү соралган, шул телләрне өйрәнгәннәр. Тарихи унжиденче елдагы революциягә кадәр шәригать фәтвалары күбрәк гарәп-фарси телләрендә языла иде.

2. Классик мәдрәсәләрдә шулай ук риязият (математика), һәйәт (космография), нәҗүм гыйльме (астрономия) һәм тыйб (медицина) фәннәре өйрәнелгән.

Мәдрәсәләр белән бер заманда зур обсерваторияләр корылган. Олуг-бек һәм аның обсерваториясе хакында белмәгән кеше аздыр, ләкин татарлар аннан ике йөз ел элегрәк һөлагу хан заманында Кавказ тауларында обсерватория корганнар.

Төрки халыклардан Ибн Сина, Бируни, Нәваи, Сәгъди кебек күп олуг әдип һәм галимнәр шул мәдрәсәләрдә житешкәннәр. Болар гарәп һәм фарси телендә язганнар. Шулар арасында безнең олуг реформатор-тарих галимебез Мәрҗанине атарга кирәк.

Ләкин заманның үзгәрүе, сәяси һәм иҗтимагый хәлләрнең башкаруы, татар халкының мөстәкыйльлеген югалтуы белән мәдрәсәләрнең тоткан урыны кечерәя, анда дини схоластика хөкем сөрә башлый. Мондый хәл рус царизмына бик уңай була. Шуның өчен XX гасыр башында татар халкының уяну дәвере башланып, мәдрәсәләрне «европалаштыру», көнбатыш культураларына омтылу башлангач, патша администрациясе бу хәрәкәтне буарга тырышты. Ләкин мәдрәсәдә башланган көчле прогрессив хәрәкәтне туктатып булмады.

1905 ел революциясе якынлаша. Демократик идеаллар белән кыздырылган шәкертләр хәрәкәте башлана. Каюм Насыйриның халык аңлы татар телендә язылган әсәрләре, гомумән төрки телләрдә язылган әсәрләрнең Казанда күп тираж белән басыла башлавы, Каюм Насыйриның һәм Мәрҗанинең рус телен өйрәнүгә өндәп, шуңа практик юллар ачулары татар халкының заманача культурасын коруга юл ача. Казанда Мөхәммәдия, Уфада Галия, Оренбургта Хөсәения, Буби мәдрәсәсе кебек, башка урыннарда да яңа тип мәдрәсәләр барлыкка килә. Боларда татар теле хөкем сөрә башлый. Хәтта Галимҗан Баруди кебек бөтен дөньяга ислам дине багымыннан гына карый торган дин галиме дә «татар балаларына татар телендә өйрәнергә кирәк» дигән фикерне яклап чыга. Ә ул, билгеле булганча, Нәкый Исәнбәт, Фәтхи Борнаш, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Хөсәен Ямашев, Газиз Гобәйдуллин, Галимҗан Шәрәф, Камил Якуб, башка бик күп галим һәм җәмәгать эшлеклеләрен үзенең дәресханәләрендә тәрбия итеп чыгарган Мөхәммәдия мәдрәсәсенең баш остазы, ректоры иде.

XX гасырның беренче унлыгында татар телен һәм тарихын өйрәнүгә багышланган дәреслекләр ел саен басылып тора. Ана теле, татар теле сарфы, нәхүе, уку китаплары, кыскасы, татар халкы куәтле шаукым белән үзенең телен, тарихын өйрәнә башлый. Галимҗан Ибраһимов татар теле һәм әдәбияты хакында күп гыйльми хезмәтләр яза. Хәтта Тукай да татарча уку китабы язудан читтә калмый. Рус телен өйрәнү башлана. Рус мәктәпләренә кереп укучылар күбәя. Үзе Бохарада «хәтме көтеп» кылып кайткан дамеллаларның угыллары, кызлары рус гимназияләренә, Казан, Петербург һәм башка шәһәрләрдәге рус югары мәктәпләренә кереп уку фикере белән дәртләнәләр. Француз һәм немец университетларына барып уку хыяллары белән, Бохарага арка биреп, көнбатыш уку йортларына йөз бирәләр. Татарстанның Миңлебай авылыннан чыгып, Чистай мәдрәсәсен ташлап киткән Фатих Кәрими Истамбул аркылы Парижга — Сорбонна университетына барып житә. Шуннан алган белеме белән иленә кайта.

Татар мәдрәсәләренең көнбатышка юнәлү процессы безнең мәдәни хәрәкәттә көчле бер фактор була. Менә шул заманнарда Тукай зур осталык белән бу европалашу процессын сурәтләгән «Толугышшәмси мин мәгърибиһа» дигән шигырен яза.

Чыкса мәгърибтән кояш, шунда заманның ахыры;
Бу — китапларда язылган күп галәмәтнең бере.
Гыйльмилә хикмәт кояшы туды мәгърибтән хәзер,
Көнчыгыш халкы, белалмыйм, инде нәрсә мөнтазыйр?

Бу шигырьдә — һәм хакыйкать, һәм Тукай каләменә генә буйсынучы сокландыргыч юмор. Дини хорафат буенча ахырзаман галәмәтләренең берсе — кояшның кире яктан, ягъни көнбатыштан калка башлавы.

Менә шул заманда Мөхәммәдия мәдрәсәсендә бу юлларны сызгалаучы Нәкый Исәнбәт белән очраша. 1910 еллар. Бу елларда Мөхәммәдия мәдрәсәсендә һәм көнкүреш, һәм уку хәлләре борынгы мәдрәсә белән һич чагыштырылмаслык рәвештә үзгәргән иде. Чаршаулар белән әйләндереп алынган җәмагать сәкеләре бетә. Яшь шәкертләрдән самовар куйдырып күп вакытлар ала торган әшәке мәдрәсә ашханәсендә шәкерт салмасы пешерүләр бетерелеп, алар урынына ятакханәләр рәвешендәге ару ятак бүлмәләре, гомуми ашханәләр, чәй өчен даими кайнап торган кублар куела. Юыну өчен аерым бүлмәләр корыла. Уку бүлмәләре (класслар) якты, иркен. Имән агачыннан ясалган, кара лак белән буялган ике урынлы уңай парталар, мөгаллим өчен уңайлы кафедра, зур кара такта, зур-зур күләмле харита (карта)лар белән җиһазланган дәресханәләр, табигыйәт һәм риязият лабораторияләре, кул эше (агачтан юнып ясау) остаханәсе, шифаханә, бакча, тимераяк өчен каток.

Нәкый белән очрашкан вакытта без рөшдия бүлегендә укый идек. Бу бүлектә иң әһәмият бирелгән фәннәр риязият (математика) фәнкәре, татар теле һәм әдәбияты, тарих, җәгърафия иде. Гарәп һәм рус телләре аерым тел дәресләре булып укытылалар иде.

Мәдрәсә программасында рөшдия циклы — иң әһәмиятле, һәр фәнгә нигез сала торган бүлек. Шунда вакытта шәкертнең барачак юлы билгеләнә.

Исәнбәтнең һәвәсе дә шул заманда ачылды. Рөшдия сыйныфларында шәкертләр газеталар чыгаралар, әдәби парчалар язалар. Бигрәк тә шигырь язу белән мавыгалар иде. Нәкый үзе укыган сыйныфта «Ташкын»мы, «Ялкын»мы дип атала торган газета чыгаруда җитәкчелек итә. Нәкый каләменең көче, аңының кодрәте шул вакыт сынала башлады.

Шул ук сыйныфларның берендә икенче бер әдип Фәтхи Бурнаш борынлады. Нәкый белән Бурнашның әдәбиятта беренче адымнары бер төслерәк башлана. Ялгышмасам, алар икесе дә Фәхрелислам Агиев нәшер итә торган балалар журналы «Ак юл» аркылы дөньяга чыгалар. Беренче шигырьләре шул журналда басылды-дип беләм. Икенчедән, алар икесе дә татар театрының атасы Габдулла Кари әйләнәсендә булып, уенчылар өчен рольләр хәзерләү белән шөгыльләнәләр иде. Бу ике әдәбият-

сәнгать сөюче яшь шәкертнең шагыйрь һәм драматург буларак иҗади юлын билгеләүдә бөек театр остасының йогынтысы булса кирәк.

Яшьлек чорында әдәби парчалар язган, «Сәйяр» труппасында эшләгән, Г. Кари түгәрәгендә «Сәйяр»ны репертуар белән тәэмин итүдә катнашы булган Фатих Бәкер белән дә Исәнбәт шул чорда таныш була. Хәзер Ташкентта юридик фәннәр профессоры Фатих ул вакытта шигырьләр һәм әдәби парчалар язды. Татар театрында уенчы буларак та эшләде. Хәзердә дә Исәнбәт белән хәбәрләшеп, күрешеп тора.

Шул ук Мөхәммәдия дәверендә Исәнбәтнең татар фольклорына һәвәсе башлангандыр. Бу вакыт Мөхәммәдия мөгаллимнәреннән бик мөлаем, бик симпатик кеше Хуҗа Бәдигый халык тел әдәбиятын җыюга керешкән иде. Халык әдәбиятына мәхәббәт тойгысын шәкертләр күңеленә урнаштырырга тырыша иде. Олуг галим һәм мәгърифәтче Каюм Насыйри халык әдәбиятын өйрәнүче буларак парлак бер эпизод булса, Хуҗа Бәдигый, шул ук Мөхәммәдия дәресханәләреннән чыккан Гали Рәхим, Г. Гобәйдуллиннар фольклор белән җитди шөгыльләнә башладылар.

Мөхәммәдиядән Уфага Галия мәдрәсәсенә күчкәч тә, Исәнбәт көчле әдипләр арасына төшә. Ул вакыт Галиядә Галимҗан Ибраһимов — мөгаллим. Мәдрәсәдә шәкертләрдән торган көчле әдәбият түгәрәге эшли. Алар арасында — соңыннан атаклы шагыйрьләребез булып үскән Сәйфи Кудаш, мәрхүм Шәйхзадә Бабич һ. б.

Һәрвакыт яңалык сөюче, табигате белән новатор булган, туктаусыз эзләнүче Исәнбәт 1917 елда булган бөек үзгәрешләр дәверендә инде буйга җитеп, аякка нык баскан язу остасы иде. Рус матбугаты аркылы Европа культурасы, төрки һәм гарәп матбугаты аркылы якын шәрык культурасы — аның иркендә, аның колачында иде.

Ул вакыт татар матбугаты да парлак бер дәвер үткәрә. Басма әсәрләр Казан, Өфе, Оренбург, Әстерхан, Мәскәү һ. б. күп шәһәрләрдә туктаусыз чыгып таралып тормакта иде. Ләкин Исәнбәтнең шау-шусыз эшләп бара торган бер изге эше бар иде. Шуны мөмкин кадәр уңышлы эшләр өчен ул туктаусыз хәрәкәттә булды. Казан артында эшләгән чагында да, Башкорстан җәйләүләрендә дә, Җаек буйларында да, Себер авылларында да һәм Казан, Өфе, Петербургның бай китапханәләрендә дә ул күп материаллар җыйды. Борынгы татар әдәбиятын, халык әдәбиятын җыюны әйтәбез. Халкыбызның бәясе чикләнә алмаслык бай хәзинәсен җыюда Нәкый иң булдыклы хәзинәдар булып, ул хәзинәне искиткеч матур һәм кыйммәтле җәүһәрләр табып, тагы да баетты һәм ул байлыкның иң ышанычлы сакчысы булды.

Сокланып туя алмаслык гөлбостаныбыз булган ана телебезнең чибәрлеге, тазалыгы хакында тынгысыз хафаланып, күз-колак булып торган оста бер багбан ул. Татар теле хакындагы фәннең иң югары түбәләренә ирешеп, киләчәк буыннар сокланып өйрәнерлек монументаль әсәрләр ясады. Бу гөлбостанның чикләрен киңәйтү чараларын күрү юлында әле дә тирән һәм күләмле гыйльми-лингвистик хезмәт алып баруын беләбез. Бу өлкәдә аның әйтәчәк яңа сүзләрен сабырсызлык белән көтәбез.

Драматургия өлкәсендә Г. Камал һәм Ф. Әмирханнардан эстафета алып, Н. Исәнбәт хәзергә хәтле татар театрының төп терәкләреннән берсе булып килә.

Мәдрәсә программасы белән казанылган белемгә нигезләнеп хезмәт иткән абыз агаларыбызның гыйльми-иҗади әсәрләрендә дәвергә хас аромат бар. Соңгы 50—60 ел эчендә татар матбугатын гомумән, татар фольклористикасын һәм татар драматургиясен хосусан, Нәкый Исәнбәттән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Бер кешенең шулкадәр күп гыйльми-иҗади эш майтаруына хәйран каласың. Татар халкының Каюм Насыйри, Тукайларга тиң мактандырырлык галим һәм әдибен тиешле дәрәҗәдә хөрмәт һәм тәкъдир итә алудан гаҗизбез.

Гөлсем Исәнбәт

# КҮП КЫРЛЫ,[1] КИҢ КОЛАЧЛЫ ӘДИП

Нәкый һәртөрле фәнни әйберләр һәм хайваннар, җәнлекләр турындагы китапларны бик яратып, мавыгып укый. Чөнки хайван, кош-корт, табигатьне үзе дә ярата. Аның «Куян мажаралары» дигән озын хикәясендә куяннар тормышын бик яхшы белеп язуыннан да моны күреп була. Бу китабы, төрле телләргә тәрҗемә ителеп, балалар арасында яратып укылып йөри.

Ул драматург буларак ничек эшли, аның иҗат процессы яки язу методы турында мин сүзгә керешә алмыйм. Тик читтән карап күземә чалынган кайбер ягын гына әйтә алам. Ул классик драматургларны күп укый һәм драматургия турында төрле материаллар укырга ярата, аларны газет-журналларда күрсә, сызгалап укып, кисеп алып, аерым папкаларга да җыя. Ул борынгы грек, һинд, кытай, япон драматургиясен җентекләп өйрәнде дияргә була. Грек язучысы Софоклны аеруча ярата. Драматургларны өйрәнгәндә, ул иң элек әсәрнең фабуласын (тоташ вакыйгасын) язып ала, аннары һәрбер пәрдәдәге вакыйганы аерым язып чыга. Соңыннан анализ ясап, үз фикерләрен яза. Гомумән драматургия турында язган төрле искәрмәләре, фикерләре, ясаган анализлары күп, аларны җыйнап, эшкәртеп бер фән хәленә китерәсе иде дип куя, тик моның өчен аның вакыты җитми.

Шекспирга мәхәббәте шулкадәр зур, ул аның әсәрләрен өйрәнгәндә, оригиналында ничек яңгыравын белү өчен, үзлегеннән инглиз телен өйрәнде һәм «Король Лир» белән «Гамлет»ны тәрҗемә иткәндә, төп оригиналыннан эшләде. Русча тәрҗемәләрен дә чагыштырып, төп оригиналга якынайтырга тырышты.

30 нчы елга кадәр аның язган пьесалары бик тиз арада, бер ай эчендә языла акка күчерелеп бетә иде. «Һиҗрәт» пьесасын ул, авылда репетиция барган чорында бер атна эчендә язып бетергәнен сөйли. Хәтта, әйтүенә караганда, ачлык елларда бәрәңге лампысы яктысында берррәттән өчәр төн утырып, бер пьеса яза торган булган. Әлбәттә, еллар үтә бара ул аларны төзәтә килде. Миңа шул хәтлесе билгеле: тормыштан алынган типны яки үзенең уена килгән идеяне ачу өчен, ул бер образны үзәккә ала, аның характерын ачу өчен вакыйгага бәйләп аның тирәсенә башка образлар җыйный. Бу образлар һәммәсе дә төп геройны ачуга хезмәт итәләр. Баштарак язылган комедияләрендә тагын шул хәл бар: геройлары гомумән һәрбер әсәрендә пьесаның ахырында тагын бергә килеп җыйналган була. («Һиҗрәт», «Шаңгәрәй», «Пикүләй Шәрәфи», «Портфель» һ. б.)... 30 нчы елдан соң аның бу язу ысулы үзгәрә. Методны схема итеп алудан кача. Билгеле, моның үзенә сәбәпләре бардыр.

30 нчы елдан соң күбрәк ул тарихи трагедияләр, фольклорлы комедияләр язарга керешә. Тарихи әсәрләрне язу бик мәшәкатьле була, бик күп материал укый. Геройның, үзе күрергә теләгән ноктасын табу өчен, шуңа бәйләнешле бик вак, кечкенә эпизодларын җыйнап тотып алырга тырыша. Мәсәлән, Муса трагедиясен язганда ул: «Мин Муса трагедиясен «Шагыйрь һәм тиран» темасы итеп күрәм, шагыйрь — ирек, азатлык каһарманы, аны бер тиран, зиндан да җиңә алмый, бу көрәштә һәр вакыт тиран җиңелә, шагыйрь авазы зиндан стеналары аша үтә, җыр һаман яши һәм тиранлыкка нәфрәт булып яңгырый. Моның өчен миңа Мусаны Гитлер белән кара-каршы куярга кирәк. Ләкин, кызганычка каршы, кулымда тарихи факт юк, аны Розенберг белән очраштырырга туры килә», дип сөйли иде.

---

[1] Гөлсем апа Нәкый аганың иҗат һәм тормыш юлы турында кызыклы истәлекләр язып калдырган. Без әлеге истәлекләрнең соңгы — XIII бүлекчәсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез. *Редакция.*



Н. Исәнбәт тормыш иптәше Гөлсем ханым белән.

Әсәрләрен кат-кат эшли. Эшләгәндә, башына ял бирү өчен, яза торган әсәрен туктатып, арага фольклор, сүзлек, әдәбият тарихы, борынгы әдәбият буенча ни дә булса кертеп эшләп ала. Шуңа күрә аның өстәле яки тирә-ягы бик күп төрле китаплар белән капланып беткәнлектән, ул өстәлнең бер җирендә кул гына сыярлык калган урында яза. Куйган китапларны, язмаларын берәр ничек тәртипкә китерүгә, кузгатырга һич рөхсәт итми.

Нәкый яшьтән үк дөнья әдәбиятындагы язучылар, философларны укып танышып барган. Кулына төшкән китапларны чайкап кына эчми инде. Һәрбер хәрефен сыгып, үзенә кирәк фикерне ала, үзенең карашын чагылдырып аркылыга-буйга сыза, төрле билгеләр куя.

Язар темасы, материалы булмаган вакытны яки ялкаулыгы килгән чагын, эшлисе килмәү, күңел төшмәү, арган-талган чагын мин бер генә дә күрмәдем. Ләкин ашарга-эчәргә туктаган вакытында, үзенә ял бирү, фикерләрен читкә бору өчен, безнең белән һәртөрле тузга язмаган җыен юк-барны сөйләргә тотына. Мин аның ни өчен кирлеморлы сүзләр сөйләп утыруын аңласам да, бергә катышып көлсәм дә, гаиләдәге башка кешеләребез гомер буе ияләшә алмадылар.

Гомер буе каләмгә өйрәнгән кулы, ашарга утыргач та, тәлинкә өстендә кашыкны беркадәр кыбырдатып, язарга иткән сыман, селкенеп тора.

Нәкый үзенең иҗади байлыкларын халыкка биреп бетерә алмыйча, үзе белән алып китмәс микән, дигән уй мине бик борчый иде. Соңгы дәвер гомерендә кайбер эшләрен иркенләп эшләп утырырга мөмкинлекләр туу, әлбәттә, куанычлы.

Исәнбәт ул — сирәк туа торган, күп кырлы, киң колачлы, халкын ярату хакына күп нәрсәгә чыдам, зур талантлы кеше. Бары халыкка булган мәхәббәте генә аның өмет яктысы булды. Ул мине дә халыкны ярата белергә, шул яратудан тәм табып яшәргә, бөтен барлыгың белән үзеңне корбан итә белергә өйрәтте.

Исәнбәт бары шагыйрь генә яки драматург кына булып эшләсә, бәлки ул бик күп шигырь, бик күп драма әсәре тудырган булыр иде. Ләкин ул үзенең нинди халыкка, аның кайсы катлавына хезмәт итүен бик аңлап (аның беренче поэмаларының «Укытучы кыз», «Качкын» кайсы катлауга хезмәт итүен башта ук ачыклый), халыкның әдәби культура байлыгын өйрәнергә, аны җыйнарга керешкән. Намуслы йөз ояла дигәндәй, башка халыклар алдында коммунизм җәмгыятенә әзергә хәзер булып буш

кул белән кермәү өчен, гомуми культурага татар халкының да нинди дә булса бер өлеш кертергә тиешлеген аңлап, шигырь, драма әсәрләреннән тыш, бер үк вакытта ул башка бик күп өлкәләргә дә чәчелеп эшләргә мәҗбүр була. Әдәбият тарихы, тел, фольклор байлыкларын җыйнап, эшкәртеп халыкның үзенә кайтарып бирергә тырышты. Фольклор әйберләрен аркылы-буйга үлчәп, гыйльми анализы тәмам булмыйча, чиле-пешле чыгаруга каршы булды. Шуңа күрә, өлгерә алмаганлыктан, бик күп материалы кулында ята.

1925 нче ел «Безнең юл» журналының 25 нче санында Кутуй («Тойгы» имзасы белән) Исәнбәтнең «Чаң» дигән шигырьләр җыентыгына язган тәкъризендә, аның:

Батыр мәйданда ятмас җан барында,
Тотар антын, түгәр актык канын да! —

дигән шигырен мисалга китереп: «Аныңча (Нәкыйчә) үлмичә көрәш мәйданын ташлау җинаять», дип язган иде.

Язучылык сыйфаты буенча ул, һәртөрле катлау кешеләре белән сөйләшүдән тартынмый. Аларның үз дәрәҗәләрендә уртак тел табып аралаша, алар белән үзен тигез тотып, бер булып китә ала.

Нәкый — табигате белән бик шат, уенчак кеше. Сахраларга чыкканда яшел үлән өсләрендә балалар кебек тәкмәч атына, ауный, бөтен яланны яңгыратып иһаһайлап кычкыра, табигатьнең эчендә табигатьнең нәкъ үзе белән бер булып тоташа. Тормышта бер вакытта да төшенкелеккә бирелми. Кешеләрне дә шулай булырга өйрәтә. Әмма эшкә утырса, бу вакыт ул бик җитди була. Исенә төшермәсәң, ашап-эчеп алырга кирәклекне дә белми. Урын сайлап тормый, һәркайда эшли, яза, урын булмаса, тезенә куеп булса да яза бирә. Эшеннән кузгатканны, яки турыдан-туры әдәбият-сәнгатькә катнашы булмаган җыелышларга йөрүне бер дә яратмый. Аның иҗат эшенә берәр ничек аз гына кырын килсәң, холыгы бик начар, үзлегеннән чыга, сиңа теләсә нәрсә кычкырырга хәзер тора.

Ул кайчан малайлар кебек шук та була. Кайбер көнне иртән мин базардан кайтуга үзенең юрган-мендәрен нәкъ йоклап яткан кеше кебек ясап куя да үзе кача. Мин барып бер уятам, ике уятам. Ахырда ачулана башлыйм. Ә ул шул арада, качып торган җиреннән чыгып, өстәл янына килгән дә эшләп утыра...

Галстук тагарга яратмый. Шуның өчен аны бәйләргә дә өйрәнә алмады. Әзер бәйләнгән галстуклар ала торган булдык. Ходаның бирмеш көне, һәр елны бер пар перчатканы кайда да булса калдырып, югалтып кайту — аның гадәте. Шуны истә тотып, перчатка сатып алганда һәр вакыт 2—3 пар итеп алып куябыз. Ни алсаң, шуны кия, ни ашатсаң, шуны ашаса да, тозлы балык белән балны бергә каба дигәндәй, бирсенә берсе капма-каршы әйберләрне дә бергә кушып ашый ала торган гадәте бар. Һич талымлап тормый. Кызыбыз Йолдызның: «Әти, безнең аппетитны бозасың», дип кәефе китүенә, «шулай яхшы, файдалы була ул, кызым», дип көлә генә бирә.



## БАШКОРТСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ СӘЙФИ КУДАШКА 75 ЯШЬ

# ХӘСӘН ТУФАН

Тукай премиясе лауреаты

## Гомер эзләрең буйлап

**I**

*Үткәннәргә кайта бүген хәтер,*
*Туктый-туктый таныш чатларга,*
*Келәш[1] мәҗлесенең көләч улын —*
*Яшь Кудашны күргән чакларга.*

*Көләч идең.*
*Бу төс сиңа, Сәйфи,*
*Каян ингән, каян күчкәндер,*
*Өметнең ул бәлки Тукай аша*
*Сиңа төшкән нуры булгандыр.*

*Турда түгел, төптә идең син дә*
*Элгәреге «зиндан Рәсәй»дә:*
*Син дә шуннан — Ленин әйткән төштән,*
*Мазлумнардан килдең яшәүгә.*

*Фидакарьлек юлын сайлап алган*
*Улы булып ябай[2] илеңнең,*
*Мәктәптән үк, үзе ирәннәрчә[3],*
*Озын юлга аяк киендең.*

*Алып китте сине*
*Җәяү дәрман,*
*Җәяү иман ялан далага,*
*Белгәнеңне бүлеп бирер өчен*
*Тирмәдәге һәрбер балага...*

[1] Келәш — Сәйфи Кудашның туган авылы.
[2] Ябай — гидай, ярлы.
[3] Ирән — халык өчен яшәүче кеше.

## II

*Үткәннәргә кайта күңел бүген,*
*Керә-керә таныш кырларга,*
*Йолдызлардан — тере классиклардан*
*«Хәер-дога» алган елларга.*

*Даулы чорда кердең шаулы юлга,*
*Җаннар төннән таңга килгәндә,*
*Гафурилар илгә оран салып,*
*— «Юктырсың ла, алла!..» дигәндә.*

*Идеалга, аңга инанулар*
*Дүңдерделәр безне диннәрдән:*
*Ходай Мөхәммәте түгел инде,*
*Тукай иде безнең «пәйгамбәр»...*

*Була, Сәйфи,*
*Тормыш диңгезенең*
*Була шундый җилле көннәре:*
*Әйләнечле юлга алып ташлый*
*Туп-турыга барган көймәне...*

## III

*Үткәннәргә кайта-кайта хәтер*
*Туктап үтә урта юлыңа,—*
*Партиянең һәр киңәшен үтәп,*
*Ат тартмасмы тарткан чорыңа.*

*Илең белән бергә көендең син,*
*Илең белән бергә сөендең:*
*— Үземнеке! — дигән егете син*
*Партиянең — Илнең — Ленинның.*

*Нинди генә циклон очрамасын,*
*Кайсы гына дулкын какмасын,*
*Маяк иде, маяк булып тора*
*Партияле асыл максатың!*

## IV

*Баш ия дә синең хозурыңда,*
*Үткәннәрдән кайтып барышлый*
*Йөрәк бүген,*
*Тирән хөрмәт белән*
*Барлыгыңа рәхмәт багышлый.*

*Борчуларның барын читкә ташлап,*
*Яңа-яңа яшь аласың:*
*Тынгы белмәс дәү кыңгырау булып*
*75 тән үтеп барасың.*

*Янар җанлы ирән булсаңчы дип,*
*Имезгәндер газиз әсәең:*

*Нәкъ чырагдай якты узаманы*[1]
*Бүген дә син*
*Безнең Рәсәйнең*

*Алыслардан*[2]*, гомер юлларыннан*
*Бәйрәмеңә кайтып барышлый*
*Йөрәк сиңа, и кылычлы чыраг,*
*Рәхмәт тулы тустак*[3] *багышлый.*

## Сәйфи Кудаш

### Көнләшәм...

— Саумысыз,— дим, әй киләчәк яшьләр?
Еллар аша сезгә эндәшәм.
Теләсәгез ничек гаепләгез,
Валлаһи, мин сезне көнләшәм!

Ихлас белән әйткән сүзләремне
Юрый күрмәгез тик кирегә:
— Дучар булган картлык көннәрендә
Бичара,— дип,— көнләү чиренә.

Мөмкин түгел сезне көнләшмәскә,
Кызыкмаска сезнең бәхеткә.
Язмышыгыз туры килде сезнең
Әкиятләрдән кызык вакытка.

Тик белегез: бу дөньяны сезгә
Без бит шулай төзеп калдырдык,—
Сезгә шулай рәхәт булсын өчен
Йөрәкләрне уттай яндырдык.

●

Бөркет килсә, тавыбыз бар,
Кунар кыя сайлар өчен.
Былбыл килсә, талыбыз бар,
Басып кына сайрар өчен.

Аккош килсә, күлебез бар,
Горурланып йөзәр өчен.
Толпар килсә, кырыбыз бар,
Җилдән узып җиләр өчен.

Мәйданнар киң батырларга:
Сынашырга, көрәшергә.
Шагыйрьләр күп ярышырга,
Чәчәннәр бар сөйләшергә.

Дуслар килсә, ишек ачык,
Өстәлләрдә ашыбыз бар.
Качып-посып дошман килсә,
Атар өчен ташыбыз бар.

Кунак килсә, хөрмәт көтеп,
Йөзләр — ачык, түрләр — әзер.
Читләр килсә, чиктән үтеп,
Казып куйган гүрләр әзер!

[1] Узаман — илнең күренекле өлкәне, аксакалы.
[2] Алыслардан — еракләрдан.
[3] Тустак — кымыз салып бирә торган савыт. Бу урында котлау тосты мәгънәсендә алына.

Эчтә ялкын,
Тышта салкын.
Җир өсте саф, ак кына.
Китсәң иде бала булып
Шул кардан атлап кына!

Тып-тын урман.
Мин генә тик
Эндәшәм каеннарга.

Йөрәктә дә,
Тирәктә дә
Юк урын ваемнарга!

Шул тынлыкның диңгезенә
Онытылып чумсаң иде.
Тормышның иң
чоңгылыннан
Җыр алып чыксаң иде!

## Исемем хакында

Әти кушкан исемем Сәйфи минем.
Үзебезчә әйтсәк: «Кылыч» ул.
Иөртә бирәм шөкер кылып кына:
Өлешемә тигән көмеш ул.

Кирәк чакта аны кулда тотам,
Кулга алмаганда — кынында.
Ул җылынып гомер итә миндә
Һич суынмый торган тынымда.

Кайда гына булсам,
Нишләсәм дә,
Һәр вакытта була янымда:
Кулларымда,
Җырда,
Кынында,
Тында,
Я йөрәкнең кайнар канында.

Мин яшәрмен исемемә тиң булып,
Юкка селтәп кулны талдырмам.
Калса калыр ул кителеп, сынып,
Тик тутыккан кылыч калдырмам!

## Әгәр дә...

Әгәр дә син минсез каршыласаң
Берәр төннең таңы атканын,
Я офыкта ялгыз торып калсаң
Туктаталмый кояш батканын,—

Борчылма син. Җуйма сабырлыгың,
Уйла кышның йончу чакларын.
Кышкы юллар зыкылырак булса,
Шәп җиләлми икән атларың...

Әгәр дә мин килеп җитәлмәсәм
Вәгъдә биргән сәгатьләремә,
Ашыкма син юлдан күзеңне алып
Таянырга яңакларыңа!

Йолдызларын танга борылса да,
Өмет капкаларын бикләмә.
Мин барыбер килермен бер вакыт,
Бүген булмый икән, иртәгә!

## Ни кылырсың

Бәрхет кебек бер өн белән,
Балдан татлы бер тел белән:
— Сөям! — дигән кеше бер көн
— Суям! — дисә, ни кылырсың?

Бер көн изге максат белән,
Күздәй тулы тустак белән
Ширбәт сузган бер кул сиңа
Агу бирсә, ни кылырсың?

Кичтән утырып түрендә
Ашаган дусың ашынны,
Иртән ашарга башыңны
Теш кайраса, ни кылырсың?

Утланырсың,
Уфылдарсың, уйланырсың.
Шундыйларны кызганырсың...
Шуннан башка ни кылырсың?

## Тиз ятмастыр...

Өмет дингезенең дулкыннары,
Мәхәббәтнең изге моңнары
Катып торса күңел ярларын,
Йөрәгеннән яшел кырларына,
Яшьлегеннән ярсу җырларына
Тиз ятмастыр, картлык, карларын!

## Тик шулай да...

Син тыныч булсаң, туган җир, мин тыныч.
Мин алам күкрәкне киереп киң сулыш.
Ил тыныч, җир дә тыныч, — мин дә тыныч.
Тик шулай да, билдә торсын бу кылыч!

## Гөлләрнең дә телләре бар икән[1]...

Әй җыюлар,
Мәгез, газизләрем,
Бу гөлләрне миннән алыгыз.
Үзегезнең гөлләрне дә естап,
Туганыма алып барыгыз!

Х. Туфан.

Гөлләрнең дә телләре бар икән,
Сөйләшәләр икән чәчкәләр.
Сүзлексез дә аңлап була икән,
Гөлләр сиңа өзелеп дәшкәләр.

Әлсерәшеп килеп кергәч бүген,
«Аккош күле»нең юлчы гөлләре,
Саулыкларын сорашудан алда
Сусын сүздым ашыгып әлгәре.

[1] Бу шигырь Мостай Кәрим Хәсән Туфанның кыңгырау чәчәкләр алып кайтып тапшыргач язылган иде. Автор.

Дим гөлләре торган вазаларга
Утырткач та назлап үзләрен,
Сирпеп куеп серле керфекләрен
Кунак гөлләр ачты күзләрен.

Башкорт белән татар кебек икән
Бакчаларда үскән гөлләр дә.
Теләкләрен бер үк төсле булса,
Аңлашыла икән телләр дә...

Кайнар көйгә килде сәламнәрен,
Гөлләреннән телен төшендем.
Чәчкәләр дә сөйли белә икән
Сагынуларын якын кешеннән!

●

Изге илһам кебек, көткән кешеләр
Син сагынган чакта килмиләр.
Башка тулган очрак уйлар төсле,
Көтмәгәннәр тынгы бирмиләр.

Көтмәгәндә килеп керә алар,
Жаны керен «бүләк» итәргә.
Нәкъ ач бүре кебек килә алар,
Тик рухыңны талап китәргә.

## Каләм югалгач

Югалды минем каләмем
Өемнән, өстәлемнән.
Кайгысы шушы бәланең
Аерды эшләремнән.

Кем алып киткән соң аны,
Нинди уй-теләк белән?
Нинди кул чәлдерде икән
Һәм нинди йөрәк белән?

Иләшкән идем аңа мин,
Ул миңа күнгән иде.
Күпме язсан да карышмас,
Ялыкмас күндәм иде.

Ул хәзер нинди карага
Манылып яза икән?
Язганы илгә, кешегә
Файда я каза микән?

Язса да манып әгәр ул,
Караның карасына,
Кылмасын иде кара эш
Һич адәм баласына.

## Урман юлыннан

...Тәлгәш баланнарга сокланып,
Серле яланнардан моң алып,
Аулак акланнарга тукталып,
Урманымның үттем юлларын.

Бер туйралык, чытырман иде
Мин бәләкәй чакта бу урман.
Курка идем адашып китеп
Шүрәлегә килеп чыгудан.

Кайсы якка карап барсам да—
Барып чыгам таныш акланга.
Әле — шатлыкларга абынам,
Әле — кайгыларга кагылам.

Сәлам бирдем иман-атайга,
Башым идем каен-әсәйгә.
Талбикәнең үптем чукларын,
Усакбайның кыстым учларын.

Бишегемә кабыгын биргән
Караманың карап күзенә,
Кулларымны куеп йөрәккә
Рәхмәт әйттем мең кат үзенә.

Туймадым мин йөреп урманда...
Һич карамый урау юлларга,
Барып чыккым килде адашып,
Шүрәледән качкан елларга.



# ҖИТЛЕККӘН ХУДОЖНИК

*РСФСРның халык художнигы Харис Якуповка 50 яшь*

Казан сәнгать техникумына укырга кергәндә Хариска нибары уналты яшь була. Егетнең тормыштагы үз юлы шулай бик иртә ачыклана. Аны башка төрле теләсә нинди һөнәрдән бигрәк рәсем ясау үзенә тарта. Әле техникумга кергәнче үк ул Казан пионерлар йорты каршындагы сынлы сәнгать студиясенә йөри, балалар иҗатына багышлап уздырылган күргәзмәләрдә катнаша, «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә үзенең рәсемнәрен бастырып килә.

Техникумда Харис күңел биреп, тырышып укый. Ул, бер дә иренмичә, өйдә эшләргә бирелгән күнегүләр өстендә утыра, рәсем ясау техникасын камилләштерә, музейларга йөреп, мәшһүр рәссамнарның әсәрләрен ныклап өйрәнә, сынлы сәнгать хакында язылган китапларны бирелеп укый. Малай кече яшьтән үк күп белергә тырышуы, җитди булуы һәм хезмәт сөючәнлеге белән аерылып тора.

Харис үзенең укытучыларыннан да уңа. Казан сәнгать техникумында аларны Мортаза Абдуллин, Садри Ахун, Нәбиулла Вәлиуллин кебек үз эшләренә чын күңелдән бирелгән реалист художниклар укыта. Яңа гына Ленинград сәнгать академиясен тәмамлап кайткан нәгышче Нәбиулла Вәлиуллинның исә яшьләргә йогынтысы аеруча көчле була[1].

Техникумны Харис профессиональ әзерлек белән, якты хыяллар, зур иҗат планнары белән тәмамлый. Әмма озак та үтми, ак финнарга каршы сугыш башланып китә. Башка иптәшләре кебек үк, ул да үзе теләп Кызыл Армия сафларына баса. Бераздан изге җиребезгә фашист илбасарлары басып керә, һәм Харис, кулына корал тотып, тагын биш ел буена илебез иминлеген яклап, илбасарларга каршы сугышып йөри.

Рәсем ясарга һәвәслек, күзәтүчәнлек аңа армия хезмәтендә дә нык ярдәм итә. Разведчик Якупов күп мәртәбәләр кыен сугышларда була, аңа күп мәртәбәләр авыр һәм куркыныч сугышчан заданиеләр үтәргә туры килә. Ул Воронеж янындагы Курск дугасындагы дәһшәтле сугышларда катнаша, Украина һәм Чехословакияне азат итешә, дошманның үз өнендә барган сугышларны күрә. Яу кырларында күрсәткән батырлыклары өчен гвардия старшинасы Якупов орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Художник Якупов өчен исә сугыш чыныгу һәм тормыш мәктәбе була. Үзенең художник икәнлеген ул бер вакытта да исеннән чыгармый. Сугышның иң авыр көннәрендә, нинди генә кыен хәлләрдә калырга туры килмәсен, Харис карандашын кулыннан те-

---

[1] Кызганычка каршы, ул озакламыйча башланган Ватан сугышына китә һәм шуннан әйләнеп кайтмый.

шерми, блокнотыннан аерылмый. Дошманны җиңүебезгә аз гына да шикләнми художник, акрынлап, киләчәк эшләре өчен материаллар тупларга тотына. Аның турыдан-туры фронт шартларында ясаган рәсемнәре әле дә саклана. Алар арасында табигать күренешләре һәм портретлар, күп кеше катнашкан сугыш күренешләре һәм төрле фронт эпизодлары бар. Ул рәсемнәр авторның үз хезмәтенә гаять дәрәҗәдә җитди каравы хакында сөйлиләр. Художник һәр нәрсәне тырышып һәм игътибар белән күзәткән, һәр күренешнең төп үзенчәлеген, асылын аңларга тырышкан.

Вакытлар узу белән саргая төшкән альбом битләрендәге ул рәсемнәрне киләчәктә зурайтып язылачак картиналарның караламалары, беренче вариантлары дип санарга мөмкин. «Фашистларны куганнан соң. Балалар». (1943) исемле картина, мәсәлән, шундыйларның берсе. Рәсемдәге сәләмә киемле, ябык гәүдәле өч ятим баланы күрүгә, күңелләрдә кабат ачыну һәм нәфрәт хисләре кузгала. Илебезгә фашистлар алып килгән вәхшәт, җәбер-золым исәпсез-хисапсыз икән, аларга боларның һәммәсе өчен дә җавап бирергә туры киләчәк.

Авторның әлеге һәм башка шундый рәсемнәре үзләренең композицион төзеклекләре белән дә аерылып торалар. Ак һәм кара төсләр пропорциясе ныклап уйланылган. Карандаш очына төрлечә басу нәтиҗәсендә барлыкка килгән нечкә тонлы күчешләр ул рәсемнәрдәге пространствога киңлек хисе, ә әйберләргә күләм иллюзиясе бирәләр. Аерым рәсемнәрне нинди төскә буярга кирәклеген аңлаткан язмалар очрый. Димәк, автор киләчәктә аларга яңадан әйләнеп кайтачагын алдан ук уйлаган. Һәм, чыннан да, совет кешеләренең сугыш кырларында күрсәткән батырлыгы, сугыш темасы белән бәйләнешле сюжет һәм образлар художник игътибарын озак еллар буе үзенә җәлеп итеп килә.

Казанга кайтып яши башлавына күп тә үтми, Якупов «Туган илдә» (1946) исемле әсәрен тәмамлый. Әсәр фронт кырларыннан кайткан татар солдатының сөйгән кызы белән күрешеп-кавышу шатлыгы турында сөйли. Ә 1948 елда автор «Төп көчләр прорывка керә» исемле икенче бер фронт картинасын төгәлли. Бу әсәрләргә Якуповның соңгы картиналары өчен хас булган камиллек, осталык җитми әле җитүен. Әмма авторның зур темаларны чишәргә, катлаулы композицияле полотноларга кыю рәвештә алынырга сәләтле булуы бәхәссез.

Сугыштан соңгы беренче елларда Якупов тарихи темаларга караган күп кенә әсәрләр иҗат итә. Алар арасында «Г. Тукай портреты», «Габдулла Тукай крестьяннар арасында», «А. С. Пушкин Казан юлында», «Алексей Пешков портреты», «А. М. Горький Марусовкада», «Ш. Камал портреты» кебек әсәрләр бар. Шул ук елларда «Иделдә эссе көн», «Казанка елгасында ташу», «Кабан күле» кебек табигать күренешләрен һәм замандашларыннан берничә кешенең портретын ясый, шулай ук «Кунаклар белән аңгәмә» исемле автопортрет тәмамлый. Күренгәнчә, кыска гына вакыт эчендә художник күпме эш эшли. Әйтерсең, еллар буе җыелып-тыелып килгән иҗат ялкыны кинәт кабынып-дөрләп китә. Табигате белән үк ашыкмый, җайлап, акрынлап эшләргә яратторган кешенең шушы кадәр күп әсәр иҗат итүе, беренче карашка, чыннан да, сәеррәк тоелырга мөмкин. Ләкин, ныклап уйлап карагында, монда гаҗәпләнерлек берни дә юк. 1946 елда ул Всекохудожникның Мәскәү шәһәрендәге Үзәк студиясендә мәшһүр художник Б. В. Иогансон кул астында эшли. Ә 1948 елда художникларның Калинин өлкәсендәге «Академик дача»сында белемен күтәрә һәм иҗат итә. Болар да аның иҗат активлыгын көчәйтүгә ярдәм итми калмый, билгеле.

Үзеннән үзе аңлашылса кирәк, авторның әлеге әсәрләре сыйфат ягыннан бердәй югарылыкта түгелләр. Арада башкару камиллеге һәм техник профессиональлек җитенкерәмәгәннәре очрый, аерым әсәрләренә яңалык хисе, тормышны яңача сурәтли белү җитми. Автор сәнгатьчә сурәтләү алымнарына никадәр генә игътибар итмәсен, еш кына аның кайбер әсәрләренең эмоциональ тәэсир көче әллә ни зур булмый. Аның үз образларына булган мөнәсәбәтендәге тыйнаклык урыны-урыны белән корылык хисенә әйләнеп киткәли. Ләкин бернәрсәне истән чыгармаска кирәк, авторның беренче әсәрләре хакында хөкем йөрткәндә, аларның көчле һәм көчсез яклары турында сөйләгәндә, аларны без художникның бүгенге әсәрләре белән чагыштырабыз, аларга без бүгенге Якупов ирешкән югарылыктан торып караш ташлыйбыз. Заманында исә әлеге «кимчелекле» әсәрләрнең дә күбесе әйбәт исәптә йөргән. «Г. Тукай портреты» (1946), мәсәлән, республика күләмендәге конкурста беренче премия белән бүләкләнә.



*Шәриф Камал портреты.*

Якуповның А. С. Пушкин, М. Горький, Ш. Камаллар хакындагы әсәрләрен Казан музейлары, «Кунаклар белән әңгәмә» исемле әсәрен исә Мәскәүдәге Көнчыгыш сәнгатьләре дәүләт музее сатып ала. Шулай яшь авторга, акрынлык белән булса да, танылу, дан-шөһрәт килә.

Җаваплы эшләргә алыну Якуповның дөньяга карашын киңәйтә, аңа иҗат тәҗрибәсе тупларга булыша. Озакламый әлеге сыйфатларның һәр икесе бик тә кирәк булып чыга. Аннан соң, кимчелекләре күпме генә булмасын, Якуповның инде беренче әсәрләре үк сынлы сәнгатебезгә талантлы һәм сәләтле яңа бер рәссам килүе хакында сөйлиләр иде. Күп тә узмады, тормыш әлеге өметләрнең урынлы һәм нигезле булуын раслады.

Дусты Л. Фәттахов белән бергә, Татарстанның 30 еллыгына Х. Якупов «В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» исемле зур әсәр тәмамлый. Сынлы сәнгатебез үсеше тарихында зур әһәмиятле урын тоткан бу әсәр турында күп сөйләргә, күп язарга мөмкин булыр иде. «Казан утлары» журналының быелгы беренче санында аның хакында шактый киң язылды [1]. Бирефә ул фикерләрне кабатлап тормыйбыз. Тик шуны гына басым ясап әйтәсе килә: күтәргән темасының һәм эчтәлегенең зурлыгы, мөһимлеге ягыннан бу картина әле бүген дә татар совет нәгыш сәнгатенең югары бер казанышы булып кала килә.

Үзенең моннан соңгы һәр әсәренә Якупов зур җаваплылык хисе белән карый. Аның һәр яңа әсәре сынлы сәнгать тормышында зур вакыйгага итеп каршы алына торган булып китә.

---

[1] «Казан утлары» журналы. 1969 ел, 1 сан. 162 бит.

1954 елгы Бөтенсоюз күргәзмәсендә Якупов үзенең «Хөкем алдыннан» исемле яңа эше белән катнаша. Мәгълүм булганча, картинада Советлар Союзы Герое, патриот шагыйрь Муса Җәлилдән сорау алу күренеше сурәтләнә.

Гитлерчылар хәзергә әле үзләрен көчле сизәләр, шагыйрьне җиңәчәкләренә шикләнмиләр дә кебек. Мусаның язмышы, язсе, алар кулында. Буйсынмаса, аны үлем көтә. Менә шуңа да шагыйрьнең курку белмәс ныклыгы аларны гаҗәпкә калдырган. Рәссам гаять киеренке драматик ситуация сайлаган. Җәлилнең үз дошманнары белән кара-каршы рухи бәрелеше әсәрнең төп идея юнәлешен билгели. Әсәрдә палач образлары да карикатурага әйләндерелмәгән. Аларның куркыныч һәм көчле дошманнар булуы күренеп тора. Бу исә әсәрнең гомуми яңгырашын тагын да трагиграк пафослы итә.

Әсәрнең эчтәлегенә зур фәлсәфи мәгънә салынган. Җәлилнең фашистлар белән бәрелештә мораль яктан өстен чыгуы коммунистик идеологиянең тантанасы төсендә яңгырый. Якупов тасвирлаган Җәлилнең көче дә шунда, ул үзенең хаклы икәнлеген тирәнтен аңлап, белеп тора. Аның таза гәүдәсендә шундый көч, шундый ныклык сизелә, андый көч бары тик бөтен совет халкы белән бербөтен булуыңны ачык аңлау аркасында гына туарга мөмкин. Җәлил образын психологик яктан ышандырырлык итеп, тирән итеп ачып бирү герой шагыйрь характерының, ул күрсәткән батырлыкның асылын аңларга ярдәм итә. Әсәрнең төп уңышы әнә шунда.

Илленче елларның икенче яртысында совет сынлы сәнгате зур адымнар белән алга китә. Бүгенге көн тормышына йөз белән борылып, художниклар замандашларыбызның истә калырлык җанлы образларын тудыралар. Төс, композицион төзелеш өлкәсендәге эзләнүләргә тагын да зуррак игътибар бирелә башлый, образларны психологик үткенәйтү чараларын эзләү көчәя. Сынлы сәнгать «теле» тагын да баеый, төрләнә төшә.

Сынлы сәнгать өлкәсендәге үзгәрешләрне даими рәвештә күзәтеп барган Якупов та әлеге яңа алымнарны күрми калмый, әлбәттә. Аның илленче еллар ахырындагы яңа әсәрләре якты, ачык буяулар белән ясалган, алардан шатлык, бәйрәм рухы аңкып тора. Биредә аның халык иҗаты әсәрләренә иллюстрацияләр ясау белән шөгыльләнүе дә билгеле бер уңай роль уйнады. Халык иҗаты әсәрләре художник иҗатын оптимизм хисе, җылы юмор һәм ачык төсләр белән баетты.

1957 елда иҗат ителгән «Герой ананы хөрмәтләү» исемле картина үзенең ачык, якты төсләре белән тамашачы күңелендә шатлыклы бәйрәм настроениесе тудыра. Күп кеше катнашкан зур күләмле әсәрнең композицион төзелешен уңышлы хәл итеп, автор бердәм яңгырашлы бөтен бер әсәр тудыруга ирешкән. Әсәрнең идея яңгырашын билгели торган төп персонажлар картинаның үзәгенә куелган. Менә герой ана. Аның бөтен карашы алга, тамашачыга төбәлгән. Артык матур булмаган, әмма мөлаем йөзендә бәхетле елмаю. Аның тирә-ягындагы кешеләрнең дә һәрберсе тормышчан, һәрберсе хәтергә кереп калырлык. Аеруча әти кешенең йөзе сине үзенә нык җәлеп итә. Ул тыныч, туры карашлы, ләкин бераз кырысрак холыклы кеше булса кирәк. Персонажларның өсләрендә милли татар киеме, башларында бизәкле яулыклар, йорт стеналарына чигүле сөлгеләр эленгән. Болар һәммәсе әсәргә милли колорит өстиләр, аны киң халык массасына аңлаешлы итәләр. Биредә без Якуповның совет чынбарлыгын милли тормыш күренешләре аша ачарга омтылуын күрәбез. Гадәттә, үз әсәрләренә геройларны ул татар халкы вәкилләре арасыннан сайлый. Әмма, коммунист художник буларак, беркайчан да милли рамкалар белән генә чикләнми, тормыштагы искергән, үлемгә хөкем ителгән гореф-гадәтләрне идеаллаштыру белән мавыкмый, халык тормышының кайсы чорына гына мөрәҗәгать итмәсен, аның әсәрләреннән заманчалык, бүгенге көн рухы аңкып тора.

1961 елда Якупов чираттагы зур әсәрен тәгәлли. Ул — «Иделдә яз» дип атала. Әсәрдә төп урынны табигать күренешләре алып тора. Үз иҗатында беренче мәртәбә диярлек автор табигатькә шулай зур урын бирә. Хәер, моңа әллә ни гаҗәпләнергә дә ярамый. Мәһабәт Иделне ул кече яшьтән күреп үсә. Вакыт җитә, совет кешеләре борынгы елганы тагын да гүзәлрәк итәргә алыналар. Мул сулы Идел күз күреме җитмәслек киңлекләргә җәелә, Казан биш диңгез портына әйләнә. Шунда инде Якупов та түзеп тора алмый, җырларда мактаган Идел хакында тагын бер яңа җыр, үз җырын иҗат итәргә була. Шулай «Иделдә яз» исемле картина туа. Кояшлы язгы

кен. Ерак еракларга җәелгән Идел есте. Әле кайчан гына шаулап бозлар аккан булган. Тыныч су естендә берәм-сәрәм боз кисәкләре тирбәлә. Яз кояшының шифалы нурлары тәэсирендә бөтен табигать уянган: тамчылар тыпырдый, ергаНаклар чылтырый, кешеләр күңеле дә яз сулышы белән тулы. Идел ярында хатын-кызлар, шунда ук балалар чыр-чу килә. Моның үз мәгънәсе бар. Табигать-әнкәбез, Идел-әнкәбез һәм аналар... Художник тирән мәгънәле, шигъри аһәңле, лирик җылылык хисе бөркелеп торган гаҗәеп әсәр иҗат итә алган.

Чынбарлыкка катлаулы, күпьяклы һәм фәлсәфи мөнәсәбәт белдерү — Якупов иҗатына хас булган иң көчле сыйфатларның берсе. Ул тормыш күренешләренең тышкы калыбын сурәтләү белән генә чикләнми. Болай караганда, алардагы һәрнәрсә гадәти кебек. Тышкы эффектлар юк диярлек. Әмма аларга зур эчтәлек, эчке мәгънә салынган. Аларны игътибар белән, озаклабрак карарга кирәк. Шул чагында син художникның тормыш, кешеләр, аларның характерлары һәм язмышлары хакында киеренке итеп уйлануын сизә башларсың.

1964 елда Якупов зур күләмле ике әсәр иҗат итә. Аларның икесе дә бүгенге колхоз кешеләренә багышланган. Теманы чишү принципларының, вакыт һәм урынның берлеге, сюжет охшашлыгы әлеге әсәрләр арасында эчке уртаклык булу турында сөйли. Шуның белән бергә аларның һәркайсы мөстәкыйль сәнгать әсәре буларак та әһәмияткә лаек.

Беренчесенең тулы исеме: «Көчле кешеләр (Яшь сыер савучылар Ф. Гәрәева, М. Исламова һәм С. Сәгыйдова)». Ул «Татарстандагы М. Вахитов исемендәге колхозның ал-



*Вахитов исемендәге колхозның алдынгы сыер савучысы М. Галиуллина.*

дынгы кешеләре» исемле сериядән бер картина. Әсәрнең исеме үк геройларның реаль тормыштан алынган чын кешеләр булуын ишарәли.

«Көчле кешеләр» исемле картинаның геройлары — шат күңелле, тазә, зифа буйлы колхоз кызлары. Автор кызларны алгы планга куеп сурәтли, аларның көчле, сәламәт һәм матур булуларына үзе дә соклана кебек. Геометрик яктан төгәл, симметрик композиция, күзгә ташланып тора торган матур, ачык буяулар, кеше фигураларын чынбарлыктагыдан да эрерәк итеп күрсәтерлек күләм — болар барысы да әсәргә ниндидер тантаналы бәйрәм төсе бирәләр. Бер Якупов иҗатында гына түгел, Татарстандагы барлык нәгыш сәнгате әсәрләре арасында да «Көчле кешеләр» — иң күтәренке рухлы әсәрләрнең берсе. Әсәрнең тормышны раслаучан пафосы — гади совет кешесенә, аның рухи матурлыгына дан җырлавында. Әсәрдәге геройлар горур булулары белән матурлар, алар үзләрен илнең чын хуҗалары итеп тоялар. Революциягә кадәрге татар хатыннары белән чагыштырганда, аларның эчке һәм тышкы дөньяларында әйтеп бетергесез үсеш, үзгәреш, яңарыш сизелә. Бер сүз белән әйткәндә, «Көчле кешеләр» — социализмга, совет дәүләтенә һәм Коммунистлар партиясенә художникның илһамланып гимн җырлавы ул. Шуңа да әсәрдә кояш нуры күп, шуңа да аңардан яктылык нурлары сирпелеп тора. Әсәрнең хатын-кызларга багышлануын автор бер генә минутка да исеннән чыгармый. Кызларның йөзләрен, кыяфәтләрен сурәтләгәндә затлы, нәфис төсләр өстенлек итсә, аларның кием-салымнарын һәм табигать күренешләрен тасвирлаганда ачык буяулар сайлаган.

«Алдынгы көтүчеләр Н. Җиһаншин, Ш. һәм Г. Шакировлар» исемле икенче картина исә башкачарак планда эшләнгән. Биредә инде художникның игътибар үзәгендә — ирләр. Алар шулай ук нык һәм бөтен шәхесләр, әмма аларның эчке дөньяларын автор башка чаралар ярдәмендә ача. «Көчле кешеләр» белән чагыштырганда, әсәрнең тоны да, ничектер, салкынрак һәм кырысрак кебек. Якупов көтүчеләрнең тулы гәүдәләрен күрсәтми, аның каравы ул аларны тамашачыга тагын да якынайта төшкән. Мондый алым исә кешеләрнең йөзләрен беренче планга чыгара. Хикмәт аларның күз карашларында, ди кебек безгә автор. Чыннан да, күз карашларыннан чыгып, аларның искиткеч камил акыллы, тәвәккәл һәм батыр табигатьле кешеләр булуын чамаларга мөмкин. Характерлары ягыннан никадәр генә милли булып күренмәсеннәр, Якуповның көтүчеләрен без бүгенге совет авылы кешеләренең типик, җыелма образлары итеп кабул итәбез.

Һәр ике әсәр художникның иҗади үсеше турында сөйли. Ул форма ваклыкларыннан һәм артык детальләштерүләрдән котылган, аз сүз белән күп мәгънә бирергә өйрәнгән. Аның палитрасы тагын да төрләнгән, яңарган. Ул кулланган буяулар ачыграк һәм кыюрак була бара. Һәр ике әсәр күләме ягыннан дөрес уйланган һәм төгәл хәл ителгән. Бу аңлашыла да. Сыер савучылар һәм көтүчеләр хакындагы әсәрләр озак еллар күзәтү, материал туплау нәтиҗәсендә иҗат ителделәр.

«Зур Идел» һәм «Советская Россия» күргәзмәләрендә Якупов «Уйлану. Тереләр һәм үлеләр» исемле яңа әсәр белән катнашты. Тереләр — көнбатыштагы бүгенге сынлы сәнгать күргәзмәсен карарга килүчеләр. Үлеләр исә — көнбатыштагы сәнгать күргәзмәсендә тамашачыны каршы алган сәнгать әсәрләре. Беренчеләре дә, соңгылары да эре план белән сурәтләнгән. Халыкка ят әсәрләр күргәзмәсенә килгән тамашачыларны аптырап калу, үзләрен чолгап алган сәнгать әсәрләрен аңлый алмый гаҗиз калу хисе биләштерә.

Әсәрнең үзәгендә — яшь итальян кызы образы. Күрәсең, ул гүзәллек дөньясы белән кызыксына һәм аның кадерен белә торган кеше, хәзер дә ул, мәсәлән, каршындагы әйберләрне чын күңелдән аңларга азаплана. Ләкин аның бөтен кыяфәтендә, бигрәк тә зур, бәрхеттәй күзләрендә — аптырау галәмәтләре. Каршындагы «сәнгать әсәрләрен» ул ни акылы, ни йөрәге белән кабул итә алмый. Куркыныч салкынлык хисе бөреп торган ниндидер галәмәт зур нәрсәләр, ямьсез чырайлы зур баш, кеше гәүдәсен хәтерләткән, әмма гаҗәеп котсыз фигуралар... Юк, мондый сәнгать аңа ләззәт бирә алмый.

Яшь кызның кичерешләре өлкәннәрнеке кебек үк катлаулы түгел түгелен. Әмма тозсызны күзсез дә белә, диләр. Тагын шунысы характерлы, үзе аңламаган өлеге рәсемнәргә кыз гаҗәпләнеп кенә түгел, хәтта куркып карый. Шук кыяфәтле карчык исә үзенә аңлашылмаган сәнгать үрнәкләрен халыкчан юмор, мыскыл катыш елмаю



*Уйлану. Терелəр һəм үлелəр.*

белəн күзəтə. Əйтерсең, аның хəзер менə əлегə əсəрлəр адресына берəр тозлы сүз ычкындырасы килə. Тамашачылар төркемен ир кеше тəмамлый, аның кырыс, усал күзлəрендə протест хислəре. Кыяфəтенə карaганда, ул тир түгеп тапкан икмəкнең кадерен аңлый торган эшче булырга тиеш, аңа мондый сəнгать бөтенлəй ят. Үзлəренə чит сəнгать белəн очрашкач, гади кешелəр күңелендə туган нəфрəт хислəрен сурәтлəү авторның төп максаты. Əсəр уйлап чыгарып, һавадан алып язылмаган. Автор, берничə мəртəбə халыкара күргəзмəлəрдə булып, модернист художниклар ясаган рəсемнəрне хезмəт иясе массаларының аңлый алмый газаплануларын үз күзлəре белəн күргəн кеше.

Картина катлаулы техника белəн, майлы һəм йомырка сарысына изелгəн буяулар ярдəмендə эшлəнгəн. Əсəр идея ачыклыгы, публицистик яңгыраш көче, композицион төзеклек белəн аерылып тора. Аерым кимчелеклəре булуга да карамастан, ул Якупов иҗатында һəм татар сынлы сəнгатендə яңа сүз булып исəплəнергə хаклы.

Күргəнегезчə, Якупов беркайчан да бер урында таптанмый. Аның дөньяга карашы торган саен киңəя бара, ул даими рəвештə яңа образлар һəм сюжетлар, яңа алымнар һəм тормышның яңа катламнарын үзлəштерə тора. Ул үзенең 50 яшен тутырган көнне дə яңалык тарафдары, Татарстан художникларының алгы сафында кыю атлап баручы иҗат кешесе буларак күренлый. Аның соңгы, əлегə тəгəллəнмəгəн эшлəреннəн берсе Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев батырлыгына багышланган. Художник атаклы очучы белəн бер фронтта сугышып йөргəн, тик берсе — җирдə, икенчесе — һавада. Үз-үзенə талəпчəн художникны əлегə əсəрнең композициясендə нəрсəдер канəгатьлəндереп җиткерми, шуңа да картина тəмамланмаган килеш тора.

Аның каравы, яшь Ленинга, студент Ленинга багышланган икенче полотно өстендə эшлəү бөтен көчкə бара. Ильичның туган җире Ульяновскида ачылачак юбилей күргəзмəсендə ул əсəр төп урыннарның берсен алып торыр, дип өметлəник.

Туктаусыз иҗат итү белəн бергə, Якупов зур җəмəгать эшлəре дə алып бара. 1951 елдан бирле ул берөзлексез Татарстан художниклар союзының председателе итеп сайланып килə. Соңгы елларда «Зур Идел» күргəзмəсендə күргəзмə комитетын җитəкли. Бирeдə дə эш җитəрлек. Идел буендагы дистəлəрчə шəһəрлəрне йөреп чыгарга, күргəзмəгə кую өчен иң яхшы əсəрлəрне сайлап алырга кирəк. Якупов шулай ук РСФСР художниклар Союзы секретаре, СССР художниклар союзының идарə əгъзасы. Оештыру һəм җəмəгать эшлəре күп вакыт сорый. Иҗат итəргə дə, бу эшлəрне башкарырга да вакыт таба белергə кирəк. Бу эштə аңа тормыш иптəше Рушан ханым зур ярдəм итə. Ул үзе дə художник. Якупов үзенең иҗат планнарын башлап тормыш



*«Серле балдак» исемле әкиятка иллюстрация.*

иптәше белән уртаклаша, яңа әсәрләре хакындагы беренче тәнкыйть фикерен дә аңардан ишетә. Уллары Фәрит тә әтисе эзеннән бара. Ул — Казан сәнгать училищесы укучысы.

РСФСРның халык художнигы, Дәүләт һәм Тукай премияләре лауреаты Харис Якупов үзенең иҗат юбилеен таланты чәчәк аткан чорында җитлеккән художник булып каршылый. Аңа бит әле нибары 50 генә яшь!

**АРКАДИЙ ФАЙНБЕРГ,**
сәнгать фәннәре кандидаты.



*РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ*

*ЕЛЛЫГЫНА*

**Якуб Чанышев,**
запастагы генерал-лейтенант, 1917 елдан КПСС члены.

# ТАТАР ЕГЕТЛӘРЕ ГРАЖДАННАР СУГЫШЫНДА



*Рус шагыйре А. Н. Майковның «Сенокос» дигән шигырен ул әле дә хәтерли, башыннан ахырына чаклы, бер дә төртелмичә, зур пафос белән сөйләп чыга. Чөнки бу шигырьне ул малай чагында, әтисе үлгәч, әнисе һәм туганнары белән, Тукай авылыннан ерак түгел Бабов, Рязапов һәм Сладков исемле алпавытларның болыннарында батрак булып эшләгәндә җырлап йөргән.*

*1908 елда авылдагы русско-татарская школаны тәмамлап имтихан биргәндә, Якубка шул «Сенокос» дигән шигырь туры килгән. Ул аны, печән чапкан чакларын искә төшереп, зур дәрт белән укып биргән һәм «яхшы» билгесе алган. Имтиханда инспектор Якубның сәләтен күргән һәм аңа Стәрлетамак өязе земствосы идарәсенә гариза язарга, стипендия алу һәм интернатта тору шарты белән, Казандагы татарская учительская школага укырга җибәрүне сорарга кушкан. Шулай итеп, Якуб Казанда учительская школада уку бәхетенә ирешә.*

*Казанда укыганда Якуб Чанышев бөек шагыйрь Габдулла Тукай, революционер Хөсәен Ямашев, язучыларыбыз Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафурилар белән таныша.*

*Казан университеты һәм ветеринария институты студентларыннан 1905—1907*



Генерал-лейтенант, гражданнар сугышы ветераны Якуб Чанышев.

*елгы революция турында мшетә, китапханәләргә йөреп, газета-журналлар укый, политик аң-белемен арттыра.*

*1912 елда, учительская школаны тәмамлап, Стәрлетамак өязе Кирманай авылында укытучы булып эшкә тотына. Ләкин озак эшли алмый, 1913 елда патша хөкүмәте аны солдатка ала һәм Варшава 3 нче гвардия дивизиясенә озата. Шул елдан башлап Якуб ага Чанышев 50 елдан артык армиядә хезмәт итә.*

*Иске армиядә ул, артиллерия фейрверкере (сержанты) буларак, беренче империалистик сугышның әчесен-төчесен татый, фронтларның иң кызган җирләрендә — Львов һәм Перемышль тирәләрендәге сугышларда катнаша, сугышның кемнәр өчен барганын, солдат каны кемнәр өчен коелганын күрә. Петроградтан фронтка җибәрелгән Путилов һәм Уралдан Мотовилихин пушка заводларының революцион эшчеләре аркылы большевизм хәрәкәте белән таныша.*

*1917 елгы февраль революциясен Якуб ага Чанышев Казанда прапорщиклар әзерли торган школада укыганда каршылый, революциянең беренче көненнән ук (1917 ел, 15 мартта) ленинчыл большевиклар партиясенә керә һәм партиянең Казан комитеты җитәкчелегендә 240 һәм 164 нче полк солдатларын Октябрь революциясенә әзерли. Революцион штаб члены буларак, Октябрь коралль күтәрелешенә актив катнаша, Ежов, Скачков белән бергә Казан хәрби округы комиссарлар советы члены булып эшли. Яшь Совет республикасына каршы корал күтәргән эчке һәм тышкы дошманнарга каршы гражданнар сугышы барган чорда — 1919—1923 елларда — Якуб ага Чанышев батыр комисарларның берсе була. Беренче татар укчы бригадасының артиллерия начальнигы, соңрак комиссары буларак, Оренбург тирәсендә контрреволюцион атаман Дутовны җиңеп, Урта Азиягә юл ачуда, Төркстандагы басмачыларны бетерүдә катнаша. Бу батырлыклары өчен ул, беренчеләрдән буларак, хөкүмәт тарафыннан «Кызыл байрак» ордены белән бүләкләнә. Бу чорда ул илебезнең зур җитәкчеләре В. Куйбышев һәм М. Фрунзелар белән бергә эшли.*

*1925 елда М. Фрунзе исемендәге хәрби академиядә укып кайтканнан соң Якуб ага Чанышев 1932 елга чаклы Казан дивизиясенең командиры һәм комиссары була, партия өлкә комитеты члены һәм Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты члены буларак хезмәт иясләре арасында тирән мәгънәле партия-политик эшләре алып бара, язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, артистлар белән аралаша, кызылармеецларны алар белән очраштыра.*



Сулдан уңга: Советлар Союзы маршаллары С. К. Тимошенко, К. Е. Ворошилов, С. М. Буденный, якташыбыз Якуб Чанышев һәм карт большевик С. И. Аралов.

*Бөек Ватан сугышы елларында Якуб ага Чанышевның хәрби таланты тагы да киң ачыла. Ул, Сәмарканд шәһәрендә төзелгән 103 нче укчы дивизия командиры булarак, немец фашистларына каршы Харьков янындагы каты сугышларда катнаша, Сталинград янындагы сугышларда каты яралана. Сәламәтләнгәч, 57 нче армия командующие генерал Толбухинның ярдәмчесе була. Аннары, 1943 елда, 96 нчы укчы корпус командиры итеп билгеләнә һәм шул корпус белән, фашистларны тар-мар итә барып, Брест крепостен азат итә. Аның корпусы «96 нчы Кызыл Байраклы Брест корпусы» исемен ала, күп сугышлар белән Варшава һәм Германиянең күп шәһәрләрен азат иткәннән соң, 1945 елның апрелендә язгы ташу вакытында мәшһүр Одер елгасын кичеп чыга да Берлин шәһәрен штурмлауда катнаша, беренчеләрдән Англия-Америка гаскәрләре белән очраша.*

*Якуб аганың күкрәгендә утыздан артык орден һәм медаль ялтырый. Алар арасында СССР хөкүмәте биргән Ленин, Кызыл Байрак орденнары, Польша хөкүмәте биргән 4 орден һәм АКШ хөкүмәтенең иң югары дәрәҗәдәге ордены бар.*

*Ватан сугышы беткәннән соң, Якуб ага озак еллар Мәскәүдә Генеральный штабның югары хәрби академиясендә курслар начальнигы булып эшли, илебезнең Совет Армиясе өчен меңнән артык генерал һәм полковниклар тәрбияләп чыгара һәм 1958 елда отставкага чыга.*

*Якуб ага Чанышев әле һаман да тынгысыз, яшьләр кебек җитез атлап йөри, күзе аның һәрвакыт елмаюлы, күзләре үткер. Ул халык алдында, яшьләр алдында докладлар белән чыга, лекцияләр һәм истәлекләр сөйли. Якуб ага Совет—Польша дуслыгы җәмгыяте президиумы, Совет ветераннары комитеты члены, партиянең Мәскәү комитетында штаттан тыш инструктор.*

Р. ГОМӘРЕВ,
персональ пенсионер.

Элек заманда барлык армияләр изүчеләргә, патшаларга, корольләргә хезмәт иттеләр. Армия ярдәмендә алар хезмәт ияләрен кол итеп тоттылар, Азия һәм Африка илләрен яулап алдылар, алардагы байлыкларны таладылар.

Кешелек дөньясы тарихында беренче тапкыр Бөек Октябрь социалистик революциясе нәтиҗәсендә яңа тип армия — халыкның үз армиясе — Кызыл Армия барлыкка килде. Ул халык казанышларын яклау, яшь Совет республикасын эчке һәм тышкы дошманнардан саклау өчен оештырылды.

Гражданнар сугышы чорында биш миллионлы Кызыл Армияне оештыручы, тәрбияләүче һәм аны җитәкләүче Коммунистлар партиясе, аның юлбашчысы В. И. Ленин булды.

Бөек Октябрь революциясе җиңеп чыкканнан соң, В. И. Ленин һәм партия социалистик Ватанны саклау турында лозунг ташладылар һәм бу эш күп милләтле Советлар Россиясенең һәр гражданы өчен изге бурыч булып әверелде.

Керенский җитәкчелегендә властьны үзләренә яулап алырга маташкан эчке контрреволюцион көчләр Гатчино янындагы сугышта тар-мар ителделәр һәм кайберләре чит илләргә, кайберләре ак казаклар хакимлек иткән Дон буена хурлыклы төстә качтылар. Шуннан алар хыянәтчел төстә көнбатыш һәм Америка империалистларын ярдәмгә чакырдылар.

Үндүрт империалистик дәүләт аларга ярдәмгә ашыкты, алар яшь Советлар республикасына гражданнар сугышын көчләп тактылар. Бу сугыш биш елга якын дәвам итте.

Яшь Советлар Россиясе утлы боҗра эчендә калды. Партия һәм бөек Ленин халыкларны интервентлар белән көрәшкә чакырдылар: «Барысы да фронт өчен!», «Барысы да интервентларны һәм ак гвардияне тар-мар итү өчен!», «Пролетарийлар, атларга!», «Коммунистлар һәм комсомоллар, фронтка!», «Җиңү яки үлем!».

Үзәктә власть Хезмәт һәм Оборона Советына тупланды. Аның башлыгы — В. И. Ленин. Бөтен ил коралллы лагерьга әверелде.

Татарстан егетләре, партия һәм Ленин чакыруына җавап итеп, үзләре теләп йөзәрләп-йөзәрләп Кызыл Армиягә язылдылар, Казанда, Уфада, Екатеринбургта, Троицкида, Пензада, Самарада, Петроградта һәм Мәскәүдә милли частьлар оештырырга керештеләр. Казанда бик кыска вакыт эчендә Аерым мөселман Социалистик полкы оешты. Аның командиры — бокс буенча РСФСР чемпионы Нур Алимов иде. Бер үк вакытта большевик Гали Касимов командалыгында Коммунистик батальон, Сафа Гобәйдуллин җитәкчелегендә Татар-башкорт батальоны, Карл Маркс исемендәге Аерым милли батальон (элеккеге әсир төшкәннәрдән), Елга флотилиясе батальоны (командиры Л. Берлин) оешты. Мәскәүдән Һади Маликов командасы астында Мөселман комиссариаты оештырган Татар-башкорт батальоны килеп төште. Оборона Халык Комиссариаты каршындагы Мөселман хәрби коллегиясе председателе Мулланур Вахитов милли частьлар оештыру буенча зур эш алып барды.

Кызыл Армиянең талантлы полководецы ленинчы-большевик М. В. Фрунзе болай дип язды: «Милли частьләр безнең өчен буш мавыгу, союздаш аерым халыкларның милли хисләрен канәгатьләндерү генә түгел. Бу — безнең дәүләтебезнең бөтен характерыннан килеп чыккан һәм безнең социалистик политиканың төп принципларын чагылдыра торган җитди чара. Армияне без башкача төзи алмыйбыз». (Фрунзе, «Сайланма әсәрләр».)

Бу милли частьлар партия һәм Кызыл Армия командованиесе ышанычын намус белән акладылар. Татар егетләре Иделдә ак чехлар белән, Оренбург янында һәм Уралда, Петроград янында һәм Украинада ак казаклар белән каһарманнарча сугыштылар. Себердән Иделгә таба англо-америка империалистлары тарафыннан кораллландырылган һәм киендерелгән өч йөз меңле Колчак армиясе һөҗүм итеп килгән чагында, ил өстенә тагын да дәһшәтлерәк куркыныч туды. Колчак белән Деникин, Иделдә үзара кушылырга план корып, җәен инде Мәскәүдә булырга өметләнделәр.

Менә шундый шартларда Казанда тагы да зуррак хәрби берләшмә — Беренче аерым Идел буе татар укчы бригадасы барлыкка килде. Бу бригада Самарадан Оренбург, Казагыстанның көньяк далалары аша Бохарага һәм Көньяк Кыргызстанга кадәр

данлы сугышчан юл үтте, гражданнар сугышы тарихына үзе турында героик сәхифәләр язды.

Бригаданы төзү эшенә партиянең Казан губерна комитеты, Көнчыгыш фронтның Көньяк группасы командующие М. В. Фрунзе актив катнашты.

Бригаданың командиры Йосыф Ибраһимов, штаб начальнигы элеккеге гвардия капитаны, литва татары А. А. Тальковский, хәрби комиссары язучы Шамил Усманов (аны соңрак чекист Бәкер Белоусов, ә Фәрганәдә бу юлларның авторы алыштырды) иде. Полк командирлары итеп Беренче дөнья сугышында тәҗрибә туплаган большевиклар-солдатлар, унтер-офицерлар, кече офицерлар билгеләнде. Полкларның командирлары һәм комиссарлары Шәйхетдинов, Унанов, Хисиев, Әсәнов, Солтанов, Садыйков, Алимбеков, Мостафин, Борнашев, Мәүлүтов, Касимов һ. б. лар булдылар.

Фатих Мөхәммәдьяров (соңыннан медицина профессоры, Татарстанның сәламәтлек саклау халык комиссары) фронтларда хәрби госпитальләр оештырды, моның өчен Казаннан минә дигән врачлар һәм шәфкать туташлары чакырды.

Шундый зур берләшмәнең ул вакыттагы шартларда, корал да, техника да, киемсалым да, азык-төлек тә җитешмәгән бер чорда чагыштырмача кыска вакытта — өч ай вакыт эчендә оешып бетүе Республиканың Реввоенсоветы һәм коммунистлар партиясе ярдәме нәтиҗәсендә генә мөмкин булды.

Менә шул вакытларда Реввоенсоветның Көнчыгыш фронты командующие С. С. Каменевка (Сембер шәһәре) җибәргән телеграммасы:

«Мәскәү. 1919 ел, 6 май. Аерым Идел буе татар (мөселман) бригадасын һәм ярдәмче частьләрен беренче чиратта оештырырга боерабыз: бригаданың идарәсен һәм Беренче полкны — Казанда, Икенче полкны — Самарада, Өченче полкны Алатырьда (Сембер губ.). Аны оператив тәртиптә оештырырга. Республиканың реввоенсовет Председателе».

Шул ук көнне Көнчыгыш фронты Командующие исеменә икенче телеграмма да килеп төшә:

«Татбригаданы оештыру, киң мөселман массаларының симпатиясе Совет власте ягына икеләнүсез күчүе сәбәпле, хәзер политик яктан гаять тә әһәмиятле эш булып тора. Шуңа күрә республика РВСы Фронт РВСына Татбригаданы һәм Запас батальонны бик тиз оештыруга һәр яклап ярдәм күрсәтергә тәкъдим итә. Бу эшкә фронт РВСына буйсынган көчләрне җәлеп итәргә»...

1919 елның 1 июнендә без, Казан белән саубуллашып, пароходларга төялдек һәм Көнчыгыш фронтның Көньяк группасы командующие М. В. Фрунзе карамагына — Самарага юл алдык.

Күптән түгел генә Колчак армиясенең көньяк канатын тар-мар иткән талантлы полководец М. В. Фрунзе бик мөлаем кеше икән. Ул безне бик җылы каршы алды һәм шунда ук өйрәнүләр башларга, Оренбургка китәргә әзерләнергә приказ бирде. В. В. Куйбышев Шамил Усманов белән электән таныш булып чыкты, ул бригаданың политбүлеген һәм полкларда партия оешмаларын төзергә зур ярдәм күрсәтте.

М. В. Фрунзеның Татар бригадасына зур әһәмият бирүе турында әйткән идек инде. Моны аның 15 июльдә фронт командованиесе белән телефон аша сөйләшүе тагын бер кат раслый:

«Павел Павлович, (П. П. Лебедев), мин бары тик берсекөнгә генә юлга чыга алам, чөнки, беренчедән, пароход юк, икенчедән, Беренче армия операциясен тәэмин итү буенча минем боерыкларымның тормышка ашырылуын үзем күзәтәсем килә. Иртәгә Татар бригадасына осмотр үткәрәм. Патроннар һәм винтовкалар җибәрегез. Кайчан юлга чыгуым турында хәбәр итәрмен».

М. В. Фрунзе 17 июльдә бригада частьләренә смотр үткәрде һәм бик канәгать булды. Митингта М. В. Фрунзе үзе һәм В. В. Куйбышев чыгыш ясадылар. Митингтан һәм парадтан соң, М. В. Фрунзе белән В. В. Куйбышев бригаданың командирларын, политработникларын аңгәмәгә чакырдылар, безне Оренбург янындагы хәрби хәл белән, Беренче армиянең ак казакларга каршы алып барган киеренке көрәше белән таныштырдылар. Без сынатмаска, үзебезнең Ватан һәм революция алдындагы бурычыбызны намус белән үтәргә сүз бирдек.

1919 елның 19 июлендә бригада фронтка чыгып китте.

Илебез һаман әле авыр хәл кичерә иде: Харьков, Донбасс, Царицын Деникин кулында, Юденич Псковны алган, Петроград куркыныч астында, Колчак Уралда зур каршылык күрсәтә. Төркстан гаскәрләре дүрт фронтта кан койгыч сугышлар алып баралар.

Ленин М. В. Фрунзедан Оренбург тирәсендә һәм Уралда ак казакларны тизрәк тар-мар итүне, Төркстанга бәреп керүне һәм Совет Төркстаны халыкларына ярдәм күрсәтүне таләп итте.

11 августта Көньяк группасы гаскәрләре (49 нчы укчы дивизия, 24 нче укчы дивизия, 20 нче укчы дивизия, 3 нче кавалерия дивизиясе һәм Беренче татар бригадасы) Урал елгасының уң як ярын аклардан чистартып, ак казаклар белән каты сугыштан соң, елганы кичеп чыктылар һәм Актүбә, Челкар юнәлешендә хәлиткеч һөҗүмне дәвам иттерделәр.

Безнең бригада, 10 нчы кавалерия полкы белән берлектә, Урал елгасын кичкәннән соң, зур казак станицаларыннан: Краснохолмскидан, Городищенскидан һәм Кордаиловскидан ак казакларны куып чыгарды. Казаклар безгә каршы биш-алты мәртәбә контратакага күтәрелделәр. Ләкин безнең сугышчылар каушап калмады, командирлар алгы сафта торып үрнәк күрсәтте. Өченче һәм беренче полкларның пулеметчылары, артиллеристлары аеруча батыр сугыштылар. Беренче полк командиры Шәйхетдинов һәм Өченче полк командиры Мәүлүтов масса төсендәге кавалерия атакасы вакытында үзләрен оста оештыручы итеп таныттылар. Коммунистлар, комиссарлар һәм политруклар, башкаларга үрнәк күрсәтеп, курку белмичә сугыштылар. Ак-Болак станциясе һәм Илецкая защита поселогы өчен барган сугышлар аеруча кан коюлы булды. Безгә М. В. Фрунзенең конкрет күрсәтмәләре ярдәм итте. Без, шул күрсәтмәләр нигезендә, дошманның зур кавалерия көчләре белән сугышканда, полкларда удар группалар булдырдык, флангларны зур көчләр белән тәэмин иттек, казакларны мылтыклардан залп, пулемет һәм артиллерия уты белән каршыладык. М. В. Фрунзе штабларны дошманның кинәт ясаган һөҗүмennән саклау кирәклеген кисәтте, чөнки штаб басып алынса, сугыш белән идарә итү дә бетә, югалтулар да күп булачак иде. Нәкъ әнә шундый хәл Лбищенск станицасында безнең белән күрше сугышкан легендар В. И. Чапаев белән булды.

Каты сугышлардан соң, безнең бригада, өченче кавалерия дивизиясе сугышчылары белән берлектә, Көньяк Казагыстанның зур шәһәре булган Тимер каласын, Уел торак пунктын алды һәм Мугаджар станциясендә Төркстанга юл ачылды. Бу тарихи әһәмиятле вакыйга уңае белән зур митинг үткәрелде. Митингтан соң, Казан һәм Актүбә артистлары зур концерт бирделәр.

Берникадәр ял иткәннән соң, безнең бригада сугыш кирәк-яраклары һәм сугышчылар белән тулыландырылды, аннары, М. В. Фрунзе боерыгы буенча, Беренче Армиянең иң яхшы частьләре белән берлектә, Фәргана һәм Сәмарканд якларына җибәрелде.

Бу турыда архив документларына мөрәҗәгать итик.

«Кызыл Армиянең талантлы полководецы Көнчыгыш фронтның Көньяк группасы һәм Төркстан фронты командующие М. В. Фрунзе командалыгында Татар бригадасы данлыклы юл үтте, Колчакның Көньяк армиясенә, Оренбург һәм Урал ак казакларына, көньяк-көнбатыш Казагстанда «Олаш-ордачы»ларга, ә аннан соң Фәрганәдә һәм Бохарада басмачыларга каршы сугышларга катнашты»[1].

1919 елда ук РКП(б) Үзәк Комитеты Төркстан комиссиясенең басмачыларны тар-мар итү һәм җирле партия оешмаларына басмачыларның, реакцион руханиларның провокацияләрен фаш итүдә, контрреволюция белән көрәштә ярдәм итү өчен Фәрганәгә эре мөселман гаскәри берләшмәсен күчерү турында ясаган тәкъдимен яхшы дип тапты. Кызыл Армиянең Беренче Аерым татар бригадасы нәкъ әнә шундый гаскәри берләшмә иде.

1919 елның 20 декабрендә Фәрганәгә Татар бригадасы төялгән эшелоннар килеп туктады. Бригаданың политбүлеге Андижанга урнашты.

---

[1] Үзбәкстан ССРның Үзәк Дәүләт архивы. 1313 фонд, 1 тасвирлама, 46 эш, 6 бит.

Төркстан республикасы партия оешмасы һәм хөкүмәте үзәктән читтә, бик авыр шартларда ак гвардиячеләргә, Англия интервентларына һәм басмачыларга каршы дүрт фронтта көрәш алып бара иде. Татар бригадасы алдына ике бурыч куелды: хәрби көч белән җирле халыкка басмачыларны тар-мар итүдә ярдәм күрсәтү һәм ленинчыл милли политиканы практик яктан тормышка ашыру, урыннарда Совет властен ныгыту, төрле милләт хезмәт ияләре арасында дуслык урнаштыру. Фәргânә өлкәсенең шәһәрләрендә һәм кышлакларында дәһканнар, бигрәк тә хатын-кызлар басмачыларның террорыннан һәм көчләвеннән бик нык җәфа чигәләр иде. Басмачылар хакимлек иткән кышлакларда хатын-кыз бүлекләренә барган өчен, пәрәнҗәләрен салган өчен хатын-кызларның башларын кисәләр иде.



Якуб Чанышев 1920 елда Фәрганәдә.

В. И. Ленин Төркстандагы шартларны даими күзәтеп торды. Һәм ул, Төркстан юлы ачылу белән, хөкүмәт һәм партия Үзәк комитетының, Төркстан халыклары арасында дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен, махсус комиссиясен (М. В. Фрунзе, В. В. Куйбышев, Я. Рудзутак, Любимов, Голощекин һәм Элиава) җибәрде.

Без Төркстанга буш кул белән түгел, В. И. Ленинның Совет Төркстаны коммунистларына мөрәҗәгать хаты белән килдек. Менә ул хат:

«Төркстандагы коммунист иптәшләргә.

Иптәшләр! Халык Комиссарлары Советы һәм Оборона Советы председателе сыйфатында түгел, партия члены буларак мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез.

Россия Социалистик Федератив Республикасы өчен хәзер Төркстан халыклары белән дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыру, арттырмыйча әйтергә мөмкин, гигант, бөтендөнья — тарихи әһәмияткә ия.

Бөтен Азия өчен, дөньядагы барлык колонияләр өчен, меңнәрчә, миллионнарча кешеләр өчен эшче-крестьян Советы республикасының затыйфь, моңа кадәр изелеп килгән халыкларга мөнәсәбәте практик әһәмияткә ия булачак.

Бу мәсьәләгә аеруча игътибар юнәлтүегезне — Төркстан халыкларына карата мисалда, иптәшләрчә мөнәсәбәт урнаштыру өчен бөтен көчне салуыгызны,— бөтендөнья империализмы белән, аның башында торган британ империализмы белән көрәшү өчен великорус империализмының барлык эзләрен юк итүгә юнәлдерелгән эчкерсез теләгебезне эш белән исбатлавыгызны,— безнең Төркстан комиссиясенә

зур ышаныч белән каравыгызны һәм аның директиваларын катгый үтәвегезне — ВЦИК тарафыннан аңа нәкъ шул рухта эш итү йөкләтелгән — үтенеп сорыйм.

Әгәр дә сез бу хатка каршы миңа җавап язсагыз, бу эшкә карата сезнең мөнәсәбәтегезне хәбәр итсәгез, мин бик шат булыр идем.

Коммунистларча сәлам белән —

В. Ульянов (Ленин)».

Бу тарихи хат Ташкентта партиянең Край Үзәк Комитеты, Мөселман бюросы Үзәк Комитеты һәм интернационаллар Үзәк Комитетының (Өч Үзәк Комитет!) берләштерелгән утырышында һәм 1920 елның 20—27 январенда булып үткән Төркстан коммунистлар партиясенең край конференциясендә (мин анда делегат буларак катнашкан идем) укып тикшерелде. Конференция делегатлары В. И. Ленинга, бу хат белән тулысынча риза булуларын әйтеп, элек эшләнгән ялгышларны төзәтергә сүз биреп, җавап җибәрделәр.

М. В. Фрунзе, кызылармеецлардан һәм командирлардан җирле халыкларга карата туганнарча мөнәсәбәт таләп итеп, һәрберебезне барлык эшләребез белән җирле халыкта Кызыл Армиягә мәхәббәт һәм ышаныч тудырырга чакырып, күп кенә приказлар игълан итте. «Басмачыларны тәмам юк итәргә вакыт,— диелгән иде приказларның берсендә,— Фәргана өлкәсеннән барлык хәшәрәтләрне тимер себерке белән себереп түгәргә һәм халыкка тыныч хезмәт белән көн күрергә вакыт».

М. В. Фрунзе һәм Төркстан комиссиясе күрсәтмәләре нигезендә: бригада частьләре Андижан, Ош, Җәләл-Абад, Наманган шәһәрләрендәге зур мамык эшкәртү заводларын, бу шәһәрләр тирәсендәге уннарча кышлакларны шефка алды. «Андижан — Ош хәрби районы барлыкка килде. Бригаданың штабы һәм политбүлеге Андижанда урнашты. Гарнизоннар халык тыгыз урнашкан Хакул-Абад, Тода, Грунч-Мазар, Курган-Түпә, Карасу, Гелчә һ. б. торак пунктларын биләде. Ревкомнар, азык-төлек, медицина пунктлары да гарнизоннар белән бергә иде. Җирле халык тынычланды, ул безнең гаскәрләрдә үзен саклаучыларны күрде, безгә тагы да киң колач белән ярдәм итәргә кереште.

Фәрганәгә килүебезнең беренче көненнән үк, җирле халык арасында, бигрәк тә яшьләр арасында без бик күп дусларыбызны таптык. Аларның күбесе инструктор-тәрҗемәче яки агитатор итеп политбүлек штатына кертелде. Андижан өязенең ревком председателе Рәхим Бабаев, Хамракул Турсункулов, Даман Ахунбабаев, Шаурук Халбатыров, А. Икрамов һәм башка бик күпләр безнең һәр эшебездә зур ярдәм күрсәттеләр. Безнең кызылармеецлар, командирлар һәм политработниклар, җирле халык телен бик тиз үзләштереп, ленинчыл милли политиканың агитаторлары, пропагандистлары булып әверелделәр. Бригададагы кавалерия частьләрендә оешкан отрядлар, милиция группалары, иң ерак почмакларга барып, басмачыларны кудылар. Ярлылар һәм яшьләр безгә босмачыларның урнашкан урыннарын табарга булышалар иде. Курбашылардан Мадәменбәк, Курширмәт, Кол-Хаҗи, Мөхетдин аеруча явыз һәм рәхимсез булып, аларга каршы бригада сугышчылары дүрт елга якын көрәш алып бардылар. Ләкин алар халыктан аерылган, асылда юл басучы бандитлар хәлендә иде. Курбашыларның кайберләре, үз хәлләрен аңлап, Совет власте ягына чыктылар. Ә Курширмәт, Аман-Палван, Кол-Хаҗи отрядларын хәрби көч белән тар-мар итәргә туры килде. Иң явыз бандит Мөхетдин курбашы, судтан соң, Ош шәһәрендә барабан тавышы астында халык алдында атылды. Аның аркасында бик күп җәфа чиккән җирле халыкның шатлыклы авазлары мылтык тавышын да, барабан тавышын да күмеп китте.

Татар бригадасының сугышчылары, командирлары канэчкеч басмачылар белән сугышларда зур батырлыклар күрсәттеләр. Бик күбәүләр үзбәк һәм кыргыз халыкларының бәхетле киләчәге өчен башларын салды. Андижан, Ош, Җәләл-Абад, Курган-түпә, Карасу һ. б. җирләрдәге туганнар каберлегеп Үзбәкстан һәм Кыргызстан яшьләре хәзер чәчәкләр белән бизиләр, алар хөрмәтенә һәйкәлләр куялар.

Бригадага бер яшь тулу көнендә, 1920 елның мартында. Төркстан Үзәк Башкарма Комитеты, Фәрганә, Сәмарканд, Коканд, Андижан, Наманган ревкомнары «Рево-

люцион Кәнчыгышның яңа тормышы һәм бөтендөнья пролетариатының бәхете өчен көрәшүче» бригада командованиесе исеменә котлаулар җибәрделәр.

Менә Төркстан фронты Реввоенсоветы һәм Политик идарәсенең В. В. Куйбышев кул куйган телеграммасы:

«Беренче татар бригадасының данлы кызыл сугышчыларына.

Безнең данлыклы частьләребезнең туюы көнендә Сезгә тантаналы котлау сәламебезне җибәрәбез. Казанда туып, Самарада ныгып, сезнең Бригада үзенең героик хәрәкәтләре белән Кызыл Төркстанны Совет Россиясе белән бәйләде, бу ике илнең омтылышын буып торган каһәр төшкән акгвардия «бөке»сен юк итте. Татищево станицасы янында Урал елгасы дулкыннары сезнең куркусызлыгыгыз, батырлыгыгыз турында күп нәрсә сөйли алыр иде. Сез анда, саперларыгыз корган күпер аша тиз агымлы Уралны кичеп, дошманга каты удар ясадыгыз. Сезнең әшегез, Татар бригадасының кызылармеецлары Фәрганәдә дә шундый ук данлыклы. Сез биредә Фәрганә халкына әчкерсез, иптәшләрчә мөнәсәбәттә торасыз, үзегезнең батырлыгыгыз белән басмачылар хәрәкәтен бастырдыгыз. Сезгә дан, каһарман сугышчылар! Сезнең туу көнегездә Төркстан фронты Политик Идарәсе эшче-крестьян Совет Россиясе исеменнән чын күңелдән рәхмәт белдерә. Яшәсен Аерым Татар бригадасының данлы кызылармеецлары!

Реввоенсовет члены һәм фронты Политбүлеге мөдире —
В. В. Куйбышев».

Беренче Татар бригадасының данлы полклары борынгы Бохара халыкларын соңгы көнчыгыш деспоты — Сәет-Алим-Хан изүеннән коткару эшенә дә актив катнаштылар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, Төркстан Совет республикасы оешкач, Бохара әмирлеге басмачыларның үзәгенә, ак гвардия һәм Англия агентурасының оясына әверелде. Әмир басмачыларының башлыкларына — курбашыларга рухи яктан да, корал белән дә ярдәм күрсәтте. Бохара әмире, революцион Урал эшчеләре тарафыннан атылган Николай II протектораты урынына, Англия империалистлары белән тыгыз элемтәгә керде. Ә империалистлар Бохараны гына түгел, бөтен Төркстанны кулга төшерергә теләделәр.

Әмирнең эчке политикасы да гаять реакцион иде. Үзбәк, төркмән, таҗик милләтләреннән торган Бохара халкы назирлар һәм бәкләр изүеннән җәфа чикте. Ярлылар уннарча төр салым түләделәр, ә түли алмасалар, аларның соңгы халатына, юрганына кадәр алып чыгалар, хәтта балаларын тартып алалар, кызларын хан гаремына тапшыралар иде. Әгәр берәрсе әмир политикасына каршы аз гына ризасызлык белдерсә, шунда ук зинданга ябалар, казыкка утырталар, таяк һәм камчы белән кыйныйлар, «үлем манарасы»ннан ташлыйлар. Халыктан талап алынган акчага әмир һәм аның бәкләре, байлар менә дигән сарайлар салдыралар, бакчалар үстерәләр, гаремнар тоталар, корал сатып алалар, кышлакларда, бигрәк тә көнчыгыш Бохарада (таулы Таҗикстанда) әледән-әле кузгалып торган күтәрелешләрне бастыру өчен гаскәр асрыйлар иде.

Сәет-Алим-Хан әмирнең гаскәре 35 мең кешедән торган регуляр частьләрдән гыйбарәт булып, анда 15 яшьтән алып 70 яшькә кадәр ирләр хезмәт итә иде. Әмирнең төп көчләре — артиллерия һәм шәхси гвардия биш метр калынлыкта, 10 метр биеклектәге 50 километр таш койма белән әйләндереп алынган крепость эченә урнашкан иде.

Борынгы Бохара халыклары, Бөек Октябрь революциясе китергән азатлык турында ишеткәч, әмир коллыгыннан котылырга теләп, канэчкеч бәкләргә һәм палачларга каршы баш күтәрделәр. 1920 елның 28 августында Төркстан коммунистлары җитәкчелегендә Бохара хезмәт ияләре Чарджуй бәген тар-мар иттеләр, үзләренең ревкомын оештырып, Иске Бохарага һөҗүм башладылар. Ләкин бу отрядларның крепостьны штурмлау өчен көчләре җитәрлек түгел иде һәм алар Төркстан фронты командующиена ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеләр. М. В. Фрунзе иң яхшы частьләрдән бик тиз удар группа оештырды. Бу группага Татар бригадасының да Беренче һәм Өченче полклары кертелде. Безнең гаскәрләр составында 7 мең җәяүле, 2 мең 5 йөз атлы сугышчы, 35 җиңел, 5 авыр орудие, 5 бронепоезд һәм 11 самолет иде.

Үзенең тарихи оператив приказында М. В. Фрунзе һәркемгә аңлаешлы итеп болай дип язды:

«Без көнчыгыш деспоты Сәет-Алим-Хан хакимлеген юк итүдә тугандаш революцион Бохара халкына ярдәм итәргә үзебезгә йөкләмә алдык. Крепостьны камап алырга һәм 1, 2, 3, 4, 5 капкаларны җимереп крепостька бәреп керергә, эмирнең сараен, аның үзен һәм барлык сарай әһелләрен яулап алырга, каршы килүчеләрне юк итәргә, бирелүчеләрне исән калдырырга, Бохара халкын коллыктан һәм изелүдән коткарырга приказ бирәм» [1].

Өч гаскәри группа һәм Аму-Дарья елга флотилиясе оештырылды. Алар, үзара ярдәмләшеп, командующий приказын мөнә диган итеп үтәделәр. Төп оператив группа — иң күп санлысы һәм техник яктан бик нык тәэмин ителгәне — Көнчыгыш (Карши) группасы иде. Аның составына Хөсәен Мәүлүтов командалыгындагы Татар бригадасы полклары, В. Т. Обухов (хәзер генерал-полковник, Мәскәүдә яши) командалыгындагы кавалерия группасы, 28 нче бронепоезд һәм 53 нче броня отряды кертелде. Безнең гаскәрләр 1 сентябрьдә Карши капкасын җимерделәр һәм крепость эченә бәреп керделәр.

Гадәттә дини фанатизмны католицизм белән, коточкыч инквизиторлар белән бәйлиләр. Бохара муллаларының, ишаннарының, аларның мөрит һәм дәрвишләренең фанатизмы да канэчкеч иезуитлар фанатизмыннан бер дә ким түгел иде. Моны атаклы таҗик язучысы Садретдин Айни үзенең романнарында бик дөрес сурәтли. Хәер, ул үзе дә әмир ялчылары тарафыннан аркасына йөз таяк алган кеше.

Бохара руханилары, бердәнбер алла хакын якларга чакырып, безнең сугышчыларны да үз якларына аударырга тырыштылар. Шул ук вакытта алар түбә кыекларыннан ут сиптерделәр. Безнең кызылармеецлар руханиларның бу хыянәтчел хәйләләрен бик тиз сизделәр һәм барысын бергә җыеп мәчет эченә ябып бикләп куйдылар.

Бохараны азат итү өчен сугышларда Татар полкларыннан йөзләрчә яшь сугышчылар һәм командирлар һәлак булды, алар беренче булып капкадан бәреп керделәр, беренче булып әмир сараена барып җиттеләр. Ләкин әмир үзенең гаскәрләрен, мал-мөлкәтен, хатыннарын ташлап, хурлыклы төстә Әфганстанга шылган иде.

М. В. Фрунзе В. И. Ленинга түбәндәге телеграмманы җибәрде: «Иске Бохара крепосте бүген кызыл бохаралылар һәм безнең частьләрнең ярдәм көче белән алынды. Бохара реакциясе һәм карагруһының соңгы үзәге юк ителде. Регистан өстендә дөнья революциясенең җиңүчән Кызыл байрагы җилферди!

Сәмарканд. 2 сентябрь. Фрунзе».

---

[1] Фрунзе, Сайланма әсәрләр, 103—110 битләр.

# ТӘРҖЕМӘ ПРАКТИКАСЫНДА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ БЕР УҢЫШ

Әйләнгечтән юл туры ди. Татарча язылып та, русча басылган (бер генә дә түгел, ике тапкыр басылган) «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» дигән ике кисәкле роман, ниһаять, үз телебездә дөнья күрде[1]. Әйе. Халкыбызның икътисади һәм мәдәни тормышын күп яктан, тирәнтен белгән Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗанинең бу китабы әдәбият хәзинәбезгә әнә шулай, гадәти булмаганрак юл белән әйләнеп кайтты. Аның һичшиксез уңай әдәби әһәмиятен тиешенчә бәяләп, китап шүрлегендәге үз урынына куюны әдипләребезгә калдырып, безне турыдан-туры кызыксындырган мәсьәләгә килик.

Әдәбият булгач әдәбият инде ул: аның идеясен, сюжетын һәм әдәби-стилистик алымнарын теленнән, сөйләменнән аерып карап булмый. һәм әсәргә куела торган төп таләпләр аның теленә-сөйләменә дә шул ук дәрәҗәдә карый. Бу очракта ул таләпләрнең берсе — сәнгатьчәлек, ягъни чын татарча, нәфис, көчле яңгырау таләбе күздә тотыла. Бер телдәге информацияне икенче телгә күчереп аңлату — барлык тәрҗемәләрнең нигезендә яткан бу эш — матур әдәбият тәрҗемәсендә төп урынны тота алмый. Матур әдәбиятның бурычы укучыларга белем-мәгълүмат бирү генә түгел, аның өчен фәнни китаплар бар.

Тәрҗемәчелекнең билгеле бер баскычында тәрҗемәнең аңлаешлылык мәсьәләсе төп урынны тотмагандыр дип әйтә алмыйбыз, ләкин бүгенгә көн өчен инде ул — артта калган, үтелгән баскыч. Безнең алда торган бурычлар: юморны юмор белән, сатираны сатира стиле белән, көлдергеч фразаны көлдергеч итеп, җылата торганын күздән яшь чыгарырлык итеп тәрҗемәләү. Кыскасы, үзебезнең бай телебез халык авызында һәм каләм осталары кулында ничек матур, көчле яңгыраса, тәрҗемәдә дә шулай яңгырарга тиеш! Телнең көче зур. Үтергән дә — тел, тергезгән дә — тел, ди халык.

Алдыбызда ята торган бу татарча роман өч төрле «материал»дан эшләнгән: бер (төп) өлеше — тәрҗемә, бераз өлеше — үз вакытында татарча басылган оригинал өзекләре, өченчесе — прошение кебек документлар. Шулай булуга да карамастан, әсәр стиль, татарча яңгыраш ягыннан бер бөтен булып кабул ителә. Шушы хакта алдан белеп, махсус кызыксынып укыганда да, тәрҗемә өлеш белән оригинал өлешләрне бер-берсеннән аерып булмый. Тәрҗемәчеләрнең икәү булуына да карамастан, әсәр башыннан ахырынача бер төсле, чын татарча яңгырый. Бу уңыш, әлбәттә, тәрҗемәче алдында торган сорауның нинди булуына да бераз бәйле. Тәрҗемәче, гадәттә, бу фикерне ничегрәк татарча әйтергә-бирергә икән дигән сорау алдында кала. Бу очракта исә, тәрҗемәчеләр автор бу урынны ничегрәк әйтте икән, бу җөмләне нинди сүзләр, сурәтләү чаралары кулланып төзегән булган икән дигән сорауга җавап эзләгәннәр.

Әсәр моннан 60—90 еллар элек булган хәлләрне тасвирлый, үзе 20 елларда языла. Билгеле, ул вакыттан бирле телебез дә үзгәрешсез калмады. Аерым алганда, күп кенә яңа сүзләр, тәгъбирләр, мәгънәләр һәм стилистик төсмерләр килеп керде; шул ук характердагы төшеп калулар булды. Автор-

[1] М. Галәү. Болганчык еллар. Мөһаҗирләр. Тәрҗемәчеләре Я. Халитов, Р. Даутов. Казан. 1968 ел.

ның әлеге татарча басылган өзекләрендәге лексиконыннан уңышлы — иҗади файдаланган тәрҗемәчеләр, билгеле, әсәрдә шул чор колоритын саклый алганнар. Мөсафир, шәрик, зыялы кебек күп кенә сүзләр бүгенге сөйләмдә нәкъ менә шуның өчен яшиләр дә инде. Чөнки «мәдрәсә шәрикләре», «голәмә мәҗлесендәге зыялылар», «мәмләкәт кануннары» (404 бит) кебек тәгъбирләрдәге сүзләр бер-берсен аңлатып торулары өстенә, шул чорны, тасвирлана торган мөхит-даирәне җанлырак итеп күз алдына китереп бастырырга ярдәм итәләр. Түбәндәге менә бу җөмләне укыгач та без тарих ишеген булмаса да, тәрәзәсен ачып, шул елларга караган күк булабыз: «Гәрәй м о р з а йөз илле сум акчаны алуы турында расписка язды, аны к а р ы й г а бирде дә, п р о ш е н и е белән вәкаләтнамә кәгазен үзендә» калдырды (272 бит). М о р з а с ы белән к а р ы е гына түгел, п р о ш е н и е с е дә шул чорныкы! Мондый стиль заманчалыгы бүтән урыннарда да яхшы сакланган. Мулла, шәкерт, бай хатларын үзара чагыштырып карасаң, аларның кайсы оригинал, кайсы тәрҗемә икәнен аеруы кыен. Персонажларның һәркайсына хас сөйләм-тел чаралары, алымнары дөрес бирелгән. Менә Бохара мәдрәсәләрендә күпчеп беткән, дөнья тормышыннан хәбәре бик булмаган Әкрәм карыйның дәмуллага мөрәҗәгать итеп сөйләү үрнәге: «Хосусан углым Исмәгыйл турында да бирәр сүз ишетеп булмасмы диюем. Андый-мондый хилаф эшләре юктыр бит!» (241 бит). Менә бу сүзләрдән исә безгә әдәбияттагы сүзләре-сөйләме белән таныш Каюм Насыйри «карый»: «Казанны алар Париж дип уйлыйлар, ахрысы!.. Үзләре монда торып эшләп карасалар иде, белерләр иде татар халкына хезмәт итүнең нәрсә икәнен!» (264 бит). Менә бер агаены алдап чыбык астына яткырырга теләүче сөйләме: «Әйдәле, энем Шәфыйк! — диде староста.— Монда сиңа тамга саласы бар икән...» (284 бит). Чыннан да Шәфыйкның аркасына «тамга салына»...

Әсәрнең (бу очракта тәрҗемәнең) теленә хас төп уңай як — аның халыкчан стиле, чын үзебезчә җанлы сөйләме. Яшеренбатырын түгел, күп кенә тәрҗемәләрдә бүтән халык теле, гыйбарәләре «тертеп чыгып» торалар. Бу романда андый урыннар юк диярлек. Аның буеннан буена шушы халыкчан стиль сакланган, торгызылган. «Менә ул! Башлана башлады!» (534 бит); «Әйтәм аны бүген күзгә чалынмады» (143 бит); «һаман ыгыр-шыгыр йөрим әле» (86 бит); «Шул котсыз кәпәчеңне кимә» (8 бит) кебек сөйләм үрнәкләрендә тәрҗемә ясалмалыгының эзе дә юк.

Сүзләр сайлауда, бигрәк күчмә мәгънәләрне табып урынлы китерүдә тәрҗемәчеләргә сүз тидерү кыен. «Кысыр хыял» (296 бит), «буяу кулшыра башлау» (275 бит) кебек үрнәкләр тәрҗемәдә бик күп, һәм шуның нәтиҗәсе буларак, шаблонлык сизелми.

Гомумән, тәрҗемәнең теле сурәтләүсәнгатьләү чараларына шактый бай: «Габдулла бай гарьлегеннән шартларга җитеште» (192 бит), «Саҗидә ирләрнең майлы күз карашларыннан бүген тәмам гарык булган иде инде» (400 бит). Персонажлар сөйләме өчен мондый гыйбарәләр бигрәк хас: «...Байның хатынына ачуы килгән дә әйткән ди: «Рәхәттә яши белмәдең, маеңа чыдый алмыйча котыра башладың, менә шуның өчен мин сине акылга утыртыйм әле, бөтен халык алдында үзеңне хур итәм»,— дигән ди» (191 бит); «Күр инде, ничек дулый бит. Әйтерсең лә, без аны таларга килгән, дөнья ярып кычкыра!» (400 бит). Әсәр теле мәкаль-әйтемнәр белән бик уңышлы һәм чаманы белеп кенә бизәлгән: «Байларның күзләренә кылчык булып кадала» (28 бит); «Әй, куян йөрәк! Мактанган була тагын!» (30 бит); «Ярар, булганы белән! Гел чама чамага туры килми бит ул. Дуңгыздан бер кыл дигәндәй, монысына да канәгать» (368 бит). Мәкальләр дә бик урынлы һәм татарча-сәнгатьчә яңгырыйлар: «Чиләгенә күрә капкачы» дигән мәкальдә әйтелгәнчә, Вафа нәкъ үзенә ярашлы җиргә туры килгән...» (177 бит); «Хәл белешергә килүчеләрнең бер ишесе: ...«Алты яшьлек юлдан кайтса, алтмыш яшьлек хәл белә килер»,— дигәннәр, дип акланып сөйләнә-сөйләнә керде» (6 бит), «Ачның хәлен тук белми» (149 бит). Гомумән, шаян, шаяртулы халык сөйләме үрнәкләре әсәрдә мул китерелгән. Әсәр телен җанландыруда җырлар да бик уңышлы кулланылганнар, алар да әсәрдә шактый күп очрый.

Алынма сүзләрнең яки кулланышта гына йөри торган шундый сөйләм чараларының халыкча, җанлы әйтелештәгечә бирелүе дә әсәрнең эстетик максатына бик җавап бирә: «Мине, пашпортсыз ә д ә м дип, я т а п белән Казанга озаттылар. Аннары, янә я т а п белән, үзебезнең б у л ы с к а күчерделәр» (506 бит); «Менә ичмасам, бу сүз дисәң дә сүз! М а л а д и с, Саҗидә!»

(425 бит). Төрек сүзләре-тәгъбирләре дә персонажлар сөйләмендә урынлы килгән-нәр: «һош гәлдиңиз, буюруңуз» (431 бит). Хәтта шушыңа нигезләп төзелгән сүз уйнатулар да бирелгән: «Каекчылар палубага күтәрелделәр һәм татарлар янына килделәр дә: — Кәтәрелемме? — дип сорадылар. Төрекчә бу сүз «Илтеп куяргамы?» дигәнне белгертсә дә, татарлар аны «Күтәримме? — дип аңладылар.— Ярар, мәшәкатьләнмә, туганкай... Үз әйберебезне үзебез дә күтәрербез» (379 бит). Монда аңлаешсыз яки сәнгатьчә урынсыз бер нәрсә дә юк.

Югарыда тәрҗемәнең нәтиҗәсе, җимеше турында сүз барды. Хәзер аның үзе, ягъни тәрҗемәләү процессы, техникасы, лингвистик детальләр турында бер-ике сүз. Ягъни тәрҗемәчеләрнең уңышка нинди юллар белән ирешүләре хакында.

Беренче күрсәтергә теләгән нәрсә — тәрҗемәчеләрнең татарча уйлап, үз телебез рухыннан чыгып тәрҗемә итүе, сүзгә яки җөмләгә, абзацка ябышып ятмау. Менә бер тәрҗемә җөмлә-абзац: «Габдулла бай, нишләргә, үзен кая куярга белмичә, кучерын уятты да ат җигәргә кушты, ләкин ниятеннән кире кайтты һәм, үзе кайтканчы кучерга кетәргә кушып, капкадан чыгып китте» (190 бит). Мондагы к у ш т ы, к у ч е р сүзләренең икешәр тапкыр кабатлануы да бу үрнәкнең тәрҗемә икәнлеген күрсәтми, бу мисалны гомумән тәрҗемә дип әйтеп булмый. Яки менә оригиналда (дөресрәге, русчада!) «почтенные и уважаемые лица» дигән тәгъбирне «голәмә» (242 бит) дип бирү бик урынлы, дөрес. Гомумән, уңышлы тәрҗемә үрнәкләре әсәрдә күп.

Шул ук вакытта әсәрнең сәнгатьчә тигез агышын бераз чуарлый, эстетик әһәмиятен кимета төшкән аерым кимчелекләр дә юк түгел: «Көннәр бик эссе и д е, арышның кибеп коела башлавы бар и д е... Ашы һәрвакыт тәмле, мул була и д е... Анда Сафа белән... Саҗидә дә бар и д е» (57 бит); Паровозның һәрбер кычкыртуы аларны тагын да дәртләндереп... җибәрә и д е. Авылда калучылар исә бу вакыт җыенга хәзерләнәләр и д е... Бәйрәмне аеруча бер җанлылык, дәрт белән каршыларга җыеналар и д е» (305 бит).

Могҗиза белән терелеп, бу җөмләләрне автор күрсә, бер шиксез алар астына кулын куймас һәм «Маладис, егетләр, булдыргансыз, тик кай җирләрендә төеннәрне генә төенләп бетермәгәнсез», дияр и д е. «Авыштырып» кына калдырган урыннар да бар: «Авыл бөтен ямьсезлеге, пычрагы белән кардан ачылып калды» (89 бит). Әгәр шушы җөмлә белән янәшә «Ул үзенең тырышлыгы белән күтәрелгән кеше» фразасын куйсак?.. Бу, әлбәттә, русча сүз сөрешенә механик иярүнең нәтиҗәсе. Бер-ике генә урында рус сүзләре тәрҗемәсез бирелгән: нар (сәке; 21 бит), гармун мехы (күрегс; 108 бит). Әгәр шулай әйтергә яраса, хәзерге бер төркем интеллигенция жаргоны дигән сөйләмнең дә чагылышы сизелә: «Төрле тикшерү йортлары буйлап берсеннән икенчесенә күчереп азаплый торгач, Таҗи белән Фәхрине, ниһаять, төрмәгә китерделәр» (305 бит). Шушы ук «стиль»нең шаукымына бирелүдәндер, бәлки, бер-ике урында грамматик хата киткән: алар «доносларының нәтиҗәсе белән бик канәгать иделәр» (119 бит). Мәктәп грамматикалары өйрәтеп килгәнчә, «канәгать» сүзе янында чыгыш килеш формасы тора кебек. Кайбер төгәлсезлекләр дә бар. «Карточный долг был для него долгом чести» җөмләсе «Ул... уен кагыйдәләрен тиешенчә үтәүне намус эше дип саный» (268 бит) диелгән. Ләкин монда оттырып бурычка уйнау турында сүз бара. «Мне за пять с полтиной л а д н у ю лошадь продали». «Минем үземә дә биш ярымга җиккән ат бирделәр» (300 бит) диелгән. Контексттан чыгып чамалаганда да биш сумның җигүле ат өчен җитәрлек булмавы күренә, ягъни кырыкмыш кына түгел, көр ат булып җиткән ат турында сүз бара. Ләкин болар — диңгездәге берничә тамчы кебек, аерым җитешсезлекләр генә.

Безнең алдыбызда — эчтәлеге-идеясе белән дә, рухы белән дә, теле-сөйләме белән дә татарныкы, үзебезнеке булган китап. Аның шулай үз, кадерле, якын булуында икенчел авторларның — тәрҗемәчеләрнең дә роле бик зур.

**Г. АХУНҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**ГАЛИ ХУЖИЕВ. Син безнең көннәрдә. Поэмалар һәм шигырьләр. Казан. 1969 ел.**

Гали Хужиев үз иҗатының күп өлешен партия һәм аның бөек юлбашчысы В. И. Ленин турында шигырьләр, поэма һәм балладалар тудыруга багышлаган шагыйрь иде. Үзе исән чагында аның ул әсәрләре газета-журнал битләрендә, альманахларда һәм шагыйрьнең күп санлы җыентыкларында басылып чыкты. Даһи Ильичның тууына 100 ел тулу уңае белән Татарстан китап нәшрияты арабыздан иртә киткән эдипнең әлеге шигырь, баллада һәм поэмаларын аерым җыентык итеп бастырып чыгарды. «Син безнең көннәрдә» дип аталган бу җыентыкка шагыйрьнең «Идел хикәясе», «Ильичның анасы», «Аврора» крейсерында», «Көнел яктысы» поэмалары, «Рафа фаҗигасе» балладасы һәм «Бирелә Ильич эшләгән» исемле шигырьләр циклы тупланган.

«Идел хикәясе» поэмасы Ильич туган апрель аеның көннәрне ашкындыра торган шау-шулы көннәрен тасвирлаган юллар белән башланып китә:

> **Апрель, апрель, безнең көннәргә**
> **Шушы көннәр белән кердең син:**
> **Кояшлы яз булып килдең җиргә**
> **Һәм Ильичны алып килдең син.**

Поэмадагы Володяның балалык елларын, аның Кокушкинода үткәргән көннәрен, көтүче татар малае һәм чуваш егете Огородников белән дуслыгын, абыйсы Александр астырылганнан соң Ильичның көнелендә туган уйларны, Ульяновлар гаиләсенең татулыгын күз алдына китереп бастыра торган бүлекләрне аеруча тирән дулкынлану белән укыйсың. Анда шулай ук Россиядә революцион агымның көннән-көн үсә баруын, ирек һәм азатлык хакына эшчеләрнең канлы көрәшкә күтәрелергә әзер торуларын чагылдыруга да шактый киң урын бирелгән.

«Ильичның анасы» поэмасын югарыда телгә алынган поэманың дәвамы дип санарга мөмкин. Бирелә без ул заманның шатлык-кайгыларын планетага бөек Ленинны тудырган олы җанлы ана күңеле аша тоябыз.

«Бирелә Ильич эшләгән» циклына «Кремльдә бу гади булмә», «Яңа декрет», «Өмәдән соң», «Балалар белән» һәм «Ул еллар калды еракта» шигырьләре кертелгән. «Көнел яктысы» поэмасы Советларның II Бөтенроссия съезды делегаты, Ильичны күмүдә катнашкан гади авыл хатыны, безнең якташыбыз Нурдидә Бухарметованың уйларын һәм истәлекләрен чагылдыруга багышланган. Китап «Рафа фаҗигасе» балладасы белән ябыла. Җыентык укучының игътибарын үзенә җәлеп итә торган матур тышлыкта чыгарылган. «Син безнең көннәрдә» җыентыгы укучыларыбыз өчен, һичшиксез, зур бүләк булачак.

**Беренче карлыгачлар. Казан. 1968 ел**

Шул исемдәге сериядә чыга торган җыентыкларда яшь шагыйрьләребезнең иң уңышлы дип саналган әсәрләре басыла. «Беренче карлыгачлар» сериясенең икенче китабында барлыгы 12 яшь каләмнең — Рәшит Гатауллин, Гакыйл Сәгыйров, Рифгат Закиров, Салисә Гәрәева, Данис Хәбибуллин, Зөлфәт, Разил Вәлиев, Әхмәт Сәйфетдинов һ. б. ларның иҗат үрнәкләре бирелгән. Җыентыкка тупланган шигырьләрдә замандашларыбызның уй-теләкләре, Ватанга бирелгәнлек, туган җиргә мәхәббәт, дуслык һәм бәхет, яшьлек һәм сөю хисләре чагылдырыла. Җыентыкта шулай ук тынычлык һәм иминлек темаларына язылган шигырьләр шактый урын били.

Салисә Гәрәеваның «Кайсы ана сугыш теләсен» шигыре мондый строфа белән тәмамлана:

> **Аналарның изге теләкләрен**
> **Җыр юлында килә сөйләсем.**
> **Илгә шундый уллар үстергәндә,**
> **Кайсы ана сугыш теләсен?!**

Кайбер авторлар бер үк темага язсалар да, алар аны үзләренчә чишәргә, үзләрен-

чә яктыртырга омтылалар. Бездә чыга торган китапларда, гадәттә, авторның рәсеме дә, аның турында мәгълүматлар да булмый. Ә менә «Беренче карлыгачлар»да алай түгел. Биредә, шигырьләре алдыннан, һәр яшь әдипнең рәсеме һәм кыскача автобиография-се урнаштырылган. Бу бик әйбәт. Чөнки укучы теге яки бу әдипнең әсәрләре белән танышканда, аның тормыш һәм иҗат юлы белән дә кызыксына. Әлеге матур башлангычны башка әдипләребезнең җыентыкларын чыгарганда да кулланырга кирәк. «Беренче карлыгачлар» җыентыгы каты тышлыкта, матур оформлениедә чыгарылган. Ләкин сүз ахырында шуны әйтәсе килә. Поэзиягә әле яңа гына аяк басучы яшьләр рәтенә Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм безнең арабыздан инде 1955 елда ук киткән фронтовик шагыйрь Гиз-эль-Габид та кертелгән. Безнеңчә, үзенчәлекле бу шагыйрьнең шигырьләрен бергә туплап, аерым китап итеп чыгарырга кирәк иде. Һәм Татарстан китап нәшрияты киләчәктә моны эшләр дип ышанасы килә.

**РӘДИФ ГАТАУЛЛИН. Юл җырлары. Шигырьләр. Казан. 1969 ел**

Рәдиф Гатауллин — поэзиябезгә соңгы елларда килгән яшь шагыйрьләрнең берсе. Кыска гына вакыт эчендә ул үз укучыларын табып өлгерде һәм аларга бер-бер артлы өч җыентыгын бүләк итте. Аның яңа, дүртенче китабы да озак көттермәде. Яшь шагыйрь күптән түгел «Юл җырлары» дип аталган җыентык бастырып чыгарды. Җыентык «Юлда тапканнарым» һәм «Исемсез йолдызлар» дигән бүлекләрдән тора. Беренче бүлеккә нигездә аның фәлсәфи шигырьләре тупланган. «Кич турында иртәнге уй», «Кеше — бала», «Яр турында», «Бу — җыр», «Фәлсәфи истәлек», «Оныт, Мәҗнүн, Ләйләне», «Өстәлемдә торна тора» кебек шигырьләрендә Рәдиф кешенең тормыштагы урыны, аның әзләнүләре, табигать белән бәйләнеше турында сөйли. Моның шулай икәнлеген үзе үк белдерергә теләгәндәй, әлеге бүлеккә эпиграф итеп ул түбәндәге юлларны ала:

**Нигә әле нәтиҗәләр...**
**Әлегә һаман тәҗрибәләр.**
**Әле монда минем йөрәк.**
**Сораулар белән тулы күзләр**
**Озак әле табигатьтән серләр эзләр.**
**Карда, комда әле озак калыр эзләр.**
**Шулай:**
**Юлда туган — юлдан эзләр.**

«Исемсез йолдызлар» бүлеге лирик шигырьләрне эченә алган. Бу бүлекнең астына ук, җәяләр эченә алып, «лирика» дип куелган. «Дагстаннан хат», «Фоторәсем артына шаян сүз», «Озын керфекләрдә яшь тамчысы», «Синнән тагын хатлар көтәм», «Син айның җиденче киче» шигырьләре күңелдә аеруча җылы тәэсир калдыралар. Китап олы һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына адресланып чыгарылган. Алар Рәдифнең бу китабын да яратып укыр дип ышанырга кирәк.

**Шигырь бәйрәме. Коллектив җыентык. Казан. 1969 ел.**

Поэзия сөючеләрнең кулларында шул исемдәге җыентыкны бик еш күрергә мөмкин.

Бу җыентык татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышлап чыгарыла. Үзган ел аның беренче китабы басылып чыккан иде. Быел икенче китабын сөенеп каршы алдык. Китапның сүз башында әйтелгәнчә, узган елгы җыентык һәр шагыйрьдән берәр яңа шигырь алу принцибында төзелгән иде. Быелгы җыентык исә татар телендәге газеталарыбызда, журналларыбызда басылган шигырьләрдән сайланып алынган. Алар арасында башкорт дусларыбызның да кайбер шигъри әсәрләре бар.

Быелгы «Шигырь бәйрәме»н «Ленин Татарстаны» исемле шигыре белән шагыйрь Мөхәммәт Садри башлап җибәргән. Аннан соң сүзне өлкән шагыйрьләребездән Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Әхмәт Исхак, Нури Арсланов, башкорт әдибе Сәйфи Кудаш, Нәкый Исәнбәт һәм Шәйхи Маннур алганнар. Аларның шигырьләре тирән кичерешле һәм хискә бай булулары белән аерылып торалар. Ул шигырьләрне укыганда тормышның күп төрле якларын күз алдына китереп бастырасың. Мәрхүм шагыйрь Әнвәр Давыдов әлеге олы бәйрәмгә үзенең «Тагын баса минс яз моңы» дип башланган шигырен бүләк итеп калдырган. Шигырьдә сине тирән дулкынландыра торган менә мондый юлларны күпләп очратасың:

**Врач кушкач, күләгәгә басам...**
**— Тик син, кояш, сорап тормачы!**
**Аңлый, ахры, ерак чатлар аша**
**Ашыга миңа күңелем кояшы.**

Быелгы «Шигырь бәйрәме»ндә барлыгы кырык дүрт шагыйрь катнаша. Алар арасында без Тукайлар, Такташ һәм Җәлилләр

калдырган эстафетаны лаеклы күтәреп баручы бик күп яшь әдипләребезнең исемнәрен күрәбез. Шигъри тавышлары көннән-көн көчлерәк яңгыраган Сажидә Сөләйманова, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Клара Булатова, Камил Мостафин һ. б. лар әнә шундыйлар. Бу җыентыкны кулына алган укучыларыбыз болардан тыш та бик күп яңа исемнәр белән танышачаклар. Кыскасы, «Шигырь бәйрәме» китабы кызыклы һәм бай эчтәлекле булып чыккан. Әмма шунысын да әйтергә кирәк, аның тиражы бик кечкенә, нибары 3000 данә. Алдагы елларда бу җыентыкны зуррак тираж белән һәм калынрак итеп чыгарырга иде.

**Бәйрәм җырлары. Казан. 1969 ел.**

Бәйрәмнәрдә, төрле кичәләрдә балалар, клуб һәм мәктәп сәхнәләренә чыгып, шигырьләр сөйләргә яраталар. Ләкин алар күп кенә очракларда теге яки бу датага багышланып язылган шигъри әсәрләрне таба алмыйча йөдиләр. Шигырь яратучы нәни дусларыбызның әнә шул ихтыяҗын күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләндерү йөзеннән, Татарстан китап нәшрияты, аларга атап, «Бәйрәм җырлары» исемле җыентык бастырып чыгарды. Шагыйрь Зәки Нури тарафыннан төзелгән бу җыентык «Ленин таңнары», «Октябрь кояшы», «Армиябез сакта», «Май шатлыгы», «Әниләргә бүләк», «Кыш бабай табыны», «Сабан туе — хезмәт туе» һәм «Букетлы көн» дигән бүлекчәләрдән тора. Исеменнән үк күренгәнчә, һәр бүлекчә аерым бер темага атап язылган шигырьләрне эченә ала. «Ленин таңнары» бүлекчәсендә, мәсәлән, сөекле юлбашчыбызның бөеклеген һәм гадилеген, аның эшенең хаклыгын һәм үлемсезлеген расларган шигырьләр белән танышырга мөмкин...

**Чыксак та без җыр гөрләтеп ялга,**
**Китсәк тә без яуга озакка,**
**Байрак булып Ленин балкый алда,**
**Зур уңышлар теләп озата.**

Әнә шундый эпиграф белән ачылган әлеге бүлекчәгә Нәби Дәүли, Рәшит Гәрәй, Әхмәт Исхак, Әхмәт Юныс, Шәүкәт Галиев, Нури Арсланов, Зәки Нури, Мөхәммәт Садри, Фаил Шәфигуллин, Касыйм Фәсәхов тарафыннан иҗат ителгән шигырьләр кертелгән. Нәүбәттәге өч бүлекчәдә халыкларга азатлык алып килгән бөек Октябрьга, аның казанышларын горур саклаучы Шанлы Армиябезгә, җирдәге барлык кешеләрне бердәмлеккә, татулыкка чакырып балкыган Май кояшына мактау һәм дан җырлана. Ул бүлекчәләрдә җыентыкка үзләренең шигырьләрен тәкъдим иткән әдипләрнең саны да ишәя.

**Күмәкләшеп без дә, дуслар,**
**Җырлап алыйк, әйдәле:**
**— Котлы булсын! Гөрләп торсын**
**Әниләрнең бәйрәме!**

Сажидә Сөләйманованың «Кем уяткан Ләйләне?» шигыре шундый юллар белән тәмамлана. Бу шигырьне без «Әниләргә бүләк» дигән бүлекчәдә укыйбыз. Моннан тыш биредә Газиз Нәбиуллин, Җәвад Тәрҗеманов, Заһирә Гомәрова, Гөлшат Зәйнашева, Энҗе Мөэминова, Галимҗан Латыйп һәм башка шагыйрьләрнең матур-матур шигырьләре белән очрашабыз. Җыентыкның соңгы бүлекчәсенә балалар ел саен сагынып көтә һәм шатланып каршы ала торган сентябрь хөрмәтенә багышланып язылган шигырьләр тупланган. «Букетлы көн» шигыре белән башланган бу бүлекчә «Мәктәп вальсы» җыры белән тәмамлана.

Китапка барлыгы йөзгә якын шигырь һәм җыр сайланып алынган. Балаларга атап языла торган мондый бәйрәм җырларын бергә туплап чыгаруны киләчәктә дә дәвам итәсе иде.

Мөхәммәт Мәһдиев

# БУБИ МӘДРӘСӘСЕ

## Кереш

Культура тарихыбызда бик аз өйрәнелгән бер тармак бар. Ул — мәдрәсәләр тарихы. Мәдрәсәләр татарлар арасында иҗтимагый фикернең өлгерүендә билгеле бер роль уйнадылар. Ә 1905 елгы хөррият дулкыннары мәдрәсә стеналары эченә барып кергәч, аларда демократик хәрәкәт тә урын алды. Шәкертләрнең яшерен оешмалары төзелде, мәдрәсә шәкертләре җилем басмада листовкалар тараттылар[1]. 1905 елгы Октябрь көннәрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре, мәсәлән, эшчеләр, университет студентлары белән берлектә, халык милициясендә катнаштылар.

Кадимчелеккә, патша реакциясенә каршы көрәштә зур роль уйнаган белем учакларының берсе Буби мәдрәсәсе иде. Әгерҗе янындагы кечкенә генә татар авылы егерменче йөз башы Россия тарихында ялтырап алды. Буби мөгаллимнәренең мәгърифәт өчен көрәшләре татар кадимчеләренә һәм царизмның азчылык милләтләрнең аның томалау политикасына каршы көрәш иде. Ахырдан татар кадимчеләре, патша жандармериясе белән берләшеп, аларга һөҗүм иттеләр, һәм Буби мәдрәсәсе тар-мар китерелде[2].

## Мәдрәсә һәм аның мөдәррисләре

Буби мәдрәсәсенең ничәнче елда салынып, кайчан шәкертләр җыя башлавын төгәл әйтүе кыен. Шулай да, моңа кагылышлы кайбер документлар бар. Риза Фәхретдиновның «Асар» дигән хезмәтендә (4 нче китап) Уфа ягындагы Каршин Шәриф авылы ахуны Габделкадыйр ибне Сөләйманның бер хаты китерелә. Ул — ахунның Буби мәдрәсәсендә укучы улына адресланган. Хат 1817 елның 10 апрелендә язылган. Тагын Казан университеты китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә Буби мөдәррисе Габдулланың 4 томлык кулъязмасы саклана. Мөдәрриснең язуына караганда унынчы елларга кадәр үк Бубида бер-бер артлы ике имам булган. Аның фикеренчә, Буби мәдрәсәсе шуларның беренчесе заманында эшли башлаган. Димәк, мәдрәсәнең 200 еллар чамасы тарихы бар[3].

Габдулла һәм Гобәйдулла — Буби мәдрәсәсенең башлыклары. Икесе дә мәдрәсәнең карт мөдәррисе Габделгаллэм уллары. Габдулла — 1871 елда, Гобәйдулла

---

[1] Татарстан АССР тарихы. 1 том. Казан. 1959 ел. 481 бит.

[2] Буби мәдрәсәсенең тарихы соңгы вакытта рус матбугатында төрле яклап яктыртыла башлады. Мәсәлән, Казан дәүләт университеты чыгарган «Очерки истории народов Поволжья и Приуралья» дигән китапта (1967 ел. I чыгарылыш) А. Мәхмүдова бубилар ачкан хатын-кыз мәдрәсәсе тарихына туктала. А. Мәхмүдованың башка мәкаләләрендә дә бубиларның дөньяви фәннәр укыту өчен башлаган эшләре уңай яктан бәяләнә.

[3] Борынгы Буби авылының төп халкы марилар булган. Ләкин 18 гасырда бирегә Казан артыннан татарлар күчеп килә башлый. Мәсәлән, бу авылга, иң беренче булып, 1730 елда Балтач ягындагы Карадуган кешеләре күчеп утырганнар.

1865 елда туган. Матбугатта аларны «бубилар» дип йөртү гадәткә кергән булган. Алар Төркиядә, Гарәпстанда уку-укыту эшләрен өйрәнгәннәр.

Чит ил мәктәпләре белән танышып, алардагы укыту эшләренең торышын өйрәнеп кайткан мөгаллимнәр әтиләреннән калган мәдрәсәне үзгәртеп кору эшенә керешәләр. Дөрес, Буби мәдрәсәсе электән үк зур уку йортларыннан исәпләнеп килгән. XX гасыр башында, Гобәйдулла һәм Габдулла мөгаллимнәр үзләре дәреслекләр чыгара башлагач, мәдрәсәнең авторитеты тагын да үсә. Бу уку йорты тәрбия алымнарының куелышы ягыннан алгы сафта торган мәктәбе белән үз янына эчке Россия, Төркстан, Кыргызстан өлкәләреннән укырга, мәдәниятка, яңалыкка сусаган күп кенә кешеләрне жыя. Гыйлемгә сусаган егетләргә бубилар заманына күрә тулы аң-фикер биреп чыгарырга тырышалар, шул максат белән дөньяви фәннәр, телләр укытыла, хөр тәрбия бирергә, белем һәм иҗтимагый тормыш белән укучыларның үзләрен зәвыкландырырга тырышалар.

Гобәйдулла Буби биш-ун ел эчендә бик күп төрле дәреслекләр бастырып чыгара. Алар арасында «Кавагыйде төркия» (төрки телләр грамматикасы), «Кечек җәгърәфия», «Җәгърәфия», «Кыйраәт төрки» (уку китабы) һәм башка китаплар бар. Бу кеше дин гыйлеме буенча да китаплар чыгарган. Шулкадәресен дә әйтергә кирәк, ул китапларда фән белән дин үзара буталып беткәннәр. Мәсәлән, «Кыйраәт төрки» китабында автор «җир карбыз кеби түгәрәктер, әйләнеп торадыр», ди, ләкин аны алла яраткан, ди. Ә «Кыйраәт фәния» китабында исә дин гыйлеме янына Уатт машинасын, Архимед законын, хәтта атом турындагы төшенчәне дә кертә! Гобәйдулла Бубиның «Физика» дәреслеге Октябрь революциясеннән соң кабат басыла.

Габдулла Бубиның күпчелек хезмәтләре дини-фәлсәфи характерда. Аның дин кануннарын аңлатып язган аерым дәреслекләре дә бар: «Фәраиз» (үлгән кешенең мөлкәтен бүлү хакындагы китап) 1898 елда басыла; «Тәракъкые фәнүн» 1902 елда һ. б. Гарәп грамматикасы буенча да бер дәреслеге чыга («Сарыф гарәби», 1910 ел). Ләкин Габдулла Бубиның эшчәнлеге башка характердарак. Укыту эшендә яңалык тарафдары буларак, ул ислам диненең катлаулы, бәхәсле, аңлаешсыз һәм каршылыклы кануннарын яңа заманга яраклаштырырга тырыша һәм фән белән динне үзара килештерергә омтыла. Аның шундый карашлары, мәсәлән, «Татарча хөтбә уку дөресме» дигән китабында аеруча нык чагылыш тапканнар. Габдулла Буби бу китапта гарәп телендә хөтбә укуны үзгәртеп корырга, аны халыкка үз ана телендә аңлатып сөйләргә кирәк, халык алдына чыгып, үзең дә белмәгән хөтбәне попугай кебек кабатлаудан мәгънә юк, ди. Бу — инде дини реформаторлык. Гомумән, аның хезмәтләрендә каршылыклы фикерләр тулып ята.

Ләкин безнең тарихыбыз өчен иң әһәмиятлесе — **Буби мөгаллимнәренең мәдрәсә һәм уку тәртипләренә керткән яңалыклары һәм татар яшьләренә яңача тәрбия бирүләре.** Хәзер шул турыда берничә сүз.

## Укыту программалары

Буби мәдрәсәсенең укыту программасы шул чор мәдрәсәләре арасында, ихтимал, иң үзенчәлеклесе иде. Буби мәктәбенең башлангыч дүрт сыйныфында җәгърәфия, рус теле, мәгълүмате шифаһия (сөйләү теле), хөсне хат (матур язу), рәсем, төрки теле, хифзыссыйхәт (гигиена), дин гыйлеме, хисап, тарихыләнбия (пәйгамбәрләр тарихы), гасырелсәгадәт (пәйгамбәрләр заманы тарихы) укытыла. Югары классларда исә фәннәр тагы да катлаулана төшә. Монда да дин гыйлеме — тарихы ислам, хәдис, тәфсир өйрәтелә. Шулай да сәгатьләр челтәрендә зур урынны рус теле алып тора. Рус лисаны атнага 12 шәр сәгать (1—5 классларда) укытыла. Югары классларда псулы фикъһе (юриспруденция), гарәпчә сарыф (морфология), гарәпчә нәхү (синтаксис), төрки әдәбияты, гомуми тарих, гакаид (теология), тарихы табигый (табигать белеме), хикмәте табигый (физика), кимия (химия), мөсәлләсат (тригонометрия), нәбатәт (ботаника), җәбер (алгебра), һәндәсә (геометрия), хайванат (зоология), һәйәт (астрономия), хисап, хифзыссыйхәт (медицина белеме), гыйльме әхлакъ, гыйльме сәрвәт (экономика), рәсем, хөсне хат, гыйльме гшья (физиканың икенче кисәге), педагогика,

мантыйк (логика), француз теле һәм башка телләр укытыла. Алгебра бишенче класстан, француз теле алтынчыдан кертелә. Француз теле атнага 1—2 сәгать, астрономия атнага 2 сәгать укытыла.

Патша хөкүмәте ул заманда татарларга бары дини мәктәп-мәдрәсәләр генә ачарга рөхсәт иткәнгә һәм мәдрәсәләрне бары тик муллалар кулына гына тапшырганга, бубилар, табигый, мәдрәсәләрен татар галәмәсы һәм хөкүмәт каршында дини уку йорты итеп күрсәтәләр. Хәер, моның дини уку йорты икәнлеге программаларындагы дин дәресләреннән дә күренә. Бу — һич тә гаҗәп түгел. Ул заманда рус дөньяви мәктәпләрендә дә «закон божий» сәгатьләре кертелә иде. Әмма бубиларның программаларына карасак, күпчелек сәгатьләр дөньяви фәннәргә бирелгәнен күрербез. Дини уку йорты булып исәпләнгән бу мәдрәсә асылда дөньяви мәктәп-гимназия булырга омтыла[1].

## Дәһшәтле бозлар явар алдыннан

Ләкин Буби мәдрәсәсенең әнә шундый дөньяви юл белән алга атлавы патша хөкүмәтен борчуга сала. Бу хәл — инородец булып исәпләнгән татарларның күзе ачылу диган сүз бит. Татар баласы... һәм рус теле, астрономия, француз теле, физика... Патша жандармериясе, карагруһ миссионерлар моңа чик куярга булалар. Шуның өстенә ишаннар, аларның мөритләре, татарның кадимче кара байлары да күптәннән Буби мәдрәсәсенә теш кайрап килә. Буби мәдрәсәсендә барган дөньявилык кадимчеләргә дә суга. Һәм кадимчеләр, рус миссионерлары, патша жандармериясе белән берләшеп, һөҗүм ясарга җыеналар.

Буби мәдрәсәсенә һөҗүм — патша хөкүмәтенең илдәге революцион, прогрессив хәрәкәткә каршы хәзерләнгән гомуми программасыннан бер пункт ул. 1910 елда Эчке эшләр министрлыгы янында рухани эшләр департаменты директоры председательлегендә махсус киңәшмә эшли башлый. Махсус киңәшмә 1905 елгы революциянең татарларга зур йогынтысы булганлыгын коты чыгып күрсәтә. 17 октябрь манифестыннан соң, дип билгели махсус киңәшмә, Уфа, Сембер, Пенза, Казан губерналарында гына да 49 мең кеше православие диненнән чыгып мөселманлыкка күчтеләр[2]. «Мөселман татарларның бөтен тормыш эшчәнлеге соңгы ун ел эчендә башлыча Идел-Кама төбәгендә тупланды» диелә киңәшмәнең беркетмәсендә[3]. Татар мәдрәсәләренен, хөкүмәт контроленнән тыш, автономияле хәлдә эшләп ятулары киңәшмәне бик борчый. 1910 елның 18 декабрендә полиция департаменты барлык губерна жандарм идарәләренә циркуляр җибәрә. Циркулярда татарлар арасында панисламизм хәрәкәте көчәю ихтималы әйтелә һәм нәшриятлар, татар мәктәпләре, мәдрәсәләре эчендә яшерен агентураны ныгытырга тәкъдим ясала[4]. Шул уңай белән Россиянең төрле почмакларыннан полиция департаментына отчетлар ява. Күп кенә губерналарда мөселманнар арасында панисламизм хәрәкәтенең әлегә күренмәве, ләкин мөселманнарның укыту мәсьәләсендә икегә аерылганлыклары әйтелә. Мәсәлән, Оренбург губернасы жандарм идарәсе начальнигы болай дип яза: «Яшь мөселманнар белән картлар буыны арасында каршылык көннән-көн көчәя. Иске мәктәп-мәдрәсәләр... татар җәмгыятенең алдынгы карашлы өлешен инде канәгатьләндерми. Гомуми белемнең кирәклеге көннән-көн ачыграк күренә»[5]. Самара губернасы жандарм начальнигы да үз территориясендә яңача укыту өчен көрәшнең көчәйгәнен яза[6]. Кыскасы, патша охран-

---

[1] Буби мәдрәсәсендә беренче классыннан алып соңгы классына кадәр уку түләүсез булган. Бу — теге атна кич саен сәдака, һәр көн иртән бер агач утын күтәреп килергә тиешле авыл мәдрәсәсе түгел, ә заманына күрә — урта мәктәп. «Төрки әдәбият» һәм Г. Бубиның «Кыйраәте төрки» китабы да, исеменә карап, төрекчә дип уйланмасын. Дәреслекләр татарча язылган. Сүз татар «төркисе» хакында бара. Ул чагында татарчаны «төрки» дип йөрткәннәр.

[2] ТАССР Үзәк дәүләт архивы. 51 фонд. 1 оп. 632 эш. 5 кәгазь (алда бу архивның исеме кыскартылып биреләчәк).

[3] Шунда ук, 4 кәгазь.

[4] Шунда ук, 91—92 кәгазьләр.

[5] Шунда ук, 179 кәгазь.

[6] Шунда ук, 227 кәгазь.

ясына эш күбәя. Жандарм идарәсе бу эштә татарның кадимчеләрен үзенә тарта һәм шулар ярдәме белән күзәтү башлый. Татарның бөтен редакторлары, наширләре, язучы-шагыйрьләре яшерен күзәтү астына алына. Сарапул янында Кәримовлар матбагасының китап сатучылары тотыла [1]. Алар кулындагы «Бәдәвам» китабы жандармерияне шиккә төшерә. Чөнки бу китапта «намазсызның түк канын, итләргә бирең итен» дигән сүзләр бар икән! Характерлы бер деталь: Әгерҗе ахуны Хөсәен Әбүбәкеревтән (патша охранкасына хезмәт иткән кеше) жандарм идарәсе: «Бәдәвам» чыннан да зарарлы әсәрме?» дип сорый. Патша хөкүмәтенә ярарга тырышкан ахун дини схоластик тезмәне хөкүмәт өчен зарарлы дип бәяли [2]. Карагруһ динчеләр белән берлектә, кулак-куштаннар жандармериягә үзләренең хезмәтләрен тәкъдим итәләр. Мамадыш өязе Түбән Ошма авылыннан Сәмигулла Мохлисуллинның доносы Казан төбәгендәге бик күп тентүләрне, тикшерүләрне башлап җибәрүгә сәбәп була. Мохлисуллин 1910 елның 10 мартында Түнтәр авылына барып чыга һәм патша охранкасының агенты Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов (Ишми ишан) белән очраша. Казан жандармерия идарәсенә «мөселманнар Төркия флотына акча җыялар» дигән донос килеп керә. Әйтергә кирәк, бу уйдырма хәбәрдән файдаланып, кадимчеләр, кара байлар Мамадыш, Казан өязләрендә бик күп кешене төрмәгә утырттыралар.

Архив документларына нигезләнеп хәзер билгеле бер нәтиҗә ясарга мөмкин. Татарлар арасында Төркия флотына акча җыю бөтенләй булмаган. Бу — чеп-чи ялган. Моның ялган икәнлеген жандармерия үзе дә таный. Эш болай була. 1910 елның башында Төркиянең шәйхелисламы (безнеңчә, мөфтие), Төркиянең диңгез флотын куәтләндерү өчен ярдәм сорап, бөтен мөселманнарга фәтва белән мөрәҗәгать итә. Россиянең Эчке эшләр министры 1910 елның 15 мартында Уфадагы Диния нәзарәтенә шәйхелисламның бу фәтвасын мөселманнарга белдермәскә дип хәбәр итә. Министрның бу күрсәтмәсе циркуляр рәвешендә бөтен мәчетләргә таратыла. Надан муллалар циркулярны халык алдында укыйлар. Шуннан нәкъ киресе була: мөселманнар арасында Төркия флотына акча җыю башланган икән, дигән хәбәр тарала [3]. Авылда мәктәп, мәдрәсә файдасына һәртөрле акча җыю турында кадимчеләр, үз дошманнарыннан үч алу өчен, «төрек флотына акча җыялар» дип жалоба язып торалар. 1912 елның 8 апрелендә Ишми ишан Мамадыш өязенең 3 нче стан урядникгына Казан арты авылларында бик күп мөгаллим-муллаларның яңача укыта башлаулары һәм аларның рус хөкүмәте кул астыннан чыгарга, Төркиягә кушылырга өндәүләре турында донос бирә. Бу донос Казан губерна жандармерия идарәсен кузгатып җибәрә.

Бу көрәштә кызыклы гына бер детальгә игътибар итмичә мөмкин түгел. XX йөз башында татар авылларындагы мөгаллимнәр, муллалар арасында патша хөкүмәтенә мөнәсәбәттә ике катлау барлыкка килә. Боларның бер ишесе (Түнтәр ишаны Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов, Тымытык мулласы Шаһиморат Аделев, Әгерҗе ахуны Хөсәен Әбүбәкерев һ. б.) чын күңелдән патша хөкүмәтенә хезмәткә күчәләр һәм охранка агентлары булып торалар. Икенче бер ишесе (мәсәлән, Яңа бистә мулласы Зариф Әмирхани, Арбор волосте ахуны Әхмәтгәрәй Зарипов һ. б.) патша хөкүмәтенә мөнәсәбәттә оппозициядә торалар. Түнтәр авылы мөгаллиме Нәҗип Шәмсетдинов патша властьларына протест йөзеннән үз мәктәбенең түбәсенә кызыл флаг та элә [4]. Арбор волосте — Малмыж юлларыннан, гадәттә, политик тоткыннарны уздырганнар. Нөнәгәр авылыннан шундый тоткыннар узган вакытта Әхмәтгәрәй Зариповтан болар турында фикерен сорыйлар. Ул крестьяннарга болай дип җавап бирә: «Бу кешеләр — студентлар. Алар безнең хакка үзләренең семьяларыннан, эшләреннән, балаларыннан аерылганнар. Алар без крестьяннар өчен җәфа чигәләр, алар алпавыт җирләрен тигез итеп бүләргә чакырганнары өчен сөрелгәннәр...» [5]

Вятка һәм Казан жандармерия идарәләренә килеп кергән мәгълүматларның бик күбесендә мондый оппозицион фикернең бигрәк тә Буби мәдрәсәсеннән таралганлыгы билгеле була. Жандармерия бу мәдрәсәгә үзенең игътибарын юнәлтә.

---

[1] Шунда ук, 199 фонд. I оп. 2086 эш. 4 кәгазь.
[2] Шунда ук, 146 кәгазь.
[3] 41 фонд. 6 оп. 4 эш. 84—85 кәгазьләр.
[4] Шунда ук.
[5] Шунда ук, 1 эш, 183 кәгазь.

1910 елның 15 августында Вятка губернаторы Камышанский үзенең яраннары белән мәдрәсәгә килеп төшә. Анын белән земский начальник, земский доктор, исправник, мәгариф инспекторы һәм башка чиновниклар була. Камышанский башта кызлар мәдрәсәсенә керә. Габдулланың кызы Галиягә русча эндәшә — теге бала бик әйбәт җавап бирә. Русча укытып карый — әйбәт. Губернатор хәйран кала. Ирләр мәдрәсәсенә кергәч, бер шәкертне туктатып, русча сынап карый. Очраклымы, түгелдерме, русчаны яхшы белгән шәкерт туры килә һәм губернаторның гаҗәпләнүе тагын да арта. Ахырдан губернаторның ни сәбәптән килгәнлеге мәгълүм була: «Буби мөдәррисләре аерым урыннарда лекцияләр укыйлар» дип, донос ясалган икән. «Мәдрәсәдән башка җирдә бернәрсә дә сөйләмәгез,— ди Камышанский.— Сак булыгыз, хөкүмәт хилафында эш күрмәгез, югыйсә, мин сезне 24 сәгать эчендә Бубидан кудыртырмын». Шулай да Камышанский Г. Бубины мәдрәсәнең үзендә лекция сөйләүдән тыярга әле базмый. Ә бу мәдрәсә эчендәге җыелышларда күп нәрсә сөйләнгән. Буби мәктәбе үзенең атна саен ясалган җыелышлары, бу җыелышларда кара реакциягә каршы сәяси нотыклары белән шәкертләрнең фикерен ачуда күп хезмәт итә.

Губернатор визиты әзерләнеп яткан трагедия турында хәбәр бирүче сигнал була.

Бубиларның дошманы жандармерия генә түгел, әлбәттә. Дошман татар динчеләре һәм Буби мөгаллимнәре арасында да бар. Шуларның иң зәһәре — Ишми ишан. Аның ни өчен Буби мәдрәсәсенә дошман икәнлеге бик гади мәсьәләгә кайтып кала. Түнтәр — Вятка ягында. Буби мәдрәсәсе дә шунда. Буби мәдрәсәсенең татарларга дөньяви фәннәр укытып, кадимчелеккә каршы көрәш алып баруларына, әлбәттә, карт үрмәкүч тыныч карап ята алмый. Ишми дә ялгыз түгел. Аның ягында Казанның һәм Казан артының буржуалашкан эре алпавыты Габдрахман Ишморатов тора. Кара фикерле Ишмигә демократик әдәбият вәкилләре Г. Тукай, Ф. Әмирханнар тарафыннан нинди бәя бирелүе мәгълүм нәрсә. Ишминең кара эшен хәтта либераль-буржуаз газеталар да кискен рәвештә тәнкыйть иттеләр. Бубилар үзләренең эшчәнлегендә әнә шундый кара эчле, мәкерле дошман белән бәрелешәләр.

Ишминең иң курыкканы — яңача укыту. Моңа чик куярга теләп, карт ишан яңача укытуның зарары турында бер пасквиль яза һәм, аны русчага тәрҗемә иттереп, патша чиновникларына җибәрә. (Китапның исеме «Ишарәтелмәрам ила мафи икамәтил борһан».) Анда болай диелгән була: «...Ысул җәдиднең (яңа методның — М. М.) асылы дәгъваи истикъляль (мөстәкыйльлек, азатлык таләп итү — М. М.) вә хөкемгә карышудан гыйбарәт... Боларның дәгъваи истикъляльлары Российский социал-демократический рабочий партия комитетларының прокламациясеннән мәгълүмдер». Кадимче әнә нинди сүзләр белән уйный! Газеталардагы революцион фикердән курыккан карт болай ди: «Гәзитәләргә шулкадәр хәясыз кабахәт бөһтаннар язуларында да ысул җәдид әрбабының асыл мәзһәбләре студентлар кеби хакимләргә вә канун низамга карышудан гыйбарәт икәнс мәфһум буладыр».

1910 елның көзендә Бубиның кара бае Әхмәт хаҗи Ишми ишанны кунакка алдыра. Мәҗлескә кадимче Әфтах мулла һәм Г. Буби чакырыла. Гомере буе «мәҗлесләрдә кеше талаштырып ләззәт алучы, Әгерҗенең үзе кара, фикере кара Әфтах мулла, мине Ишми белән талаштырырга теләп, ысулы җәдид мәсьәләсен кузгата башлады,— дип яза Г. Буби үзенең истәлекләрендә.— Ләкин минем шайтаным аның шайтанына галиб килде, ничек итсә иттем, мин талашмадым, бәлки Ишми ишан белән аны талаштырдым. Ике этнең талашуы бик кызык бит, мәҗлес бик хозур узды»[1]. Икенче көнне Ишми мәдрәсәгә килә. Мәдрәсәнең тышкы кыяфәтен, хуҗалыгын, андагы тәртипне күреп, Ишми гаҗәпләнә. Бу — бер дә теге мөһмәлят чәйнәп шәкерт гомерен җилгә җибәрә торган сасы мәдрәсәгә охшамаган. Ул Габдуллага болай ди:

— Мәхдүм! Сезнең мәдрәсәгез бик ыспай. Юлыгыз һәм яхшы. Ләкин сез кешеләрне котыртасыз. Кешеләр сезгә ияреп эздән чыгалар бит. Бу эшегездән туктагыз...

Мөдәррис аңа, мәдрәсә эченә кереп, шәкертләрнең нәрсә укыганнарын карарга тәкъдим итә:

— Әгәр берәр хилаф нәрсә укысалар, мин ташламага әзер,— ди ул.

Тискәре карт мәдрәсә эченә керми. «Беләм, мин беләм,— ди ул.— Әгәр мин әйткән

---

[1] КДУ китапханәсе. Кулъязмалар фонды. 207 том. 2653 сан. 68 а бит.

белән бу эшегезне ташламасагыз, башка төрле юл белән ташларсыз»,— ди һәм китеп бара.

1910 елның декабрендә Г. Буби, гадәттәгечә, мәдрәсә файдасына татар байларыннан вәкыф җыю өчен, Минзәлә ярминкәсенә килә. Шунда аңа Ишми ишанның Вятка жандарм управлениесенә язган доносының эчтәлеген сөйлиләр. Ишан анда: «Бубилар Төркия флотына иганә җыялар, мәктәптә хөкүмәткә каршы котырталар, Россия мөселманнарын берләштереп, Төркия химаясе астында, татар хөкүмәте ясарга телиләр»,— дип язган була. Шулай итеп Ишминең Әгерҗе ягына нинди максат белән килгәнлеге ачыклана. Бу факт Ишминең патша жандармериясе кулында уңайлы корал булганлыгын күрсәтә. Ихтимал, аның Буби мәдрәсәсенә килүе дә югарыдан кушу буенча булгандыр. Әлбәттә, мондый шартларда жандармериядән шәфкать көтәргә ярамый иде. «Дәһшәтле бозлар явачагы мәгълүм булды»,— дип яза Г. Буби үзенең көндәлегенә.

## Белем учагы тар-мар ителә

Чиркәү, «Казанский телеграф» газетасы, миссионерлар һ. б. Буби мәдрәсәсендә «Россияга, рус милләтенә каршы эш алып барыла, панисламизм идеясе таратыла», дип матбугатта шау-шу күтәрәләр. Ләкин Әгерҗе ягындагы гади халык бубиларга ихтирам белән караган. Мәсәлән, 1911 елның 29 гыйнварында Буби мәдрәсәсенә погром ясау өчен отряд җибәрелгәч, бу турыда бубиларга алдан хәбәр итүче кеше Атабай авылы крестьяны Степан Кривоногов дигән рус була. Шуңа күрә төнлә белән «кинәттән» камалып алыну мәдрәсә мөгаллимнәрен гаҗәпкә калдырмый, һәм шактый нәрсә алдан яшерелә. Буби мәдрәсәсендә кулъязма әсәрләрне басып тарату өчен бер гектограф булган. Монда кадимчеләрне, патша чиновникларының кара эшен тәнкыйть иткән листовкалар басылып килгән. Гектографта Сәлимов дигән шәкерт эшләгән. Үзешчән сәнгать коллективы мәдрәсәдә еш кына сәхнә әсәрләре куйган, әсәрләрнең күбесе цензурадан үткәрелмәгән кулъязма хәлендә булган. Болар барысы да тиешле урыннарга яшерелгәч һәм байтак кәгазьләр яндырылгач, мөгаллимнәр «кунаклар» көтәләр. Шәкертләр коридорда эленеп торган патша рәсеме янына килеп патшаны әшәке сүзләр белән сүгәләр. «Синең аркаңда җәфа чигәбез...» дип рәсемгә яныйлар. (Шәкертләрнең сүгенү сүзләре бер дә үзгәртелмичә аты-юлы белән жандармерия протоколларына кертелгән.) Иж-Буби урамына чыгып, шәкертләр татарча «Марсельеза» җырлыйлар. Яндырылган китап-дәфтәрләрнең көленнән Иж-Буби урамнарындагы кар кап-кара төскә керә.

29 ыннан 30 ына каршы төндә мәдрәсә ишек алдына атка атланган, кылычлы йөзләп стражник, алар белән җиде становой пристав, исправник һәм жандарм ротмистры килеп керәләр. Һәр мөгаллимне үз бүлмәсенә биклиләр, сак астына алалар һәм тентү башлана. Тентү өч тәүлек дәвам итә. Буби мөгаллимнәрен Сарапул төрмәсенә озаталар. Алардан жандарм офицерлары ришвәт көтә, моны төрлечә аңлатып та карыйлар, ләкин мөдәррисләр аңа бармый. Ришвәт бирү — үз өстеңә гаеп алу дигән сүз булыр иде. Охранка машинасы оста эшли: Буби мәдрәсәсен тәмамлап чыккан бик күп шәкертләрнең исемлеге әллә кайчан әзерләнеп куелган була, һәм шул көннәрдә Россиянең төрле почмакларында тентү ясала. Мәсәлән, Астраханьда Сәгыйт Рәмиев квартирасында тентү уздырыла (Буби шәкертләре арасында Рәмиев шигырьләре бик популяр булганлыгы ачыкланганнан соң).

Буби вакыйгасы уңае белән җирле төрмәләр шактый тула. Тарихчы Риза Фәхретдиновның ике ат йөге кулъязма материаллары тентү вакытында алып китеп юкка чыгарыла. Алар — Россия татарлары тарихына, мәгърифәткә һәм галимнәр эшенә кагылышлы язмалар — Р. Фәхретдинов тарафыннан күп еллар буена зур тырышлык белән җыелган документлар булалар. Риза Фәхретдинов үзенең бу кулъязмалары турында борчылып Оренбург жандармерия идарәсенә мөрәҗәгать итә. «Минем «Асар»ның басарга хәзерләнгән язмаларын алып киттеләр. Болар — саф тарихи материал булып, мөселман галимнәренең биографияләреннән, тарихи документлар, хатлар, рәсемнәрдән тора иде. Моны җыюга минем бик күп вакытым һәм хезмәтем сарыф ителде. Мин алар белән саграк эш итүләрен сорар идем, чөнки китап булып

чыккач, мин аларны Россиянең берәр тарих музеена тапшырырмын дип тора идем...» — дип яза галим үзенең гаризасында. Шул чорда бик күп татар китапханәләре ябыла. Ләкин китапханәләрдән һәм аерым кешеләрдәге китаплар арасыннан «панисламизм һәм пантюркизм эзләгән жандармнар рус һәм дөнья әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен табалар [1]. Вятка ягындагы белем-мәгърифәт учагы әнә шулай сүндерелә. Кадимчеләр һәм кара реакция тантана итә. Ирләр мәдрәсәсе белән берлектә, кызлар мәдрәсәсе дә таратыла.



## Процесска әзерлек

Бубилар эше буенча берьюлы ун кеше төрмәгә утыртыла. Болар: Габдулла Буби, Гобәйдулла Буби, Котдус Габдрахманов, Мирзамөнәвәр һәм Миргаяз Алеевлар, Харис Сайманов, Әхмәтшәриф Габделсаттаров, Нәҗип Туктамышев (Думави), Габделхак Саматов һәм Габдрәхим Сәлимовлар. Казан жандармерия идарәсендә Н. Ф. Катанов һәм Духовный академиянең гарәп теле укытучысы П. К. Жузе көнтөн тәрҗемә эше белән шөгыльләнә. Катанов бубилар процессы уңае белән җыелган дәфтәрләр, хатларны тәрҗемә итү өчен Алжирдан махсус политик сүзлек соратып ала [2]. Тәрҗемәләрдә Катановның үзлегеннән берниндн фикер өстәмичә, объектив булырга тырышуы сизелә. Сарапул ротмистры Будагоский белән Әгерҗе ахуны Әбүбәкерев зур инициатива күрсәтәләр. Будагоский Катановның кайбер тәрҗемәләре белән риза булмый һәм Казан жандармерия идарәсенә болай дип хәбәр җибәрә: «Профессор Катановка ышанырга ярамый. Ул үзенең китапханәсеннән тыелган татарча китаплар сатты...» [3].

Әйтергә кирәк, жандармерия папкаларына килеп кергән дәфтәрләрдән иң хәтәре — Габдрәхим Сәлимовныкы. Анда патша хөкүмәтенә каршы юнәлдерелгән революцион җырлар язылган. Сәлимов дәфтәрендәге бу җырлар экспертлар тарафыннан русчага тәрҗемә ителгәннәр. Арада мондый эчтәлекле җырлар бар:

«Самодержавие бетсен, тораташ булып катсын. Аның юлы җәһәннәмдә булсын. Самодержавие корысын, аның башын этләр ашасын. Самодержавиенең тамыры һәм нәселе бетсен, самодержавие башында торучы кадалып китсен! Эшчеләр сыйныфына кушылыйк та бөтен чиновникларны атып үтерик. Чиновниклар башында торучы иң зур кешене үтерик! Чиновниклар башларыннан муенса тезик! Самодержавиенең канын агызыйк! Син безне сугымлык хайван һәм эт көненә калдырдың, муеныбызга муенчак кийерттең. Без Николайдан башка да яши алырбыз. ...Бер ахмак, тәхеттә үзенә оя корган да, безне талый. Әйдәгез, азатлык яулап алабыз да ул ахмакны утка ташлыйбыз!

Әйдәгез бергәләп күтәрелик, чиновникларны кулга алыйк, үзебезгә кирәкне яулап алыйк, республика төзик, полицияне һәм жандармнарны кырып бетерик!» [4]

Жандармериягә килеп кергән барлык дәфтәрләр, кульъязмаларның эчтәлеге бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: бу мәктәптә патша хөкүмәтенә каршы пропаганда алып барылган.

Буби процессын әзерләгәндә, патша жандармериясе Казан, Вятка якларында киң күләмдә тикшерү эшләре алып бара. Казан, Сарапул шәһәрләрендә, Әгерҗе, Буби авылында күп кешеләрдән сорау алына. Түнтәр авылына Ишмидән сорау алу өчен, махсус следователь китә.

[1] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казан. 1964. 358 бит. Татарстан Үзәк дәүләт архивында моңа кагылышлы бик кызык документлар бар. «Панисламизм» эзләгән жандармерия мөгаллимнәр һәм шәкертләрнең өендә менә нәрсәләр таба: «Что нужно рабочим», «Когда будет настоящая свобода», «Хезмәт һәм капитал» (татар телендә), Сүзлек дәфтәрләре (монда революция, капитал, социализм, коммунист дигән сүзләрнең аңлатмалары бирелә), Богдановичның «Пролетарии всех стран, соединяйтесь» дигән китабы, С. Федоровичның «На что собираются и куда тратятся народные деньги» дигән китабы, Л. Андреевның «Рассказ о семи повешенных» дигән әсәре һ. б., һ. б.

[2] 41 фонд. 6 оп. 9 эш. 192 кәгазь.

[3] 199 фонд. 1 оп. 2086 эш. 110 кәгазь.

[4] 41 фонд. 6 оп. 1 эш. 179 кәгазь.

Карагруһ кадимчеләрнең күпчелеге бубиларны дөньяви фәннәр укытуда гаепли. Ишми ишанның Сарапулдагы мөрите Тимкин мондый мәгълүмат бирә: «Яңача укыту безгә ошамый, чөнки алар голуме диниягә аз вакыт куялар һәм мәктәпләрендә рус лисаны да укыталар. Хосусан, Буби мәдрәсәсендә тәкмил кыйлган шәкертләр Аурупа формасында киенәләр. Без, картлар, менә шуннан куркабыз: бу яңа күренеш, бу яңача тәрбия алган татарлар яңа фурмыда хөкүмәт эсти күрмәсеннәр»[1] (курсив безнеке — М. М.).

Менә Г. Ишморатовтан сорау алган протокол. Ишморатов бөтен тискәрелеге белән бубиларның укыту методына һөҗүм итә. «Ислам дине буенча 29 хәрефле гарәп әлифбасы мөкатдәс санала,— ди ул следовательгә.— Аллаһы тәгалә шул 29 хәрефле әлифбаны адәм Галәйһиссәламгә биргән, аны үзгәртергә берәүнең дә хакы юк».

Бубиларның төп гаепләреннән берсе әнә шул икән. Ләкин бу әле башы гына. Бубилар тагын әле мәдрәсәгә төрле дөньяви фәннәр керткәннәр. «Хәлбуки, мөселманнар ноктаи назарыннан караганда, ул фәннәрне мәдрәсәгә кертү асла ярамыйдыр». Алар «хатын-кызның битен ачалар, җир кояш тирәсендә әйләнә диләр, ахирәт көненә ышанмыйлар». Казан бае үзенең рухи юлбашчысы Ишми ишанны следователь каршында күкләргә күтәрә: «Ысул җәдидчеләрнең залялятләрен бәһадиранә ачып күрсәтүче зат — Түнтәр авылы мулласы Ишмөхәммәт Динмөхәммәтевтер. Бу зат иң намуслы, иң диндар, ислам динен иң нечкәләп аңлаучы, ялгыз алладан гына куркучы заттыр». Г. Ишморатов үзенең шаһитлек күрсәтмәсендә яңача укытучыларны турыдантуры революция белән бәйли. Алпавытны менә нәрсә куркыта икән! «Ысул җәдидчеләрнең күбесе ихтилял тарафдарларыдыр,— ди ул (следователь бу сүзне «настроены революционно» дип яза),— ысул җәдидчеләрнең кайберләре 17 октябрь манифестыннан соң 1905, 1906 вә 1907 елларда хөкүмәткә каршы прокламацияләр чыгардылар». Моннан инде Ишморатовның корьән хәрефләре турында кайгыртуы бер ширма гына икәнлеге аңлашыла. Шулай да Ишморатов следователь кызыксынган төп сорауга төгәл җавап бирә алмый. Җәдидчеләрнең мөселманнарны берләштерергә теләүләре миңа мәгълүм, ди ул, «ләкин ул берләштерүне Төркия химаясе астында булдырырга теләүләрен ишеткәнем юк»[2].

Казан окружной судының аеруча мөһим эшләрне тикшерүче судебный следователе карагруһчы татар бае Мөхәммәтрәхим Юнусовтан да күрсәтмә ала. Монысы да бубиларның укыту методына һөҗүм итә. «Мин ысул җәдидне шул җәһәттән зарарлы дип беләмен ки,— ди ул,— аның тарафдарлары динне тәнкыйть итәләр... Моннан нигилизм вә дәһрилек туарга, шуның белән бергә хөкүмәткә итагатьсезлек вә ата-анага ихтирамсызлык мәйданга килүе мөмкин». Юнусовка следователь сорау куя: «Җәдидчеләр мөстәкыйль татар дәүләте төзүне планга керталәрме, юкмы?» Бу сорауга ул төгәл, ачык җавап бирә алмый. «Гомумән, ысул җәдидчеләрнең рус дәүләтеннән аерым бер земство нигезләргә теләүләре, рус падишаһы вә хөкүмәтенә каршы фикер таратулары миңа һич мәгълүм түгел,— ди ул.—...1905 елда татарлар арасында хөкүмәттән хокуклар таләп итү булды, ләкин мин татар ханлыгы торгызу фикерен ишетмәдем»[3].

Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Камал тарафыннан сатира уты астына алынган печән базары каһарманы Мөхәммәтҗан хафиз да Буби мәсьәләсе буенча следовательгә чакыртыла. Аңа да шул ук сораулар куела. Ысул җәдидне, Буби мөгаллимнәрен никадәр дошман күрсә дә, печән базары каһарманы бубилар арасында «иттихад ислам» (панисламизм — М. М.) турында мин бернәрсә дә белмим», дип җавап бирә. Ләкин бубиларның укыту программасын ул да бик каты гаепли. «Алар мәдрәсәгә җәгърәфия, тарих вә әдәбият керттеләр,— ди ул.— Хәлбуки, мәдрәсәдә тик дини гыйлемнәр генә өйрәтелергә тиеш. Ысул җәдид белән тәгълим ителгән мәдрәсәдә курс бетергән шәкертләр, минем фикеремчә, ышанычсыз (следователь «неблагонадежный» дип яза — М. М.) булып чыгалар, чөнки аларның һәркайсы... начальствоны да хөрмәт итми башлый... Хөләсән, мин сезгә шуны әйтергә тиешлемен ки, минем мәсләкдәшләрем — ысул кадимчеләр корьән, шәригать, патша вә хөкүмәт ягында торалар, ысул җәдидчеләр исә һәрнәрсәне тәнкыйть итәләр,

[1] Казан дәүләт университеты китапханәсе. Кульязмалар тасвирламасы. X чыгарылыш. 1962 ел. 17 бит. (Алда бу чыганакның исеме кыскартылып биреләчәк.)

[2] 41 фонд. 6 оп. 4 эш. 3 кәгазь.

[3] Шунда ук.

ачыктан-ачык хөкүмәткә каршы бармасалар да, үзләренә ниндидер хокук эзлиләр» (курсив безнеке — М. М.).

Мөхәммәтҗан хафиз Габдулла Буби турында хәтәр күрсәтмә бирә. Мәкәрҗә ярминкәсендә, ди ул, Г. Буби «үзеннең хокукларыңны кулга төшерү өчен, җаныңны фида кылырга вә хәтта куәт истигъмал итәргә тиеш», дип нотык сөйләде»[1]. Мөхәммәтҗанның күрсәтмәсе соңыннан суд процессында төп урынны алып тора[2].

Шаһитләрдән иң кабахәт төстә яла ягучы кеше провокатор, Буби мәдрәсәсенең үз мөгаллиме Әхмәтфәез Даутов була. Даутов Буби мәдрәсәсендә гарәп теле укыта. Бу кеше Буби мөдәррисләренең авторитетына кызыгып, көнләшеп йөри. Ул мәдрәсәдә гектограф булганлыгын һәм погром ясаласы төндә бик күп кәгазь яндырылганын әйтә. Бубилар, ди провокатор, «Россия кул астындагы һәммә мөселманнарны, Төркия химаясе астына кертеп, бер ислам дәүләте кору фикерендәләр... Бубиларның иттихад исламчы булуларына мин ышандым»[3]. Әлбәттә, сатлык җанның мондый күрсәтмәсе бубиларның язмышын нык катлауландыра. Даутовның Буби процессындагы кабахәтлекләре әле моның белән генә бетми. Погром вакытында мәдрәсәдән Сарапул жандарм идарәсенә китерткән китапларны, кулъязмаларны карап чыгып нәтиҗә ясарга Сарапул ахуны Хөсәен Әбүбәкеревне билгелиләр. Аңа ярдәмгә үзенең провокаторлыгы, доносчылыгы белән танылган мәдрәсә учителе Мирсәет Юнусовны утырталар. Соңгысы кулъязмаларны тенденциоз рәвештә, бозып тәрҗемә итә[4].

Бераздан бу эшкә Даутов та тартыла. Тикшерү вакытында ул жандарм ротмистрына «панисламизм» турында бик күп нәрсә сөйли һәм хөкүмәттән бүләк алу турында хыялланган чиновник «болай булгач, пошло́ дело» дип куана (чыннан да, бераздан Будагоский повышение белән Варшавага күчерелә). Даутов жандарм идарәсеннән бик күп акча ала һәм Буби процессына гаепләү материалы туплауда төп фигурага әйләнә[5]. Прокурор шаһитләре арасында Буби авылының үз кешеләре дә була. Болар — авыл куштаны Шәймәрдән Апаков һәм аның хатыны белән улы. Аларның бубиларга каршы шаһит булуының сәбәбе бик гади: 1910 елда Буби авылында ваба чире тарала. Габдула Буби земстводан докторлар китертә. Шул вакыт Шәймәрдән куштан: «Докторлар дару белән кеше үтерәләр», дип, профилактика уздыруга каршы килә, халыкны котырта. Г. Буби һәм докторлар, Вятка губернаторына хәбәр итеп, куштан картны бер айга авылдан җибәртүгә ирешәләр. Эчке тәртипкә буйсынмаган өчен улы да мәдрәсәдән куыла.

Шулай итеп, тикшерү органнары иллегә якын шаһиттән сорау алалар. Гаепләү ягыннан да, Буби мөгаллимнәре ягыннан да күп кеше күрсәтмә бирә. Процесс материаллары 200—250 шәр биттән торган 12 томга җыела.

Тикшерү нәтиҗәсендә гаепләү акты төзелә. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларга Уголовное уложениенең өч матдәсе буенча гаеп тагыла:

1. Мәктәптәге падишаһ сурәтен шәкертләргә хәкарәт кылдырган өчен (103 матдә. Бу матдә буенча, император һәм императрицаның сурәтләрен мәсхәрә итүчеләрне 8 елдан артык булмаган срокка каторгага җибәрү күздә тотыла).

---

[1] Шунда ук.

[2] Г. Тукай «Гаҗәп талантлар» дигән фельетонында Мөхәммәтҗан хафиз турында болай дип язды: «Маймыл хафизның — ысулы җәдидкә каршы, авыл никрутлары да ул кадәр начар итеп чыгара алмаслык җырулар язарга фәүкыльгадә истигъдатлары һәм гаҗәп талантлары бардыр» (Г. Тукай. Әсәрләр. 4 том. 47 бит).

[3] «Корылтай». 1917 ел. 13 сан. («Корылтай»ның мәгълүматлары жандармерия архивыннан алынганнар. Автор.)

[4] Архивта М. Юнусовка кагылышлы материаллар бу шәхеснең кем икәнлеген тулысынча ачалар. Иж-Буби авылы крестьяны аның турында мондый күрсәтмә бирә: «М. Юнусовның даны бик начар. Ул сугыш чукмары һәм эчкече». Бирск өяз исправнигы болай дип хәбәр итә: «М. Юнусов... Эчүчелек белән шөгыльләнә, бөтен кешегә яный, үзен жандармериянең агенты итеп күрсәтеп матди файда теләнә, коралдан ата. Тентү вакытында аннан порнографик рәсемнәр табылды. Револьверны аңа Будагорский бүләк иткән» (41 ф. 6 оп. 3 эш. 138 кәгазь һәм 4 эш, 35 кәгазь). Тентү вакытында кемнән нәрсә табылганына игътибар итик: төрмәгә утыртылган мөгаллимнәрдән марксистик әдәбият, политик брошюралар табылган иде.

[5] 1917 елда Ә. Даутов провокатор буларак фаш ителә һәм кулга алына.

2. Шәкертләрне котыртып, Төркия флотына иганә җыйган өчен (128 матдә)[1].

3. «Хакыйкать» китабының цензурага эләккән 9 нчы кисәге өчен (132 матдә. Бу матдә буенча, властьны ихтирам итмәү, бунтовщиклык характерында булган әдәбият тарату өчен өч елдан да артык булмаган срокка крепостька ябу күздә тотыла).

Сарапул төрмәсендә 16 ай яткан мөдәррисләргә шундый гаепләү акты җиткерелә.

Без, алдарак, гаепләү ягындагы шаһитләрне санап чыктык. Хәзер Буби тарафдарларының кайберләре белән танышу кызыксыз булмас. Буби мөдәррисләрен яклаган шаһитләрнең күпчелеге — Буби авылы крестьяннары. 32 шаһит арасында руслар да шактый гына. Мәсәлән, Сарапул шәһәренең нотариусы, элеккеге земский управа председателе Тюнин, Сарапул купецы, училище советы члены Ф. Н. Смагин, шәһәр училищелары инспекторы В. Ананьин Буби мәдрәсәсенең бөтен эшчәнлеген яклыйлар. Алар земство җыелышларында элек-электән Буби мәдрәсәләрендәге яңа тәртипләрне мактап килгәннәр һәм земстводан бу мәдрәсәгә акча бирдертүгә дә ирешкәннәр. Әгерҗе почта-телеграф бүлеге начальнигы Ризван Чыңгыз бубиларның бөтен эшенә ярдәм итә һәм аларны яклый. Гаепләнүчеләргә адвокат ялларга тәкъдим ителә. Буби мөдәррисләрен якларга Мәскәүдән В. А. Маклаков[2], Казаннан присяжный поверенный А. Г. Бать, Уфадан адвокат Ибраһим Әхтәмов киләләр, Сарапул шәһәреннән адвокат Егоров катнаша. Суд составы 7 кешедән торып, шуның дүртесе Казаннан (А. Г. Бать алар турында «иң карагруһчы кешеләр», ди), өчесе Сарапулдан була. Шунысы характерлы, бу өч рус (шәһәр башлыгы, земский управа начальнигы һәм старшина) бертавыштан Буби мөдәррисларын яклыйлар. Хәбәрчеләр: «Рус шаһитләренең шаһәдәтләре гаять әһәмиятле булачактыр. Алар Буби муллаларының иректә вакыт кылган эшләрен мәгъкуль күрә булганнар», дип язалар. Матбугатта таралган хәбәрләргә караганда, рус җәмәгатьчелегенең алдынгы карашлы кешеләре бу процессның уйдырма икәнлеген яхшы аңлаганнар. Мәсәлән, «Камско-Волжская речь» газетасы Буби мөдәррисләре турында болай яза: «...обвиняются они, как известно, в так называемой «панисламистской» пропаганде, о которой трубила года два-три тому назад черносотенная печать»[3]. Суд утырышының ябык рәвештә үткәрелүе дә очраклы түгел: жандармериянең кара эшен мөмкин кадәр яшерергә кирәк була. Суд утырышы 1912 елның 28 маена билгеләнә. 27 майда төрмә камерасына адвокатларны кертәләр.

## Искелек белән яңалык көрәшә

Сарапул шәһәрендә атмосфера кыза: суд булырга берничә көн кала бөтен жандармерия аякка бастырыла, урамда өч кешедән артык бергә җыелырга рөхсәт ителми. Сарапулга күрше авыллардан, чит шәһәрләрдән халык агыла, гостиницалар тула. Төп гаепләүче Ишми дә, юлга чыгарга куркып, хөкүмәт органнарыннан солдат сорый. Сарапулга килгәч тә урамда күренергә курка, шыпырт кына үзенең мөрите Якуп Тимкинның өенә урнаша, хәтта җомгага да бармый...

28 май көнендә Сарапул төрмәсе белән суд урнашкан йорт арасындагы урам халык белән тула. Процесста катнашу өчен бик күп руслар киләләр. Газета хәбәрчесенә алар бубилар турында ихтирам белән: «Монда Буби профессорларына сәяси суд була, аларның Буби авылында университетлары бар», дип сөйлиләр. Суд тирәсенә 600 ләп кеше җыела. Атлы стражниклар һәм полицейскийлар халыкны таратырга тели, ләкин юкка гына. Мылтыклы солдатлар, кылычлы стражниклар белән уратылган укытучыларны халык арасыннан юл салып, төрмәдән судка китерәләр. Судка газета

[1] Бубиларны төрек флотына акча җыюда гаепләү өчен жандармерия кулында бер-ике генә документ була. Шуларның берсе — Буби мәдрәсәсенең 12 (!) яшьлек шәкерте Хәсән Ибраһимовтан сорау алган протокол. Ул бала: «Укытучылар дүрт атна кич рәттән Төркия флотына акча җыйдылар»,— дип күрсәтмә бирә (41 фонд. 6 оп. 3 эш. 95 кәгазь). Ахырда бу акчаларның Төркиядә укучы бер Буби шәкерте өчен җыелганлыгы билгеле була.

[2] Маклаков В. А. (1870—1957) 2, 3, 4 Дәүләт думаларына Мәскәүдән депутат булып сайлана. Тарихта зур шау-шу куптарган Тагиев, Бейлис процессларында катнаша. В. И. Ленин аны «Кадетларның иң уңнарыннан» дип атады (В. И. Ленин. Әсәрләр. 17 том. 99 бит).

[3] «Камско-Волжская речь». 1912 ел. 114 сан.

хәбәрчеләре кертелми. Хәтта Сарапул окружной судының прокурор ярдәмчесе дә кертелми.

Суд бара. Адвокатлар биргән сораулардан Ишмиләр, Мөхәммәтҗан хафизлар калтырап, коелып төшәләр (Даутов белән Ишморатов судка бөтенләй килми). Карагруһчылар көлкегә калалар. Менә суд председателенең Мөхәммәтҗан хафиздан шаһитлек күрсәтмәсе алуы:

— Сез бубиларны нәрсәдә гаеплисез?

— Мәкәрҗәдә Габдулла Буби нотык сөйләде, хөкүмәткә каршы.

— Нәрсә дип сөйләде?

— Тән белән, җан белән тырышырга, диде.

— Нәрсәгә тырышырга?

— Ирешер өчен, диде. Алар бик яман кешеләр бит. Харап әш, харап.

— Нәрсәгә ирешер өчен диде ул?

— Болар минем китабымда язылганнар. Мин мөәллиф бит, мөхәррир бит...

— Шулай диген.

— Тәрҗеман кая соң? Бик шәп сөйләр идем.

— Тәрҗеман нигә? Болай да беләсез бит...

Карагруһчылар барысы да әнә шулай буталалар. Аларның җаваплары нигездә бубиларның укыту программасын гаепләүгә кайтып кала. Ишми ишан, түбән карап, дога мыгырдап, Мөхәммәтҗан хафиз «казаки итәге белән борынын сөртә-сөртә» утыра. Бубилар үзләренең җаваплары белән кадимчеләрне тар-мар китерәләр. Ишми үзе судта көлкегә кала. Бөтен төрле гаепләрне үз өсләреннән алып ташлагач, Маклаковның чыгышыннан соң, Габдулла Бубины 6 айга, Гобәйдулла Бубины 2 айга крепостька ябарга хөкем чыгаралар.

Коеп яуган яңгыр астында халык суд карарын белергә көтеп тора. Менә суд ишеге ачыла: Ишми килеп чыга. Кемдер аның кулын үбә. Халык, гөр килеп, ул кешегә ачуын белдерә, Ишмигә һәм Мөхәммәтҗан хафизга усал сүзләр кычкыралар. Соңгысы мактана:

— Ну кызык иттем соң, бетердем үзләрен,— ди.

Сарапулның бер кара бае: «Бубиларга каты җәза бирсәләр, фәкыйрьләргә 100 сум акча өләшәм», дип, вәгъдә биргән була. Суд карарын ишеткәч, ул янындагы теләнчеләрне куып җибәрә. Бубиларга «бик авыр җәза бирелмәве халыкны шатландырды», дип яза «Йолдыз» хәбәрчесе [1].

Хәбәрчеләр суд членнарын, адвокатларны урап алалар. Адвокат Маклаков хәбәрчеләргә: «Бубилар панисламист түгел. Уң газеталарның бу турыдагы хәбәрләрен ялган дип саныйм. *Ул фикернең Россия мөселманнарында булмавына ышанам*»,— дип белдерә (курсив безнеке — М. М.) [2].

Суд карарын сенат раслаганчы дип, 29 май көнне Буби мәдәррисләрен төрмәдән чыгаралар. Бу көн Сарапул урамында халыкның исәбе-хисабы булмый, шәһәр бәйрәм төсен ала. Халык арасында: «Мизан» исемле китабында җәдидчеләрне сүккән өчен Ишми судка биреләчәк,— диган хәбәр тарала. Шаһитләр, адвокатлар, хәбәрчеләрне пароходлар төрле якка таба алып китәләр. Сарапул тынып кала.

Без алдарак адвокат Маклаковның В. И. Ленин тарафыннан «кадетларның иң уңнарыннан» дип бәяләнгәнен телгә алган идек. Хәзер Маклаковның ни өчен бу процесска катнашырга ризалык бирүен һәм процесста Буби мөгаллимнәрен ни өчен яклап чыгуын тикшереп карыйк.

Чыганакларга мөрәҗәгать итик. 1911 елның маенда (ягъни бубилар процессыннан якъ бер ел алда) Дәүләт думасында Столыпинга каршы чыгып, Маклаков «мин монархияне Столыпиннан да ким яратмыйм» дип горурланып әйтә [3]. Бейлис процессында да ни өчен яклаучы булып катнашуы аның үз сүзләреннән үк күренә. Мәгълүм булганча, Бейлис процессы карагруһ погромчыларның яһүдләргә каршы алып барылган антисемитик политикасын фаш итте һәм суд процессында Бейлис акланды. Ләкин Маклаков монда, *гаепсез Бейлисны яклаудан бигрәк, патша хөкүмәтен акылсыз адымнан туктатырга теләи*.

[1] «Йолдыз» газетасы. 1912 ел. 840 сан.
[2] Шунда ук.
[3] А. С. Тагер. Царская Россия и дело Бейлиса. 1934 ел. 302 бит. Рус телендә.

Нәкъ шул позициядә торып, ул Буби мөгаллимнәрен дә якларга алына. Патша хөкүмәте аппаратындагы ачыграк күзле дәүләт эшлеклеләре, либераль-буржуаз газеталар татарлар арасында аң-белемгә омтылышның көчәя баруын күрәләр һәм моның котылгысыз бер процесс икәнен таныйлар иде. Земстволарда да татар мәктәпләре ачу өчен акча сораган, мәктәпләрне татар баеның вакыфыннан азат итеп дәүләт карамагына тапшыру турындагы таләпләр көннән-көн ешрак яңгырыйлар.

Буби процессы — татарларның күзе ачылудан коты алынган патша хөкүмәтенең хурлыклы акты булды.

## Көрәш дәвам итә

1913 елның көзендә Габдулла Буби крепостьтан чыга. Төрмәдән ул үзенең бик күп язмалары, истәлекләре белән кайта. Тарихчылар өчен болар искиткеч бай материал. Ул язмаларында Г. Буби патша чиновникларының икейөзлелеген, ришвәтчелеген фаш итә. «Жандармский вахтмейстер да өч йөз сум ришвәт алган иде. Төрмәдән чыкдыкымыз соңында анысын сәер иттек: «Судка бирәмез»,— дип куркытып, аякларымызга сәҗдә кыйлдырдык, өч йөз сумны тәмам түләттек. Безне хәбес кыйлганда аждаһа кебек йөргән кешенең аякларыбыз астында, еланнар кебек бөгәрләнүе әмма кызык, көлке булды соң...» [1]

Г. Буби, төрмәдән чыккач, «мәҗрүх указ»ын сорап йөрми. Ул Столыпиннар, Ишмиләр Россиясендә эшли алуына ышанмыйча, дөньяның икенче бер читенә — Голҗага китә. Анда килү белән Голҗа шәһәрендәге татарларга яңа мәктәпләр ачу өстендә эш башлый, халык алдында аң-белем алуның кирәклеге турында докладлар белән чыга. Аның җитәкчелегендә Голҗада ирләр һәм кызлар өчен яңа мәктәпләр ачыла, театр, музыка түгәрәкләре төзелә, әдәбият кичәләре уздырыла [2]. Шул ук вакытта ул бик күп санда әдәби әсәрләр (хикәяләр, памфлетлар h. б.) иҗат итә, тәрҗемә белән шөгыльләнә [3].

Империалистик сугыш башлангач, ул дөньяда зур үзгәрешләр буласын сизенә. Абыйсы Гобәйдуллага язган хатында болай ди: «Әллә нинди хыялларга чумам. Бу сугышлар соңында Русиядә зур бер хөррият була калса,— мөгаен, булачак,— безгә укытырга мәктәпләр ачарга ирекләр бирелсә,— әлбәттә, бирeләчәк,— Буби мәктәпләрен ачарга имкян табылса,— шөбһә юк, табылачак,— ул чакта мин монда бер көн дә тормам, кайтырмын. Бубида... кызлар мәктәбен ачармын, шунда русчаны да мөкәммәл кертеп, кызлар һәм мөгаллимә, һәм учительница итеп чыгарырга иҗтиһад кыйлырмын... Син, мин — барыбыз бергә җыелып хезмәт кыйлырбыз, ул вәйран мәктәпләрне яңадан гөрләтербез» [4].

Халыкара хәлне даими күзәтеп барган Г. Буби Россиядә революция якынлашканын сизә. «Вакыйгалар күрсәтә, калебем шәһадәт бирә,— дип яза ул кызы Галиягә,— озакламас, бик тиз бер вакытның эчендә бик зур хөрриятләр булачак... Бик зур сәгадәт вә шатлык көннәре туачак, бер дә исемезгә дә килмәгән дәүләт вә имтиязлар безне чолгап алачак... бу минутлар озак түгел инде, килеп җитте. Мин әнә шул вакытта кайтырмын, Галиякәй. Буби кызлар мәктәбен ачармын. Бар куәтем белән тырышып аны дарелмөгаллимәт итәрмен. Русча лисанны мөкәммәл укыттырырмын... Әнә шул вакытта бергә-бергә милләтебезгә хезмәт кыйларак бик татлы вә бик сөевемле бер хаят кичерергә муәффәкъ булачагымны уйласам, бар хәсрәтләремне, бар күргән вә күреп яткан авырлыкларымны онытам, калебем шатлыклар белән тибә, күңелем тула, сизми дә калам, битләрем җылы яшьләр белән чыланган була, ләкин монысы хәсрәт яше түгел, бәлки шатлык вә сөенеч яше» [5].

Патша власте бәреп төшерелү хәбәрен Г. Буби зур шатлык белән каршы ала. Шул хәбәрне ишетүгә, ул ватанына кайтып китә. Ләкин төрмәләрдә, чит җирләрдә

---

[1] Кулъязмалар тасвирламасы. 12 бит.
[2] «Вакыт». 1917 ел. 2008 сан.
[3] Г. Буби. М. Е. Салтыков-Щедринның «Орел-меценат» һәм «Хозяйственный мужичок» дигән әсәрләрен тәрҗемә итә.
[4] Кулъязмалар тасвирламасы. 13 бит.
[5] Кулъязмалар тасвирламасы. 14—15 битләр.

йөрү аның сәламәтлеген нык какшаткан була, һәм каты авыру хәлендә, ул өендә истәлекләр язуга керешә. Октябрь революциясен Г. Буби авыру хәлендә каршылый. Шулай да крестьяннар арасында Совет властеның төзелеше турында политик әңгәмәләр ясый, аңлату эшләре алып бара. Ул 1922 елның 27 февралендә 51 яшендә үпкә туберкулезыннан үлә.



## Безнең тарихыбызда бубиларның урыны

Г. Бубиның татар халкын агартудагы прогрессив эшчәнлегенә заманында совет-партия матбугаты югары бәя бирде.

Буби мәдрәсәсеннән чыккан кешеләр революциядән соң дәүләт, партия аппаратында, фән-әдәбият, мәгариф өлкәсендә актив эшләп килделәр. Әдәбият галиме доцент Җ. Вәлиди, язучы С. Җәләл, шагыйрьләр Нәҗип Думави, Г. Бигн, Д. Гобәйди — заманында Бубида белем алган яки эшләгән кешеләр. Болардан тыш Буби шәкертләреннән кайберләренең соңгы язмышы белән танышу кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Мәсәлән, Г. Мостакаев мәдрәсәдән соң Бельгиядә Энергетика институтын, Зыя Мөҗәвиров Америкада Тау институтын тәмамлап совет промышленностенда эшлиләр. Тәкыюлла Алиев — Мәскәү Энергетика институтын тәмамлый. (Ул Березники, Караганда һ. б. урыннарда баш инженер булып эшли.) Гобәй Балтанов — Татарстан Мәгариф комиссары урынбасары була. Миргаяз Алиев, Хөршидә Назирова, Зәйтүнә Назирова Татарстан Үзәк Башкарма Комитетында, Мәрьям Зәйнуллина Партия Өлкә Комитетының хатын-кызлар бүлегендә эшлиләр. Мирза Алиев егерменче елларда партия тарихы, социология, дарвинизм буенча татарча кулланмалар чыгара. Гобәйдулла Госманов — Алабуга педтехникумын оештыручылардан берсе. Зәки Алиев — Минзәлә Өяз мәгариф бүлеге мөдире. Лотфи Гаделев — Уфа радиокомитетында эшли. Буби шәкертләренең бик күбесе гражданнар сугышы елларында хәрби комиссарлар буларак танылалар. Нәҗип Искәндәрев 2 Армия Политбүлегендә һәм ЧОН отрядларында, Юныс Вәлидов Мусвоенколлегиядә хезмәт итә һәм ахырдан Татарстан Җир эшләре халык комиссары була. Нәби Мансуров Төркстан фронты политидарәсендә эшли, Коканд шәһәрендә «Фергана» исемле газетаны оештыра һәм аның редакторы була. Сәлим Әминев — Алабуга педтехникумында укыта. Абүсәгыйт Шакиров соңыннан Казанда медицина институтын тәмамлый һәм врач буларак таныла. Гарәп теле белгече Зәйнәп Максудова, татар театрына нигез салучылардан берсе Габдрахман Мангушев — шулай ук Буби шәкертләре. Соңгы вакытта өлкән буын вәкилләреннән алынган хатларга караганда, Әгерҗе, Вятка ягындагы беренче совет мәктәпләренә нигез салучылар, мәгариф фронты хезмәткәрләренең зур күпчелеге Буби шәкертләре булганнар. Зәйнәп Максудовада, мәсәлән, аклар тарафыннан җәзаланып үтерелгән Буби шәкертләренең исемлеге бар. Д. Гобәйди — шуларның берсе.

Дөрес, бубилар үзләренең патшага каршы хәрәкәтләрендә сыйнфый көрәш мәсьәләсен күтәрмәделәр. Бу хәрәкәт үзенә күрә либераль-мәгърифәтчелек хәрәкәте булды. Бу хәрәкәтнең топ этәргеч көче милли изелү хисләре иде.

Татар мәдрәсәләрендәге азатлык хәрәкәте турында Г. Ибраһимов: «Искене җимереп яңага баруда хезмәтләре зур булды — болар тарихның бер буынында бер тармак урынын тоталар»[1] дип язды.

---

[1] «Октябрь яшьләре» журналы, 1924 ел, 3—4 сан.

# ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

## Рәдиф Гатауллин

О, без нинди матур идек!—
Күбәләктәй җинел йөрдек,
очып сөю тирәсендә:
гашыйк син дә, гашыйк мин дә...
Идеалларны таптык гүя,—
бар булганыбыз — Поэзия...
Ахыр — юллар бергә булмыш.
Җинел генә бармый тормыш:
үпкәләштек бераз гына,
үртәштек тә — аз-маз гына.
Җилләр тынса, дулкын шыма,
эзе калса, кала азга...
Ну болары инде — Проза.

### Гаилә жанрлары

Көнчел — шайтан. Бер-береңне
көнлисең дә — Комедия!
Аңлашканда — тулы Драма.
Характерлар туры килми,
Ә жанрлар ерак йөрми —
булып куяр Трагедия.
Катлаулы ла Әдәбият!
Безгә дә бер төрлелек ят:
бер-беребездән өйрәнәбез;
өйрәтәбез, көйләнәбез,
хаталарны әйтеп, чәнчеп.
Гаиләне ныгытырга да
кирәк икән — шул ук Тәнкыйть.

●

*Гәрәй Рәхим*
*Ялгышырмын, мин бит кеше.*

Мин дә Кеше:
Булды, кайчак ялганладым.
Кайчак алдавымны белеп,
Кайчак белми мин алдадым.
Шулар хәтерегездә калса,
кичерегез ялганнарым —
Кичергәндәй язганнарым!

Тик белегез: нык ышанып,
Бирелгәндәй язганыма
үзе алдап, үзе ышанган
Хуҗа кебек, ышандым мин
үземнең һәр ялганыма.
һәм шулай ук... язганыма.

### Көйләндем мин

Ниләр генә әйтим, вакыт,
мин үзгәрдем. Рәхмәт сиңа!
Курыкмыйча керә алам
(яки керми кала алам,)
утына һәм дәрьясына.
Булды вакыт! — һәрбер сүзгә,
һәр чәнчүгә — реакция,
Булды — янып чыктым!
Җырым
кисеп басса редакция.
Булды — артык бәһа бирдем
гайбәтчеләр «иҗаты»на.
Буш куыклар «выставкасына»
өч килдем мин атнасына.

Өстә очкан кошлар белән,
я алдаган дуслар белән,
я былтыргы кышлар белән
җаным күккә ашып очты!—
Надан гына тәнкыйть өчен,
шуңа бүлгән вакыт өчен,
тумаган тай — бәхет өчен,
шайтан өчен эчем пошты!
Хәзер нинди тынычмын мин
Инде
күп сөйләдем, күп көйләдем,
Хәзер менә мин көйләндем,
мин көйләндем —
мин өйләндем.

## Мәҗит Рәфиков

# БЫЛБЫЛ ХӘБИР

Көннең кичке ягы. Авыл Советы идарәсенең алгы бүлмәсендә сүзгә сүз ялганып китте.

— Ә суыгызны нинди су дип йөртәсез? — дим.

— Айчабар дибез, Айчабар,— ди күпне белгән, нурлы йөзле, тасма телле бер апа.— Бала-чага коеныр җирләре бар әле. Авылыбызга кергәндә күргәнсездер...

— Ә чәй суын каян аласыз? Кое суларыгыз тәмлеме?

— Коелар иске урамда гына безнең. Чәй суына күбесе үрге очка, Былбыл Хәбир чишмәсенә төшә.

— Былбыл Хәбир чишмәсе? Менә бусы исем! — дим, шатлыгымны яшермичә. Кесәдән тизрәк каләм-кәгазь чыгардым.

Апам бөтенләй ачылып китте.

— Печән өстендә былбыл булып сайраган ул, Кама буе болынында. Картлар сөйли аны. Эш арасында уены-көлкесе дә була бит анын. Кичен шулай яшь-җилкенчәк, малай-шалай кайсысы бака булып бакылдый, юри кеше көлдерә инде, кайсысы алпут айгыры булып кешни, кайсысы әтәч булып «кикрикүк» кычкыра... Хәбир атлы берәвесе сандугач булып сайрый икән. Шундый чутылдап-чутылдап сайрый ди бу! Юри генә куе куаклык эченә кереп чут-чут иттерә башласа, олы тирәклектәге бер сандугач моның янына килә ди, әй... Былбыл Хәбир кушаматы шулай чыккан аның. Ул да шул ярлы гына тормышлы булгандыр инде. Мин, кечкенә кызчык, бер шулай кардан яланаяк Сәмигаләргә йөгерәм, курчак уйнарга, урам аша ачык капкадан күрәм: Хәбир абзый Хәким байга утын яра. Таза, матур сынлы, кара мыеклы, бишмәтен салып элгән, башында үзе теккән куян бүрек, түмәрен каптырып бер генә селтәп сала — утын агачлары шалтыр-шолтыр сикерешәләр... Илла да чәйне эчкән инде үзе! Бездә чәйне бик тәмләп, күплəп эчкән кешегә әле дә: «Бу хәтле Былбыл Хәбир булырсың икән», дип тә куялар... Бер шулай Хәбир абзаң бәрәңге бакчасыннан гына Айчабар буена төшкән дә комнан саркып яткан суны казый барып, казый барып чишмә ачкан. Тонганын көтеп карап тора ди. Саф көмештәй салкын су тибеп ята икән шул! Куш учлап та тәмен татып карый, җиргә түшен куеп ятып та эчә— суы менә дигән салкын, тәмле икән лә!.. Төпләрен тирәнәйткән, казыклар кагып, тирәли читән үргән, ике такта сузып улагын куйган. Бөтен авыл чәйлек суны, тыкрыктан төшеп, шул җырлап торган улак авызыннан гына ала башлаган...

Үзе күптән юк инде ул Хәбир абзаң. Гражданнар сугышында үлеп калган. Чапаев командасында йөргән. Аяксыз кайткан авылдашы әйткән: Уфаны алганда яр башында бер бакчада сугыш яман да каты булды шул, дигән ди... Чишмәсе генә Былбыл Хәбир чишмәсе булып калды. Суын һаман эчеп туймыйбыз...

Иртәгесен август кояшы белән бергә торып иртәнге авылны күрергә чыктым. Тулы-тулы чиләкләре белән тыкрыктан, Былбыл Хәбир чишмәсеннән менгән кызларны, төрлесе төрле капкаларга кереп күздән югалганчы, карап тордым.

## ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ

Шушы елның октябрь аенда Оренбург шәһәрендәге бер бинага истәлек тактасы куелды. Мәрмәр тактага: «1926—27 елларда комсомолның Оренбург губкомы аппаратында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил эшләде», дигән сүзләр язылган.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Татар совет әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән күренекле шагыйрь Әнвәр Давыдовның истәлеген мәңгеләштерү өчен, Камышлы авыл Советы башкарма комитеты Камышлының бер урамына Ә. Давыдов исеме бирү турында карар чыгарды.

## ТУМАНЯННЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫ

1969 елда алдынгы кешелек дөньясы һәм илебез халыклары әрмән әдәбияты классигы О. Туманянның 100 еллыгын билгеләп үттеләр. Бәйрәм тантаналары әдипнең ватаны Әрмәнстаннан башланып китте. Туманянның якты истәлегенә хөрмәтләү өчен, Ереванга киң илебезнең бөтен почмакларыннан, шулай ук Англия, Франция, Канада, Скандинавиядән һәм башка чит илләрдән күп санлы кунаклар килгән иде.
Татар язучылары исеменнән Туманян юбилеенда М. Әмир һәм З. Нури катнаштылар, алар Әрмән академия театрында, шулай ук университетта уздырылган кичәләрдә чыгышлар ясадылар.

## БЕЛОРУССИЯДӘ КУНАКТА

Октябрь урталарында Белоруссиядә РСФСР әдәбияты көннәре үткәрелде. Анда Россия Федерациясенең бер төркем әдипләре катнашты. Алар арасында татар язучысы Н. Дәүли дә бар иде.

## БОЛДИНО КӨЗЛӘРЕ

Кайчандыр А. С. Пушкин яшәгән Болдино авылында шигырь бәйрәме уздыру матур бер традициягә әйләнеп бара. Һәр елның көзендә бирегә илнең төрле почмакларыннан шагыйрьләр җыела. Быелгы бәйрәмгә татар язучылары исеменнән шагыйрь Әхмәт Исхак барды.

## «КҮК КАПУСЫ АЧЫЛСА» — ӘЗЕРБӘЙҖАН СӘХНӘСЕНДӘ

М. Азизбеков исемендәге Әзербәйҗан академия драма театры үзенең 1969/70 еллы яңа сезонын татар драматургы Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» исемле комедиясе белән ачып җибәрде.
Әсәрне сәхнәгә режиссер Лотфи Мамедбеков куйган.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Октябрь аенда Алабуга педагогия институтында шагыйрь Сибгат Хәкимнең иҗат кичәсе үткәрелде. Шагыйрьнең иҗаты турында доклад белән филология фәннәре кандидаты Т. Галиуллин чыкты. С. Хәким үз әсәрләренең ничек язылуы турында сөйләде, яңа шигырьләрен укыды.
Кичәнең икенче бүлегендә институт студентлары әдипнең шигырьләрен сөйләделәр, аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар.
Шундый ук кичә культура-агарту мәктәбендә дә уздырылды.
Иҗат кичәләрендә шулай ук шагыйрьләр Ш. Галиев, И. Юзеев, прозаик Э. Касыймов катнаштылар.

* * *

Ф. Хөсни, Ш. Галиев һәм И. Юзеев Мөслим районының «Трудовик» совхозы эшчеләре, мәктәп укучылары һәм укытучылар белән очраштылар, тыңлаучыларны татар әдәбиятындагы яңалыклар һәм үз әсәрләре белән таныштырдылар.

* * *

18 сентябрьдә Мөслим газетасы каршындагы әдәбият түгәрәгенең чираттагы утырышы үткәрелде. Анда Г. Шәяхметова, Л. Галиеваның хикәяләре һәм М. Закировның шигырьләре тикшерелде. Утырыш эшендә язучы Фатих Хөсни, шагыйрь Шәүкәт Галиев һәм ТАССР Язучылар союзының консультанты, шагыйрь Илдар Юзеев катнаштылар.

* * *

26 сентябрьдә Түбән Кама шәһәрендәге әдәби берләшмәнең отчет-сайлау җыелышы булды. Берләшмәнең секретаре Айдар Хәлим бер ел дәвамында башкарылган эш турында отчет белән чыкты. Яңа бюроның председателе итеп М. Зәйнетдинов, секретаре итеп Ә. Гаязов (Әхмәт Гадел) сайланды.
Җыелышта ТАССР Язучылар союзының әдәби консультанты шагыйрь Илдар Юзеев һәм язучы Габдрахман Минский катнашты.

* * *

Сентябрь аенда Баулы районы Кызылъяр урта мәктәбенең Фәнис Яруллин исе-

мендәге пионер отряды укучылары авылдашлары Фәнис Яруллин белән очрашуга килделәр. Ф. Яруллин пионерларга үзенең яңа шигырьләрен укыды, укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

* * *

Октябрь аенда шагыйрь М. Хөсәен һәм прозаик Х. Сарьян тугандаш Башкортстанда булып кайттылар. Алар анда укучылар белән очраштылар, республика хезмәт ияләре арасында татар язучыларының яңа әсәрләрен һәм «Казан утлары» журналын пропагандаладылар.

* * *

Яшь шагыйрь Б. Сәләйманов Төмән өлкәсендә булып кайтты, ул укучылар белән очрашты, «Казан утлары»н тарату буенча күп эш башкарды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлекнең сентябрь аенда уздырылган утырышларыннан берсе яшь язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин иҗатын тикшерүгә багышланды. Фикер алышуларда язучылардан Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, С. Кальметов, С. Сөләйманова, Г. Афзал һәм Ә. Маликовлар катнашты. Алар М. Хәбибуллинның зур тормыш мәктәбе үтеп әдәбиятка килүе һәм әдәби иҗат эшенә бик җитди каравы хакында сөйләделәр.

* * *

Әлмәт язучыларының әдәбият сөючеләр белән очрашып торулары матур традициягә әверелде. Август-сентябрь айларында Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал иптәшләр, шәһәрнең музыка училищесы вәкилләре белән берлектә, Лениногорск районының Куйбышев исемендәге, «Шушма», «Дружба» һәм «Спартак» колхозларында булып, клубларда, ындыр табакларында һәм мәктәпләрдә 9 әдәби-музыкаль кичә уздырдылар. Алар, авыл эшчәннәренә культура хезмәте күрсәтү белән бергә, татар совет әдәбиятының соңгы 50 ел эчендәге уңышлары турында сөйләделәр, «Казан утлары», «Социалистик Татарстан» һәм башка басмаларны яздырып алдыру турында үтемле әңгәмәләр оештырдылар.

* * *

30 сентябрьдә бүлекнең гомуми җыелышында Әлмәт районының Яңа Кәшер авылында укытучы булып эшләүче яшь шагыйрә Клара Булатованың иҗаты тикшерелде. Җыелышта Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, Р. Төхфәтуллин, С. Кальметов, Ә. Маликов, Ю. Әминов, С. Сөләйманова яшь һәм башлап язучылардан М. Газизов, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Зыятдинов, Н. Касыймов иптәшләр катнашты. Клара Булатованың «Язлар алда», «Һәрвакыт янымда» исемле шигъри җыентыклары турында иптәшләрчә ачык, эшлекле сөйләшү булды. Чыгыш ясаучылар Клараның табигый таланты бар икәнен, китапларында йомшак шигырьләрнең байтак очраштыргалавына карамастан, соңгы вакытларда иҗат иткән шигырьләрендә камилләшә баруы, иҗаты үсүгә йөз тоткан шагыйрә икәнлеген әйттеләр.

* * *

Әсәрләренең китап булып чыкканчы ук укучылар алдында сынау үтүе — игътибарга лаеклы күренеш. Әлмәт шәһәренең 4 нче мәктәбендә шагыйрә С. Сөләйманованың «Елмаеп тора Ильич» дип аталган шигырьләр циклын балалар белән кумәк уку оештырылды. Кичә тыңлаучылар өчен дә, автор өчен дә бик файдалы булып, кызыклы җанлы үтте. Шагыйрәнең бу китабы Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак.

## КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

Язучылар союзы каршындагы консультация бүлеге яшь язучы Р. Кәрамиевның «Безгә илтәсе юллар» исемле повесте буенча индивидуаль семинар үткәрде. Семинар эшендә язучылардан Ә. Маликов, С. Сабиров һәм Б. Камаловлар катнашты. Авторга әсәре өстендә бик ныклап эшләргә киреклеге күрсәтелде.

* * *

Яшь шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның «Утмар» исемле яңа поэмасы тикшерелеп, төзәтелгәннән соң «Идел» альманахында басарга тәкъдим ителде.

# 1969 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


ЛЕНИН ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА

В. И. Ленин. **Партия оешмасы һәм партияле әдәбият.** № 8.
В. И. Ленин. **Рус телен чистарту турында.** № 8.

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

А. Батыров. **Өч каен янындагы өй.** № 4.
Ф. Галимов. **Ленин туган шәһәрдә.** № 1.
Ж. Ишморатова, И. Ишморатов. **Кокушкинода розалар үсә.** № 6.
А. Мөслимов. **Ленин — студент.** № 4.
А. Мөслимов. **Ленин «Искра»сы һәм Казан.** № 5.
И. Надиров. **Халыклар шигъриятендә Ленин образы.** № 5.
И. Никифорова. **Ленин, Горький, Казан.** № 6.
С. Рафиков. **Халык зурлый.** № 1.
Ф. Табеев. **Даһи Ленинча яшәргә һәм көрәшергә.** № 4.
С. Фәйзуллин. **Ленинны тәрҗемә иткәндә.** № 5.
М. Хәсәнов. **Ленинны аңлау, өйрәнү юлында.** № 7.
Г. Әпсәләмов. **Без һәрвакыт Ленин белән.** № 4—5.

*Казаннан киткәч*

Г. Мөхәммәтшин. **Шушенскоеда яз.** № 10.
Ә. Рәшитов. **Ленин яшьлегенә шаһит җирләр.** № 8.
Х. Сарьян. **Уфа кунагы.** № 12.
М. Хәсәнов. **Псковта сиксән өч көн.** № 11.

*Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

**Алтын таң.** Ойрот халык легендасы. № 4.
Ә. Баянов. **Ил гизүче карт турында баллада.** № 3.
В. Байдерин. **Төрмәдә. Юл уңаенда. Уз ачкычы.** Ленин турында хикәяләр. № 7.
И. Волобуева. **Кокушкинода. Казан университеты.** Шигырьләр. № 8.
Винь Ле. **Солдат рәхмәте.** Шигырь. № 10.
**Гаҗәеп кошлар.** Әкият. № 10.
Е. Дьёркеи. **Кремльдә Ленин белән очрашу.** Хикәя. № 5.
**Ике кояш.** Грузин халык җыры. № 1.
**Кояш турында легенда.** Саам халык җыры. № 9.
Л. Кондырев. **Кокушкинодан репортаж.** Шигырь. № 11.
**Ленин рәсемен сатып алам.** Донбасс кызлары җыры. № 1.
**Ленин хакыйкате.** Әкият. № 3.
**Ленин чишмәсе.** Әкият. № 12.
Э. Лотяну. **Ленин.** Шигырь. № 10.
В. Маяковский. **...Университет.** Шигырьдән өзек. № 4.
П. Михня. **Аппассионата.** Шигырь. № 10.
**Мич чыгаручы.** Истәлек. № 3.

**Мәйданда тирмә күренә.** Кыргыз халык җыры. № 6.
П. Неруда. **Ленинга мәдхия.** Поэма. № 11.
А. Парнис. **Ленин сүзе.** Шигырь. № 7.
**Рәхмәт сиңа, Ленин.** Рус халык такмаклары. № 1.
Ә. Рәшитов. **Исәнме, Ленинград! Пролетарийлар юлдашы.** Шигырьләр. № 5.
Р. Сафин. **Терәлердән тирәрәк.** Шигырь. № 3.
Д. Сирай. **Анын сүзе. Ишкәкче. Эзләр. Йөз еллык иманнар. Язмыш аны үзе саклаган.** Шигырьләр. № 9.
Л. Сәйфуллина. **Ленин турында мужиклар хикаяте.** Хикәя. № 4.
В. Тельпугов. **Бияләй. Легенда. Чаң тавышы. Репортер.** Ленин турында хикәяләр. № 11.
Х. Туфан. **Ленин каены. Ленин.** Шигырьләр. № 11.
**Төймә.** Истәлек. № 3.
**Төркмән сөйли.** Төркмән халык җыры. № 6.
Р. Төхфәтуллин. **Давыл чәчәге.** Новелла. № 7.
Т. Фәттах. **Күңелгә якын кала.** Шигырь. № 4.
**Хачо.** Әрмән халык җыры. № 1.
**Хафизлар яңа җыр башлады.** Таҗик халык җыры. № 6.
**Ялкынлы Ленин.** Үзбәк халык җыры. № 6.
**Яңа Кояш.** Дүнгән халык җыры. № 6.
**Һәр җирдә, һәр нәрсәдә. Шушенскоеда. Наташа исемле кыз һәм яхшы бабай. Кадак турында бер язу. Карт шофер. Очрашу. Зурларның зуры. Көннәрнең берендә. Ленин булмасендә. Халык әйтә.** Халыкның Ленин турындагы язма иҗаты үрнәкләре. № 12



*Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА ПРЕМИЯЛӘРЕ КОМИТЕТЫНДА № 5.*

## РОМАННАР, ПОВЕСТЬЛАР ҺӘМ ХИКӘЯЛӘР

Ә. Баянов. **Декабрьның уночинче көне.** Повесть. № 10—11.
Г. Галиев. **Бөтенесе дә бергә.** Хикәя. № 2.
А. Гыйләҗев. **Урамнар артында яшел болын.** Роман. № 10, 11, 12..
Ә. Еники. **Җиз кыңгырау.** Хикәя-истәлек. № 12.
Э. Касыймов. **Көмеш язулы кылыч.** Повесть. № 5.
А. Расих. **Каһарманнар юлы.** Роман. № 2, 9.
С. Сабиров. **Дустымның үлеме.** Хикәя. № 5.
Х. Сарьян. **Паку!** Хикәя. № 5.
Р. Төхфәтуллин. **Гомернең кырык сигез минуты.** Хикәя. № 1.
М. Хәбибуллин. **Унсигезенче яз.** Повесть. № 1.
М. Хәбибуллин. **Чын төш.** Хикәя. № 6.
Ф. Хөсни. **Гыйльмениса.** Повесть. № 4.
Г. Шәрәфетдинов. **Сусыз дәрья.** Солдат язмалары. № 9.
Г. Әпсәләмов. **Яшел Яр.** Роман. № 6, 7, 8.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

И. Абдуллин. **Якты күңел.** Комедия. № 1
С. Кальметов. **Көнбагыштан башланды.** Комедия. № 8.
Г. Мөхәммәтшин. **Тынгысыз төн.** Комедия. № 7.
Ю. Әминов. **Өти балак.** Комедия. № 3.

## ШИГЫРЬЛӘР, ПОЭМАЛАР

Н. Арсланов. **Изге теләк. Көчле дә син. Синең төсле. Сөйдең-кайдердең. Мәхәббәткә рөхсәт... Чыраемны сыттым... Халык әйтте... Бер тәнкыйтьчегә җавап. Көзге моңнар. Адым саен әкият. Кинешма бәете. Идел такмаклары.** Шигырьләр. № 5.

Н. Арсланов. **Романтика.** Поэма. № 11.

Г. Афзал. **Нишләдең син, Пушкин! Фәлсәфәне ничек... Мең төрле... Тукай турында уйлаганда. Рәхәт булып калды... Суык җилләр... Якты уйларымның...** Шигырьләр. № 2.

Г. Афзал. **Борчылу.** Шигырь. № 10.

Ә. Баянов. **Дөньяга ялвару. Урман... Сентябрь. Гомер — биек тау бугай ул... Җырлый белсә елан... Була сүзләр... Җиңәргә тиеш. Элегия.** Шигырьләр. № 6.

К. Булатова. **Мөмкиндер дә кебек... Сөйләр сүзләр әле никадәр... Яфрак-яфрак кар яуганда. Кайда булдың, дисең. Сукмакларга сары...** Шигырьләр. № 6.

Р. Вәлиев. **Вәгъдә.** Шигырь. № 3.

Ә. Гадел. **Кошлар кайта. Чам. Янгын сүндерүчеләр.** Шигырьләр. № 8.

Ш. Галиев. **Сигезюллыклар.** № 12.

Р. Гатауллин. **Өстәлемдә торна тора. Тел ачкычлары. Иртән язылган кечкә шигырь. Җил исмә... Якын килмә...** Шигырьләр. № 3.

Ф. Гыйззәтуллина. **Игенче һәм тургай. Чаптар атлар кире кайтмады. Чишмәләр дә серле.** Шигырьләр. № 11.

Р. Гәрәй. **Кайгырма диләр дуслар. Урман аша уза поездлар. Чишмәләрдә таңкә чыңы. Ап-ак бәхет булып. Зиратына килдем... Әй, кайда син, яшьлек... Истәлеккә калган кауриләр.** Шигырьләр. № 2.

С. Гәрәева. **Урал!.. Кайтып килэм... Сүзсез генә.** Шигырьләр. № 11.

Ә. Давыдов. **Йокысыз төннән соң.** Роман-симфония. № 1—2.

Н. Дәүли. **Көндәшләр. Минем бүләгем. Кое.** Шигырьләр. № 9.

Р. Закиров. **Өермә. Моң. Онытылган кайгым булсаң да. Бер күңелдә. Күк гөмбәзе.** Шигырьләр. № 6.

А. Закиров. **Буяу. Буш күңелең белән... Март җилләре... Бик күпләрнең...** Шигырьләр. № 11.

Г. Зәйнашева. **Яшәгән бу җирдә бер ана. Миңнәхмәт батыр.** Шигырьләр. № 3.

Зөлфәт. **Ильич өмәдә. Керәш сөлгесе. Ориентир. Әни. Кандалый турында баллада. Беләктә — көч... Чабышкыда безнең җиз йөгән. Яңа Сәет.** Шигырьләр. № 5.

Х. Камалов. **Ленин сүзе. Туган җирем. Дәмин.** Шигырьләр. № 11.

Т. Камалиев. **Казаным. Бу Ташкичү инде... Апалар. Баш имм йөргән...** Шигырьләр. № 7.

Г. Латыйп. **Болыт — батыр. Минем нәсел.** Шигырьләр. № 1.

Г. Латыйп. **Кызыл Яр.** Поэма. № 10.

К. Латыйп. **Шыртан. Кылыч. Эллада. Олы юлда бер шәһәр бар. Камышлыдан аккош киткән.** Шигырьләр. № 9.

Н. Мадъяров. **Аерылабыз... Ялгыз гына... Балкый офык... Язгы ташкын... Җитсен, дидем...** Шигырьләр. № 2.

Ә. Маликов. **Чигүле кулъяулык.** Поэма. № 4.

Ш. Маннур. **Нинди булыр иде... Мираж гына... Яңгыр. Бере җирдә, бере күктә. Кыен уен. Хатын-кыз иптәшләргә. Ялгыз учак. Дулкыннар җыры. Котлау шигыре. Шаян кояш. Табигатькә һаман... Уйлап-уйлап...** Шигырьләр. № 4.

Э. Мостафин. **Йөрәк турында. Гомер кайдан башлана. Бу төннән... Ә мин һаман бер могҗиза көтәм. Күктә очкан... Тәрәзәләр. Дөнья миңа... Рифма өчен. Кайгырабыз, шатланабыз. Күңелләргә... Яшәү авыр.** Шигырьләр. № 7.

К. Мостафин. **Ачкыч. Инженерлар. Безнең исем... Без серләрне... Китапларны язалар да... Болгар кызы. Эмигрант. Фантаст Хуҗалар. Урал бик зур.** Шигырьләр. № 9.

Ш. Мәхмүдов. **Авыл кичә. Табигать йөзе. Балбаллар. Мәскәү язы. Кичке шәфәкъ. Марс каналлары. Ике тол. Мәрхүм абыйга элегия. Китәбез.** Шигырьләр. № 7.

Э. Мөэминова. **Россия тудырды. Я җыр итеп аны ишетәм. Иң олы мәхәббәт.** Шигырьләр. № 3.

З. Насыйбуллин. **Уйлый идем. Кара шәле килә сөйрәлеп. Җөйсез яра. Моңсуланып карап калдым әле. Үзгәрттең дә куйдың. Ялганган җеп була төенле.** Шигырьләр. № 7.

М. Садыйков. **Балыкчы карт. Көне буе... Юлда. Юлдагы уйланулар.** Шигырьләр. № 2.

Л. Сафаров. Кулларын кучерә килеп. Ник читләргә кылыч күтәрик без. Музей. Килә берәү. Шундыймын шул. Егермене узгач... Бозлар китә, кызлар китә. Шигырьләр. № 4.

К. Сибгатуллин. Тамчылар. Эзлим үземне. Таң алдыннан агачларның шавы. Шигырьләр. № 7.

М. Сиражи. Җәйге яңгырлы юлдан... Бу йөрәгем... Көнгә ачык тәрәзәләре. Соңлаган мәхәббәт. Шигырьләр. № 8.

Г. Сәгыйров. Ике кояш. Кыш көне дә ачып куям. Мең төрле буласың. Шигырьләр. № 1.

Б. Сөләйманов. Кеше — гаҗәп... Ни телисез... Мин төп... Чибәр кызлар... Рас әйткәнсең... Бер ел үткән. Шигырьләр. № 1.

С. Сөләйманова. Әй, солдатлар. Күзләр якты быел. Ни белән үлчәнә. Кермим кеше биләмәләренә. Авыл урамы. Ялгышым дип уйласам да. Каен. Шигырьләр. № 5.

Р. Фәйзуллин. Алмазга. Мин зур түгел... Яз төсе бу күздә... Үлемнәре белән... Өндәде... Җанга якын... Миңа бары бер җыр кирәк... Шигырьләр. № 5.

Р. Хуҗин. Ташлар. Тумыштан ук... Кайчак. Төн. Юлларга карлар яуган. Шигырьләр. № 8.

С. Хәким. Дуга. Поэма. № 2—3.

А. Хәлим. Кайсыгызны юатыйм! Матурларым минем. Тол ана сүзе. Дуска. Экспромт. Шигырьләр. № 6.

М. Хөсәен. Бик инсафлы... Сиңа урын... Сабый чагың... Яшь дигәнең... Җырлар яздың... Сонетлар. № 2.

М. Шабаев. Кашкарыйлар сары... Ра-ра-о-ом! Соңлый язган тәүбә. Чыршы урыны — урманда. Шигырьләр. № 2.

Ф. Шәфигуллин. Мәңгелек ут. Төнге күктән. Кызык хәл. Диңгез. Эш коткара. Шигырьләр. № 4.

Ф. Яруллин. Кешелек якыная Ильичка. Ике елга. Теләр. Шигырьләр. № 6.

М. Әгъләмов. Балам, бәгырем, диеп. Уфа юлы. Каз канаты ак була. Ленин рәсеме. Юлдашым. Кыңгыраулар эзлим. Шигырьләр. № 12.

Р. Әхмәтҗанов. Ильич дивары. Аклы-каралы... Яшьлек кырлары. Кырларда җил... Июнь иле. Шигырьләр. № 6.

Х. Әюпов. Сау бул, ялгызлык. Минем хисләр. Уйламаска тырышасың... Уеннар. Таш әти. Мәхәббәт. Иске яулык. Алдану. Шигырьләр. № 8.

### БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. Галиев. Кырмыскалар туп уйный. Чаналар ла чаналар. Химчисткага бирәм, ди... Җайдак. Шаян. Габышмак шигырь. Шигырьләр. № 1.

Ш. Галиев. Шөпшә. Яңгыр яуганда. Ничә мәче! Зөһрә. Борын. Җәен. Шигырьләр. № 9.

З. Гомәрова. Исем бирделәр. Куян артыннан. Бер һәм биш. Битлек. Шигырьләр. № 4.

З. Нури. Сәгать. Кичә, бүген, иртәгә... Берсе тирги, берсе аклана. Шигырьләр. № 6.

Р. Фәйзуллин. Дөрт сүзе бар улымның. Бәлли-бәлли. Шигырьләр. № 11.

М. Фәйзуллина. Мин кунаклар яратам. Юк нәниләр этәче. Мин Артектан кайттым. Кәрпе кабак. Шигырьләр. № 3.

Р. Хәлиуллина. «Бөрлегән». Илгиз, без һәм үгез. Шигырьләр. № 11.

### ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Ш. Галиев. Аптырагач... Үзең нинди... Шигырьләр. № 2.

Ш. Галиев. Әнкәй белән бәхәс. Балта. Сәргәләп тотыйк. Мәхәббәт уставы турында. Шигырьләр. № 5.

Р. Гатауллин. Гаилә жанрвары. Мин дә кеше. Көйләндем мин. Шигырьләр. № 12.
Р. Исаев. Күрше киңәше. Янчык югалгач. Хикәяләр. № 4.
Ш. Мадриш. Эзе бар... Шигырь. № 2.
Т. Миннуллин. Шикле кеше. Малайлар. Гаптелвәли. Хикәяләр. № 7.
З. Нури. «Үзтәнкыйтьче». Уң кул белән сул аяк. Кино сөюче сүзе. Шигырьләр. № 2.
З. Нури. Хатынга ярамагач... Икесе дә котә. Килен белән кайнана. Әйтүе дә авыр... Күршең нинди! Улы атасын юата. Тиздән буласы ярдәм. Ике күрше сөйләшә. Хушлашканда. Шигырьләр. № 7.
Г. Рәхим. Таныш шагыйрьгә. Шигырь. № 1.
Г. Рәхим. Иптәшләр үзебезнеке, бәлки гаеп итмәсләр. Эпиграммалар. № 5.
М. Рәфиков. Былбыл Хәбир. № 12.
Ә. Синегулов. Түбәтәй юуу. Шигырь. № 1.
Р. Фәизов. Биш минут. Хикәя. № 9.
Ф. Хөсни. Үземне югалттым! Хикәя. № 10.
Ш. Шәрәпов. Энә. Мәсәл. № 1.
Ф. Яруллин. Гыйльминур карчык курортта. Хикәя. № 4.

## ДУСЛАР ИҖАТЫ

Ш. Абдыраманов. Солдат. Хикәя. № 5.
М. Гапаров. Наташа Ростованың беренче балы. Хикәя. № 5.
Р. Халид. Яратам сине, Нева. Өмет. Кояш нуры... Шигырьләр. № 3.
Ф. Яннакопулу. Мин — Эллада кызы. Минем куллар. Мәңгелек сәнгать. Әнкәемә хат язасым килә. Шигырьләр. № 3.

## СОВЕТ БАШКОРТСТАНЫНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

С. Агиш. Айлы кич. Хикәя. № 3.
Башкортстан... республикасының 50 еллык тарихыннан. № 3.
З. Биишева. Кешечә. Шигырь. № 3.
Р. Бикбаев. Заман! Бирче пульсыңны. Шигырь № 3.
Ш. Биккол. Безнең як. Җыр. № 3.
М. Гали. Мин тауларга китсәм. Шигырь. № 3.
Р. Гарипов. Өйгә кайтканда. Шигырь. № 3.
Х. Гыйлаҗев. Әдәбиятыбыз турында берничә сүз. № 3.
Й. Гәрәй. Ленин янында. Шигырь. № 3.
А. Игебаев. Авылдашым. Шигырь. № 3.
В. Исхаков. Әтием утырткан өянке. Хикәя. № 3.
Ф. Исәнгулов. Гафләт. Хикәя. № 3.
К. Кинҗәбулатова. Чәй. Шигырь. № 3.
Я. Колмый. Кирәк миңа тынычлык. Шигырь. № 3.
С. Кудаш. Яңа өй. Шигырь. № 3.
М. Кәрим. Ярлар кала. Шигырь. № 3.
Х. Кәрим. Ташта эзләр калган. Шигырь. № 3.
Н. Мусин. Нөгеш буйкайлары бөдрә чаука. Хикәя. № 3.
Р. Назаров. Мин батыр да түгел. Шигырь. № 3.
Н. Нәҗми. Үземнеке... Шигырь. № 3.
Г. Рамазанов. Революция дәвам итә. Шигырь. № 3.
З. Хисмәтуллин. Киңәш. Хикәя. № 3.
Г. Әмири. Карт имән. Шигырь. № 3.
Ә. Әхмәтхуҗин. Һыбай чыксам. Шигырь. № 3.

## ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Л. Гадилов. Дипломат. № 2.
С. Латыйпова. Татар студентлары һәм революцион хәрәкәт. № 3.
Т. Насыйров. Ул В. И. Ленин белән бергә эшләде. № 10.
Я. Чанышев. Татар егетләре гражданнар сугышында. № 12.
Р. Сабиров. Хәзинә эзләп. № 9.
Р. Сабиров. Нефть һәйкәлләре. № 11.
А. Сәләхетдинов. Канлы туфрак. № 7.
А. Җәләлов. Яшьлек көрәштә чыныкты. № 7.

## БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Күпне бирсәң, күпне аласың. № 3.
П. Чернов. Халык мәхәббәте — иң зур булэк. № 2.
Әкият булып күтәрелә Казан. № 6.
Үр менеп җиткәндә. № 1.

## ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Ш. Вядро. Уңган кыз. № 3.
Г. Галиев. Ак басу. № 4.
Ф. Дунай. Бәхетле син, Бәхетгәрәй. № 2.
Н. Ихсанов. Гадиләрнең берсе. № 9.
М. Мостафин. Еллар һәм юллар. № 6.
Г. Мөхәммәтшин. Райком секретаре. № 8.
Э. Мөэминова. Бәхетле булырсың диган иде... № 11.
Җ. Рәхимов. Дуслык тау күчерә. № 5.
Т. Сәгыйтов. Күккә гашыйк егет. № 7.
К. Тимбикова. Алтын сәгать. № 3.
С. Хәйруллин. Муса эзе калган колхозда. № 10.
М. Хәмитов. Мировой Әмир. № 1.

## БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

И. Зәбиров. Җәлил көрәштәшләре. № 2.
С. Кристи. Әхмәт Симаев — Җәлил дусты. № 2.
А. Марченко. Дуслык кичте утлы юлларны. № 2.
Р. Мостафин. Тик бер өмет. № 1.
Р. Мостафин. Муса көрәштәшләре. № 10.
Ш. Рәкыйпов. Егерме икенең берсе. № 2.
З. Әхмәтҗанов. Алтын йолдызлы лачын. № 5.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. Батуллин. Витаминнар хакында. № 8.
Т. Галиуллин. Шигъри ачышлар һәм югалтулар елы. № 7.
Ә. Исхак, Г. Ишмөхәммәтов. Күңелсез кимчелекләр. № 2.
Р. Мостафин. Бәхәс дәвам итә. № 2.
Р. Мостафин. Үз җырың, үз көең булсын. № 4.
Ф. Мусин. Реализм юлыннан. № 11.
И. Нуруллин. Онытылмас еллар шаһите. № 10.
Р. Төхфәтуллин. Җепләрне ныграк төйнисе бар. № 6.
Р. Харисов. Эредәнрәк, олыданрак. № 7.
Ф. Хөсни. Кайда сез, олы язмышлар! № 6.
Р. Шәмсетдинова. Ялкын кебекләр. № 4.
А. Әхмәдуллин. Драматургия уйлана, эзләнә. № 8.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Ф. Миннуллин. **Туган җир җылысы. № 8.**
З. Нури. **Тормыштан һәм тормышчан. № 5.**
Ә. Синегулов. **Җыр — бомба. № 9.**
Г. Халит. **Таләпчән һәм эзләнүчән талант. № 3.**
Н. Хисамов. **Матурлык хакына. № 6.**

## ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Н. Лаисов. **Тукай лирикасында элегик мотивлар. № 4.**
И. Нуруллин. **Иҗат методыбыз турында уйланулар. № 5.**
Ф. Урманчеев. **Тарихи җырлар. № 3.**

## ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Ү. Байчура. **Әдәби телебез һәм яңа лингвистик ысуллар. № 1.**
Й. Вәлитова. **Тукай шигырьләренең теле хакында берничә сүз. № 3.**
Й. Гәрәй. **Сүз җыярга кирәгез! № 10.**

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. Абдуллин. **Татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләренә карата. № 10.**
Ф. Вәлиев. **Мәһабәт биналар һәм алардагы ямь. № 4.**
Н. Исәнбәт. **Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре. № 4.**
М. Мәһдиев. **Буби мәдрәсәсе. № 12.**
Ә. Нәҗип. **«Котадгу белег» әсәренә 900 ел. № 2.**
Ә. Нәҗип. **Хикмәт энҗеләре. № 4.**

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. Ахунҗанов. **Тәрҗемә практикасында үзенчәлекле бер уңыш. № 12.**
Р. Батуллин. **Вәгъдә һәм омтылыш. № 9.**
М. Госманов. **Файдалы хезмәт. № 7.**
Г. Иделле. **Канатлар кая илтә! № 1.**
Т. Камалиев. **Йолдызлар ничәү! № 9.**
Ш. Маннапов. **Шигъри дулкыннар. № 7.**
Ф. Миннуллин. **Җылылык хисе. № 6.**
К. Мостафин. **Сандугач җыры дәвамлы булсын. № 3.**
М. Мәһдиев. **Шагыйрь күңелендә ниләр бар! № 11.**
Г. Рябков. **Алыпкулның сигезенче улы. № 8.**
А. Сурков. **Җирдә яшәү хакына. № 5.**
Ф. Урманчеев. **Халкыбызның уен-бию җырлары. № 8.**
С. Хәким. **Шигырьнең көче — фикердә, хистә. № 9.**
Р. Юсупов. **Белмәмеш татарча сөйләшә. № 6.**
Бәләкәй рецензияләр. **№ 8, 11, 12.**

## ЯҢА КИТАПЛАР

Р. Галявин. **Сары яфраклар коела. № 4.**
Зөлфәт. **Минем елмаю. № 2.**
Ф. Макаев. **Диңгез эзлим. № 1.**
Ф. Макаев. **Ачык ишек. № 5.**
К. Мостафина. **Шиһабетдин Мәрҗани. № 4.**

В. Нуруллин. Солдат хатлары. № 1.
Б. Сөләйманов. Кешеләр һәм чәчәкләр. № 3.
С. Хәкимҗанов. «Ике аккош» турында. № 2.

## ФОЛЬКЛОР

З. Нури. Партизан уклары. № 2.
Х. Мәхмүтов. «Коман мәҗмугасы»ндагы табышмаклар. № 11.

## ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Г. Галиев. Безнең Кутуй. № 5.
Ә. Камал. Аны үз юлыннан тайпылдырмакчылар иде. № 10.
Г. Кашшаф. Башкортстанда. № 6.
М. Кутуева. Кутуйны сагынам. № 2.
М. Мирвәлиева. Шагыйрь белән очрашулар. № 1.
Г. Миңнул. Яшьлек эзләреннән. № 6.
М. Новигатский. Кутуй Катуков танкистлары арасында № 2.
С. Рәимов. Кечкенә генә бер истәлек. № 1.
Ә. Сафин. Муса — Татрабфак студенты. № 11.
А. Фадеев. Полк командиры. № 2.
Фронтка да, фронттан да, Хатлар. № 2.

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Н. Хәкимуллин. Хөрмә илендә. № 9.
Ә. Җәлилова. Кояш чыккан Алман җирендә. № 10.

## СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Х. Гобәйдуллин. Бай гомер юлы. № 7.
И. Иляпова. Исеме — Ринат аның. № 2.
Н. Исәнбәт. Олы иҗат, халыкчан иҗат. № 7.
Р. Кәримов. Киң колачлы иҗатчы. № 11.
А. Файнберг. Шагыйрь күңелле рәссам. № 1.
А. Файнберг. Җитлеккән художник. № 12.
С. Червонная. Туган җир җылысы. № 5.

## ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНА 50 ЕЛ

С. Сабиров. Данлы юл. № 8.

## ӘНВӘР ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Р. Мингалимов. Бик бәхетле шагыйрь. № 3.

## НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 70 ЯШЬ

Ф. Ганиев. Исәнбәт — тел галиме. № 12.
Г. Исәнбәт. Күп кырлы, киң колачлы әдип. № 12.
Б. Урманче. Исәнбәтнең урыны. № 12.
Ф. Урманчеев. Энҗеләр бөртекләп җыела. № 12.
С. Хәким. Исәнбәт — шагыйрь. № 12.
Г. Шамуков. Исәнбәт драматургиясе. № 12.

ГАЛИӘСГАР КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Х. Хисмәтуллин. Заман белән бер эздән. № 1.

СӘЙФИ КУДАШКА 75 ЯШЬ

Х. Туфан. Гомер эзләрең буйлап. Шигырь. № 12.

С. Кудаш. Күңләшәм... Бәркет килсә... Эчтә ялкын... Исемем хакында. Әгәр дә... Ни кылырсың. Тиз ятмастыр... Тик шулай да... Гөлләрнең дә телләре бар икән... Каләм югалгач. Урман юлыннан. Шигырьләр. № 12.

ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

С. Хәким. Үлем турында уйлама. № 1.

МОСТАЙ КӘРИМГӘ 50 ЯШЬ

Ф. Хөсни. Кешеләр кирә шагыйрьгә. № 10.

М. Кәрим. Сабантуйдан кайтып киләм. Әйләнә карусель... Ярсу Таныш... Шагыйрь шатлыгы. Дау күтәрә. Сандугачка... Котчыккыч төш... Шигырьләр. № 10.

ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Н. Хисамов. Үлемсезлек җырчысы. № 11.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ф. Ганиев. Татар филологиясенә зур өлеш керткән галим. № 11.

Л. Җәләйнең Афзал Шамовка язган хаты. № 11.

Дәрдмәнд. № 11.

И. Сибгатуллин. Якты истәлеге күңел түрендә. № 10.

Г. Якупова. Гыйбад Алпаров. № 1.

ТӨРЛЕСЕННӘН

Г. Бәширов. «Гөлҗамал» кайсы як кызы! № 3.

Газета укучыларыбыз игътибарына. № 8.

М. Гәрәев. Сочида үсә бер агач. № 6.

К. Зарипов. Легендар Севастопольдә. № 10.

«Казан утлары» журналы 1970 елда. № 9.

М. Садри. Фронт матбугатыннан. № 2.

И. Туктар. Әйтемнәр. № 4

Ю. Әхмәтҗанов. Табыннарыбыз турында. № 9.

М. Һади. Псевдонимнар хакында берничә сүз. № 1.

ЯҢА ҖЫРЛАР

Безнең җыр. А. Батыршин музыкасы, Н. Дәүли сүзләре. № 1.

Бәхтияр батыр турында җыр. Р. Яхин музыкасы, М. Ногман сүзләре. № 11.

Нигә, нигә син җырладың миңа! Ф. Әхмәтов музыкасы, Н. Дәүли сүзләре. № 5.

Солдат турында җыр. З. Хәбибуллин музыкасы, К. Латыйп сүзләре. № 2.

Тугайларың. С. Садыйкова музыкасы, И. Ганиева сүзләре. № 3.

Тегермәнчеләр. З. Гыйбадуллин музыкасы, Г. Латыйп сүзләре. № 7.

Язлар, язлар... А. Батыршин музыкасы, З. Нури сүзләре. № 4.

Безнең сафка № 2, 6.

Укучылар сүзе. № 3, 6.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. №№ 1—12.